# казан утлары

11
НОЯБРЬ•1977

Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, культура работниклары! Совет сәнгатенең партиялелеге һәм халыкчанлыгы байрагын югары тотыгыз! Талант һәм осталыгыгызны халыкка хезмәт итүгә, коммунизм эшенә биregez, бөек Ватаныбызга лаеклы әсәрләр иҗат итегез!

*БӨЕК ОКТЯБРЬ СОЦИАЛИСТИК РЕВОЛЮЦИЯСЕНЕҢ 60 ЕЛЛЫГЫНА КПСС ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ӨНДӘМӘЛӘРЕННӘН.*

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ
1922 елның май аеннан башлап чыга

**11**
НОЯБРЬ
1977

## Бу санда

**Ф. ТАБЕЕВ. Гүзәл һәйкәлләрнең берсе** . . . . 3
**З. НУРИ. Октябрь язы.** Шигырь . . . . . . . 10
**И. ЮЗЕЕВ. Мәңгелек хис.** Шигырь . . . . . . 10
**Г. АФЗАЛ. Тарих мең дә...** Шигырь . . . . . . 11
**С. СӨЛӘЙМАНОВА. Яр-Чаллы.** Шигырь . . . . 12
**Ә. БАЯНОВ. Кунаклар килде.** Шигырь . . . . 13
**Г. РӘХИМ. Юлың якты.** Шигырь . . . . . . 14
**М. МАЛИКОВА. Язгы такыялар.** Повесть . . . 15
**Ф. ЯРУЛЛИН. Без — беренчеләр.** Шигырь . . . 89
**Ф. ШӘФИГУЛЛИН. Кызыл мәйдан аша.** Шигырь . 89
**З. НАСЫЙБУЛЛИН. Корыч коя кеше.** Шигырь . 90
**Ф. САФИН. Безнең хакта хак сүз.** Шигырь . . . 91
**Ш. АНАК. һәр көнне, һәр сәгатьне.** Шигырь . . 92
**Г. ӘПСӘЛӘМОВ. Яктыга таба.** Хикәя . . . . . 93
**Н. АРСЛАНОВ. Аяз булсын тирмәң.** Шигырьләр . 101
**Н. ДӘҮЛИ. Мадам Клод трагедиясе.** Шигырь . . 107
**Г. ЛАТЫЙП. Тополь.** Шигырьләр . . . . . . 111

### ОЧЕРКЛАР

**М. РАФИКОВ. Бер дистә Мифтахетдиновлар** . . 114
**И. АБДУЛЛИН. Х. Ямашев автобиографиясе** . . 124
**Р. ХӘЙРЕТДИНОВ. Татарстанда Октябрь тарихыннан** . . . . . . . . . . . . . . . 131
**М. ЯҺУДИН. Калининның Татарстанга килүе** . . 135

### ДУСЛАР ЖЫРЫ

**Ж. МУЛДАГАЛИЕВ. Көтеп алган бәхет.** Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 143
**М. МИРМУХСИН. Йөрәк җылысы.** Шигырьләр . 145

### КАЗАН РАДИОСЫНА 50 ЕЛ

**Ш. РАХМАНКУЛОВ. Тыңлагыз, Казан сөйли** . . 147

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

**Н. МУРАДЫМОВ.** Дуслык эзләре . . . . . . 153
**С. АКБИЕВ.** Татар мәгърифәтчесе таулар илендә . 157
**Т. КАҺҺАРИ.** Уйгур-татар мәдәни бәйләнешләры . 162

КИТАП КҮЗӘТҮ

**Ф. ӘГЪЗӘМОВ.** Данлы юбилейны каршылап . . 167
**Р. БАТУЛЛИН.** Кызык өчен түгел . . . . . . 174

УКУЧЫ СҮЗЕ

**М. ЯНБАЕВ.** Уралдан хат . . . . . . . . . . . 176
**Р. ШӘРИФУЛЛИНА.** Язучыга бер сорау . . . . 177
**М. НУРМӨХӘММӘТОВ.** Заман герое . . . . . 177
**Р. ИСМӘГЫЙЛОВА.** Сәмум кичкән геройлар . . 178

ЕЛМАЕП ТА, КӨЛЕП ТӘ...

Шул да булдымы әхлак! . . . . . . . . . . . 179

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . . . . 189

Редакциянең адресы. Казан, 420066, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: Баш редактор — 3-07-60, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-69, поэзия бүлеге — 3-07-69, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-61, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Баш редактор: **Зәки Нури**

Редколлегия: **Әхсән Баянов** (редактор урынбасары), **Хәй Вахит**, **Шәүкәт Галиев**, **Аяз Гыйләҗев**, **Ләбибә Ихсанова** (җаваплы секретарь), **Шәйхи Маннур**, **Рәфыйк Нәфиков**, **Атилла Расих**, **Гали Халит**, **Сибгат Хәким**, **Нил Юзиев**, **Мирсәй Әмир**

Техник редакторы *Р. Нәбиуллина*
Корректорлары *Р. Сөләйманова*, *К. Корбангалиева*

Производствога бирелде 1/VIII-1977 ел. Басарга кул куелды 11/X-1977 ел. ПФ 09038. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 84544 экз. Заказ Б-300. Бәясе 50 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1977 ел.

**Ф. Ә. Табеев,**

*КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре*

# ГҮЗӘЛ ҺӘЙКӘЛЛӘРНЕҢ БЕРСЕ

Бәхетебез безнең,
гаять эре
Җимешләрнең
татлы тәме булып,
Алсуланды
һәм мул булып уңды
Октябрьның
кызыл чәчәгеннән.

*Владимир Маяковский.*

1918 елда Бөек Октябрь социалистик революциясенең бер еллыгын билгеләп үтү тантаналарында чыгышларының берсен тарих моңарчы тыңдәшен күрмәгән шушы революциянең юлбашчысы даһи Ленин: «Без бүген Октябрь переворотының бер еллыгын бәйрәм итү өчен унларча һәм йөзләрчә митингларга җыелабыз,— дип башлап киткән иде.— Эшчеләр хәрәкәтендә күптәннән катнашып килгән, элektән эшчеләр массалары белән бәйләнештә булган, фабрикага һәм заводка якын торган кешеләр өчен үткән елның чын пролетариат диктатурасы елы булганлыгы бик ачык. Бу төшенчә элек аңлаешсыз латин теле белән язылган китап сүзе иде, ниндидер кыен аңлашыла торган сүзләр тезмәсе иде... Үткән ел эчендә безнең төп хезмәтебез бу сүзләрне аңлаешсыз латин теленнән аңлаешлы рус теленә күчерү булды. Эшчеләр сыйныфы үткән елны акыл сату белән шөгыльләнмәде, бәлки эштә пролетариат диктатурасын иҗат итте...»

Бүген, шул переворотның 60 еллыгы көннәрендә, без, шул революцияне оештырган, әзерләгән һәм җиңүгә китергән буынның дәвамы, бар тавышка әйтә алабыз һәм моңа тарих үзе, бар дөнья шаһит: «пролетариат диктатурасы», «социализм», «коммунизм» сүзләре үлеп калган латин теленнән һәм башка телләрдән бишеллыклар дәвамында илебезнең барлык халыклары телләренә күчерелеп кенә калмады, бәлки бездә яңа социалистик җәмгыятьнең мәһабәт бинасы калкып чыкты.

Андый җәмгыятьне кешелек белми иде әле. Бу җәмгыятьтә кешенең кешене эксплуатацияләве мәңгегә бетерелде, экономика кризисларсыз һәм туктаусыз үсә, социалистик мөнәсәбәтләр коммунистик эчтәлек белән баетыла бару юнәлешендә камилләшә.

Бөек Октябрьдан башланган яңа эрада совет халкы инде ирешкән казанышларны менә нинди саннар белән чын мәгънәдә художестволы итеп тасвирларга мөмкин: 60 елның егермегә якын елы халкыбызга көчләп тагылган сугышлар һәм шуннан соң хуҗалыкны торгызу елларына туры килүгә карамастан, 1976 елда илебезнең милли доходы революциягә кадәрге дәрәҗә белән чагыштырганда 65 тапкыр артты. Промышленностебыз 1913 елда җитештерелгән продукцияне хәзер ике көн ярымда бирә. Революциягә кадәр безнең илебез өлешенә бөтендөнья промышленность продукциясенең 4 процenttан аз гына күбрәге туры килгән булса, бүген инде аның биштән бер өлеше — безнеке.

Социалистик дөнья белән капиталистик дөнья ярышында иң мөһиме — экономиканың үсеш темпы күрсәткечләре. Әйтик, соңгы биш елда СССРда промышленность продукциясе күләме 43 процентка, ә АКШта нибары 6 процентка гына артты. Советлар Союзында һәм Экономик ярдәмләшү советы члены булган башка социалистик илләрдә промышленность продукциясенең уртача еллык үсеш темплары соңгы 25 елда алга киткән капиталистик илләрдәгегә караганда ике тапкырдан күбрәккә югары булды.

Авыл хуҗалыгын тагын да үстерүнең партия тарафыннан эшләнгән комплекслы программасын тормышка ашыру буенча бик күп нәрсә эшләнде һәм эшләнә. 1976 елда, мәсәлән, бу тармакны үстерүгә 32,1 миллиард сум акча тотылды. Беренче алты бишьеллыкларда шушы максатка юнәлтелгән суммага караганда шактый күп сан бу. Совет властеның беренче елларында В. И. Ленин авыл хуҗалыгына 100 мең трактор бирү турында хыялланган иде, хәзер исә илебез кырларында 2,3 миллион трактор, 680 мең бөртекле ашлык комбайны һәм күп төрле башка техника эшли.

Совет кешеләренең тормышы һаман яхшыра бара. Промышленность һәм төзелеш эшчеләренең реаль доходлары 1913 ел белән чагыштырганда 10 тапкыр, ә крестьяннарныкы — 14 тапкыр артты.

Илебездә түләүсез медицина хезмәте күрсәтү, гадел социаль тәэминат гарантияләнә. Үткән елны кайбер категориядәге работникларны пенсия белән тәэмин итүне тагын да яхшырту чаралары үткәрелде.

Социализм барлык хезмәт ияләренә белемгә, рухи культура байлыкларыннан файдалануга киң юл ачты. Патша Россиясендә олы кешеләрнең дүрттән өч өлеше диярлек укый-яза белмәгән. Хәзер исә халык хуҗалыгында эшләүче работникларның дүрттән өч өлешеннән күбрәге югары яки урта белемле. Илебездә гомуми урта белем бирүгә күчү нигездә тәгәлләнде. Иҗтимагый аң гасырлар буена дини һәм башка төрле хорафатлар белән томаланып ятудан азат ителә бара. Совет кешеләренең иҗтимагый аңында дөньяга фәнни материалистик караш урнашты. Бу инде тән һәм җан асрау өчен экономик һәм социаль мөмкинлекләр алу гына түгел, бәлки кешенең аңы, аның рухы азатлыкка ирешү, ягъни югары тәртиптәге азатлыкка күтәрелү дигән сүз. Коммунизм җәмгыятен төзү алга китә барган саен кешеләр тулы азатлыкка якыная барачак. Һәм аның һич тә җәмгыятьтән, кешелек цивилизациясе ирешкән һәм ирешәчәк коммунистик әхлак нормаларыннан өстен азатлык булмавы билгеле. Кеше үзен олы мәгънәсендә кеше итеп тәрбияли алырлык азатлык — мәңгелек хыял әнә шундый була һәм без хәзер горурланып әйтә алабыз: бу безнең бүгенге һәм киләчәктәге казанышыбыз!

Хәзерге Татарстан — шундый җәмгыятьнең бер өлеше. Социалистик революция татар халкының да гасырлардан килгән хыялы-омтылышын тормышка ашырды: аның үз дәүләтен тудырды. Бүгенге социалистик Татарстан — ул Октябрь революциясенә, аның юлбашчы көче — Коммунистлар партиясенә гүзәл һәйкәлләрнең берсе булып үсеп килә. Иле-

бездәге барча халыкларның да бүгенге матур язмышы, тагын да ышанычлы киләчәге шул ук мәгънәгә ия.

Шул уңайдан кайбер мәгълүматларга күз салыйк: республика промышленностеның тулай продукциясе күләме Совет власте елларында 595 тапкыр артты. 1976 елда бездә 27704 миллион киловатт-сәгать электр энергиясе эшләнде. Бу — республиканың барлык электр станцияләре һәр көн саен 80 миллионга якын киловатт-сәгать энергия эшләделәр, ягъни беренче бишьеллыкның беренче елында эшләнгәннән дүрт мәртәбә артык энергия бирде дигән сүз.

Машина төзелеше һәм металл эшкәртү — республика промышленностеның төп тармагы. Тугызынчы бишьеллыкта бу тармакның тулай продукциясе 1,9 тапкыр артты. 1940 елда житештерелгән кадәр продукция хәзер көн саен эшләп чыгарыла. Күп кенә төр продукция эшләү буенча республика СССРда алдынгы урынны алып тора. Ул илебезне ИЛ-62 континентара лайнерлар, компрессорлар, төрле приборлар, медицина инструментлары, фотожелатин, кетгут белән күпләп тәэмин итүче әлегә бердәнбер республика. Татарстанда житештерелә торган машиналар һәм приборлар 60 илгә чыгарыла.

Хәзерге өч орденлы Татарстан автомобиль төзелеше гиганты булачак та инде танылды. КамАЗ ел саен 150 мең йөк автомобиле эшләп чыгарачак.

Безнең «кара алтын» осталарыбыз 1976 елда 101,5 миллион тонна нефть чыгардылар. Нефть химиясе промышленносте продукциясе үткән бишьеллыкта 2,4 тапкыр (1940 ел белән чагыштырганда 33 тапкыр, ә 1913 елгыдан 670 тапкыр) артты.

Игенчеләребез, һава шартлары авыр булуга карамастан, 1976 елда бөртеклеләрдән рекордлы уңыш — 4 216 мең тонна иген җыеп алдылар: җан башына 1 227 килограмм бөртекле ашлык җитештерелде! Дәүләт амбарларына 1 646 мең тонна ашлык салынды. Бу тугызынчы бишьеллыктагы уртача еллык күләмнән ике тапкыр күбрәк күрсәткеч иде.

Социалистик Татарстан республикасы хәзер — фән һәм культура республикасы да. 12 вузда һәм өч институт филиалында 65 меңнән күбрәк студент укый. 9 театр, филармония, 11 музей, 2500 дән артык клуб һәм культура сарае, 2 меңнән артык китапханә һәм шуннан да артык киноустановка халыкка хезмәт күрсәтә. Татар сәнгате һәм әдәбияты чәчәк ата.

Патша Россиясенең Европа өлешендәге 50 губерна арасында Казан губернасы халыкның аң-белемле булуы ягыннан иң соңгы урында торган. Бередә һәр ун кешенең бары тик берсе укый-яза белгән. Чөнки мәгърифәт эшенә дәүләт җан башына бер елга нибары унике ярым тиен акча тоткан... Ислам дине һәм аның төп законы — шәригать җыр һәм музыка яңгырашын, рәсем ясауны катгый тыеп килә. Ә халык йөрәге барыбер җырга сусап типкән, аның күңел тирәнлегендә моң учаклары өзлексез көйри килгән.

Хәзер татар культурасының моннан күп еллар элек башланып, аны күп буын иҗат эшлеклеләре дәвам иттергән һәм үстергән традицияләре, ачышлары, казанышлары ни хәтле зур икәне бөтен дөньяга билгеле. Кайчандыр Кол Гали һәм Сәйф Сараи, Габделҗаббар Кандалый һәм Каюм Насыйрилар иҗатының беренче шытымнары үсеп чыккан җирлектә революцион егерменче гасырда Галиәсгар Камал, Мәҗит Гафури, Гафур Коләхметов, Фатих Әмирхан, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Шәриф Камал кебек гигантлар әдәбият мәйданына килә. Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы, социалистик төзелеш һәм Бөек Ватан сугышы елларында зур пафос белән яза башлап хәзер инде хрестоматияләргә кергән һәм бөтен илгә танылган әдипләребез

күп безнең. Фашизмга каршы көрәштә батырлыгы өчен Советлар Союзы Герое исеменә, шул ук елларда күбесенчә «таш капчык»та язган сугышчан шигырьләре өчен Ленин премиясенә лаек булган Муса Җәлил әсәрләре җир шарындагы төрле континентларның бик күп телләренә тәрҗемә ителде. Ә хәзерге язучыларыбызның яңа әсәрләре исә Татарстан китап нәшриятында һәр өч көн саен яңа бер китап булып, Мәскәүдәге Үзәк нәшриятларда һәм тугандаш республикаларда ел саен дистәләп чыгып тора. Әдәбият, сәнгать һәм культурабызның иң яхшы казанышларын без ел саен Габдулла Тукай һәм Муса Җәлил исемендәге премияләр белән бүләкләп килəбез.

Әдәбият белгечләре арасында Мөхәммәт Гайнуллин, Гали Халит, Мансур Хәсәнов, Нил Юзиев һәм башкалар кебек фән докторларыбыз һәм профессорларыбыз, күп дистә филология фәннәре кандидатлары бар.

Язучылар коллективы кебек үк, Татарстанның композиторлар, рәссамнар һәм архитекторлар иҗат оешмалары да Россия федерациясендә, Мәскәүдән һәм Ленинградтан кала, шулай ук иң зурлардан санала. Алар сафында Казан консерваториясе ректоры, Дәүләт премияләре лауреаты, СССРның халык артисты, композитор Нәҗип Җиһанов, илебезнең художество академиясе член-корреспонденты рәссам Харис Якупов, СССР халык артистларыннан сәхнә осталары Фоат Халитов, Шәүкәт Биктимеров һәм опера җырчысы Азат Аббасов һәм башкалар кебек зур осталар бар. Республиканың атказанган сәнгать һәм культура эшлеклеләре, халык артистлары чыгышын тамашачылар һәр вакыт көтеп ала. Татар филармониясенең җыр һәм бию ансамбле исә шулай ук төрле континент илләрендә дә мактальп кайтты.

Үткән елның азагында гына орденлы Татар академия театрының 70 еллыгы тантаналы төстә бәйрәм ителде. Хәзер Казанның төп үзәге булган Кабан күле буена аның заманча җиһазландырылачак яңа бинасы салынып ята.

Татарстанның хәзерге галимнәре һәм фән эшлеклеләре турында да, кыскача итеп булса да, бик күпне әйтергә мөмкин. Аларның хәзерге буыны — кайчандыр Казанда атаклы математик Лобачевский, мәшһүр химиклар Бутлеров, Зинин һәм Арбузовлар башлап киткән мәктәпнең шәкертләре кайда гына юк хәзер! Әйтик, инде Бөек Ватан сугышыннан соң Мәскәү университетында укыган якташыбыз, хәзер илебездә иң яшь академикларның берсе Роальд Сәгъдиев СССР Фәннәр академиясенең космик эзләнүләр институты директоры булып эшли. Әнә бит нинди биек сикереш! Татарстан промышленностеның күп тармакларында алда әйтеп үтелгән бүгенге гаять зур үсеш, әлбәттә, барыннан да элек галимнәр эшчәнлегенә, фәнни-техник революция чорының гыйльми ачышларына бәйле.

Татар һәм рус телләрендә һәм бүтән күп телләргә тәрҗемә ителеп, төрле республикаларга һәм төрле илләргә таралган безнең әдәби һәм фәнни китаплар, сәнгатебезнең бүтән төр әсәрләре барып житкән юллардан исә безгә төрле яклардан дусларыбыз иҗаты кунакка килә. Халыклар һаман саен якынрак аралашалар, тупланган тәҗрибә уртаклашыла, күңелләр, эстетик зәвык һәм рухлар байый төшә. Моңа мисал итеп дөнья әдәбияты һәм рус классикасы әдәбиятларыннан, хәзерге төрле милләт совет классикасыннан һәм тугандаш әдәбиятлардан иң яхшы үрнәкләрнең татар телендә күпләп чыгып торуын әйтү дә җитә. Укучыларны, мәсәлән, татар телендә алты томлы лениниана чыгуы, аннары тагын «Дуслык букеты» дигән сериядә, Маяковский әйткәнчә, брошюралар яңгыры булып яуган, барлык союздаш республикалар поэзиясе китаплары аеруча куандырды. Чөнки корычның нык, ташның каты икәне билгеле, ләкин дуслыктан да ныграк нәрсә һич була алмый.

Халыклар һәм илләр белән дуслык көннән-көн ныгысын өчен без-

нең өч орденлы республикабызның нефть үзәге Әлмәт каласыннан юл алып Европадагы барлык социалистик илләргә чаклы «Дуслык» исемле нефть үткәргече сузылды. Территориясе бары тик ике Бельгия мәйданы чаклы гына булган Татарстан менә ничә ел рәттән инде, әйткәнебезчә, елына 100 миллионнан артык тонна «кара алтын» чыгара.

Тамчылап тамган яңгыр да зур күлләрне тутыра, ди халык. Безнең иҗат интеллигенциябез Ватан куәтен, җирдә тынычлыкны һәм дуслыкны ныгыткан шундый хезмәт батырлыгын сәнгать чаралары белән тагын да тырышыбрак сурәтләячәк, әлбәттә.

60 ел эчендә совет халкы ирешкән иң зур казаныш — илебездә житлеккән социализм төзү булды. «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгы турында» КПСС Үзәк Комитеты карарында билгеләп үтелгәнчә, «Социализм — реаль гуманизм җәмгыяте ул. Аның иң зур байлыгы — хезмәт кешесе. Барысы да кеше бәхете өчен, кеше хакына — яңа, социалистик яшәү рәвешенең тирән мәгънәсе әнә шунда».

Аннан соң тагын менә нәрсәләр турында укыдык без анда: социализм кешене изүнең барлык төрләрен юкка чыгара, хезмәткә, белем алуга һәм ял итүгә, хезмәт ияләренең эш белән тулысынча тәэмин ителүенә хокук бирә, җәмгыятьнең барлык членнарына һәрьяклап иҗади үсү өчен реаль мөмкинлекләр тудыра... Социаль оптимизм җәмгыяте буларак, ул хезмәт кешесендә иртәгәге көнгә, балаларның бәхетле киләчәгенә, тәэмин ителгән картлыкка ныклы ышаныч тудыра. Социализм халыкларга яңа, тигез хокуклы мөнәсәбәтләр, үзара файдалы хезмәттәшлек һәм тынычлык китерә.

Экономик, политик һәм рухи тормышны социалистик оештыру бары тик социализмның гына хәзерге заманның иң мөһим һәм кичектергесез гомумкешелек проблемаларын хәл итү юлын ачканлыгын күрсәтте...

Хәзерге этапта экономиканың динамик үсеше нигезендә совет җәмгыятенең социаль йөзе яңа сыйфатлар белән байый: сыйнфый аермалар кими, җәмгыятьнең социаль бертөрлелеге арта. Эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар һәм халык интеллигенциясе союзы, эшчеләр сыйныфы җитәкчелегендә, илебездә барлыкка килгән яңа тарихи гомумилекнең — совет халкының какшамас нигезенә әверелде. Бездә барлык милләт һәм халыкларның туганнарча дуслыгы һәм бердәмлеге нык һәм монолит. Советча яшәү үрнәге үзган юлыбызның мөһим йомгагы булды. Аның гүзәл сыйфатлары — чын коллективизм һәм иптәшлек атмосферасы, илебездәге барлык милләтләрнең һәм халыкларның тупланганлыгы, дуслыгы — халык аңына һәм канына сеңә бара, безнең чынбарлыгыбызда көн саен, адым саен тулырак чагылыш таба. Совет кешеләре бергә азатлык яулап, үз язмышларының хуҗасы булдылар, барлык сынауларны уздылар, үз Ватаннарын танымаслык итеп үзгәрттеләр һәм үзләре дә үзгәрделәр. Совет кешесе идея инанганлыгын һәм тормыш энергиясен, белем һәм культура биеклекләренә туктаусыз омтылышны, коллективизм һәм иптәшләрчә ярдәмләшү сыйфатларын берләштерә.

«Совет халкының бүгенге эшләре,— диде партиянең XXV съездында КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре Л. И. Брежнев,— Октябрь эшенең турыдан-туры дәвамы. Алар — бөек Ленин идеяләренең практикада тормышка ашуы. Бу эшкә, бу идеяләргә партиябез турылыклы һәм һәр вакыт турылыклы булачак!»

Республика хезмәт ияләренең юбилей елында ирешкән уңышлары, политик һәм иҗтимагый активлыгы, бәйрәм хөрмәтенә алынган социалистик йөкләмәләрен үтәүдә фидакарь хезмәте җимешләре шуның дәлиле. Татарстан хезмәт ияләренең 94 проценты социалистик ярышта, шулардан 62 проценты хезмәткә коммунистик мөнәсәбәт өчен хәрәкәттә катнашты һәм катнаша. 700 меңнән артык кеше шәхси еллык һәм бишьеллык планнар нигезендә ярыша. Ел уртасында ук инде 46 мең

эшче үзләренең еллык заданиеләрен үтәп, киләсе ел исәбенә хезмәт итәләр иде. Вакытны узып шулай эшләүчеләр саны соңрак икеләтә артты.

Партия өлкә комитеты моторлар төзү һәм «Теплоконтроль» берләшмәләре, Түбән Кама химиклары, Азнакай бораулаучылары, Баулы игенчеләре һәм Октябрь районы терлекчеләренең һәм башкаларның юбилей елы башлангычларын вакытында хуплады. Тагын бик күп коллективлар «Сыйфат бишьеллыгына — эшче гарантиясе», «Октябрьның 60 еллыгына — 60 удар атна», «Эш вакытының бер генә минутын да әрәм итмәскә» кебек патриотик девизларга кушылып хезмәт итәләр.

Нәтиҗәдә продукция реализацияләүнең квартал планнары һәм хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү планы арттырып үтәлде. Машина төзүчеләрнең уңышы безне аеруча шатландыра. Бишьеллык башыннан алып санаганда бу тармакта 150 яңа төр җиһаз үзләштерелде, йөзгә якын җиһаз сыйфат билгесе белән чыгарыла. Бөек Октябрь юбилеен лаеклы каршылау өчен социалистик ярышта Горбунов исемендәге, «КамАЗ», «Теплоконтроль» берләшмәләре, язу җиһазлары, электрон исәп-хисап машиналары, төгәл машина төзелеше заводлары һәм башка предприятиеләр коллективлары аеруча уңышка ирешteләр.

Хезмәт батырлыгы һәркайда шулай дәвам итә! «Татнефть» берләшмәсе коллективлары да ярты еллык планны намус белән үтәделәр. Илебез планнан тыш 112 мең тонна нефть һәм 2,2 миллион кубометр газ алды. Химия тармакларында да беренче ярты еллыкта йөкләмәләр арттырып үтәлде: полиэтилен җитештерү — 78, дивинил җитештерү 25 процентка күбрәк. Быел Татарстан 188 мең тонна синтетик каучук эшләп чыгара — бу бөтен илдә җитештерелгән каучукның дүрттән бер өлеше.

Авыл хуҗалыгында да эшләр уңышлы барды. Сөт, ит, йомырка сатуның ярты еллык планнары арттырып үтәлде.

Дәүләт планнарын һәм социалистик йөкләмәләрне үтәү өчен тырыш хезмәт быел Бөек Октябрь бәйрәме хөрмәтенә һәм СССР Конституциясе проектын тикшерү айларына туры килде. Яңа Конституция проектын бөтен халык тикшерүенә куюю юбилей елын илебез тормышында тарихи яктан тагын да истәлеклерәк итте. Совет кешеләре, Конституция комиссиясенә җитәкчелек итеп, җитлеккән социализмның Төп законын эшләүгә гаять зур шәхси өлеш керткән Л. И. Брежнев докладлы белән бик кызыксынып таныштылар.

КПСС Үзәк Комитетының май Пленумы, бездә юридик яктан да, фактик яктан да милләтләрнең тигезлегенә ирешелде, дип күрсәтте. Социализм җиңү белән бездә милли мәсьәлә тулысынча һәм бөтенләйгә хәл ителде. Бу казанышны без горурлык белән СССРда яңа җәмгыять төзүдә ирешелгән гаять зур җиңүләр — илне индустрияләштерү, коллективлаштыру һәм культура революциясе белән бер рәткә куябыз.

Безгә, Татарстан кешеләренә, милли политиканың ленинчыл принципларына нигезләнгән дуслыкның нәтиҗәлелеге бик ачык. Татарстанның материаль һәм рухи тормышының бик күп төрле сфераларында барган һәм бара торган үзгәрешләр — илебез милләтләренең һәм халыкларының дуслыгын, ярдәмләшүен һәм рухи туганлыгын тудырган конституцион тигезлек нәтиҗәсе.

Халкыбыз Конституциядә Советлар Ватанын чәчәк аттыру, аның куәтен һәм авторитетын ныгыту, гражданнарга үзләренең иҗат көчләрен, сәләтләрен һәм талантларын үстерү һәм куллану өчен, шәхеснең гармоник үсеше өчен иң уңай шартлар тудыру турында партия кайгыртучанлыгының яңа ачык чагылышын күрә.

Бөек Октябрь революциясенең юлбашчысы Владимир Ильич Ленин моннан 59 ел элек, революциянең берьеллыгы тантанасы көннәрендә, хезмәт ияләре алдында чыгыш ясап, болай дигән иде: «Үткән елның

октябренда совет оешмасы нинди хәлдә иде? Бу беренче адымнар иде... Ә хәзер бездә Совет Конституциясе бар. Без беләбез: июльдә раслан- ган бу Совет Конституциясе нинди дер комиссия уйдырмасы түгел, юристлар гына уйлап чыгарган бер нәрсә түгел, ул башка конституция- ләрдән күчереп язылмаган. Дөньяда безнең Конституция кебек консти- туциянең булганы юк...»

Бу сүзләр, Советлар власте озак яши алмас дип, буржуазия больше- виклардан зәһәрләнеп көлгән чорда әйтелгән иде. Халкыбыз беренче, икенче һәм өченче Конституцияләре нигезендә үз властен ныгытты, социализм җәмгыяте төзеде. Октябрь революциясе җимеше — Совет иле инде 60 ел яши. Социализм безнең ил чикләреннән тышка атлады, һәм азатлык идеаллары яңадан-яңа халыкларны көрәшкә күтәрә. «Һич шик юк, иптәшләр,— диде Л. И. Брежнев партия Үзәк Комитетының май (1977) Пленумында,— СССРның яңа Конституциясен, нык үскән социализм Конституциясен, төзелә торган коммунизм Конституциясен кабул итү безнең илебез өчен тарихи вакыйга булып кына калмас, бәлки гаять зур халыкара әһәмиятле вакыйга булыр. Аны тормышка ашыру ватаныбыздан читтә дә озак вакытлар буена тирән йогын- ты ясар.

...Ул безнең Ленин партиясенең, бөтен совет халкының коммунизм төзүнең бөек эшенә һәм шуның белән бергә азатлык, кешелек прогрес- сы, җирдә ныклы тынычлык өчен бөтендөнья хезмәт ияләре алып бара торган көрәшнең интернациональ эшенә керткән тагын бер тарихи өле- ше булыр.»

Әйе, әле Октябрь революциясенең беренче еллыгы тантанасы уңае белән В. И. Ленин әйткәнчә, менә быел 60 еллык юбилей көннәрендә без уннарча һәм йөзләрчә, меңнәрчә митингларга җыелабыз. Аларда без илебез үткән зур, данлы һәм шанлы юлга күз салабыз, тиңдәшсез казанышларыбызны барлыйбыз, киләчәккә бурычларыбызны билгели- без. Тарихта яңа эра ачкан, аның казанышларын авыр көрәшләрдә саклап калган һәм җитлеккән социализмны практикада төзеп күрсәт- кән халкыбызның барлык буыннарына дан җырлаганда безнең иң изге уйлар ил тормышындагы барлык процессларга, Октябрь чорыннан алып безнең көннәргәчә, җәмгыятебезнең юнәлеш бирүче, оештыручы, туп- лаучы көче — Коммунистлар партиясенә юнәлгән. «Безнең партиябез — Октябрьның ленинчыл гвардиясе,— диелә «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгы турында» КПСС Үзәк Комитеты карарын- да,— Россия пролетариатының чәчәге һәм горурлыгы булган ленинчыл большевикларның онытылмас когортасының бөек тарихи эшен, тиң- дәшсез мөмкинлекләре булган хәлдә, башка чаралар белән һәм башка тарихи шартларда дәвам иттерә... Коммунистлар тарихта беренче тап- кыр чын мәгънәсендә ирекле, социалистик җәмгыять төзегән халыкка турылык һәм дәреслек белән хезмәт итәләр һәм итәләр.

Алар үзләренең барлык уйларын, акыл көчләрен, йөрәкләренең бөтен капын бөек коммунизм эше тантанасы өчен көрәшкә бирәләр». Безнең 16 миллионлы партиябез Октябрьның 60 еллыгына үзенең ленинчыл Үзәк Комитеты тирәсенә тыгыз тупланган фикердәш комму- нистларның сугышчан союзы булып килде.

1917 ел.

1977 ел.

Бөек Октябрьның планета буйлап тантаналы адымы инде 60 ел дәвам итә. Октябрьда җиңгән идеаллар бөтендөнья халыкларының барыр юлын яктыртып торган маякларга әверелә бара. Безнең гасыр — Октябрь гасыры, марксизм-ленинизм тәгълиматының тантана итү га- сыры. Совет халкы Бөек Октябрь байрагы астында, Ленин партиясе җитәкчелегендә ышанычлы адымнар белән алга, коммунизмның җи- ңүенә бара.

## Зәки Нури

### Октябрь язы

Күзге күккә мәңгелек бу сүзләр
Сүнмәс утлар белән язылды:
«Киләчәккә төбәлегез, күзләр!
Каршыла, ил, якты языңны!»

«Аврора»ның залпы күкрәвендә
Кабатланды халык теләге:
«Россиянең кайнар күкрәгендә
Азатлыкның типсен йөрәге...»

Атомлы һәм җырлы гасырга без
Шулай салдык тәүге эзләрне.
Күрдек җирдә давыл ярсыганын
Еллар аша төбәп күзләрне.

Купты давыл. Илдән-илгә күчте...
Ачыла бара юлның киңнәре.
Кызу җилләр, кыю җилләр исә,
Ул — Октябрь язы җилләре.

## Илдар Юзеев

### Мәңгелек хис

Салкын Җирне җылыткандыр Кеше
Ут чыгарып чакма ташлардан,
Тик шулай да бик нык ышанам мин:
Тормыш мәхәббәттән башланган.
Ике йөрәк бер чак табышкандыр
Берсен-берсе эзләп, тилмереп.
Җирдә йөрәк дигән җылы булган
Утлардан да алда, иң элек...
Кеше акылыннан калалмыйча
Еллар тизрәк алга чапкандыр,
Парны, электрны, атомнарны
Гашыйк җаннар уйлап тапкандыр.

Заман... Тизлек... Юлдаш-ракеталар...
Нинди акрын булган юл башы...
Кеше тизрәк җитәр максатына
Сөю булса даим юлдашы.
«Кем баласы?» диеп сорасагыз,
Мин — мәхәббәт, сагыну баласы,
Шашып яратулар бездән соң да
Оныкларга күчеп каласы...
«Бу ноктада тормыш бармы?» диеп
Галәм түрләреннән кем дәшәр?
Сөю хисен йөрәк югалтмаса,
Җир суынмас мәңге, Җ и р яшәр!

## Гамил Афзал

### Тарих мең дә...

Иске йортның чормасында китап яткан:
Рәнҗү яткан,
Фикер яткан,
Тарих яткан.
Актармаган,
Укымаган аны кем дә,
Кайгыларын сөйләгән ул кара тенгә.

«Якшәмбе көн.
Себер китте Сабир мескен,
Гаепләме, гаепсезме — ходай белсен.
Ни булса да — гаеп бездә,
Камчы безгә...
...Бисмиллаһи, тарих мең дә сигез йөздә...»

«Тарих мең дә...
Алпавытның йорты янды.
Пристав килде, Хәтмулладан допрос алды...
Урманнарда качкылар күп.
Карья бөлде...
Галләм кызы чибәр Гайшә батып үлде...»

Китап яткан.
Хикмәтләрен чәчми яткан,
Тузан йотып, гасыр ярым дәшми яткан.
Керле,
Соргылт битләреннән кычкырды ул:
«Тарих мең дә...
Нигә без кол?
Нигә без кол?!»

Олы юлдан атлар узган,
Чорлар узган.
Гаепле дә, хөкемдар да тәпи сузган.
Ярдан-ярга сулар ташып,
Дөнья янган.

Патша төшкән.
Байлар беткән.
Китап калган.

Иген иккән
Илгә карап фикер йөрткән,
Каләм язган сүз гомере озын икән.
Бәет булып аһәң йөри айлы төндә:
«Тарих мең дә...
Сөйдем мин дә...
Көйдем мин дә...»

## Саҗидә Сөләйманова

### Яр-Чаллы

Текә ярлы, бөдрә таллы Яр-Чаллы.
Чабыш атлар сыман Чулман чал яллы.
Тарих атлы гомер акты, моң акты,
Тынгы белми җирдә күпме ел акты.

Яр буйлары язлы-көзле парчалы,
Сандугачлы, аккаенлы Яр-Чаллы.
Эш өстендә ай урак та ай чалгы —
Ай да кояш — белмәделәр ал-ялны.

Кышкылыкка кибән койды, мал чалды,
Җәйгелеккә карбазларга кар салды,
Яшь үрчемнәр килә торды пар санлы,
Киләчәктән әмер көтте Яр-Чаллы.

Корыч кошлар уза кыю бөркетне.
Атом-төшләр дер селкетә җир-күкне.
Табигатьнең ачып җибәр чаршавын,
Чыксын Алып батырларың, Яр-Чаллы!

Айда эзләр. Йолдызларга кул җитә.
Гасыр җиле бәреп уза — кем читтә,—
Юллар кысан, вакытларның тар чагы,
Удар хезмәт узар, җиңәр барчаны.

Ишетелсен иген шавы, җыр шавы,
Җир шарының өзик тимер кыршавын.
Тотынышсын миллион куллар, как чаңны,
Әйт әмереңң, сүзең саллы, Яр-Чаллы!

Кара туры атлар чаба — ут күзле,
Кем күтәрә җирнең йөген, шул көчле!—
Мең тугыз йөз җитмеш җиде — чал яллы.
Яңа гасыр капкасын ач, Яр-Чаллы!

Әхсән Баянов

# Кунаклар килде

Сүриядән кунаклар килде.
Нинди генә сыйлар өстәлне
Бизәмәгән дисең бу көнне:
Каз һәм үрдәк, тавык һәм балык,
Кызган шашлык... Шатлык шикелле,
Барысы — гүзәл, барысы — мактарлык.
Елмаюга, шаян сүзләргә
Кымыз белән шәраб өстәлде.

Янда гына аккан чишмәдән
Тылсымлырак сыман шәраблар.
Ә кунаклар? Шулай, гаҗәплән:
Гади суны артык күрделәр.
Сорадылар. Биргәч, көлделәр.
Сүздән бигрәк, күзләр сафланды:
«Безнең сәфәр инде акланды!»

Мең тылсымны шушы сүз җыйде:
«Су бит — тормыш, су бит ул — изге!»
Бу су — минем туган су инде,
Ургып чыга Әшмән җиреннән.
Изге дигән сүзгә шуңадыр
Тиз ышанган ул мин булгандыр.
Кемдер бәлки ышанмас иде...

Кемдер бәлки күз салмас иде.
Изге диеп, ерак кыйблага
Азмы бәндә моннан юл алган.
Зәмзәм суын барып эчкәннәр
Һәм ят комга башлар төрткәннәр...
Аллага баш органмы алар.
Ә шайтанга — сүзсез органнар.

Алар миңа ышанмас иде.
Ничек кору тиеш тормышны,
Ачыкларга шуны тырышып
Килгән дусларны мин төшендем.
Төшенер тиздән бөтен кешелек:
Кем өчендер бәлки юк алар,
Һаман кирәк ләкин кыйблалар.

Ерактыр ул, бәлки якындыр,
Кем өчендер көмеш, алтындыр.
Минем өчен кыйбла бер генә,
Минем кыйблам — минем җиремдә.
Су һәм кояш — алар изге дим,
Шуңа дәлил — дуслар сүзе дим.
Минем белән,— ишетәм,— әйтә Җир:
— Кыйбла — Ленин, кыйбла — Октябрь!

## Гәрәй Рәхим

### Юлың якты

Бөек Октябрьның үреннән мин
Карыйм: юлың якты.
Бер бәһадир булып күренәсең,
Бөек татар халкы!

Пугачларга әйткән бәетләрең,
Җыр-моңнарың татлы.
Батыр да син, эшчән, киң күңелле
Бөек татар халкы!

Мактауларга мохтаж түгелсең син,
Тик мактауга хаклы,
Илгә Җәлил кебек уллар биргән
Бөек татар халкы!

Һәр туганың кебек көчле, зирәк,
Уңган син, талантлы,
СССРның шанлы бер баласы,
Бөек татар халкы!

Намусың ак тарих каршысында,
Йөзең ачык, якты.
Киләчәккә кыю атлап кер син,
Бөек татар халкы!

**Мәдинә Маликова**

# ЯЗГЫ ТАКЫЯЛАР

ПОВЕСТЬ

— Туктат әле машинаңны!

Киң асфальт юлдан зур тизлек белән гүләп килгән газикның шоферы, куе озын чәчле, кара мыеклы яшь егет, янында утырган юка гәүдәле карчыкка гаҗәпләнеп карады:

— Нишләп инде, Газзә әби! Кыр уртасындамы? Хәзер капка төбенә үк кайтарып куям мин сезне!

— Мин әйткәнне тыңла әле син, улым! — диде карчык тавышын күтәрә төшеп. — Турыдан, Коры елгадан гына кайтыйм әле.

— Ташлап киткәнсең дип, әни ачуланыр бит!

— Гөлзәйнәпкә әйт, үзе төшеп калды, диген. Бер дә борчылмагыз, хәзер кайтып җитәм мин.

Егет, кире уйламассыңмы дигән сыман көттереп кенә, тормозга басты, юлдашының алдыннан сак кына үрелеп, тимер ишекне ачты. Карчык, тәвәккәл кыланып, ләкин шактый җайсыз итеп җиргә төште, утыргычтан ялтырап торган кечкенә коңгырт сумкасын алды.

— Ярты көн буе йөртүеңә рәхмәт, улым,— диде.— Инде бар, үз эшеңне кара.

Машина китеп барды. Карчык, утызынчы еллар комсомолкалары шикелле итеп, кыска, тигез киселгән, әз генә чал керә башлаган кара чәчен сыпырып, кәкре тарак белән кадап куйды, вак бизәкле зәңгәр күлмәген, зәңгәр кофтасын рәтләде.

Машинада хәрәкәтсез утырганга, аның болай да сызлаучан аяклары оеп киткән, бензин исе башына тигән иде. Каты җиргә басып, җәй башының хуш исле һавасын күкрәк тутырып сулагач, аңа җиңел булып китте. Ул ерагаеп барган газикка байтак вакыт карап торды. Машина кечерәйгәннән-кечерәйде, ниһаять, ярты офыкны каплаган, буе чакрымга сузылган күксел завод бинасы артына кереп күздән югалды.

Карчык бинаның буеннан-буена тезелеп киткән, кояш нурларында тоныкь ялтыраган тәрәзәләреннән, бинага төрле яктан килеп тоташкан торбалардан, завод тирәсендә кайнашкан трактор-машиналардан күзен ала алмый торды. Аның күңелен гаҗәпләнү, соклану катыш сагыш биләгән иде.

Өч ел, нибары өч ел кайта алмады ул туган ягына. Ләкин зур шәһәрдә, кызы белән бергә яшәгән уңайлы, якты квартирында бер генә

көн дә туган авылын искә алмый калмады. Сагынды ул аны, үзәкләре өзелеп сагынды.

Ниһаять, менә талпынып, ашкынып кайтты. Ләкин туган ягын танымады. Аңа бик таныш булган кечкенә район үзәге урынында зур шәһәр үсеп чыккан, ул гомере буе җәяү иңләгән-буйлаган басулар аркылы асфальт юллар, юан торбалар сузылып яткан, тирән чокырлар казылган, завод биналары күтәрелгән. Дөрес, баштан ук белә иде ул боларны, төзелеш ничек баруын зур кызыксыну белән газеталардан күзәтеп бара иде. Ләкин белү бер хәл, ә үз күзләрең белән күрү — бөтенләй икенче. Менә өч көн инде ул туган ягында йөри, ләкин үзен һич кенә дә авылына кайткандай хис итә алмый. Ул каядыр, бөтенләй таныш булмаган җиргә барып эләкте кебек, хәтта вакыт та алмашынды, карчык бүгенге тормышта түгел, киләчәккә барып керде шикелле. Дөрес, таныш йөзләр дә очрап тора, аны һәркайда хөрмәт белән каршы алалар, җыелышларда: «Колхозлашу чорының герое Кәримова», «Районыбызның йолдызы», «Безнең Газзә апабыз» дип мактап сөйлиләр, аңа ихтирам белдереп кул чабалар. Ул профтехучилищеда, төзелеш мәйданнарында, клубта чыгышлар ясады — заман кешеләренең көч-кодрәтенә сокланып сөйләде. Әмма күңеле белән һаман туган ягын эзләде, эзләде — табалмады.

Хәзер дә аның шәһәр читендәге яңа поселоктан кайтып килүе иде. Поселок моннан ерак түгел икән, бик матур җирдә, урман арасына урнашкан. Күркәм кыяфәтле, ачык, тулы чырайлы, ир уртасы председатель Галимов яңа поселокны аңа үзе күрсәтеп йөрде. Матур иде поселок, берәр, икешәр, өчәр катлы йортлар кечкенә ихаталар эчендә утыра, үзләрендә бөтен уңайлыклар бар икән.

— Сезнең Имәнлегез бөтенләе белән шушында күчәчәк бит инде, Газзә апа, — диде Галимов. — Беләсездер, кою заводының санитар зонасына эләкте бит Имәнле. Моннан ары шушы поселок кешесе булачаксыз инде, туган якны сагынсагыз, шушында кайтачаксыз.

Председательнең эчке горурлык белән елмаеп әйткән бу сүзләре исенә төшкәч, Газзә апаның йөрәге кысылып куйды.

Матур иде поселок, әйтеп торасы юк! Ләкин нинди генә матур булса да, чит поселок туган авылны алыштыра алмый шул.

Әнә ул, Газзә апаның туган авылы, газиз Имәнлесе, асфальт юлдан күренеп үк тора, Коры елганың бормалы яры буйлап, чирәм үскән сукмактан барсаң, нибары чакрым ярым чамасы гына. Уч төбендәге кебек. Ләкин ул да үзгәргән, җанга газиз чалымнарын югалткан, күңелдән читләшкән. Ул ятим кебек, авыру кебек. Йортлар арасында буш нигезләр күбәйгән, яз чыгу белән ап-ак итеп агартыла торган морҗалар, тәрәзә яңаклары агартылмаган, ындырлар казылмаган, коймалар ауган.

Юк, Газзә апа авылын мондый итеп күз алдына китерми иде!

Күп куанычлар, шатлыклар, җиңүләр китерде бу заман кешегә, ләкин аның үзенә генә хас сагышлары да бар бит! Авылы белән хушлашкан, күз яшьләре аша: «Хуш, авылым!» — дип басу капкасыннан билгесез юлларга чыгып киткән кешеләр элек-электән күп булган. Ләкин алар чит-ят җирләрдә, бәлки, башларын саласыларын белсәләр дә, бер ышаныч белән юанганнар: туган якларының ерактагы улларын сагынып көтәчәгенә, мәңге яшәячәгенә аларның иманы камил булган.

Ә менә Газзә апаның хәле киресенчә: ул авылының юкка чыгуын үз күзләре белән күрә иде...

Газзә апа асфальт юл уреннән чирәмгә төште. Аның аяк астыннан вак бакалар чокыр төбендә кибеп бетмәгән суга сикерештеләр.

Шунда кинәт дөнья үзгәрде. Газзә апа чирәмле сукмакны, үлән арасында, кояш кыйпылчыклары сибелгәндәй, янып торган сары чәчкәләрне, бөдрә талларны таныды. Күңеленә саф чишмә булып тургай моңы

агып керде һәм аның бөтен барлыгын биләп алды. Имәнле басуларында гына шулай сайрый иде тургайлар. Аларның болай сайраганын Газзә апаның башка беркайда да ишеткәне булмады... Һәр якның сандугачы үзенчә сайрый, диләр. Тургайлар да шулайдыр, мөгаен. Ничек әле ул аларны өч көн буе ишетми йөргән, ничек танымаган. Хәер, асфальт юлларда тузганаклар үсми, машинада тургай җыры ишетелми шул.

Газзә апа сумкасын куеп, тал куагы төбенә утырды. Янныннан гына җемелдәп торган сары чәчкә өзеп алды. Аннары зәңгәр күке күзен үрелде. Аларның сабакларын бергә китереп бәйләде. Кинәт колагына:

— Ай-һай, минем кызларымның такыялары бигрәк матур икән! — дигән тавыш ишетелгәндәй булды, авыл ягында әнисе күренгәндәй тоелды. Күлмәк итәген алъяпкыч бавына пөхтә генә итеп кыстырган, яулыгын яшь киленнәрчә артка чөеп бәйләгән, йөзендә беркемдә булмаган ягымлы елмаю, наз балкый.

«Үрдем, әнием, үзем үрдем, — диде Газзә апа эченнән генә. — Чәчкәләрне генә түгел, гомерем елларын да такыялар итеп үрдем инде. Ак, кызыл, сары, зәңгәр — төрле чәчкәләрдән...»

Менә ак чәчәк. Ул карга охшаган. Мең тугыз йөз унтугызынчы елның көзендә Имәнленең киң урамына йомшак юрган булып төшәлгән карга...

## Беренче сабаклар

Сигез яшь әле тулып җитмәгән Газзә, әтисеннән калышмаска тырышып, йөгерә-атлый югары очка таба бара. Кемдер чана белән юл ярып та өлгергән, тояк эзләре ярылып ята, Газзәнең әтисе шуннан эре, үрчемле атлый. Аның аркасы Газзәдән ярты дөньяны каплый, шундый зур ул, шундый көчле. Очраган агайлар аңа баш иеп:

— Нихәл, Асылкәрим, исәнлек-саулыкмы? — дип баш иеп узалар.

Газзә үзе дә бүген әтисе янында ким-хур булырлык түгел. Аның кулында кечкенә генә төенчек — абыстайга сәдака, өстендә гәүдәсенә таманлап тегелгән өр-яңа бишмәт. Дөрес, бишмәтенең түше белән аркасы күксел, ә җиңнәре зәңгәр, чөнки әнисе аны өлкән улларының искергән бишмәте белән кечерәйгән камзулыннан бозып тегеп бирде. Ләкин Газзәгә калса, бу төрлелек бишмәтне тагын да матурлый гына. Ул әле түшенә, әле җиңенә карап куана, артына борылып, Вәҗһетдин абзыйдан шушы көн өчен махсус ясатып алган чабатасының шакмаклы эзләренә соклана. Аннары әтисе артыннан терек-терек йөгерә. Дөнья ак-пакь, әтигә аркаланып баруы искиткеч рәхәт!

Ак-пакь дөнья белән әтисе артта калып, ярым-караңгы өйнең бусагасын атлап кергәч тә, Газзәнең кәефе кырылмады әле. Күзе ияләнеп, сәкедә утырган берничә баланы шәйләгәч, чабатасын салып, башкалар кебек үк бишмәттән килеш, сәкегә, түр тәрәзә янынарак үрмәләп менеп китте. Ләкин теләгән урынына барып җитә алмады, елтыр күзле, кара башлы Салый аны төртеп төшерде: «Монда сиңа урын юк!» — диде. Газзә кече якка үзләренең уң як күршесе, җирән чәчле Мәһруй янына елышмакчы булды. Ләкин соңрак килгән балалар аннан да: «Кит әле, минем урын бит бу!» — дип кысрыклап чыгардылар. Балалар ишәйгәч, Газзәгә идәндә дә урын калмады. Баштарак аны төрткәләп мич авызы турына — «көрәк асты» дигән җиргә үк кысрыкладылар, аннан мич арасына — гөлбәчкә үк кертеп җибәрделәр.

Менә өй эчендәге ыгы-зыгы кинәт тынды, абыстай керде һәм һәр балага аерым-аерым, син моны укы да, син тегене укы дип, сабак биреп йөри башлады.

Менә, ниһаять, казан кунасы өстендә дә энҗеле калфак, кырыс чырай күренде, абыстай юка иреннәре арасыннан чем-кара итеп каралткан тешләрен җемелдәтеп:

— Кем бар тагын анда? Кем кызы син? — дип сорады.

Асылкәрим кызы дигән җавапны алгач, кәлиматен-таибәтенне укырга кушты да, казан өстеннән юкка чыкты.

Абыстайның тавышы шактый коры ишетелде. Газзә, башка балалардан күрмәкче, күзләрен чытырдатып йомып, алга-артка чайкалып, «кәлиматен-таибәтен»не нихәтле генә тырышып ятласа да, абыстайга ярый алмады. Көн саен иртәнге якта, казан кунасы өстендә, энҗеле калфак һәм каралткан тешләр чагылып китә һәм Газзәнең колагына:

— Ә син, Асылкәрим кызы, шул сабагыңны кабатла, — дигән сүзләр генә чалынып кала иде.

Әнисе көннән көнендә тәүфикълы бул дип колагына киртләп җибәрсә дә, тиктормас кызчыкның түземе озакка бармады. Үзе белән бергә мич арасында утырган бала-чагага белгәннәрен сөйли башлады ул. Башта янында утырган кызның колагына пышылдый иде, аннары миңа да әйт, миңа да дип башкалар да елыша башлады. Бусага янында утырган, югары очның Бармаксыз Һади малае Әхтәм дә, йомры башына ябыштырып куелгандай тырпаеп торган колагын сузып, мич арасына табарак шуышты. Кече як сәкесеннән җирән чәчле Маһруй шым гына килеп төште.

Кыскасы, берничә көн үтүгә, балалар абыстай чыгып киткәнне генә көтеп торалар да, шунда ук җыелышып: «Сөйлә дә сөйлә, кычкырыбрак сөйлә», — дип Газзәне кыстарга керешәләр иде.

Сөйли Газзә, ярым караңгы өй эчендә гадәттәге гөжләү урынына аның нечкә тавышы гына яңгырап тора. «Сак белән Сок бер-берсенә кычкырып, тавышларыннан бер-берсен эзләп табалар, ди. Инде кавышабыз дигәндә генә араларында биек булып Каф тавы...»

Иң кызык җирендә генә кинәт ишек ачыла, абыстайның ачулы тавышы ишетелә:

— Каһәр суккырлары, нәрсә дип мичкә сырыштыгыз?

Бала-чага тирә-якка борчактай сибелә, абыстай мич арасына карый, ә анда һәркайсы күзен йомып, чайкалып, мыгыр-мыгыр үз сабагын ятлый, ипи көрәге артында Асылкәрим кызы да «кәлиматен-таибәтен»не тәкърарлый. Абыстай чыгып китүгә балалар тагын «шуннан! шуннан!» дип Газзәне төрткәлиләр.

Ә кыз ялындырып тормый. Ул көн саен диярлек әнисеннән экияткыйссаларның яңаларын отып килә.

... Кич җитүгә, Асылкәримнең балалары әниләренең эше беткәнне түземсезлек белән көтәләр. Менә ул савыт-сабаны юып, сәкедән ашъяулыкны җыеп ала. Әтиләре, мич буендагы киң эскәмиягә утырып, итеккә олтан сала, балалар түгәрәкләнеп сәкегә, йон язарга утыралар. Уртадагы йон өеме, күпергән ак болыт кебек, торган саен зурая, биегәя, сәке йөзлегенә беркетелгән тоткычта чыртлап нарат чыра яна, вакыт-вакыт әниләре кагып куйганда, утлы күмер идәндәге сулы савытка төшеп чыжлый. Ул аягы белән Сәмига яткан бишекне тирбәтә, куллары йонны үзеннән-үзе генә яза кебек, күзләрен боз каткан кеч-кенә тәрәзәгә төбәп, йөрәккә сары май булып ята торган ягымлы-йомшак тавыш белән салмак кына сөйли дә сөйли. Чыра уты бер көчәя, бер сүрелә, аның йөзе дә бер яктыра, бер сүрелә, вакыт-вакыт күзләре очкынланып китә. Балаларның куллары ак йон эченә чумып хәрәкәтсез калган, экият тылсымына бирелгәндәй, песиләр дә — Газзәнең соры песие дә, Саниянең ак песие дә — хәрәкәтсез калганнар.

Ана бер экияттән икенчесенә күчә, ә балаларга һаман әз, алар, әни сөйлә, тагын сөйлә, диләр, әниләре арыпмы, әллә шул кирәк дипме, аларга догалар өйрәтә башлый иде. Догаларның сүзләре ят, аң-

лаешсыз. Ләкин нәкъ менә шул аңлаешсызлыклары белән алар Газзәгә тылсымлы, кызык тоелалар. «Рабби әнзилни мөнзәлин...» Ничек зыңгылдап тора!

Әкиятләр, догалар, бәетләр, пәйгамбәр кыйссалары — һәммәсе Газзәнең башында бутала, аның төшләренә керә, ул канатлы кош булып, таулар-елгалар өстеннән очып йөри, бер-берсен күрергә зар-интизар булган Сак белән Сокны кавыштыра, Йосыфны тирән коедан тартып ала. Кай төннәрдә, әтиләре олау белән киткән чакта, ул Газзә белән Санияне ике ягына яткыра иде. Газзәнең аркасы, иңнәре һаман да әнисенең назлы җылысын онытмаган...

Бу әкиятләрнең, кыйссаларның күбесе китапта язылганын белә иде Газзә. Олы як белән кече якны аерып торган чаршау өстендәге киштәдә почмаклары кителгән, калын көрән тышлы, кыштырдап торган саргылт битле бернечә китап та бар иде. Әтисе белән әнисе ул китапларны бик изгегә саныйлар, балаларга кагылырга рөхсәт итмиләр иде. Өлкәннәр өйдә юк чакта. Газзә, дулкынланып, аларны кулына ала, сырлы-төрткеле тамгаларның серенә төшәргә тырыша, җай туры килгәндә, бу нинди тамга, дип абыйларыннан сораштыра. Акшар чиләгеннән алган ак ташлар белән өй бүрәнәләренә шундый ук тамгалар ясарга азапланып карый иде ул.

Абыстайга сабакка баргач, Газзә әнисеннән ишеткәннәрне нәкъ әнисенә охшатып салмак кына сөйләргә тырыша иде.

Шулай бер көнне, бөтен бала шым булып, тын да алмый тыңлаганда, «Йосыф-Зөләйха»ның иң кызык җирендә, — Зөләйха гайбәтче хатыннарны чакырып, алларына ит куеп, һәркайсының кулына үткен пычак тоттыргач кына — ак башлы Әхтәм кычкырып җибәрмәсенме:

— Әл-ләлә-лә! Изде кулымны! Елтыр тәре! Монда сиңа ни калган! Менеп кит түр башыңа! Көн саен абыстайга ит-май ташыйсың! Түр башында утырыр өчен! Сыпыр сәкегә!

Елтыр Салые моның бармагына баскан икән.

— Мин сыпырмы? Минме? Сәдакага кызыл акча да бирмәгән башың белән! Хәерче! Зимагур токымы!

Китте талаш, китте сугыш. Сәкедән бай малайлары сикерешеп төште, идәннән сәдакага кызыл акча, ягъни бакыр тиеннәр генә китерә алган ярлы балалары күтәрелде. Йодрыклар уйнады, бишмәтләрдән тузан бөркелде, һавада көл-күмер, тузан очты. Абыстай кергәнне дә сизми калдылар, ул ачы тавыш белән:

— Нишләвегез бу, ристаннар! — дип кычкыргач кына мышный-мышный таралыша башладылар. Тик Салый белән Әхтәм генә, берсе дә алдан туктарга теләмичә, һаман дөмбәсләшәләр иде әле. Абыстай аларны якаларыннан эләктереп алды да, маңгайларын бер-берсенә китереп бәрде — шык иткән тавыш ишетелде.

— Менә сезгә, менә!

— Минмени! — дип кычкырып җибәрде Салый. — Үзе килеп ябышты бит! Сәдаканы күп ташыйсың дип үзе килеп бәйләнде! Шуңа сине түргә утырталар, ди!

Абыстай аны коры гына:

— Бар, урыныңа утыр! — дип бүлдерде дә. Әхтәмне:

— Ә син, бәдбәхет, бар, атаң белән кил! — дип җилтерәтеп өйалдына чыгарып, ишекне шап итеп ябып та куйды. Бу хәлләрне мич арасыннан башын сузып күзәтеп торган Газзә, абыстайның карашыннан куркып, кинәт чигенгән иде, артында шытырдаган тавыш ишетелде. Минутында ул моңа игътибар бирмәде, тизрәк «кәлимәтен-тайбәтен»не кабатларга кереште. Инде кайтырга кузгалып, мич арасыннан чыккач кына, аны Маһруй туктатты:

— Бишмәтеңне ерткансың бит! — диде.

Газзә бишмәтен салып караса, чыннан да аркасы буйдан-буйга ертылган, эченнән мамык урынына язып салынган ак йон бүсеп чыккан. Мич арасында табагач сабы сынган да шуңа эләгеп ертылган икән. Инде нишләргә? Ничек итеп әни күзенә күренергә?

— Ә син аны анаңа күрсәтмә, — ди Маһруй. — Аркан борылма, гел алдың белән генә тор.

Үзе, җебен-җепкә бәйләштереп, ертыкны рәтләштермәкче була, миһербанлы җан!

Алар Газзәнең гаебен яшерергә мең төрле хәйлә корып урам буйлап кайталар. Ләкин гаебен йому аның кулыннан килә торган эшме соң! Ул капкадан кереп, ишек төбенә җитә алмый, артыннан әнисенең тавышын ишетә:

— И, бәбекәччәем, хараплар гына иткәнсең бишмәтеңне!

Газзә өнсез калып борылды да, әнисенең кулында каба күреп шуның белән китереп органны көткәндәй, ике кулын башына таба күтәрде.

— Инде ни киеп йөрерсең сабакка! — диде әнисе сыкранып. Үзе кабаны баскычка куйды да — ул аны Хәкимҗан абзыйлардан алып чыгып килә икән — кызының аркасын борып карады:

— Рәтләр чамасы да калмаган, ичмасам! Ямаулыкка төсе дә юк бит әле аның!

Әнисенең тавышында әрнү шул хәтле көчле иде ки, Газзәнең дә хәсрәте ташып чыкты, ул кычкырып елап җибәрде:

— Үзегез сәдакага кызыл акча гына бирәсез! Мине гөлбәчтән чыгармыйлар! Анда табагач сабы сынган! Әнә Салый сәке түрендә утыра! Атасы ак акча биргәч! Сез миңа май да, ит тә бирмисез!

Бөтен үпкәсен берьюлы чыгарды да салды ул. Әнисе:

— Сәдака әз дип, бишмәт ботарлап йөрмиләр инде аны! Сигез җанга бер сыер, каян җиткерим мин ул майны! — дип җилтерәтеп өйгә алып кереп киткәч кенә туктады.

Әмма дәгъва моның белән генә бетмәде. Күрше кызы Маһруй Газзәнең әнисен күреп калган да аларның ниләр сөйләшкәнен койма ярыгыннан карап, тыңлап торган икән. Өенә кергән дә: «Минем олы якның түр башында утырасым килә, абыстайга сәдаканы күп итеп бирегез, әнә Газзә дә әнисеннән ит-май сорый», — дип, әнисе Маһикамал түтигә ябышкан.

Иртәгесен Газзәнең сүзләре абыстайга барып ирешкән, алай гына түгел, абыстайның җавабы да, авыздан-авызга күчеп, Асылкәримнәр өенә килеп җиткән иде инде. «Гайбәтемне саткан кешегә биргән гыйлемем харам булсын! — дигән ди абыстай.— Моннан ары Асылкәрим оясыннан берсе дә бусагабызны атлап кермәс, алла боерса».

Шулай итеп, Газзәнең тиктормас теле аркасында, аның үзенә генә түгел, Сабирҗан муллага сабакка йөри торган ике абыйсына да «гыйлем» юлы киселде.

Бик кайгырган иде моңа бичара ана, ифрат борчылган иде... Юкка хәсрәтләнгән икән, мескенкәй, Газзәгә белем бирәсе кеше ул чакта инде юлга чыккан булган.

Ул Газзәләр өенә үзе килеп керде. Сәке тулы бала-чагага, аягына килеп уралган песиләргә, акшар белән чуарланган бүрәнәләргә карап елмайды, кычкырып сәлам бирде, Асәлкәримнең сумалага буялган кулларын учына алып, ике куллап күреште:

— Мин яңа килгән мөгаллим, — диде, — Зиннур Гомәров дигән кеше булам.

Мөгаллимнең бөдрә бәрән тиресеннән тегелгән аклы бүреге дә, чәче дә, шома итеп кырган бите дә, өстендәге билле бишмәте дә авыл кешесе түгеллеген әллә каян белдереп тора иде. Тик калын күк олтан салган кара киез итекләре генә авылча күренде.

Асылкәрим күз керфекләрен бер генә сирпеде — балалар мәчеләрен култык асларына кыстырып кече якка шылдылар, чаршауның астыннан, кырыеннннан олы яктагыларны шым гына күзәтә башладылар.

Ят агай нык кына аксый иде, бишмәтен салып, түргә узганда да таягын калдырмады, аны сәке йөзлегенә сөяп кенә куйды.

Ул хуҗа белән кара-каршы чәй эчеп, шактый озак сөйләшеп утырды. Мөгаллим гражданнар сугышыннан яраланып кайткан, хәзер балалар өчен мәктәп ачачак икән.

Асылкәрим тирән көрсенеп:

— Каршы килеп булмый инде, — диде. — Мулла абзый белән абыстай барыбер безнекеләрне якын җибәрмиләр, өйдә шукланып ятканчы, йөрсеннәр әйдә!

Ләкин мөгаллим абзый балаларның барысын да түгел, хәзергә әле хәреф танымаганнарын гына җыя икән. Ул үзенең каты тышлы кечкенә дәфтәренә Газзәне генә язып куйды.

Әнисе Газзәнең бишмәтен бик пөхтә итеп, арка уртасыннан зәңгәр тасма сузып ямап куйган иде. Ул аңа киндердән әйбәт букча да тегеп бирде.

Мәктәп югары очта, иң кырый өйдә. Бармаксыз Һадилар каршындагы Сөбхиямал әбиләрдә ачылган иде.

Өй чиста итеп юылган, идәннән сәкегәчә берничә озын өстәл, эскәмияләр ясап куелган, түр як стенага кара такта эленгән иде. Сөбхиямал әбинең шахтадан кайткан улы Таҗетдин ул тактаның соңгы кадагын кагып азаплана, ә мөгаллим кәгазь-каләм өләшеп йөри. Газзәне күргәч, Таҗетдин борылып карады да, мәзәк кенә итеп күз кысып куйды.

Газзә, абыстайдан алган «сабак»ны исендә тотып, почмаккарак елыша башлаган иде, мөгаллим:

— Нишләп анда торасың? — диде. — Син бәләкәй бит, алгы рәткә утыр.

Беренче дәрескә биш-алты гына бала килгән иде. Мөгаллим алга чыгып басты да, тантаналы рәвештә:

— Бүген без, балалар, укырга-язарга, санарга өйрәнә башлыйбыз, — диде һәм эшне озакка сузмыйча, киң итеп селтәнеп, кара біктага беренче сызыкны сызып та җибәрде, аның кулындагы акбурдан тирә-якка кыйпылчыклар чәчрәде...

Газзәнең мәктәптән кайтканын әнисе, капка төбенә үк чыгып, түземсезләнеп көтеп ала торган иде. Кайнар чәй эчерә дә, кызы бераз җылынуга, кече якка алып кереп, чыш-пыш сораштырырга тотына: бүген ни укыдыгыз? Мөгаллимегез ниләр сөйләде?

Ә мөгаллим ни укыганнарын әйтергә кушмый, ни укыдыгыз дип сорасалар, «Гыйлемхан» укыдык, «Гасыр сәгадәт» укыдык дип әйтегез, ди, югыйсә, миннән ишеткәннәрегезне сөйләсәгез, үзегезне бүтән мәктәпкә җибәрмәсләр, дип көн саен кисәтеп җибәрә торган иде.

Ләкин әнидән дөресен яшереп буламы соң? Бигрәк тә үзе белән кара-каршы бәрәңге әрчергә утыртса, я токмач басканда камыр өзеп бирсә... Газзә камырдан шарлар, шакмаклар, ә кайчакта мәче рәсемләре ясарга ярата иде.

— Мөгаллим абый әйтә, олы тимер кошлар бар, ди. Аларга утырып күктә тилгәннән тиз очып була, ди. Аннары шундый арбалар бар, ди, аларны матур дигән нәрсәләр тартып йөри, ди, үзләре аттан кызу чаба, ди...

— Бардыр, кызым, бардыр, — ди ана. — Күп йөргән кеше күргәнен сөйлидер... Сез үсәрсез, бөтенесен күрерсез әле, безгә генә насыйп булмады...

Газзәнең андый рәхәтләрдән әнисен мәхрүм итәсе килми, ул аны юатырга тырыша:

— Мөгаллим абый әйтә, аңа бөтен кеше утырып йөриячәк, ди. Без әле олыларны да укытаячакбыз, ди...

Ана, анысына ышанып җитмәгәндәй, керфекләрен түбән төшерә дә, кызулап эшенә керешә.

Шулай да аны иң хәйран калдырганы мөгаллимнең балаларга җыр өйрәтүе булды. Хәрефләр язып, саннар ятлап аргач, мөгаллим:

— Әйдәгез, балалар, бер җырлап алыйк әле, — ди иде. Беренче тапкыр аның бу сүзләрен ишетеп, Газзә дә хәйран калды: сабакта? Җырлап? Ә мөгаллим балаларның аптырашканын сизмәде дә кебек, гади генә итеп:

— Менә бу җырны беләсезме? — диде дә, карашын балаларның баш очыннан каядыр еракка төбәп, бик җитди кыяфәткә кереп, калын, ләкин йомшак тавыш белән әкрен генә җырлап та җибәрде:

Сагынам туган-үскән илемне,
Әллә кай җирләре ямьледәй,
Сөямен, шул илемне уйлап көямен.
Яшел чирәмнәрдән чөлтерәп аккан
Сулары да татлы-тәмледәй.
Бигрәк тә шул су буе тора йөрәктә.

Җыр таныш түгел иде, ләкин барысына да ошады. Алай да мөгаллимгә кушылырга кыймадылар. Бары тик аның чын-чынлап җырлатасы килгәнен, бу эшнең бер дә гаеп түгел икәнен аңлагач кына әкренләп авызлары ачылды. Үзләре дә белгән җырларын җырлап күрсәтә башладылар, кайсыдыр кыюланып:

— Ә Әхтәмнең гармуны бар, уйный ул, — дип тә әйтеп салды.

Югары очның ярлы Һади малае ак чырайлы, ябык Әхтәм һич көтмәгәндә мәктәпнең күркенә әйләнде. Аның атасы, ихатам җимерек дип, ашарыма юк дип тормаган, малаена кызыл күрүкле гармун алып биргән иде. Үзенең уң кулында өч бармагы юк — аларны ул читтә, шахтада калдырып кайткан, шуңа ачу итепме, улын тәпи басканчы ук гармун тартырга өйрәтә башлаган иде.

Мөгаллим абый бит очлары уттай янып чыккан Әхтәмгә гармунын алып килергә кушты. Өйләре каршы гына, минут эчендә әйләнеп керде малай. Каешларын беләкләренә элде дә, тотынды сиптерергә авыл көйләрен, шахта көен! Ә үзенең кызыл күрүк өстеннән алланган колак яфрагы гына күренеп тора.

Әй мактый мөгаллим абый Әхтәмне, әй үсендерә:

— Бик сәләтле малай икәнсең, зур кеше булырсың, тырышып укы гына, — ди.

Боларын тыңлагач, Газзәнең әнисе куркынып:

— Атаңа әйтә күрмә, — дип пышылдады. — Кыз балага ир-ат каршында авыз күтәреп җырлап утырырга кушмый китап. Гөнаһ була.

Ә үзе кызыннан мөгаллимнең җырын өйрәнеп алды һәм абзар-кура тирәсендә йөргәндә, ире юкта өйдә дә аның авыз эченнән генә шуны көйләгәне ишетелгәли иде.

Ана белән кыз бу хәлләрне Асылкәримнән бик зур сер итеп сакладылар. Әмма әти кеше барысын да читтән ишетеп, белеп торган, ул гына да түгел, болар бөтен авылга фаш булган икән.

Асылкәрим җомга намазларыннан кара коелып, шомланып кайта иде:

— Бүген тагын Сабирҗан мулла вәгазь укыды, Сөбхиямал Таҗетдине белән мөгаллимне каргады. Халыкны ходай тәгаләгә каршы котырталар, балаларга җыру өйрәтәләр, диде. Бәладән башаяк, әллә соң Газзәне сабактан туктатып торыйкмы?

Газзәнең әнисе каршы сүз әйтми, ә үзе һәр иртән кызын мәктәпкә мыштым гына озату ягын карый иде.

Ләкин бер көнне этиләре бу эшкә ныклап чик куйды:

— Картлар бик кызган анда, — диде, — Биекъяр артындагы авылларда әллә нинди «кара бөркет» дигән адәмнәр күтәрелгән, ди, мөгаллимнәрне, сәвит яклы кешеләрне рәттән юк итеп баралар, ди. Алла сакласын, шаукымы монда да килеп җитәр...

Моны ишетеп торган Газзә «кара бөркет»не әкиятләрдәге, кара болыт кебек киң канатлы, озын, очлы, кәкре томшыклы, кешеләрне әллә кая күтәреп китәрлек көчле сәмруг кошы төсле итеп күз алдына китерде. Шул куркыныч кош килер дә, мөгаллим белән Таҗетдин абыйларны күтәреп китәр, аннары Газзәгә, Әхтәмгә, мәктәпкә йөргән башка балаларга ташланыр сыман тоела иде. «Мөгаллим абый белән Таҗетдин абый да кара коштан куркалардыр, урамга чыкмыйлардыр», — дип үз-үзен юатты ул. Ләкин өйгә качып кына котылып була торган булып чыкмады ул «кара бөркет» афәте.

Өйдән чыгуга тынга каба торган суык, чалт аяз бер көнне Газзә Хәкимҗан абзый карчыгыннан агач савыт белән катык оеткысы алып чыгып килә иде. Урам киң, ачы җил савыт тоткан ялан кулны чеметтерә, Газзә ашыга иде. Урам уртасына җиткәч, ул мәчет ягыннан, түбән очтан ашыгып кайтып килгән этисен күреп алды. Этисе нәрсәгәдер бик борчылган сыман, кызын күрми дә шикелле, чөнки, бөтен дикъкатен биреп, югары оч ягына караган. Ә аннан колакчыны күтәреп бәйләнгән бүреген кыңгыр салып Таҗетдин килә. Асылкәрим капкага илтә торган, тирән итеп көрәлгән сукмак башында туктап калды, әле мәчет ягына, әле Таҗетдингә карады, «кил әле монда» дигәндәй егеткә ишарә ясады да, үз капкасына борылды.

Газзә алар артыннан ирде, ишегалдына кергәч, кулы туңганны да онытып, тегеләрне күзәтеп торды. Менә этисе урамга кире чыгып як-ягына каранды, аннары Таҗетдинне ишегалды түренә, абзарга таба алып кереп китте.

Газзә оеткыны тиз генә әнисенә кертеп бирде дә мич буеннан бияләй эләктереп чыкты. Әтисе абзардан бияне алып чыгып килә иде. Менә ул аны ашыгып чанага җикте, Газзәгә:

— Ач әле, кызым, капканы, — диде.

Урам буш иде. Асылкәрим, урта юлга чыккач, атын туктатты да, артына ымлады:

— Утыр, кызым, син дә.

Бик мөһим һәм шактый ук хәвефле юлга чыкканнарын сизеп, этисе кебек үк җитди һәм тәвәккәл кыяфәт белән чанага утырды Газзә. Туры бия, чана табаннарын чыжлатып, югары очка таба дерт-дерт юыртып китте.

Асылкәрим аны Сөбхиямал капкасына борды, хуҗаларның чыкканын да көтмичә, капканы ачып ташлады, ишектән үк:

— Сөбхиямалтти! Әҗәтеңне түлисеңме? Кибәннәрең бар чакта бирел кал! — дип кычкырды.

Артыннан килгән Газзәгә:

— Бар, кызым, бар, урамга чык әле, берәрсе күренсә, әйтерсең! — дип пышылдады.

Әтисенең нидәндер бик хафаланганын сизеп, Газзә капка төпләрен искәштереп йөргән эттән дә шикләнеп торды.

Күпме вакыт үткәндер, капкадан, Газзәгә җылы сулышын бөркеп, бия чыкты. Чанага ат сырты биеклегендә солы көлтәләре төялеп, өстен бастырык белән бәйләп куелган иде. Асылкәрим кызын күтәреп йөк өстенә утыртты, ә үзе сул яктан җәяү китте.

Урта юлга чыкканда, чана салулап китте, Газзә шома салам өстеннән төшеп кала язды, ярый әле, аягы ниндидер каты әйбергә терәлеп, туктап калды.

— Ныграк тотынып утыр, — диде әтисе теш арасыннан.

Ә Газзә һаман иелеп уңга карый, карамый түзә алмый, чөнки аннан, салам арасыннан ниндидер таныш нәрсә күренә! Астына күк олтан салынган кара итек башы бу. Ул гына түгел, аннан очына кадак кагылган таяк башы да тырпаеп чыккан! Бу бит мөгаллим аягы!

— Тик кенә утыр, кыбырсынма,— ди аны-моны сизмәгән әтисе Газзәгә. Ә үзенең күзләре түбән очтан якынлашып килгән агайлар төркемендә.

Менә алар яныннан, Асылкәримне күрмәгән дә сыман, ап-ак чалма белән яшел чапан кигән, түгәрәк кара сакаллы, мәһабәт кыяфәтле Сабирҗан мулла узып китте. Асылкәрим, аларга юл бирер өчен, бияне туктатып торды.

Ә Газзәнең күзе аста, итек башында. Менә солы саламы селкенә башлады, итек әчкә тартылды, ләкин барыбер очы күренеп калды. Нишләп ята анда мөгаллим абый?

— Әти! — дип атасының җиңеннән тартты Газзә.— Анда мөгаллим абый...

— Тик тор диләр сиңа! — Асылкәрим ачу белән җиңен тартып алды. Үзе борылып карады да агарынып катты, ашыгып йөк өстеннән төште. Калтыранган тавыш белән, ләкин һич көтмәгәндә йомшак итеп:

— Каяле, кызым, син дә төш, җайлабрак бәйлик, — диде. Газзә җиргә төште, тез буыннары йомшап, саламга сөялде, үзе дә аңлап җитмәстән, бишмәт чабуы белән итек башын каплады.

Ул арада агайлар чананы ике яктан уратып алдылар.

— Әйдә, Асылкәрим, бор бияне!

— Бәдбәхетләрне акылга утыртырга!

— Савaплы булырсың!

— Мәптегенә барабыз. Корткычның үз оясына!

Асылкәрим бастырыгын рәтләштерә иде.

— Хәзер... Менә... Йөкне генә кертеп бушатыйм инде... — дип сөйләнде ул.

— Озаклама!

— Кызыгын күрми калырсың! — диешеп, агайлар үз юллары белән китеп бардылар.

Ишегалдына кергәч, әтисе Газзәгә мөлдерәп карады да:

— Кызым, Таҗетдин абзаң белән мөгаллим абзаңны сораучы булса, күрмәдек диген, яме, — диде. — Абыйларыңа да әйтмә.

Шул ук кичне, караңгы төшүгә, ул тышсыз толыбын алып өйдән чыгып китте. Әниләре дә, сәкедән паласны алып, аңа иярде.

Озакламый шыгырдап капка ачылганы, ат пошкырганы ишетелде, балалар, тәрәзә бозын сулышлары белән эретеп, әтиләренең югары очка, олы юлга таба киткәнен күреп калдылар. Ул таң алдыннан кире әйләнеп кайтты. Әниләре сәке йөзлегенә утырып:

— Инде ходаем, бусы афәтләрнең соңгысы булсын, моннан ары җан тынычлыгы бирсен, — дип дога кылды.

Ләкин аның догалары кабул булмады.

Егерме беренче елның ачлыгы килде. Ишле булса да хәлле генә саналган Асылкәрим гаиләсе бер кыш белән бер яз эчендә юкка чыкты — Газзәнең әтисен, әнисен, туганнарын Таштүбә итәгендәге зиратка илтеп җирләделәр.

Ятим калган кызны Каратал авылына илттеләр дә, чәчен кырып, алпавытның ташландык йортында ачылган приютка бирделәр.

Үлем фаҗигасен күп күрде Газзә, әмма нәни күңеле белән һич кенә дә аңлый алмады. Хәер, кем генә аңлый соң ул үлем дигән нәрсәне! Әтисенең, туганнарының, терсәген бөгеп апасыннан уздырырга тырышып йөгергән төймә күзле Саниянең, бигрәк тә әнисенең шулай кинәт юк булуын берничек тә акылына сыйдыра алмый иде Газзә. Зур гаиләдә үскән бала, ул беркайчан да ятимлеккә күнегә алмады, хәер,

ятимлеккә ризалашу адәм баласы өчен мөмкин эш микән? Бигрәк тә әнисен сагынды Газзә, аны көтте, ул каядыр киткәндер дә, менә-менә кайтыр, газиз кызын приюттан килеп алыр кебек иде.

Приютта балалар төннәрен идәндә тезелешеп йоклыйлар иде. Газзә бик озак йокыга китә алмый, тәрәзәдән төшкән салкын ай яктылыгының әкрен генә шуышканын тоеп, чикерткә чырылдаганын, тычканнар кыштырдаганын тыңлап ята. Үз өйләрендә кич утырганнарын, әнисенең кыйссаларын исенә төшерә. Аның күңелендә әнисенең җылы кочагына сыену теләге шул кадәр көчле булып кузгала ки, әгәр шул минутта теләге тормышка ашмаса, йөрәге тибүдән туктар шикелле...

Газзәнең зарын сөйләрлек, шушы теләген әйтерлек кешесе юк, ул, әнисеннән өйрәнгән бөтен догаларны укып, ходайга ялвара: кайтар, әниемне, ди, кайтар! Ул сорый, үтенә, алай гына да түгел, таләп итә, боера! Һәм йөрәгендә шундый көч кузгала, аның теләгенең үтәлми калуы һич мөмкин булмастыр шикелле.

Күп уйлаганга, бик теләгәнгәдер инде, бер төнне Газзәнең төшенә әнисе керде. Бу төшен ул, өнендә булган тетрәткеч вакыйгалар кебек үк, гомере буе онытa алмады.

Ул болын уртасында басып тора, имеш. Үлән ямь-яшел, күк йөзе җете зәңгәр. Кинәт күк гөмбәзен бормалы-сырмалы сызыклар телгәли башлады. Ул сызыклар корьән хәрефләре рәвешендә, тик Газзә аларны укып кына өлгерә алмый. Менә күк шул сызыклар эзеннән ярылып китте, аннан ак болыт кисәге шуып чыкты. Болыт өстенә, аякларын бөкләп, бер карт утырган, ул Сабирҗан муллага охшаган, тик сакалы гына ак, карт Газзәгә ым кага, артыңа борылып кара, ди, Газзә борылып караса, ни күрсен: сәке кебегрәк бер урында әнисе ята. Күмәр алдыннан аны Газзәгә шул хәлендәрәк күрсәткәннәр иде. Йөзе нәкъ шул чактагыча ак, күзләре йомык. Менә ул, кызының карашыннан җан иңгәндәй, алсуланып китте, йөзе нурланды, керфекләре тетрәнеп күтәрелде. Менә ул башын күтәрде, кызын күреп, елмаеп куйды. «Әнием, син бит бу! Мин сине шул хәтле сагындым, сине кайтар дип, ходай тәгаләгә шул хәтле ялвардым! Ул сине терелтте, әнием?» Һәм Газзә, кулларын сузып, бөтен җаны-тәне белән әнисенә омтылды. Менә-менә ул аның янына барып җитәчәк тә, кочагына сыенып, назлы җылысын тоячак. Тик аяклары гына, сумалага ябышкандай, атлый алмыйлар. Ә әнисе чакыра, тизрәк кил, ди...

Шунда Газзә уянып китте. Янында яткан озын торыклы керәшен кызы Лиза, йокы аралаш саташып, аңа тибеп җибәргән иде.

Газзә торып утырды. Йөрәге дөпелдәүдән аның колагы чыңлый иде. Төн салкыны, балаларның саташып көрсенгән, йөткергән тавышлары аны әкренләп аңына китерде. «Нишләдем мин? — диде ул өзгәләнеп. — Ник уяндым? Әнием кайткан иде бит!»

Ул кире ятты, Лизаның сөякчел салкын аягын тезе белән этеп җибәрде дә, бишмәт чабуын башыннан ук бөркәнеп, күзләрен чытырдатып йомды.

Ләкин төше кире кайтмады.

Ә иртәгесен өлкәнрәк кызлар Газзәнең төшен карчыклар шикелле оста итеп юрап та бирделәр, үлгән кешенең сине чакырганын төшеңдә күрсәң, үзең дә озакламый үләсең, диделәр.

Бәхеткә каршы, ул чакта әҗәлнең рәхимсезлегенә чик куелган иде инде. Бер көнне балаларга:

— Без сезне ипиле якка, Украина дигән җиргә озатабыз, — дип игълан иттеләр.

Болытлы ямансу бер иртәне приют капкасы төбенә җигүле атлар килеп туктады, халык җыелды. Ятимнәрнең дә кардәшләре бар, күрше-күләне, күз күргәне бар. Саубуллашырга килгәннәр, күчтәнәчләр китергәннәр. Балаларны башларыннан сыйпыйлар, хәерле юл телиләр.

Тик Газзә янына гына килүче, аңа хәер-фатихасын бирүче юк. Чытыр арба артына ялан аякларын салындырып, юл читендәге тузанлы, кипкән үлән сабакларына карап, тып-тын утыра ул. Кемдер килеп иңенә кагылгач та күтәрелеп карамый.

— Балакаем, сабый! Арба аратасыннан күренмисең дә! Баядан бирле сине эзлим бит инде!

Газзә букча хәтле генә киндер капчык тоткан карчыкны башта танымый торды. Тавышы гына кемнедер хәтерләткән кебек.

— Күрми калам, әманәтне тапшырмый калам, дип котым очты. Әле дә таптым, аллага шөкер!

Карчык җилдә каралган, җыерчык баскан битен иске яулык чите белән сөртте:

— Мөгаллим абзаң әманәте бар бит миндә, балакаем.

Шунда гына Газзә карчыкны танып алды: Сөбхиямал әби! Мәктәп өенең хуҗасы! Газзә арбадан көлтә шикелле шуып төште дә әбекәйнең җиңенә ябышты.

— Бармаксыз Һади Биекъярда мөгаллим абзаңны күреп кайткан. Чирле икән мөгаллим. Теге чакта атаң мәрхүм, авыр туфрагы җиңел булсын, аны, Таҗетдин белән икесен, Караталга илткән иде бит. Шунда алар Серебров дигән керәшеннең базында качып ятканнар. Таҗетдин, аллага шөкер, исән-сау, шахтыда хәзер. Ә мөгаллимгә баз суыгы тигән, бик каты хасталаган, ди. Сине сорашкан, күчтәнәч җибәргән...

Әби капчыктан кызыл билле берничә прәннек белән бер китап чыгарды. Тукайның шигырьләр китабы иде ул.

— Йөрүләре бик читен бит, тиз арада килеп булмады, — диде әби. — Укысын, тырышсын, зиһенле бала ул, дигән мөгаллим абзаң. Менә, хәзинәдә барын мин дә салдым, юлда ашарсың. Ходай тәгалә савабын бирсен.

Ул арада арбалар кузгала башлады. Әби, арба кырына тотынып, бераз вакыт Газзә белән янәшә атлады.

— Юлларыгыз уң булсын, балакайлар. Чит-ят җирләр үз илең түгел дә бит, нихәл итәсең, насыйбыгыз шулдыр. Җыясы ризыкларыгыз шундадыр. Киткән кошлар да кире кайта, сезгә дә исән-сау әйләнеп кайтырга язсын. Бәхетең-тәүфигың белән үс, балам...

Авыл очында торып калган озатучылар төркеме шактый зур иде. Әмма авызын яулык чите белән каплап торган карчыктан башкалары Газзәнең күзенә күренмәде. Ул карчык ялгызы аның үзен генә озата сыман тоелды.

Атлар зират турыннан борылып, төркем күздән югалгач, Газзә капчыкны чиште. Аннан, мөгаллим күчтәнәченнән тыш, көлгә күмеп пешерелгән өч-дүрт бәрәңге, шалкан, валчык сырышкан кечкенә генә шакмак шикәр, бер кыерчык арыш ипие чыкты. Болары — әбинең үз күчтәнәчләре иде.

Атлар басу юлыннан җай гына атлыйлар, майламаган арба күчәрләре яман шыгырдый иде. Чәчелмәгән-урылмаган кара басуларда көзге җил тузан өермәсе уйната, дүңгәләкләрне әрле-бирле тәгәрәтә. Әле чүмәләләп өеп куя аларны, әле таратып җибәрә. Газзәгә никтер бик күңелсез булып китте. Кая бара ул? Туган ягын ташлап кемнәр янына китә? Ә монда Сөбхиямал әби кала, ерак та түгел, Биекъярда мөгаллим абыйсы кала. Газзәнең йөрәге әнисен төшендә күреп уянгандагы шикелле сызланып куйды. Ул нишләгәнен үзе дә аңлап җитмәстән, арба араталары арасыннан шуып төште дә, юл читенә җил өеп куйган дүңгәләк чүмәләсе артына посты. Яше унга җитсә дә, гәүдәсе йомгак хәтле генә иде. Арбалар шыгыр-шыгыр китеп барды, Газзәнең төшеп калганын абайлаучы булмады. Атлар үрдән төшеп күздән югалгач, Газзә дүңгәләк арасыннан күтәрелде дә, авылына таба йөгерде...

Нечкә сабакта ачылып җитмәгән бөре — Газзәгә үсмер чагын хәтерләтә. Чәчкәнең ни төсле буласын белеп тә булмый әле — ул тыгызланып, яшел яфраклар эченә яшеренгән.

Газзәнең ачылмаган чәчкә бөреседәй үсмер чагы кеше кулында, асраулыкта узды.

Чытыр арбадан төшеп калгач, ул туп-туры югары очтагы бер өйгә кайтып керде. Сөбхиямал әби күреп хәйран калды. Ул аны көтмәгән иде, юк, көтмәгән иде. Үзе дә кышка Бармаксыз Һадиларга өйдәш керергә дип сөйләшеп куйды бит. Кая инде, кеше өстендә тагын ятим бала асрарга! Авылдашлар аркылы сөйләшеп, ятимә кызны Биекъярга, сәүдәгәр Ханбиковларга бала карарга җибәрделәр.

Озатканда Сөбхиямал әби:

— Игелекле бул, балакаем, канат асларына сыйдырган, тамагыңны туйдырган мәрхәмәт иясенә мең-мең рәхмәт укып яшә, — дип үгетнәсихәт әйтеп калды. — Алар сыйдырмаса, кая барырыең?

Биекъярда Газзәне күргәч, хуҗа хатын Рабига:

— И-и, бик бәләкәй икән шул әле бу, ни генә эшли алыр икән, — диде. — Ярар инде, килгән икән калсын, ризыгыбыз җәл түгел, ходай тәгалә бәрәкәтен бирсен. Ятимәнең догасы изге була диләр, дога кылса — безгә шул җитә.

Ләкин үзе дога кылганга гына риза булмады, юк, риза булмады. Асраулыкта яшәгән елларын исенә төшергәндә, Газзәнең хәтеренә бала чакта әнисеннән ишеткән бер җыр килә:

Җиде яшемнән үк мин мескенне
Бала карарга дип алдылар;
Алдылар да минем йөрәгемә
Мәңге сүнмәс утлар салдылар.

Их, бала карау гына булса ни әйтер икән! Ул килгәнче үк бишектән төшкән Рәйсә янында утырулар Газзә өчен бер ял гына иде! Ләкин хуҗалар аның белән генә канәгать түгел иде шул!

Беренче көннән үк Рабига Газзәне караңгылы-яктыда уята торган булды. Озак та үтми, кыз үзе вакыты җиткәч сикереп торырга күнекте, хуҗа хатынга иртәнге тәмле йокысын бүлеп йөрисе дә калмады. Газзә юка сырмасы белән каткан мендәрен мич алдыннан — көрәк астыннан җыеп куя да, чиләк алып, ике сыерны саварга чыга. Ул кышын малларга башак сала, җәен — көтүгә куа. Хуҗа хатынны якын да китермичә тибенә торган мүкләк ала сыер Газзәгә шул хәтле күнекте, хәтта аның артыннан эт шикелле ияреп йөри торган булды.

Дөресен генә әйткәндә, асрау тормышының иң авыры, иң үзәкка үткәне шул иртә тору иде. Анысыннан Газзә җиде ел буе интекте. Ә калганы — идән, кер юу, атнага бер мунча ягу — бер күнеккән кеше өчен читенмени? Рабига да асравын: «Тырыш, тырыш, эшләгәнең кеше өчен булса, өйрәнгәнең үзең өчен булыр», — дип, гел үсендереп торды. Тырышты Газзә, авыр эштән башканы күрмәде, озак йоклауны, матур киенүне белмәде. Дөрес, Газзәне ялангач йөртмәделәр. Рабига иске күлмәкләрен чыбыктан үргән кәрзин шикелле сандыкта саклый иде. Исенә төшкәндә шуннан берәрсен тартып ала да аннан-моннан кечерәйткәләп асравына кигезә. Газзә шуны өстеннән коелып төшкәнче кия. Шуннан соң Рабига чыбык сандыктан тагын берәр күлмәген чыгара:

— Эссе тәнеңдә тузсын, рәхәтен күр, — ди. — Абзаңның сәүдәсе уң булсын дип изге теләктә тор.

Кышын асрау өстендә тышы тузганга эче тышка әйләндергән иске бишмәт, башында — хуҗасының искергән бүреге була.

Газзә барысын да шулай тиеш дип саный, нәфесен күпкә сузмый. Бары бер генә тапкыр кием мәсьәләсендә үзәге өзелгән иде кызкайның.

Бер заман хуҗа кызы Рәйсәгә куян бүрек алып кигезделәр. Йомшак иде, ак иде бүрек, ике колакчыны түшкә салынып төшә иде. Кызыкты бит Газзә шул бүреккә! Иртә дә, кич тә шуны уйлый, шундыйны кию турында хыяллана. Шулай туктаусыз уйлый торгач, моның күңеленә: «Рәйсәгә яңа бүрек алгач, монысын миңа бирмәсләр микән?» — дигән уй килде. «Бирерләр, ник бирмәсеннәр, — дип җавап та бирде ул үз-үзенә. — Рабигатти үзенең иске күлмәкләрен дә кызганмый бит әле». Хәзер инде хуҗа кызының бүректән гайрәте чиккәнен, янсә башы бүреккә сыймас булып үскәнен генә көтәсе калган иде. «Рәйсә үзе үк тә аны миңа бирмәсме әле,— дип уйлый иде Газзә.— Мине ярата бит ул».

Чыннан да, асрау кызга кечкенәдән күнегеп үскән Рәйсә аннан башка уйнамый да, сабагын да укымый иде. Аның белән бергәләп сабак уку — Газзәнең үсмер чагындагы иң бәхетле сәгатьләре булды.

Ул Рәйсә мәктәптән кайтканчы өй эшен бетереп куярга ашыга. Хуҗа кызы капкадан кергәч, түр якка чәй табыны әзерли, үзе кече якта гына капкалап ала да, почмактагы урындыкка мыштым гына барып утыра. Колакларын торгызып тыңлый: түр яктан кәгазь кыштырдаган тавыш ишетелмиме? Озак көтәргә туры килми, Рәйсәнең иркә тавыш белән:

— Әни-и! Газзә керсе-ен! — дип сузганы ишетелә.

Баштарак Газзә аңа әнисеннән отып калган әкиятләрен сөйли, мөгаллимнән өйрәнгән сабагын укыта иде. Әз генә вакыт эчендә шактый белем биреп өлгергән икән кызыл сугышчы Зиннур Гомәров! Бай кызын өйрәтергә шактый вакытка җитте. Кайбер дәресләрне Газзә үзе белмәгәнне китаптан укытып аңлата башлады. Кайбер дәресләрне Рәйсә үзе дә аңлатып биргәли иде — ни дисәң дә ул мәктәптән дәрес тыңлап кайта бит — андый чакта гаҗәп эре кылана ул, асрау кызны:

— Томана! Надан! — дип үрти.

Шулай бергәләшеп азаплана торгач, хәтта рус хәрефләрен дә танырга өйрәнде Газзә.

Юк, хуҗаларыннан зарланмый иде ул. Күршеләрнең асрау кызы Клава белән кое янында очрашканда да аның аһ-зарын тыңлап кына тора, колакка ят яңгыраган рус сүзләрен аңларга тырыша, ә үзе хуҗаларын яманлап теш арасыннан сүз чыгармый иде. Хәтта куян бүрек хакында да сөйләмәде ул аңа.

Бер көнне Рәйсә никтер алгы якка чыгып киткәч, Газзә түзмәде, теге бүрекне чөйдән алып башына киде. Түр стенадагы көзгегә карап, тынсыз калды: и килешә иде аңа бүрек, хур кызыдай итә иде, әнисенең кулы кебек йомшак, җылы иде үзе! Шуңа сокланып, Газзә хуҗа кызының кире кергәнен сизми дә калды.

— Сал бүрекне! — дип кычкырды теге. — Әни синә киемемне кигезергә кушмый, пычрата, ди.

Газзә бүрекне кире урынына элде, әмма телен тыеп кала алмады:

— Син кими башлагач, барыбер миңа була ул, — диде. — Анаң миңа бирә. Ул үзенең иске күлмәкләрен дә миңа кигерә әле.

Рәйсә аның бу сүзләрен әнисенә җиткергән, ишеткәненчә генә түгел, үзенчә үзгәртеп әйткән: «Анаң үзеннән калган иске-москыны миңа кигезә дип әйтте Газзә», дигән. Хуҗа хатын бу сүзләрне ифрат авырга алды. Куян бүрек кызының башыннан төшкәч, теләнеп кергән чегән хатынына шуны биреп, асрау кызның күз алдында кәрт ачтырды.

Бу вакыйга Газзә өчен ачы сабак булды, ул, хуҗаларга ошамаслык сүзне әйтергә тел күтәрү ярамый икән, дип күңеленә бик нык киртләп куйды.

Шулай җиде ел яшәде Газзә асраулыкта. Орчык хәтле үсмер баладан бит очлары янып торган түгәрәк йөзле, очкын чәчрәтеп торган кара күзле, җыйнак гәүдәле, житез хәрәкәтле, өлгер кыз булып житеште. Күрше-күләннән, асрау кыз Клавадан ул комсомол турында, ярлы балалары өчен мәктәпләр ачылу турында, асрауларга да ниндидер хокуклар бирелү турында ишетеп белә һәм, канат ярып килгән кош баласы шикелле, киң дөньяга очарга талпына иде. Ләкин кайсы тарафка китәргә? Кая барып сыенырга? Бары тик шул сорауларга җавап булмаганга гына ул тыелып яши иде.

Салкын кырау төшкән көзге томанлы бер иртәне мунча иДәнен юып чыгып килгән Газзә, капкадан кергән бер яшь егетне күреп туктап калды. Ә егет өй ишегенә таба борылмады, туп-туры Газзәгә таба атлады. Сары чәче эре дулкын булып биек, ак маңгаена бөселеп төшкән, күн тужурка киген, озын буйлы, нечкә билле бу егет күк күзләре белән Газзәгә бик житди һәм туры карады. Якын ук килеп туктады да:

— Исәнмесез, — диде.

— Саумысыз. Хуҗа абзый өйдә әле, кибеткә китеп өлгермәде, — диде Газзә.

— Миңа аларның батрагы кирәк. Синме ул?

— Мин аларда яшим,— диде Газзә.

— Ә мин Борис Серебров, волкомолдан. Батракларның хәле белән танышып йөрим.

Һәм ул шунда ук бик төпченеп сораша да башлады: хуҗалар Газзәгә күпме хезмәт хакы түлиләр? Ничә сәгать эшләтәләр, күпме ял бирелә? Эш киемнәре алалармы?

Газзә бу сорауларга ничек җавап бирергә белми аптырап калды. Нинди хезмәт хакы? Нинди эш киеме? Җитмәсә, кыз өстендәге ямаулы күлмәге белән ялан аягына эләктергән иске киез ката өчен кыенсына, өстәвенә, ят егет белән ялгыз сөйләшеп торганымны хуҗа хатын күрсә, ни әйтер дип курка иде.

Ул озак сөйләшеп тормады, эшем күп дип, кире мунчага кереп китте.

Ләкин егет, ул зарланмады дип, китеп бармаган икән, хуҗалар янына кергән. Газзә, өйгә керүгә, түр яктан аның көр тавышын ишетте:

— Без договорның үтәлешен тикшереп торачакбыз...

Алар хуҗа белән шактый вакыт сөйләштеләр. Аннары Газзәне үзләре янына чакырып керттеләр. Борис Серебров тужурка төймәләрен генә ычкындырган да, терсәкләрен өстәлгә куеп, хуҗага каршы иркенләп утырган иде. Газзә аның үткен күзләренә туры карый алмады, кыек якасыннан бик матур булып чыгып торган, төз, көчле муенына карап кына сөйләште.

— Моннан ары шушы договор буенча эшләрсең, — дип Борис аңа ике бит кәгазь күрсәтте. — Укы, берәр сүзе белән риза булмасаң, турыдан-туры әйт, риза булсаң, кул куй. Договор буенча син көненә тугыз сәгать эшләргә тиеш, хуҗаларың сиңа атна саен ике кием чабата алып бирерләр, абзар тазарту эше пычрак эшкә аерым кием булдырырлар...

Газзә аның сүзләрен юньләп тыңлый да алмады, чөнки хуҗа юан муенын бөгеп, бу эшнең үзенә бер дә ошамаганын сиздереп, аска карап утыра иде. Бары тик ул:

— Куй әйдә, куй кулыңны, хәзер тәртибе шул инде аның, — дигәч кенә, Газзә калтыранган кулы белән «Кәримова» дип яза алды.

— Моннан ары без синең белән элемтәдә торырбыз, комсомол эшенә тартырбыз, укырга ярдәм итәрбез, — дип, аның күңеленә васвәсә салып китте егет.

Тик ул Газзә күңеленә генә түгел, хуҗаларга да шом салып киткән икән. Әйтеп тә торасы юк: теге договор дигән кәгазьдә язылганнары

Газзә егет күздән югалуга ук онытырга тырышты. Кая ул тугыз сәгать эш! Хуҗа хатын савыт-саба юганны асрау кыз карап утырсынмыни? Әллә сыерларны таңнан торып Рабига үзе саусынмы? Мүкләк ала сыер тибеп кенә очыра бит аны, якын да җибәрми! Ул тагын атнага ике кием чабата! Җирдә кар ятмаганда Газзәнең кайчан аягына кигәне бар?! Язгы кырау төшкән иртәләрне зират буеннан ялан аяк көтү куулары әҗәлгә тиң иде, югыйсә. Олыгайгач аякларның бу хәтле сызлавы да шул чакларда суык тигәннән түгел микән?

Кыскасы, договорны юкка исәпләргә бик риза иде Газзә. Әмма договор төзүне хуҗа хатын күтәрә алмады. Асрауга күңел өчен генә булса да җылы сүз әйтүләр бетте, җае туры килгән саен күрше-күләнгә:

— Какмадык, сукмадык, ризыктан аермадык, ни казынып йөри торгандыр ул чукынган керәшен, — дип зарлана торган булды. — Кылган яхшылыгыбызның әҗерен күрәбез хәзер. Мәче баласына ризык биргән саен борынына чирт диләр иде, хак икән. Үги бозау асрасаң, авызыңборының май булыр, үги бала асрасаң, авызың-борының кан булыр...

Боларны сөйләгәндә Рабига асрау кыз ишетәме-юкмы дип тә тормый иде. Ә Газзәнең күңелендә мәкальнең башкасы: «Ятимнең авызы ашка тисә, борыны каный... Теге егет килеп бутап китмәгән булса, мине болай ук какмаслар да иде әле...»

Договорга рәнҗүен Рабига иренә дә сиздерде, ә тегесе:

— Синдә асрау кайгысы! Бөлеп барганыбызны күрмисеңмени! — дип кырт кисте. — Бу чаклы налог түләп, кеше баласын асрау түгел, үзебезнең ашарга да калмас. Сыерларның да берсен сатарга туры килә, мәшәкате кимер... Сүзе дә ишәя бара, ялчы тотасыз, диләр... Үзеңә генә авыр булса, көнлекләп ялларсың...

Тора-бара Газзәнең Борисны тагын бер тапкыр күреп сөйләшәсе килә башлады. Ләкин үзе эзләп барырга кыенсынды. Минзәләдә авыл хуҗалыгы мәктәбе ачылганын ишеткән иде, шунда керергә ниятләде. Рәйсә белән бергәләп алган гыйлемен ул бик зурга саный иде, мәктәпкә керер өчен шул бик җиткән дип уйлый иде...

Саубуллашканда Рабига аның төенчегенә ярты ипи тыкты, учына бер тәңкә акча төртте. Күңеле йомшап, тавышы калтырап куйды:

— Рәнҗеп китмә инде, — диде. — Үзебезнең дә хәлләр мөшкелләнеп бара...

Капка төбенә чыгып озатып калды.

Мәктәпкә керә алмады Газзә — әзерлегең җитәрлек түгел диделәр. Тагын туган авылына кайтты ул. Кайтты, читтә үткән җиде ел гомеренең истәлеге итеп, күңелендә моңлы җыр алып кайтты:

Җиде яшемнән ук мин мескенне
Бала карарга дип алдылар...

## Тамыгыз, тамчылар!

Шикәрләнеп каткан кар өсте, кояш нурларында җемелдәп, күзләрне чагылдыра, коры, салкын һава сулышны сафландыра, тәнгә җиңеллек бирә. Биек күк гөмбәзенең зәңгәрлегендә, һаваның яктылыгында яз сулышы сизелә.

Алар Елтыр Кашапның кибәндә кышлаган солысын сугалар. Ындыр табагы — ишегалды түрендә бозланып каткан такыр урын — чипчиста итеп себерелгән. Шуңа солы көлтәләрен ике рәт итеп башларын бер-берсенә каратып җәяләр дә, бер-бер артлы басып чабагач белән сугып чыгалар. Иң алдан Әхтәм бара, аның артыннан — Газзә, аннары Елак Махас хатыны Монтазима, иң арттан — Газзәләрнең элекке

күрше кызы Маһруй. Алар бер-берсенең җаен алганнар, гармунга кушылган җырчылар шикелле, Әхтәм башлаган көй белән эшлиләр. Газзәнең кулында Вәҗһетдин абзый ясап биргән чабагачы уйнап кына тора, ул эченнән генә кабатлый:

Ары лап-лап, бире лап-лап,
Сөңге саплап, киез каплап.

Такмагына нокта куйгандай итеп, каш астыннан гына Әхтәмгә карап ала. Һәм еш кына, егетнең солы саламы төсле алтынсу керфекләре арасыннан сирпелгән зәңгәр яктылыкны күреп, башына кайнар су коелгандай эсселәнеп китә, кызарынып башын ия.

Көлтәләрне әйләндергәндә кайчак аларның куллары-кулга тиеп китә. Әхтәм бармакларының кайнарлыгы, кызның йөрәгенә барып җитеп, көйдереп алгандай була.

Тибеп сукканда, Әхтәмнең яңа чабатасы көлтәләрне күз иярмәс тизлек белән әйләндереп сала, аның аяк очыннан ефәктәй салам сирпелә, орлык чәчри.

Ары лап-лап, бире лап-лап...

Салам җыйганда алар кара-каршы киләләр, икесе бер лачинканы[1] күтәрәләр. Газзә егетнең буйлы ак күлмәк аркылы көчен сиздереп торган нык җилкәләренә, артка шудырган кара кәләпүше астыннан бигрәк ак, нәфис булып күренгән муенына сокланып атлый. Аның көенә басып, ун-унбиш адымдагы салам эскертенә хәтле бару Газзә өчен җан рәхәте.

Дөнья иркен, саф, күңел каядыр талпына, киләчәк көннәрнең җиргә ташу суларын, сандугачлар җырын, шомырт чәчәкләрен алып киләсе бәхәссез булган шикелле, алар Газзәгә дә сөенечләр генә китерер сыман тоела. Ул бөтен кешегә — язны сизүдән сипкелләре тагын ныграк чекерәешкән Маһруйга да, һәрчак борчулы, вакытсыз сулган Монтазимага да — елмаеп карый — яратуы, сөенече, ашкынуы аларга да җитә.

Газзә үзен читлектән ирекко чыккан кош кебек бәхетле саный. Туган авылында күп нәрсә сагынылган, таныш, шул ук вакытта яңа да. Менә ни өчен аның күңелендә өзлексез җыр яңгырый, шуңа күрә арганын тоймый, көн үткәнен сизми ул. Менә инде алар соңгы җәймәне җәяләр, әнә Кашап хатыны Мәгъсүмә аларны ашарга чакыра.

Яшел капка җиңел генә ачыла, кара айгыр җиккән җиңел чанада хуҗа белән аның улы Салихҗан кайтып керәләр. Хуҗа, ындыр табагы янына килеп, «бетерәсезме, әйбәт булган», дип өенә кереп китә, Салый ат тугара.

Гадәттә, эшкә кеше чакырганда, хуҗа да, малае да башкалар белән бергәләп эшли торганнар иде. Бүген исә иртәдән ат җигеп каядыр чыгып киттеләр. Шулай итүләре әйбәт булды: хуҗалар булмаганда эшләү рәхәтрәк, иркенрәк. Бигрәк тә Салый юкта...

Газзә белән Әхтәмнән ике яшькә өлкәнрәк Салый тәмам егет булып житешкән, аның калын иренө өстендә мыегы каралып тора, алгарак чыгып торган иягендә дә кара бөртекләр тырпаешкан. Тар маңгае өстенә бүселеп чыккан, ат ялы кебек каты, туры чәчләре астыннан түгәрәк күзләре «сезнең ишеләрне күп күргән» дигән сыман, эре, тәкәббер карыйлар. Эшкә җен шикелле нык Салый, гөнаһсына кереп булмый, бергә эшләгәндә башкаларга да сулу алырга да ирек бирми.

Менә ул айгырны тугарып, лапаска алып кереп китте, сугучылар җәен, бер кат сугып чыкканчы, эшен бетереп тә куйды.

Үкчәсенә кара күн сапкан ак фетр итекләре белән каты карга арысландай йомшак басып, күн тышлы бишмәтен уң як иңенә генә салган

[1] Лачинка — носилка.

килеш, ындыр табагы янына килде. Ул якынлашкан саен, күнлекчеләрнең йөзләре сүрелә, җилкәләре иңә барды.

— Ничек соң, күрше, алма ашап үсеп буламы?

Бу сорауны Салый Кыям кызы Маһруйга бирде. Ә Маһруй кызарынып: «Нинди алма инде бу вакытта», — ди, ә үзе артка, биек итеп өелгән кар көртенә таба чигенә. Бичара! Фәкыйрь кеше баласы да түгел бит үзе, бүген, бетерәсе эшебез бар, ирләр өйдә юк, ярдәмләшергә генә кер инде дип, Мәгъсүмә чакырганга гына кергән иде.

Маһруйның бит очлары сипкелләре чәчрәп коелырлык булып кызышкан, ул курка, чөнки Салыйның бер яман гадәтен бик яхшы белә — мыекларын тырпайткан бу егет кызларны авырттырып чеметмичә яннарыннан уза алмый. Ә бармаклары каты, келәшчә шикелле!

Монтазима, кызның хәлен аңлап, Салыйның ак итегенә себеркесе белән китереп бәрде:

— Кая, Салихҗан үскәнем, бетереп алыйк инде. Анаң да ашарга чакыра, суына, ди. Маһруй, син дә катып торма, суык тимәсен!

Салый өенә кереп киткәч, барысы да җиңел сулап куялар.

— Иянәнде шөпшә көнбагыш чәчкәсенә, — ди Монтазима әллә гаепләп, әллә хуплап. — Салыйны кулга төшергән кызның бәхете баштин ашачак инде анысы, — дип өсти үзе. — Безнең кебек нужа чигеп яшәмәячәк, балда-майда гына йөзәчәк.

Таза, нык гәүдәле, түгәрәк битле, алтынсу-җирән чәчле Маһруй чыннан да көнбагыш чәчкәсенә охшаган иде. «Сыер теле» дип аталган үлән суына манган сары күлмәге бу охшашлыкны тагын да көчәйтә шикелле.

Кашап хатыны табынны ике якка әзерләгән иде: ирләргә — түр якта, хатыннарга—алгы якта. Җылыга кергәч, борынга тәмле ит исе килеп бәрелде, тәндә рәхәт талчыкканлык сизелде, карын ачканы сизелде.

Киндер ашъяулыкта ипи телемнәре, тәлинкә белән тоз, бер җамаяк катык тора. Агач табактан бу чыгарып, куе токмачлы аш та шунда утырды. Кашыклар алгач, бисмилла әйтеп, табакка үрелгәннәр генә иде, өйалдыннан тамак кырган, бала елаган тавыш ишетелде. Гаҗәпләнүдән түгел, итәгать саклап, кашыкларын кире куйдылар: кем килгәнен барысы да алдан ук белеп тора иде инде. Алай да көл төсле, чуалчык очлы сакаллы, бәләкәй чырайлы ябык агайны күргәч, борын астыннан гына көлемсерәп куйдылар: Елак Махас өмә ашыннан каламы соң, бигрәк тә ул аш Елтыр Кашапларда булганда!

— Акыра гына, һич тыяр әмәл юк,— диде Махас, сәләмәгә төрелгән баланы Монтазимага сузып. Аның тавышы нечкә, ә күзләре хәтта хатынына да туры гына карамый, ничектер чет-чет йомылып, йөгереп тора иде.

— Урам буйлап бала акыртып йөрмәсәң! — диде Монтазима. Әйтерсең ул иренең ник килгәнен белми иде.— Килешмәгәнне! Гарифны гына җибәрәсең калган!

— Тотарсың Гарифның койрыгын! — диде Махас. — Бар булган чабаталарны әләктереп чыгып качканнар, эт белән эзләсәң дә табарлык түгел. Өйдәгеләре ялан аяк, ялан өс калган. Ишле бала шул инде, хәсрәтне генә арттыра, бөлгенлеккә генә китерә.

Түр өйдән хуҗаның көр, калын тавышы ишетелде:

— Әйдә, кордаш, әйдә, бик мактап йөрисең икән, түрдән уз!

Авылның башка юньлерәк кешеләре дә, юк сәбәпне бар итеп, кирәккирәкмәскә Елтыр Кашапның ишеген ачарга, ай-һай, кыяр иде микән! Андыйны Кашап үзе дә хуш килдең дип, түргә чакырып тормас иде!

Әмма нәкъ менә шушы булдыксызлыгы һәм тормыштан туктаусыз зарлануы белән авылда дан тоткан фәкыйрь Махас бу өйдә үзен шактый иркен тота иде. Яз җитсә әҗәткә чәчүлек орлыкны да шушыннан ала, ат, сабан сорап та Кашапка бара. Ә эшкә хатынны йөртә, чөнки

үзе гражданнар сугышында яраланып, эчен имгәтеп кайткан. Соңыннан Мәгъсүмә: «И, балалы хатынның эше ташка үлчим инде аның, үзләренә бер яхшылык булсын өчен генә чакырабыз», — дип артларыннан авыл буйлап сөйләп йөри. Монтазима көнлектә чакта алар ирле-хатынлы икәүләшеп тамакларын үткәреп кайталар, шуның өстенә Мәгъсүмә биреп җибәргән төендә балаларга кыты-мытысы, иске-москысы да була.



Монтазима белән Махас моны Елтырларның бик зур яхшылыгы дип саныйлар, шул ук вакытта бу игелеккә үзләренең хокуклары бар дип тә исәплиләр иде. Чөнки Махас, сүз җае чыкса-чыкмаса, без, Кашап белән бергә, кызылларның фәлән отрядендә акларга каршы сугыштык дип мактанырга ярата.

Бу юлы да түр яктан гел аның нечкә тавышы гына ишетелеп торды:

— Исендәме, Кашафетдин, Киръәфкә дигән стансада безне тривога белән күтәрделәр...

Ул «тревога» ише башкаларга аңлаешсыз сүзләрне аеруча басым ясап, үзенчә тырылдатып әйтә. Ләкин Газзә аны тыңламый, шау-шу арасыннан Әхтәм тавышын гына аерып алырга тырыша. Ә егет, үч иткәндәй, сүзгә катнашмый, хәтта көлешкән чакта да аның тавышы аерылып тормый. Газзә әле кузгалышкач ишектән бергә чыгып булмасмы, Әхтәм югары очка, үзе түбән очка борылып киткәнче, урта юлга чаклы бергә барып булмасмы, дип өметләнеп утыра.

Әмма кызның ул теләге тормышка ашмады. Өйалдында тагын шыгырдау ишетелде, кызарган битле үсмер малай — Махасның олы улы Гариф килеп керде дә сәлам дә биреп тормыйча гына:

— Каравыл өенә ике кеше килгән, анда Кашап абзыйны чакырырга куштылар, — диде. Газзәне күреп: — Батракларны да сорадылар,— дип өстәде.

Кашап — авыл советы председателе, Газзә — Имәнледә бердәнбер батрак кыз, килгән бер вәкил аны күрмичә, аңа киңәшләрен бирмичә китми иде. Шуңа күрә бу хәбәр берәүне дә гаҗәпләндермәде. Бары тик Газзә генә эченнән: «Соңрак килсәләр дә ярар иде», — дип уйлап куйды.

Болай булгач аңа ирләрнең табыннан кузгалганын көтеп тору кирәкмәс иде, шуның өстенә Кашап белән урам буйлап янәшә барасы да килми иде. Гарифны хатыннар табынына ашарга утырттылар, Маһруй белән Монтазима хуҗа хатынга ярдәм итә калды, Газзә берүзе киенеп чыгып китте. Ямансу иде аңа. Ләкин аңа вәкил дигән кеше белән наданлыкны бетерү, налог җыю, газит тарату хакында сөйләшеп утырырга каравыл өенә барырга кирәк иде.

Әгәр дә вәкилнең кем икәнен белгән булса, ул авыл советына ике кулын канат итеп очып барган булыр иде. Газзә аны бусагадан атлауга таныды. Шул ук озынча, җитди йөз, шул ук үткен караш, шул ук озын итеп җибәрелгән чәч, хәтта бөдрә бәрән тиресеннән тегелгән очлы бүреге дә шул ук.

— Мөгаллим абый! Исәнме, мөгаллим абый!

Зиннур Гомәров бөтен гәүдәсе белән борылып аңа карады, күзләрендә гаҗәпләнү чагылды.

— Мин бу, мөгаллим абый, Асылкәрим кызы Газзә.

— Газзә! Син шундый булдыңмыни инде? Ничек син монда? Сезне Украинага җибәргәннәр иде бит!

— Китмәдем мин, мөгаллим абый, калдым мин...

Газзәнең, мөгаллим абыйсы кулына битен куеп, ничек приют арбасыннан төшеп калганын, Биекъярга баргач урамнарда мөгаллим абыйсы очрамасмы дип ничек өметләнеп йөргәннәрен сөйлисе килә иде.

Әмма сүзләр бөтенесе берьюлы тамакка төер булып утырган, назлануларны оныткан күңел тиз генә чишелеп китә алмый, өстәвенә түр-

дә озын буйлы, сары чәче биек маңгаена дулкын булып төшкән яшь кенә егет тураеп баскан да күзләрен Газзәдән алмый текәлеп карап тора.

— Ә мин сезне беләм бит, — диде егет кинәт бик ачык елмаеп. — Сез Ханбиковларның асрау кызы. Ә мин волкомолдан Серебров. Хәтерлисезме?

Газзә мөгаллим белән очрашудан бик нык дулкынланганга күрә генә егеткә игътибар итмәгән дә иде. Таныды, ник танымасын.

— Теге чакта ник качтыгыз? — диде Серебров Газзәгә. — Мин тагын килсәм, сез юк, китеп баргансыз...

— Качмадым мин... Син... Сез үзегез килмәдегез бит. Авылга кайттым менә.

— Их, син, — диде Серебров, аңа үпкәсен белдереп. — Инде мин бара алмаганмын икән, үзең комитетка килергә иде. Без укырга керергә дә ярдәм иткән булыр идек.

— Ә мин сине укыгансыңдыр дигән идем, — диде мөгаллим дә.

— Син җибәргән китапны яттан өйрәндем мин, мөгаллим абый, «Шүрәле»не дә, «Кисекбаш»ны да, кыска шигырьләрне дә...

Аларның сүзен шунда бүлеп, тамак кыргалап, ышанычлы басып, председатель Кашап килеп керде. Аны күрүгә Зиннур Гомәров кырысланып, агарынып китте. Шунда гына Газзә мөгаллим абыйсының шактый олыгайганын күреп алды. Сигез ел гомер аның өчен дә эзсез үтмәгән: маңгаен биегәйтеп аңа өч рәт тирән буразна салган, чәчен сирәгәйтеп аңа көл сипкәндәй иткән, яңагындагы сырларын тирәнәйткән, хәтта буйга да бераз кечерәйткән кебек. Элек Газзә аңа башын артка ташлап, үрелеп карый иде...

Елтыр Кашап, кунакларының төкселегән сизмәгәндәй, ике куллап күреште, юл хәлләрен сорашты. «Башта безгә төшәсегез калган, бераз тамак ялгап, хәл алган булыр идегез», — диде.

Кашап белән Салый кыяфәтләре белән нәкъ бертөрле иделәр. Андыйлар турында, суйган да капланган инде менә! диләр. Тик Кашапның сакалы бар да, гәүдәсе юанрак, таушалганрак. Ләкин холык-фигыль ягына килгәндә, алар җир белән күк шикелле иде. Кашапның йөзендә ягымлылык балкый, тавышы йомшак, сөйләгәндә теленнән бал тама. Шул ук вакытта ул үзенең могтәбәр кеше икәнен бер генә минутка да онытмый.

Ул такта өстәл уртасындагы җиделе лампаның филтәсен калкытыбрак куйды, аннары почмактагы сандыкны ачып, калын дәфтәр алды да заданиеләрнең үтәлешен сөйли башлады. Дәфтәрнең бите саен, сука белән ермачлагандай эре-калын итеп шәмәхә карандаш белән исемнәр, саннар язылган иде. Шулай булмый хәле юк, ул елларны икмәкне генә түгел, маен-тиресен, йомыркасын, сөсен-печәнен дә бөртекләп аерым хуҗалыклардан җыярга туры килә иде бит.

— Авылда җитмеш тугыз хуҗалык безнең, — дип сөйләп китте Кашап гадәтенчә салмак кына. — Заданҗәләрне гадел итеп салырга тырышылды. Билгеле инде, кызыл сугышчы һәм присидәтел буларак, үзем үрнәк күрсәтергә тиеш дип санадым. Әз дә түгел, күп тә түгел, сиксән пот икмәк тапшырам дип торам. Бер үземнең хуҗалыктан гына бу. Аллага шөкер, сәвит алдында йөзем ак, сүземдә тордым. Әле менә бүген генә унбиш потны тагын тапшырып кайттык. Булганны кызганып тору юк. Бүтәннәр дә карышмый. Әнә, Газзә ялганларга ирек бирмәс. Җыелышларын да вакытында җыябыз, һәр яңалыкны халыкка җиткереп торабыз...

Кашапның сүзләре кара сакалы арасындагы кызыл иреннәреннән чишмәдәй шома, тоткарлыксыз агып тора иде. Тик нигәдер Серебровның карашы боз шикелле салкыная бара да, Гомәровның туры кашлары торган саен ныграк җыерыла. «Ни ошамый аларга?» — дип аптырый Газзә. Кашап дөресен сөйли иде. Җыелышлар чыннан да узып

тора, заданиеләр үтәлә, хөкүмәткә каршы сүз әйтүче юк. Әйтеп кара? «Сәвит влачы дигәч тә ул сезнең бертуган абзагыз түгел, — дип Кашап җыелыш саен кисәтеп тора. Андый чакларда председательнең тавышы үткен кылыч шикелле зыңгылдап куя. — Хөкүмәт хөкүмәт инде ул. Карыша башласаң, рәхим-шәфкать көтмә». Аның сүзен баш иеп тыңлый халык. Абруе зур чөнки. Ник дисәң аңа бурычы булмаган, аңа баш иеп ни дә булса сорап килмәгән кеше авылда, мөгаен, юктыр...

Наданлыкны бетерү мәсьәләсендә дә сүзе әзер председательнең:

— Олыстан килгән мөгаллимәбездән ифрат уңдык, гаҗәп тырыш булып чыкты, — ди ул. — Үзенә ярдәмгә яшьләрне дә тарта белә. Әнә Газзә дә ничәдер катынга хәреф танытып йөри...

Бу урында Газзәнең мөгаллимә хакында бер-ике сүз әйтәсе килә килүен. Каладан килгән ул мөгаллимә борынны бик югары тота, авыл халкын санлыйсы килми, бары тик остабикә белән генә серләре килешә, дип сөйлиләр. Мәктәбендә дә, парта өстендә дөньяви китап ята, ә аста корьән дә һәфтияк дигән сүзләр йөри. Кеше-кара күрмәгәндә балаларга дин сабагы укыта, диләр. Ә Газзә хатыннарны мөгаллимә кушканга түгел, волостьтан килгән вәкилләр кушканга күрә укыта. «Кашап абзый боларны белми торгандыр», — дип уйлый Газзә. Тик олылар сүзен бүләргә кыймый, тыелып кала.

Ә Гомәров белән Серебров сорау артыннан сорау яудыралар:

— Коллективлашуга әзерлек ничек бара? Актив күпме? Комсомолга керергә теләүчеләр бармы?

Кашапның җавабы барсына да әзер:

— Калхуз дигәннән, уйлана бит әле халык... Аркылысын-буен үлчи. Ат сорый күбесе, сәвит безгә ат бирсен башта, ди. Актиф бар анысы. Әнә Махас Сираҗиев бик ярдәмчел. Фәкыйрь адәм. Минем белән бергә кызыл отрядта сугышып йөргәндә имгәнгән кеше. Кыям Мөхәммәдиев тә җәмәгать эше дигәндә аһ итеп тора. Ә камсамулга керәм дигән кеше күренми сыман әле. Грамытлары җитеп бетми, авыл балалары бит...

— Моңарчы сез волостьтан ераграк булдыгыз шул, — ди Гомәров коры гына.— Кайбер эшкә кул җитеп бетмәде. Хәзер үзәк сезгә якыная. Биекъярда яңа район оеша.

Кашап кунакларны үзләренә алып китмәкче иде, Гомәров:

— Монда килгән-киткән күп булыр, барын да кунак итеп бетерә алмассыз, — диде. — Менә Газзә бер фатир табып бирер әле.

Тышта ай тагын да биегрәк күтәрелгән, йортлардан, агачлардан зәңгәрсу кар өстенә карасу күләгәләр төшкән иде. Юлдашлары калтыранып куйса да, Газзәнең үзенә көн җылынып киткән сыман тоелды. Саф, салкын, тыныч һавада кайнар агым булып, югары очтан дәртле-моңлы гармун тавышы агыла.

— Бу суыкта кем шулай күңел ачып йөри икән? — диде Борис.

— Әхтәм... Туңмый ул. Мунчаларында уйный торгандыр әле.

— Теге миндә укыган гармунчы малаймы әллә? — дип сорады Гомәров.

— Шул инде. Башка кем булсын.

— Ул да синең кебек зур булып үстеме инде?

— Егет кеше Газзә хәтле генә булмас инде, — диде Серебров көлеп. Гармун моңы югары очка чакыра иде, ә Газзә көрсенеп түбән очка борылды.

— Үз өеңдә яшисеңме? — дип сорады Гомәров.

— Юк, мөгаллим абый. Ачлык елны безнең нигез таралып бетте, ташлары гына тырпаеп калды. Вәҗһетдин абзыйларда торам. Балачагалары юк, күңелләре иркен. «Бары уртак булыр, югын сорамассың», — диделәр.

— Алай да барыбызга берьюлы барып керү килешмәс, — диде Борис шикләнә төшеп. — Алдан кисәтеп куйган кешеләр түгел бит.

— Сыйдыралар алар, — диде Газзә һәм хуҗалары турында бер мәзәк тә сөйләп алды.

Вәҗһетдин белән Фагыйлә егерменче елда өйләнешкән булганнар, егерме беренче елда читкә чыгып киткәннәр, өч елдан кире әйләнеп кайтуларына икесенең дә таралган нигезләре генә калган булган. Алар хәзер кечкенә генә өй җиткереп кергәннәр, чабата ясап, киндер сугып көн итәләр. Кулларыннан эш төшми, ә мантыган җирләре юк. Баемауларын Фагыйлә үзе күңелләре йомшаклыктан күрә. Вәҗһетдин акчасы юкка чабатаны ярты бәясенә дә биреп җибәрә, Фагыйлә ярлы кызына бирнәне арзанга да әзерләшә. Суык көннәрдә Махас малайларының урамда ялан аяк йөргәнен күрсә, Вәҗһетдиннең кайнар йөрәге түзми, ул сатарга дип әзерләп куйган чабатасын аларга кигезеп чыгара.

«Кайнар» дигән кушаматы да шул Махас малайлары аркасында тагылган. Алар Вәҗи ихатасында хуҗа булып йөриләр. Бер заман көз көне, үзләре юк чакта, ындырларыннан бәрәңге йолкып учакта пешереп ашамакчы булганнар. Өйнең җиргә тиеп торган салам түбәсенә гөлт итеп ут капкан. Ярый әле, Вәҗинең кайтып килгән чагы икән. Тирә-күрше «Ут бар! Янабыз!» дип йөгерешеп килсәләр, ни күрсеннәр: Вәҗһетдин өй түбәсенең саламын ике селтәнүдә сыдырып төшергән дә, үзе түшәм өстендә басып тора, ди. Кызарынган, бүртенгән, ди, көл-корымга буялып беткән, ди, куе җирән сакалына салам ябышкан, ди.

— Гаеп итмәгез инде, җәмәгать, — дип әйтә ди үзе. — Сезгә бер кызыгы да калмады. Ярлының янгыны шуннан артмас инде, — дип әйтә, ди. Кайнар Вәҗи дигән кушаматы шуннан калган, имеш.

Кунаклар бу кушаматның Вәҗигә ифрат килешеп торганын бик тиз аңладылар. Алар килеп керүгә, хуҗа өй тутырып торган киндер сугу станогын ишек катынарак шудырып куйды, мич буендагы эскәмияне сәке йөзлеге янына алып килде.

— Кая самаварыгыз! Мыштырдыйлар гына! — дип, Фагыйлә белән Газзәне утка бастырды.

Ә чәй табынында, кызыл әтәч кебек кабарынып, кунаклар өстенә очып-очып кунды:

— Бу нинди заман, ә? — диде. — Елтыр Кашаплар заманы бу, халык влачы заманы түгел. Ачлык елны да алар байый, тыныч елны да. Менә без, бу йортта яшәүче ачлык елны ятим калган, бөлеп калган өч ятим көне-төне эшләп тә мантый алмыйбыз. Һаман Елтырларга ишелеп килә мал!

— Кем баета соң аларны? — дип сорады Гомәров.

— Үзләре байый алар, бездән сорап тормый. Сорарлар, сорамаган кая! Көч алар ягында, влач үз кулларында!

— Властьны кем биргән соң аларга? Шул ук Кашапны председатель итеп кем сайлады?

— Мин түгел инде, минем гомердә дә ул канечкеч яклы булганым юк!

— Нигә соң җыелышта чыгып үз сүзеңне әйтмәдең?

— Мин ул җыелышта булмадым шул, — диде Вәҗи бераз сүрелеп. — Биекъяр базарына чабата сатарга киткән идем.

— Авылның язмышы хәл ителгәндә чабата сатып йөрмиләр аны.

— Авылны уч төбендә биетә ул, беләсегез килсә. Кемдә байлык, шунда көч.

— Андый заманнар узды инде. Совет власте ни дигән сүз соң ул, беләсезме? Сезнең власть дигән сүз ул. Синең власть, Газзә власте, бөтен халыкныкы.

Газзә власте! Бу сүзләрне ишеткәч, кыз кызарынып чыкты. Сүзгә әллә ни катнашмаган Серебров та, чәч дулкыны астыннан елмаеп,

«ишеттеңме абзаңның сүзен» дигәндәй, ишарә ясап, үз итеп карап куйды.

Газзә самавар артында чәй ясап утыра, өлкәннәрнең сүзенә катнашмый, әмма һәр сүзне күңеленә сеңдереп бара иде. Аңа калса, Вәҗһетдин абзый артыгын кыза, Кашапны юкка тирги иде кебек. Ни дисәң дә Газзә шуларда эшләп тамак туйдыра. Әхтәм дә... Их, тагын шулай ялласыннар иде дә, тагын бергә эшлисе иде... Аннан да бигрәк, җаен туры китереп, мөгаллим абый турында, Серебров турында, шушы кичтә ниләр сөйләшеп утырганнары турында Әхтәм белән бер иркенләп сөйләшәсе иде. Шуны өмет итеп бит инде, Әхтәмгә сөйләр өчен, Газзә бар ишеткәннәрен сүзен-сүзгә хәтеренә сеңдереп барырга тырыша...

Иртәгесен Гомәров белән Серебров мәктәптә булдылар, каравыл өенә авыл агайларын җыеп сөйләштеләр. Көндезге чәйне эчкәндә Газзә түземәде, мөгаллимә турында да бер-ике сүз ычкындырды, Елтыр Кашаптан авыл халкының шүрләп торганын да әйтми булдыра алмады.

— Безгә монда үзебезнең таянычны булдырырга кирәк, — диде Гомәров. — Без синең ярдәмеңә ышанабыз, Газзә.

— Ә хәзергә менә комсомол уставын укып таныш, укый беләсең бит, — дип куен кесәсеннән кызыл тышлы кечкенә генә китапчык чыгарып бирде Борис.

Төштән соң Газзә, авыл советы биргән атка утырып, аларны авыл очына кадәр озата барды.

— Инде бу хушлашу озакка бармас, тиздән күрешербез, — диделәр алар киткәндә.

Кайтырга борылгач, кояш нурларыннан Газзәнең күзләре чагылды. Юлдагы ат тизәкләре тирәли кар эреп, уелып төшкән, ә Бармаксыз Һадиларның салам түбәсе кырына очланып каткан бозлардан тамчылар тама иде. Ул тамчыларның бер-икесе Газзәнең керфегенә тамгандай булды...

## Көрәш нинди була ул?

Зәңгәр чәчәк зәңгәр күкне хәтерләтә. Ак дала өстендәге тирән, зәңгәр күкне...

Газзә кар каплаган буш кырны, шул кыр аркылы бормаланып-сыргаланып сузылган ат юлын, шул юлдан ялгыз баручы яшь бер кызны — үзен күз алдына китерде.

Тирләп тә пешмәслек, туңып та төшмәслек кенә итеп, адымнарны бер җайга салып атлый иде ул. Яннан ачы җил иссә дә, Фагыйләттинең йон шәле суыкны бишмәт эченә кертми иде. Ялгызына олы юлдан чана эзеннән, уйлар йомгагын сүтеп бару рәхәт иде Газзәгә. Ә ул көнне очына чыгасы уйлары күп иде аның.

Нәкъ шул көнне аны комсомолга кабул иттеләр. Газзә иркен, биек бүлмәне, өстәл тирәли һәм стена буендагы урындыкларга утырган җитди, хәтта кырыс чырайлы яшь егетләрне, алар арасында кызыл яулыклы бердәнбер кызны кат-кат күз алдыннан үткәрде. Әгәр дә шунда ишеккә каршы, өстәл артында утырган Борис Серебров күз карашы белән генә елмаеп куймаса, Газзә бөтенләй югалып калыр иде, мөгаен. Ә аңа каушарга һич ярамый, күп сорауларга ачык итеп җавап бирергә кирәк иде: атаң-анаң кемнәр? Син социализм өчен көрәшкә әзерме? Бу көрәштә каушап калмассыңмы?

Сорауларга җавап биргәндә Газзә кешеләрдән бигрәк, стенадагы лозунгларга карады. Анда да шул ук сүз: «Көрәш», «Икмәк өчен көрәш — социализм өчен көрәш!», «Барыгыз да бөек төзелешләргә — якты киләчәк өчен көрәшкә!»

— Кем дә кем Газзә Кәримованы комсомол сафында булырга лаеклы дип саный, шулар кул күтәрсен!

Газзә һаман лозунгларга карап торды. Ул берәрсенең каршы күтәрелгән кулын күрүдән курыкты. Серебровның:

— Бертавыштан! — дигән сүзен ишеткәч күнеленә кайнар дулкын тулгандай булды, ул иркен итеп елмайды. Барысы да урыннарыннан кузгалып, елмаешып аның кулын кыстылар. Бу минутта алар Газзәгә бик якын, күптәнге дуслар шикелле кадерле кешеләр булып күренде.

Иң ахырдан кызыл яулыгын туры кашлары өстенә үк төшереп бәйләгән озын буйлы, каратут йөзле кыз килде, елмаеп «нинди иптәш булырсың икән син» дигәндәй сынап карады, Газзәнең кулын егетләрчә каты итеп кысты.

— Менә Гөлзәйнәпне сезгә җибәрәбез, укытучы итеп, — диде Борис кызга ишарәләп.— Ул әле генә укуын тәмамлады. Бергәләшеп эшләрсез.

Белемле, акыллы кыз булырга ошый иде Гөлзәйнәп. Ә Газзәгә бик күп нәрсәдә ярдәм кирәк иде. Әйтик, шул ук көрәш мәсьәләсендә. Газеталар укыганда ул бик аңлашыла: эксплуататорлар — канечкечләр, аларга каршы аяусыз көрәшергә кирәк. Ә менә авылда кемгә каршы көрәшергә? Газзә үзенә таныш бер генә кеше турында да «ул эксплуататор — канечкеч» дип өзеп әйтә алмас иде...

Ханбиковлар?

Ни дисәң дә алар Газзәне бик авыр елларда сыендырдылар бит, җиде ел буена бер казаннан ашап, бер йортта яшәгән кешеләргә Газзә берничек тә ачу саклый алмый иде. Өстәвенә, Сөбхиямал әбекәйнең үгет-нәсихәтләре дә күңелгә бик нык сеңеп калган.

Ел әйләнәсендә ике ялчы тотып, эш өстендә тагын көнлекчеләр дә яллаган, илле-алтмыш дисәтинә җир чәчкән Гыйбадулламы? Ләкин бит аның турында да ялчылары Зәйнетдин белән Баһаветдин бер генә дә яман сүз әйтмиләр! Гыйбадулла ялламаса, алар башка берәүгә ялланыр иделәр. Ничек тә тамак туйдырырга кирәк бит. Рәнҗетми, эшләгәнне күрә, хакын түли, дип сөйлиләр үзләре...

Шул уйларга чумып, аяк астында кар шыгырдаганын да сизми кайтып барган Газзә, колак төбендә диярлек ат пошкырганга сискәнеп читкә тайпылды, тездән карга батып туктап калды.

— Тр-р-р! — диде Елтыр Кашап. — Салихҗан, күчеп утыр әле, Газзәгә урын бир!

Салый, елтыр күзләре белән кызны бер чәнчеп алгандай итте дә, бер талпынуда алга күчеп утырды. Газзә аптырабрак калды: аның Елтырлар чанасына утырып йөргәне юк иде әле. Кашап үзе исә янындагы печәнне йомшартып куйгандай итте:

— Кил, Газзә, утыр, әйдә....

Кара айгыр авызлыгын чәйнәп тора, тояк астыннан кар кантарлары чәчри иде.

— Чабатаң ябышып катты мәллә? — диде Салый көлеп.

— Иплэп кенә сөйләш! — диде аңа этисе. Үзе толып чабуларын жыебрак куйды, аяк очыннан кечкенә палас тартып алды:

— Төренебрәк утыр. Җил.— Бусы Газзәгә әйтелгән иде.

Чыннан да, тик утырганда дала җиле шактый сиздерә икән. Газзә шәл читен битенә тартыбрак куйды. Аның ялгызы уйланып килгәннәре Кашапка килеп тоташты. Чыннан да, Елтырларны кем дип белергә менә? Бер карасаң, кызыл сугышчы, председатель, икенче карасаң, Кайнар Вәҗи кебекләр аны «Елтыр корткыч» дип кенә йөртәләр. Күпләрнең яратып бетермәгәнен Кашап үзе дә белә:

— Йорт-җир рәтле булганга теш кайраучылар күбәйде хәзерге заманда, — дип зарлана. — Агу чәчүчесе күп, тик үз тамагын туйдыручысы гына аз! Аңла инде син шуннан соң бу дөньяны!

Ул арада Газзәнең Биекъярда ни йомыш белән йөргәнен сорашты Кашап, комсомолга кергәнен белгәч:

— Дөрес иткәнсең, бик дөрес, — дип хуплады. — Районда үз кулың бар хәзер, күтәрелергә җаең бар. Бик кирәк ул хәзерге заманда. Камсамул дигәч тә, аннан бер дә куркып торасы түгел. Менә мин дә Салихҗанны камсамулга керергә үгетлим әле. Кызыл сугышчы баласы, аны дүрт куллап алачаклар.

Газзә кузлага кадаклап куйгандай туры утырган Салыйның куна кебек тигез аркасына карап куйды. Юк, ул Салый белән бер оешмада торырга теләмәс иде. Бүген аны комсомолга кабул иткән яшьләр арасында, Борис, Гөлзәйнәп белән янәшә, Елтыр Кашапның мактанчык, үз-үзенә гашыйк малаен күз алдына китерү дә кыен иде.

— Әйе-е-е, — дип сүзен дәвам итте Кашап. — Менә без дә бик зур эш бетереп кайтып киләбез бит әле. Ипине тапшырып бетергәнгә дүкәмитләрен алдык. Үзебезгә әзрәк калды калуын. Чәчүгә җитәрме, юкмы. Аның бит әле әҗәткә чәчүлек сорап килүчесе дә булмый калмас. Аларына хөкүмәт ярдәм итәр инде, җирне кысыр калдыруга юк куймас...

Аның Газзә белән сөйләшәсе килә иде шикелле. Ләкин кыз дәшмәгәч сүзне озайтмады, толып якасын күтәреп тынып калды. Кара айгыр бик үрчемле юырта иде, кояш кызарынып дала читенә төшеп җитүгә, алар авылга кайтып керделәр.

Салый, шома саплы каеш чыбыркысын уйнатып, атны хәтәр куа башлады, ата казын күтәреп кайтып килгән Сөбхиямал әбине бәреп ега язды. Коты очкан әбекәй, юл читендә карга батып, әстәгъфируллаһсын укып калды, Салый аңа: «Атлыга юл бир!» — дип кенә кычкырып узды.

Газзә, рәхмәт әйтеп, чанадан төшеп калмакчы иде, Кашап аны туктатты:

— Безгә керик әле, — диде. Ничектер бик мөһим сүзе бар кебек итеп әйтте ул. Каршы як капкасыннан чыккан Маһруй, юлыннан туктап, аларга сәерсенеп карап калды.

Өсләрен салып, кулларын югач, Кашап Газзәне түр якка чакырды. Ачык ишектән Мәгъсүмәнең мич буенда кайнашканы, ашык-пошык токмач кискәне, суган тураганы күренеп тора иде. Кеше эшләгәнне карап утырырга күнекмәгән Газзә аңа булышырга әллә ничә талпынды, Кашап сүз кушкалап аны туктатып торды.

Ашны, аннан соң ит белән бәрәңгене, дүртәү бер табынга утырып, сүз куертмый гына ашадылар. Тулы гәүдәле Мәгъсүмә ике өй арасында җил-җил йөреп, савытларны тиз-тиз генә җыеп алды да табынга бер җамаяк чөгендерле катык китереп куйды. Кашап кара төк үскән юан бармакларын тезендәге тастымалга сөртте һәм бик зур сүз башларга җыенгандай, тамагын кыргалап алды. Ләкин сораганы бик гади булды:

— Сиңа ничә яшь инде, Газизә?

— Унсигезенче китте, Кашафетдин абзый.

— Безнең Салихҗаннан ике генә яшькә кече икәнсең.

Ул Газзәне, үлчәгәндәй, баштанаяк күздән кичерде.

— Күрер күзгә яшьрәк күренәсең күренүен. — Салый белән чагыштырганда, Газзә үсмер кыз кебек кенә иде, әлбәттә. — Ятимлек үстерми шул ул, мантытмый, — дип дәвам итте Кашап. — Атаң-анаң бәдәнле кешеләр иде, югыйсә, урыннары җәннәттә булсын. Үтә гомер, дөнья куып, балаларның үсеп җиткәнен дә сизми калабыз. Мәрхүм Асылкәрим исән булса, сөенеп туймасие. Дөнья бәһасе кешене, асыл җанлы күршеие. Гомер буе тату яшәдек...

Асылкәрим гаиләсе белән ярдәмләшеп, киңәш-табыш итешеп яшәгән чакларын искә алырга тотынды Кашап.

Газзә үзе Елтырлар белән бик керешеп йөргәннәрен ничектер хәтерләми иде. Әмма ата-анасын мактап сөйләгән сүзләрне тыңлау күңелле иде. Ул этисен күз алдына китерергә тырышып карады. Ләкин томанлы гына хәтерли алды. Төсе-кыяфәте аермачык булып хәтердә калмаган, бары тик ул исән чакта булган балаларча ваемсызлык, үз-үзеңә ышаныч, үз дәрәҗәң үсүдән туган бер рәхәтлек кенә истә. Менә аның этисе олаудан кайтып төшә, ишектән бөркелеп кергән ак томанда ниндидер тылсымчы шикелле пәйда була иде. Бала-чага сикерешеп сәкедән коела: эти кайтты, эти кайтты! Этиләре өстен дә салып тормый, киндер капчыгын чишеп «куян күчтәнәче» өләшә. «Куян калачы» — этиләренең юлда ашарга дип өйдән үк алып чыгып киткән ипие — телеңне йотарлык тәмле, ә өйдә бәйрәм!

— Ятимлек газабын күп чиктең, кеше өстендә йөреп күп интектең...

Кашапның кара сакал-мыегы арасыннан судай аккан сүзләре Газзәнең аңына көчкә барып җитте.

— ... Инде алдагы көнеңне уйларга кирәк. Атаң-анаң исән булса, моны күптән исәпли башларларие инде...

Газзәнең ике бит очы, унлы лампа куыгына тиеп пешкәндәй, кызышып чыкты. Ул, ярдәм эзләгән кебек, як-ягына каранды, Салыйга күзе төшеп тәмам каушап калды. Салый, кыздан оятсыз карашын алмыйча, нәрсәгәдер ишарәләп елмайды, кызыл телен чыгарып, катыклы кашыгын ялап куйды.

Бу ни дигән сүз тагын? Кашап нәрсәгә юллый да Салый нигә шулай астыртын елмая? Газзә, җаядәй тартылып, бу сорауларның ачыклангакынын, сүзнең дәвамын көтте. Ләкин Кашап «тәкъдир, киләчәк» дипниләрдер сөйләнде дә ашка дога кылырга кулларын күтәрде.

Кая басканын белмичә, Елтырлардан чыгып килгәндә, Газзә урта юлдан узып барган Әхтәмгә тап булды. Көтелмәгән бу очрашудан икесе дә каушап калдылар, караңгы булса да, каушаганнарын икесе дә сизделәр.

— Кая барасың болай? — дип сорады Газзә дулкынланганын сиздермәскә тырышып.

— Хәкимҗан абзый яшь хатын алып кайткан икән. Этигә, ясту намазыннан соң мәҗлес җыеп алам, гармун белән малаеңны алып кил дип әйттергән. Этинең ютәле купты, килә алмый, үземне генә җибәрде менә...

Әхтәм култык астындагы гармунын күрсәтте. Икесенең дә сөйләшәселәре килә иде. Сөйләр сүзләр дә күп, ай-һай, күп иде. Тик ул сүзләр берсе дә юл уңаеннан әйтелә торган түгел, Әхтәмнең дә юлы ашыгыч, өстәвенә, егет белән кызга урам уртасында кара-каршы басып тору, гәрчә кич булса да, килешми дә иде шикелле.

Газзә башта акрын-акрын чигенде, аннары борылып китеп барды. Ул байтак киткәч кенә, Әхтәм баскан җиреннән кузгалды.

Ләкин шушы бер минутлык очрашу да Газзәнең күңелен сафландырып җибәрде. Кашапны да, Салыйны да онытырды.

## Салыйга өйләнергә кирәк

Кич. Каравыл өе. Өстәлдәге сукыр лампа уты сулыш алганнан да тирбәлә, почмаклар караңгы. Эскәмиягә тезелеп утырган, бусагага чүмәшкән биш-алты авыл агае белән бердәнбер хатын-кыз Газзә кечкенә өстәл артында утырган Гомәровның сүзен йотылып тыңлыйлар.

— Крестьяннар комитеты авылда яңа тормышны башлап җибәрүче булачак, ул безнең беренче таянычыбыз. Ул икмәк тапшыруны оештырыр, кемгә күпме задание салуны хәл итәр.

— Нигә, чәчелгән җир чутыннан салынмаячакмыни ул заданиe? — дип әкрен генә сорап куя кемдер.

— Юк, монда, әлбәттә, кемнең нинди мөмкинлеге барын да чамаларга туры килер. Шуннан инде кемнең нинди сыйныф кешесе икәнлеген ачыкларсыз... Ширкәт оештыру эшенә дә җиң сызганып керешергә бик вакыт...

Бусагада бөрешеп утырган батрак Зәйнетдин муенын сузып сорады:

— Ул ширкәте ни нәрсә тагын? Җыен хәерче оешып анда ни генә кырыр икән?

Ширкәткә берләшкән кешеләр җирне бергәләп эшкәртә, аннары уңышны җан башыннан тигезләп бүләчәкләр. бу инде күмәк хуҗалыкка беренче адым булачак, дип, Гомәров сабыр гына аңлаткач, агайлар кыймылдашып алдылар:

— Аны башта бер кеше җиренә барып, аннан икенчесенә авышып сөрергә туры килер микәнни?

— Нәрсә белән сөрербез икән? Бармак белән тырнапмы? Хәерченең аты бармы, сабанымы...

Тагын аңлату: шобага салганда, ширкәт членнарына җирне бергәләп бер тоташтан алырга кирәк булыр. Шуңа күрә мәсьәләне яз җиткәнче хәл итәргә кирәк тә. Аннары ширкәткә фәкыйрьләр генә түгел, теләгән урта хәллеләр дә, атлы кешеләр дә алыныр. Эш коралына килсәк, ике тәрәнле сабанны, ургычны, сепаратны районнан ширкәткә әҗәткә биреп торачаклар.

Газзә мөгаллим абыйсының һәр сүзен күңеленә сеңдереп кенә барды. Димәк, барысы да ныклап уйланган. Җиң сызганып эшкә генә тотынырга кирәк. Моннан ары Газзә кебекләр Елтырларга, Гыйбадулла ишеләргә баш иеп, алар эшен эшләп йөрмәячәкләр, үз җирләрендә нык басып, иркен сулап эшләячәкләр. Димәк. моңарчы газеталарда, китапларда гына укылган яңа тормыш Имәнлегә дә килеп җитә! Моның өчен ару-талуны белмәскә, таулар күчерергә була, ә агайлар әле әнә нәрсәдер уйланып, икеләнеп утыралар түгелме?

— Кашафетдин кордаш ни әйтер бит әле. Аны тыңлап карыйсые, Сәвит башлыгын...

Махасның нечкә, сузынкы тавышы иде бу.

— Тыңларбыз аны да, — диде Гомәров. — Ә хәзергә әйдәгез, комитет эшен ничек юлга салабыз, шуны хәл итик әле. Кемнәр бу эшкә катнаша, кем нәрсә өчен җавап бирәчәк.

Агайлар тагын тынып калды. Газзә түзмәде, яшьлек ашкынуы белән чәчрәп сикереп торды:

— Инде шул хәтле мөмкинлекләр бирелгән икән... байларга бил бөккәнче, үз җирендә рәхәтләнеп эшләмәскә... Бөтен кешегә яхшылап аңлатырга кирәк моны. Минемчә, берәү дә каршы килмәс!

— Сиңа сөйләве асаттыр, — дип мыгырданды Зәйнетдин. — Син авылда чит кеше хөкемендә. Ә монда тагын шул байларга барып егылмагаең. Дөнья куласа!

— Их сез!— диде Газзә чын күңелдән өзгәләнеп. — Безнең өчен эшләнә бит болар! Сез, без кешечә яшәсен өчен! Моның өчен җан да җәл түгел.

— Җәл булмаса, үзең башлап йөреп кара әнә. Балаң-чагаң юк, грамытың җитәрлек,— дип мыгырданды Зәйнетдин.— Безнең койрыклар ябышып каткан инде...

— Эшләрмен дә! Кулымнан ни килсә, шуны башкармый калмам!

Ничектер артык сабырсыз, яшьләрчә кайнар килеп чыкты Газзәнең сүзе. Агайларның да күпчелеге Гомәровның сүзләренә эчтән куаналар иде, тик алар моны тыштан сиздерми, кычкырып хупларга ашыкмый гына утырды. Ләкин алай да Газзәнең шулай ялкынланып сөйләве аларның күңеленә ошады, ахрысы, мыек асларыннан гына елмаешып:

«Эш чыкмаса алыштырырбыз!»— дип уйладылар булса кирәк, алар Газзәне комитетка баш итеп сайладылар. Кулай кеше иде ул — беркемгә бәйле түгел, кирәк чакта районга йөгереп барып кайта ала, укыйяза белә, эшкә омтылып тора — тагын ни кирәк!

Махастан башкалары берсүзсез ширкәткә берләшергә теләк белдерделәр. Ул гына:

— Башта карап карыйм әле, ашыгып ашка пешмәгәем, — диде.

Соңыннан, башкалар саубуллашып чыгып киткәч, Гомәров Газзәгә тын гына карап торды да:

— Башлыйбыз, Газзә, — диде.

— Нәрсәдән башларбыз икән, мөгаллим абый?

— Тамырыннан, Газзә.

— Көчем җитәр микән, мөгаллим абый? Куркыныч та бит...

— Курыкканыңны берәүгә дә сиздермә, Газзә. Белеп тор: хаклык безнең якта. Моннан ары сиңа кешегә ялланып кына тамак туйдырырга туры килмәс, — дип тә өстәде ул. — Паек бирерләр. Аена бер утыз кадак чамасы икмәк, бәлки бераз акча да булыр әле.

— Рәхмәт, мөгаллим абый. Тик минә Кашап абзый белән ничек килешербез микән?

— Авыл советлары үзгәрергә тора әле. Имәнле белән Аксуның икесенә бер булачак. Үзәге — Аксуда. Сиңа башка кеше белән эшләргә туры килер, мөгаен.

«Тамырыннан гына түгел, башыннан да үзгәрә икән дөнья», — дип уйлап куйды Газзә.

Газзә төнен рәтләп йоклый алмады, үз җилкәсенә төшкән эшләрне күзалларга тырышты. Иң элек икмәк заданиеләрен үтәү турындагы язуларны Кашаптан күчереп алырга кирәк иде. Ләкин Кашапның кин, сизгер борыны җилнең каян искәнен бик яхшы чамалый, ул соңгы вакытта халык арасында бик чуалып йөрми, өендә утыра иде. Шуңа күрә Газзә аның өенә кереп сөйләшми булмас дигән карарга килде.

Ләкин Елтырлар капкасын ачып керү аның өчен шактый четерекле нәрсә иде. Хикмәт шунда, теге чакта, Газзәне район юлында чанасына утыртып алып кайтып, түр башына утыртып сыйлап чыгаргач, Елтыр Кашап кызның кызарынып-каушап төшүен үзенчә аңлап калган икән. Берничә көн үтүгә, Махас Монтазимасы Газзәне үзләренә чакырып кертте дә, самавыры янына, каршысына утыртып, сүзне туп-турыдан башлады:

— Салихҗан миңа бик олы йомыш кушты бит әле,— диде. — Газзәгә әйт, туйны озакка сузмабыз, чәчүгә хәтле үткәреп алырбыз, ди. Әллә ни олыдан кубып булмас, заманасы ул түгел, ди. Газзә кешегә серен чишмәсен, әмма дә ләкин үзе әзерләнеп торсын, ди.

Алдына куелган чәен онытып, аптырап утырган Газзә көчкә телгә килеп:

— Ни сөйлисең син, Монтазиматти? Нинди туй?— дия алды.

— Бәлеш, минем алда кыланып утырган була тагын. Салихҗан белән күптән килешеп куйгансыздыр инде!

Газзәнең чырае качты, ахрысы, Монтазима корым сеңеп беткән, мунча кергәч тә агармый торган кулын селтәде:

— Ярар әйдә, анысы минем эш түгел, — диде. — Мин үземә әйткәнне генә җиткерәм. И-и, Газзә, илла да дөрес итәсең инде Салихҗанга чыгып! Әллә нинди заманалар килсә дә Елтырлар сырт белән төшми алар. Әнә Кашафетдин абзый әйтә икән, туй ясыйбыз да, шундук башка чыгарам, ди икән. Асылкәрим нигезенә минә дигән йорт җиткереп бирмәкче, ди!

Ул арада Газзә дә аңына килә башлаган иде инде.

— Минем кияүгә чыгарга уйлаганым да юк әле, — диде ул өзеп,

һичнинди икеләнүгә урын калдырмаска тырышып.— Укыйсым кила минем. Комсомол эше дә бик күп.

— Камсамул да әдәм баласы, аңа да кияүгә чыгуны тыймаслар. Камсамул дип гомер буе җил куып йөри алмассың, барыбер кая да булса ныклап тамырланырга туры килер.

Газзә: «Яратмыйм бит мин ул Салыйны!» — диярга авыз ачкан иде, Монтазима аны тагын бүлдерде:

— И Газзәкәем, ярату дигән нәрсә гөлт итеп кабына да сүнә бит ул, ә тормышның көйсезлеге, нигезнең ныксызлыгы гомер буена бара! Мин тиле дә яшь чагымда җаннарымны фида кылырдай гашыйк булганыем! Хәерче димәдем, чәрексез димәдем, олылар киңәшен тотмадым, ябышып чыктым бит шушы Махаска!

Монтазима чын йөрәктән чыкканын сөйли, ачы тормыш тәҗрибәсен уртаклаша, Газзәгә чын күңелдән яхшылык тели, аны үз хаталарын кабатлаудан кисәтергә омтыла иде. Ул тәбәнәк, кысан өй эчен кулы белән ишарәләп күрсәтте, сәкедә, идәндә чыр-чу килеп яткан ярым-шәрә балаларын күздән кичерде.

— Күр син минем тормышны! Күр үземне! Кыз чагымда мин ул Мәгъсүмә ише генә иемме! Мин бар җирдә аңа борылып караган кеше дә югые. Ә хәзер мин аның янында әби булып күренәм инде.

Юк, Монтазиманың тормышы да, кыяфәте дә кызыктырырлык түгел иде, билгеле.

— Дөнья шулай ул, Газзәкәем. Син әле яшьлегең белән белмисең генә. Әхтәм ишеләргә кызыкма син. Әргән тартып кына дөнья көтеп булмый ул. Киләчәгеңне уйла. Бүген булмаса иртәгә Бармаксыз Һади урын өстенә егылачак та кеше кулына карап ятачак. Аны бияләй хәтле Хәтирәсе ничек карап бетерсен! Бөтенесе килен җилкәсенә төшәргә тиеш. Күрерсең шуннан соң укуыңны! Күрерсең камсамулыңны! Шуларын уйла!

Юк, әллә риза булыйммы соң, дигән уй Газзәнең башына да килмәде, билгеле. Ләкин Монтазима әйткәннәр бик уйландырды аны. Ни өчен мәхәббәт белән кавышкан кешеләр болай интегеп гомер итәләр? Ни нәрсә моңа сәбәп? Әле бер Монтазима гынамы! Әнә, Вәҗи белән Фагыйлә дә яратышып өйләнешкәннәр, аларның да башы нужадан чыкмый. Мәхәббәт гаепләме моңа? Юк, юк... җитмәүчелек гаепле, факыйрьлек. Ә нигә берәүләр ярлы, икенчеләр бай? Аннары байлыгына кызыгып кына Салыйга барган кеше бәхетле булырмы?

— Юк, яратмый өйләнешкән кешеләр барыбер бәхетле була алмый, — диде Газзә үз уйларын очлап. — Җенең сөймәгән кеше белән гомер итсәң, байлыгың да күзгә күренмәс.

— Ярата торгандыр әле, яратмаса сорамасые,— диде Монтазима.— Син дә яратырсың. Бу әле синең яшьлек алгысавың гына. Замана бик болганчык, бер көнне килеп, Кашафетдин абзыйның гомере буе җыйган мал-мөлкәтен сыдырып алып чыгып китәрләр, алла сакласын. Ә син камсамул, районда үз кешеләрең бар, синең өлешкә беркем кул суза алмый. Ике йортка бүлгәч, күп күренми дә ул...

Монтазима сәкедә елап яткан Гайнанын кулына алып, түшен ычкындырды да ялваргандай елмайды, аның яргаланган иреннәре арасыннан сынык теше чагылып китте.

— Мине дә бөтенләй үк буш итмәссез, алла боерса. Әйткән не диярсең, гомер буе миңа рәхмәт укып яшәрсез әле.

Бу минутта аны үз фикереннән тайчандыру һич мөмкин түгел иде. Мәсьәләгә үз язмышын да китереп бәйләгәнгә — ай-һай, яшь чакта ул үзе дә берәр бай кияүне ычкындырмаган иде микән! — ул чамасыз дулкынланган. Газзә аның белән артык сүз үрчетмәде. Ә икенче көнне, Монтазима инде суынгач-сүрелгәч, аны өеннән чакырып чыгарды да капка төбендә:

— Кашап абзыйга өзеп әйт: мин Салыйга чыкмыйм,— диде. — Бу уем гомергә үзгәрмәячәк. Якын арада кияүгә чыгарга ниятем бөтенләй юк әле.

Газзәнең сүзе нык иде, бу юлы Монтазима сүз көрәштереп торуның мәгънәсез икәнен аңлады, бары тик: «Их, ялгышасың!» дигәнне белдереп, башын чайкап кына куйды.

Шуннан соң Елтырлар тынып калдылар: яучы да килмәде, көнлеккә дә чакырмадылар.

Эзсез үтте шикелле бу сөйләшү, әмма шуннан соң Газзә, үзе дә аңламастан, Елтырлар капкасын читтәнрәк урап үтәргә тырыша иде.

Бу хәлләр турында ул, билгеле, мөгаллим абыйсына сөйләп тормады, ничектер вак, четерекле, артык шәхси нәрсә дип санады. Шуңа күрә мәсьәләне үзе генә хәл итәргә булды.

Кояш Коры елга өянкеләренең челтәрләнеп торган, бөреләре бүртә башлаган ботаклары артына кереп чуалгач, койма буендагы кипшенгән сукмактан, Елтырларга таба китте. Көн җылы, кар эреп беткән, тик урам уртасындагы күлләвекләр генә кибеп җитмәгән иде әле.

Яшел капканы ачканда, Газзә бөтен кыюлыгын җыйды. Әмма бер дә юкка курыккан икән, аны күргәч, Елтыр Мәгъсүмәсенең түгәрәк майлы йөзе елмаюдан тагын да киңәеп киткәндәй булды:

— Бигрәк вакытлы килдең, мактап йөрисең икән, самавырым кайнап кына чыккание! Абзыеңнар Биекъярга киткәние, алар юкта өйне юып-җыеп куйыйм дип, утырып ашый да алмадым бүген. Инде менә аш кайнаган арада берәр чынаяк чәй эчеп алыйм дигәнием...

Шундый ачык кылана Мәгъсүмә, теге кодалап йөрү әйтерсең бөтенләй булмаган диярсең. Газзә:

— Миңа Кашап абзый гына кирәк иде, ул кайткач килермен инде,— дип борылып чыгып китмәкче иде, Мәгъсүмә аны кулыннан ук тотып алды.

— Юк, ходай язмаганны! Җибәрәмме соң? Үзебезнең балабыз кебек бит син! Менә абзыеңнар да кайтып җитәр! Караңгыга калмабыз дигәннәрие. Әйдә, сал өстеңне!

Газзә бишмәтен, чабатасын салып түргә узарга да өлгермәде, Мәгъсүмә:

— Ай алла, сөтләрне ачымасын дип кар базына чыгарып куйганыем, чәйгә дә калдырмаганмын. Авырсынма инде, Газзә, бер очтан шунда катык та алып менәрсең,— диде һәм мич буеннан ачкыч алып бирде.

Газзә, аягына ишек янындагы катаны гына эләктереп, ялан өс кар базына чыкты.

Ул савытларын тутырып, чүлмәк авызларын чүпрәк белән бәйләп азапланганда, капка ачылган, ат пошкырган, ир-ат сөйләшкән тавышлар ишетелде. Газзә, бу хәлендә ирләргә күренеп йөрисе килмичә, баз баскычыннан яртылаш күтәрелгән килеш туктап калды, ихтыярсыздан, тегеләрнең нәрсә сөйләшкәнен ишетеп торды.

— Аллага шөкер, бусы соңгысы булыр инде, — диде Кашап. — Махаска да әйтеп куярбыз, бетте, бүтән йөрисе булмас. Монда бик чуалмасын, кайда нәрсә яшергәнне белми торуы хәерле.

— Инде шулай әйбәт хакка җибәргәч, бер хром итек алып кисәм дә буладырые, — диде Салый тавышы. — Кала малайларыныкы шикелләне.

— Кеше төсле генә киенеп йөр әле! Хәерче пачутта хәзерге заманда! Кулыңнан эш килсәе! Шул чыпчык хәтле Асылкәрим кызын кулыңа төшерә алмаган башың белән! Атны кара әнә!

Нәрсәдер сатканнар, нәрсәдер яшергәннәр. Ни икән? Икмәк түгелдер ләбаса! Кашап әллә кайчаннан бирле бит инде, бер бөртек запас калдырмадым, ашарга, чәчәргә җитәрлектән гайресен бөртегенә хәтле элеваторга илттем дип сөйләп йөри. Соң алайса нәрсә сатканнар алар?

Өзек-төтек ишетелгән сүзләрдән моны аңлап булмый иде. Газзә ишегалды тынгач кына баздан чыкты. Тегеләр өйгә яки сарайга кереп киткәндер дигән иде. Ләкин күгәргән богау йозакны бикләп азаплангандa, артында аяк тавышлары ишетте. Савытларын җирдән алып, борылып караса, Салый басып тора.

— Карале, килен төшкән түгелме соң безгә?— диде ул күзләрен майландырып.— Ачкычларны кулга төшергән, хуҗа булып өлгергән, ә миңа әйткән кеше юк әле!

Ул кулын Газзәнең иңенә салып, каты итеп кысты.

— Кагылма!— диде Газзә.

— Син инде яшь килен икәнсең, киявеңә каршы әйтергә тиеш түгел, ярамый алай! Шәригать кушмый!

Өй ягыннан Мәгъсүмәнең:

— Газзә! Йозак ачылмыймы әллә?— дигән тавышы ишетелде.

Салый икенче кулын да Газзәнең иңенә салып, иелә төшеп, үбәргә үрелде.

— Җибәр!— дип кыз тайпылды.

— Кара! Чапаланып маташкан була тагын! Синең ишеләрне генә күрмәгәннәр ди монда!

Газзә ике кулындагы җамаякларны берьюлы селтәп Салыйның битенә бәрде дә ишегалды ягына омтылды. Болдырда басып торган Мәгъсүмәне әйләнеп үтте, өйгә атылып кереп чабатасы белән бишмәтен кулына алды, капкадан чыгып китте. Урамда коймага сырышып, сөт-катык чәчрәгән битен, муенын сөртте, бишмәтен киде, калтыранган бармаклары белән чабата киндерәләрен бәйләде. Аннары башын күтәреп, бик тыныч булырга тырышып, өенә кайтып китте. Әмма Фагыйләтти аны күргәч:

— Ни булды?— дип сорады.

— Юк, ни булсын!

— Чыраеңнан кан качкан!

Газзә дәшмәде. Салыйның яман гадәтләрен электән белгәнгә күрә, тынычланырга, моңа әллә ни әһәмият бирмәскә тырышты. Кашаптан кәгазьләрне кешеләр алдында сорарга кирәк иде, дип уйлады.

Ләкин сер сандыкта ятмый шул, ул серне дөньяга фаш итү берәрсенә кирәк булса — бигрәк тә.

Шул ук көнне авылда гайбәт таралды. Мәгъсүмә кемгәдер сер итеп кенә — бер генә кешегә булмагандыр, билгеле: «Менә безнең Салихҗан белән Асылкәрим Газзәсенең аралары бик якынаеп киткән бит әле, бер-берсен күрми тора алмыйлар, кыз үзе, сәбәп тапкан булып, гел безгә килеп йөри. Бик өтәләнә инде, безгә килен булып төшәсе килә. Тик менә хуҗабыз икеләнебрәк тора әле, нәсел-нәсәпсез кешене алдырасы килми малайга», — дип сөйләгән, имеш.

Иртәгесен Газзә, әле аны-моны белми, ян тәрәзә буенда, Коры елга өянкеләре башында кар-кар килгән каргаларга караштырып, оекбаш бәйләп утыра иде. Ул башта Фагыйләнең тыр да пыр йөрүенә игътибар да бирмәде. Хуҗа хатын бәби көтә. шуңа гел кәефе үзгәреп тора, Газзә моңа күнеккән иде инде. Ләкин Фагыйлә мәче койрыгын ишеккә кысып, тегесе яман тавыш белән чырылдап җибәргәч, Газзә сикереп торды:

— Кая, Фагыйләтти, берәр эш бармы әллә?

— Утыр, утыр, үз эшеңдә бул, — диде Фагыйлә һичкайчан булмаганча төксе итеп. — Бирнә кирәк бит сиңа.

Газзә аны йомшартырга тырышып елмайды:

— Бирнә кайгысы юк әле миндә, Фагыйләтти.

Фагыйлә йомрыланган гәүдәсе белән кинәт аңа борылды да:

— Нәрсә миннән дә яшереп маташкан буласың инде!— диде. Бөтен авылга фаш булган нәрсәне мин генә белми дип уйлыйсыңмы әллә?

Аның түгәрәк мөлаем йөзе ачулы, вак кына кара миңнәре чекерәешеп тора, күзләреннән нәфрәт очкыннары чәчри иде.

— Ни яшерәм ди мин синнән? Ни булган.— Газзә тәмам аптырашта иде.

Фагыйлә ялындырып тормады, Мәгъсүмә тараткан гайбәтне чыгарды да салды. Хатыннар Газзәнең Елтыр чанасына утырып йөргәнен дә, аларның түр башына утырып сыйланганын да, узган кичтә Кашаплар капкасыннан кызарынып-бүртенеп, күлмәкчән, оекчан гына килеп чыкканын да — барын да күреп торганнар, берсен дә онытмаганнар, хәзер бөтенесен бер бауга ишеп, кыз муенына салырлык муенчак ясап куйганнар икән.

Бөтенесен берьюлы әйтте Фагыйлә, рәхмәт аңа, берсен дә яшереп тормады.

— Асылкәрим абзый, мәрхүм, исән булса, бу кыланышларына мәңге риза-бәхил булмас иде,— диде ул сүзен йомгаклап.— Сезнең нигезне корыткан Елтыр бит ул!

Ни кызган булса да Газзәнең йөзе үзгәргәнне сизми калмады Фагыйлә:

— Син нәрсә, әллә шуны да белмисеңме?— диде.— Ачлык елны сезнең бөтен йорт-җирегезне шул сатып алган бит инде. Алты пот алабута онына. Күпме кешенең мал-мөлкәтен шулай бушка җыйды ул канечкеч! Күпме кешене күрәләтә талап баеды!

Бөтен йорт-җирне! Алты пот алабута онына! Газзәнең күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Шул елларны, шул хәлләрне күз алдына китерергә, бу сату-алуны хәтерләргә тырышты. Үзе дә шунда иде бит, белергә тиеш бит! Ләкин агарган йөзле, хәлсез әтисенең ишектән кайтып кергәндә бары тик кулына гына караганы исенә килде. Әгәр аның кулында берәр нәрсә булса — әчкә җылы керә, булмаганда — җаннар өшеп китә. Кашапның аларга кереп йөргәне хәтердә калмаган, кереп тормагандыр, әтисе аның белән читтә сөйләшкәндер. Ничектер шулай капчык күтәреп кайткач, әтисенең: «Баш исән-сау булса, куыш табылыр, җәйгә генә чыгыйк, язга гына барып элгәшик...» — дигән сүзләре хәтергә чалынып калган иде шикелле. Ләкин ач балада аның кайгысымыни, аларның барсының да күзләре казан тирәсендә чуалган, ачлыктан шешенгән, көч-хәл белән хәрәкәтләнүче әниләрендә иде бит!

Алсын иде йорт-җирен дә, тик нигә ул шул хәтле мал өчен, ичмасам, җан сакларлык ризык бирмәгән! Бик тиз бушады бит ул капчык, әтисе тагын буш кул белән кайтып керә торган булды!

«Елтырларның сандыктай ихатасына безнең әти-әниләрнең, минем туганнарымның сөякләре дә кереп киткән икән,— дип уйлады Газзә.— Кая куйды икән ул безнең өй бүрәнәләрен? Без акшарлап хәрефләр язган бүрәнәләрне, кичләрен әнинең күләгәсе төшкәннәрне... Ындыр түрендәге ак мунчаларына куйды микән? Такта түбәле келәтенәме? Әллә өенең берничә ниргәсенә яраганмы?»

— Туктале, Газзә, утыр әле син,— диде Фагыйлә ул арада.— Ай алла, уйламыйчарак әйтеп ташладым бугай. Беләсеңдер дигәнием. Ул елларда барыбызны да шулай рәнҗеттеләр бит инде, бер син генә дә түгел...

Газзәгә өйдә һава җитмәгәндәй тоелды. Ул ишегалдына чыгып китте.

Ул чакта Гөлзәйнәп авылга килгән, көндез балаларга дәрес бирә, кичләрен өлкәннәрне укырга-язарга өйрәтә иде. Буш вакытларында Газзә аннан рус теле дәресләре ала.

Ул көнне Газзә вакыты җиткәнне дә көтеп ала алмады, иңенә шәлен салды да югары очка таба китте. Гайбәт мәктәпкә дә барып җиткән иде инде, моны Газзә бусаганы атлауга сизде.

Башка чакта, ул килеп керүгә, Сөбхиямал әби самаварын кузгата торган иде. Бүген исә Газзәне күрү белән чөйдәге шәленә ябышты да:

— Хәтирәдә йомышым барые,— дип чыгып та китте.
Газзә ишек янындагы эскәмиягә утырды.
Гөлзәйнәпнең калын кара толымнары биек якалы ак кофтасы өстеннән күкрәгенә салынып төшкән. Ул туры кашларын җыерып, кулларын күкрәгенә кушырып, идән уртасында басып тора. Бераз тын гына тордылар шулай. Аннары Гөлзәйнәп Газзәнең алдына, кара таплар төшкән такта өстәлгә, китап китереп салды.
— Укы, укырга килгәнсеңдер ич.
Газзәгә китап битендәге хәрефләр борча кебек сикерешкән сыман тоелды.
«Мы — не рабы, рабы — не мы!» — дип укыды ул.
Газзә русча «е» авазын дөрес кенә итеп әйтә алмый, «и»гә охшатып укый иде.
— Алай түгел, — диде һаман әле аяк өсте торган Гөлзәйнәп. — «Рабыни мы», дисең ич син, «колиһәләр без» дигән сүз килеп чыга. «Рабы — не мы!»—«Коллар без түгел!».
— «Коллар — без түгел!» — дип кабатлады Газзә.— Ә мин синең ник болай ачулы икәнеңне беләм бит, Гөлзәйнәп.
— Шулаймыни?
— Беләм. Сиңа минем хакта начар сүз ишеттергәннәр.
— Шуннан?
— Мин дә бүген бик күп нәрсәне белдем, Гөлзәйнәп. Мин сыйнфый дошманның нинди икәнлеген аңладым.
Газзә, иңенә шәлен салып, аягүрә торып басты. Ул күз алдына Елтыр Кашапның төче елмаюын, Мәгъсүмәнең түгәрәк, майлы чыраен китерде, алар аңа кешенең чын йөзен яшерү өчен кигезелгән битлекләр сыман гына булып тоелды. Бүген ул битлекләр шуып төштеләр. Газзә алдында ерткычларның кан баскан пыяла күзе, аяусыз тешләре күренгәндәй булды. Менә нинди икән алар — «канечкечләр»!
Газзәнең һәр тамырын, һәр күзәнәген бер хис — ачы нәфрәт хисе биләп алды. Башыннан кичкән кеше белә: кешене көчле, зирәк, куәтле итә торган мәңге сүнмәс хис ул — сыйнфый нәфрәт. Ул кешене бирешмәс, аяусыз итә, аны хәрәкәткә, көрәшкә этәрә. Газзә дә үзен кинәт үсеп, ныгып, җитлегеп киткәндәй тойды.
Аның күз алдын каплап торган пәрдәләр төшеп, кинәт дөнья яктырып киткәндәй тоелды.
Гөлзәйнәп моны күреп, йомшап китте.
— Утыр әле, Газзә, сөйлә, ни булды?
Газзә кыскача гына бүген Фагыйләдән ишеткәннәрен сөйләп бирде. Сөйләгән саен үзе өчен дә күп нәрсәне ачыклады.
— Алар менә шулай: башта кешене үзләренә эшләтеп, амбарларын икмәк белән тутыралар, аннары теге кеше ачтан үлә башласа, аның бөтен мал-мөлкәте бәрабәренә дә җан сакларлык ризык бирмиләр. Күрәләтә үтерәләр. Шуның өстенә үзләрен мәрхәмәт ияләре, фәкыйрьләрне яллап яхшылык эшләүчеләр итеп күрсәтергә тырышалар! Үзләренә коллар тәрбиялиләр!
— Әйе, коллык психологиясе тәрбиялиләр алар...
— Миңа да бит бәләкәй чактан шуны сеңдерергә тырыштылар...
— Үзгәргәнсең син, Газзә,— диде Гөлзәйнәп.— Синең турыда ни өчен гайбәт тараткан нары аңлашыла хәзер.
— Аларның максаты шул инде: мине үз кубызларына биетү, я булмаса авылдан ук кудыру. Әле Сабирҗан мулла мәчеттә, байларны мактап, мине хурлап вәгазь укыган дип ишеткәч, мин аны үз явызлыгы белән генә шундый сүзләр сөйләгәндер, дип уйлаган идем. Алар барысы да бер сүздән йөриләр икән. Хәзер бездән дә рәхим-шәфкать көтмәсеннәр инде.

Алар — ике кыз, ике комсомолка — башларын-башка терәп озак сөйләшеп утырдылар. Газзәнең бер шиге бар иде: Елтыр икмәк белән сату итеп ятмый микән? Ай-һай, үзе сөйләп йөргәнчә үк намуслы рәвештә тапшырып бетерде микән ул икмәкне? Аннары Газзә кулына каләм алып, дәфтәр битендә санап чыгарды: сиксән пот кына Елтыр ише күп җир чәчкән кешегә аз ул, барыбер аз! Аннан күбрәк тә алып була. Тик, мөгаен, яшергәндер ул икмәген... Ничек тә эзенә төшәргә кирәк иде...

Ул урамга чыкканда ай калыккан, бөтен дөньяны ямансу нурга күмгән иде. Айлы кичнең тылсымлы сагышын көчәйтеп, авыл өстендә гармун моңы агыла. Гармун сыкрана, зарлана, сызланып яшь түгә кебек иде. Шул хәсрәтле моңнан Газзә барысын да аңлады: кара гайбәт гармунчыга да барып җиткән, агулы угын аның бәгыренә дә кадаган.

Их, Гөлзәйнәп янына барып кергән шикелле гади генә итеп, Бармаксыз Һадиның кара мунчасына барып керәсе иде дә, гармунчының каршысына басып: «Әхтәм, җаным, ышанма ятлар сүзенә, минем бер гаебем дә юк, мин сине генә өзелеп сөям»,— диясе иде.

— Иртәгә хәтле генә көт инде, бәгырем, — диде Газзә эченнән генә Әхтәмгә. — Иртәгә комитетны җыеп сөйләшербез.

Ә иртәгә хәтле көтәсе бик озак, ай-һай, озак кебек тоела иде.

Ләкин аларга иртәгесен дә, берсекөнгә дә очрашып сөйләшү, аңлашу насыйп булмады. Әхтәм Газзәне урамда күргәндә читләшә, кырыйга карап узып китә, күрәсең, ул теге гайбәткә ышанган, Газзәгә бик каты рәнҗегән иде булса кирәк.

Ул комитет утырышына да килмәде, унлап кеше җыелган каравыл өенә, сабыр гына елмаеп, аның әтисе Бармаксыз Һади гына килеп керде.

Бу юлы утырышта бик кызу бәхәсләр купты, каравыл өе тын алгысыз тәмәке төтене белән тулды, Газзәнең күзләре кычытты, тамагы чатлап кипте, ләкин аны чылатырга мөмкинлек булмады, ул чакта өстәлгә су куярга өйрәнмәгәннәр иде әле.

Комитет авылның һәр кешесе өчен бик мөһим мәсьәләне хәл итте ул утырышта: алар кайсы хуҗалыкны — байлар рәтенә, кайсын — урта хәллеләр, кайсын — ярлылар исемлегенә кертергә тиешлеген карадылар. Монда кешенең киләчәге, язмышы хәл кылынганын барысы да аңлыйлар иде. Дөрес, әле хәзергә кемгә күпме икмәк тапшыру заданиесе бирергә кирәклеген генә билгеләргә тиеш иделәр, ләкин киләчәктә тагынниләрдер булачагын барысы да сизенеп торалар иде.

Иң әлек Гыйбадулла белән тегермәнче Нургатаны байлар исемлегенә теркәп куйдылар. Елтыр Кашап исеменә тукталгач, каты бәхәс чыкты. Газзә аны мал-мөлкәтенә, илле-алтмыш дисәтинә җир чәчүенә карап байлар исемлегенә кертергә тәкъдим иткән иде.

Ләкин агайлар каршы төштеләр. Ни дисәң дә, Кашап кызыл сугышчы, сәвит башлыгы булып торган кеше, даими ялчы тотмый, чәчү, уру чорында гына көнлекчеләр яллый, өстәвенә, болай да икмәкне күп тапшырдым, дип сөйли диделәр. Кыскасы, нык хәлле крестьяннар исемлегенә теркәделәр Кашапны.

Чират Сабирҗан муллага җиткәч агайларның башлары иелде. Кашап мәсьәләсендә Газзәнең сүзен өскә чыгармагач, бу юлы да аныңча булмас шикелле иде.

— Мулла абзыйны рәнҗетеп булмас,— диде батрак Зәйнетдин.— Мулла авылда кирәк кеше. Бүтәннәр рәтеннән икмәк тапшыра икән, шул бик җиткән. Аңа орынмыйк без, җәмәгать. Гөнаһлы булмыйк.

— Сабирҗан мулла үзе дин сүзе генә сөйләп калмый бит, дөнья эшенә дә тыгыла,— диде Газзә үтемле итеп.— Кеше көченә баеганнарны күккә күтәреп мактый, халык арасында аң-белем таратып йөрүче-

ләрне, ярлылар яклы яшьләрне аяк астына салып таптый. Ә нигә әле без аңа яхшатланырга тиеш? Байлардан ни аермасы бар аның? Күпме кешене үзенә эшләтә, күпме фытыр сәдакасы җыя. Йорт-җире бер дә Нургатаныкыннан ким түгел. Байлыгы бар икән, заданиене дә башка байлар белән тигез түләсен!

Авыл агайлары мулла хәтле муллага ачыктан-ачык тел тигезүне яхшысынмыйлар иде. Алай да батрак Баһаветдин:

— Икмәкне күпме тапшырса да, Сабирҗан мулла бөләчәк түгел инде ансы,— дип куйды.

Бармаксыз Һади да башын күтәрми генә:

— Дөнья гаменнән бөтенләй ваз кичкән кеше түгел, авырлыкны да мир белән күтәрешсен бераз, саваплы булыр, — дип Баһаветдинның сүзен куәтләде.

Берничә кеше каршы килеп маташсалар да, Газзә үз сүзендә нык торды: Сабирҗан мулланы иң бай кешеләр исемлегенә язып куйдылар. Байлардан икмәкне башкаларга караганда, җан башыннан исәпләгәндә, икеләтә артык тапшыртырга карар кылынды.

Җыелыштан соң өенә кайткач, Газзә кулына каләм алып, санап чыгарды: берничә кеше, шул исәптән Елтыр Кашап та, тапшырган өстенә тагын шактый икмәк тапшырырга тиешләр иде.

Ләкин алар бу хакта ишетергә дә теләмәделәр, алдан әйткәнен тапшырдык, артык бер бөртек калмады, теләсәгез нишләтегез, диделәр. Елтырларга Газзә үзе бармады, комитет членнарын җибәргән иде, Баһаветдин белән Зәйнетдин бик кыенсынгандай, боегып кайттылар.

— Теләсә нинди этрәк әләм сүзенә карап, ир башыгыз белән юләрләнеп йөрмәгез, мин сез өйрәтүгә калмаган, нишләргә икәнен үзем беләм, — дигән Кашап.

Ләкин Газзә дә ансат кына бирешмәячәк — ул Елтырның чын йөзен фаш итәргә бер генә мөмкинлекне дә ычкындырмаячак иде.

Озакламый андый мөмкинлек килеп тә чыкты: район үзәгеннән кулакларның яшергән икмәген эзләп алу өчен махсус кешеләр килде. Алар барысы бишәү иде: район үзәгеннән өч кеше, Аксудан — икәү. Ул вакытта шулай итәләр иде: комитет членнарын районнан килгән кешеләргә ярдәмгә башка авылларга җибәрергә тырышалар иде: Аксу кешеләрен — Имәнлегә, Имәнледәге комитет членнарын — Аксуга.

Елтырларга Газзә аларны үзе дә алып барырга теләк белдерде. Районнан килгән кешеләр арасыннан бердәнбер хатын-кыз — аның фамилиясе Борһанова иде — кара бишмәте өстеннән билен кысып бәйләгән тулы гына гәүдәле, мөлаем йөзле апа Газзәгә бармаска киңәш итте:

— Синең әле бу авылда күп эшлисең булыр, мондый хәлләрдән бераз читтәрәк тору яхшы.

— Миннән башка сез анда бернәрсә таба алмаячаксыз, — диде Газзә. — Ә мин аларның ихатасын яхшы беләм, мөгаен, ярдәмем тияр.

Алар яшел капкадан алтау барып керделәр — бер ирнең кулында озын нечкә тимер таяк — шомпол да бар иде. Кашап аларны күргәч астыртын гына елмайды, Мәгъсүмә кашын-күзен җимереп, түгәрәк, кечкенә күзләре белән Газзәне ашардай итеп карады.

— Юкка мәшәкатьләнеп йөрисез,— диде Кашап.— Вакытыгызны гына исраф итәсез...

Газзә ындыр табагы янындагы күгәргән салам чүмәләсе янына барып басты. Аның чабатасы эзенә кадалган тимер таяк җиргә берничи каршылыксыз кереп тә китте. Ике кәрәк тирәнлегендә туфракны казып алуга, чокырдан ямаулы капчыкка төрелгән бер нәрсә килеп чыкты. Нәрсәдер, тик икмәк түгел иде бу. Актарып карасалар — бер чирекле шешә белән керосин булып чыкты.

— Ник монда күмдеӊ аны, карчык?— дип кычкырып сорады гаҗәпләнгән булып Кашап.

— Ут-күздән сак булуыӊ яхшы,— диде болдырдан Мәгъсүмә. Аныӊ тавышында тантаналы кинәнү ишетелде.

Газзә, кара чокырга текәлгән килеш, башын күтәрергә дә кыенсынып басып тора иде. Шулай ук хур булдымыни ул? Ә бәлки ата-анасы, туганнары, ятим узган яшьлеге өчен үч алу теләге аӊа Елтырларныӊ намуслы, яхшы кешеләр икәнен күрергә комачаулыйдыр?

Ләкин... ник күмгәннәр соӊ алар бу керосин шешәсен? Бер сере булырга тиеш бит моныӊ, бер хикмәте. Мөгаен, эзне адаштыру өчен эшләнгәндер бит бу!

— Туктагыз әле, — диде Газзә капкага таба борылган Аксу кешеләренә. — Аз гына сабыр итегез.

Һәм абзар артына өелгән тирескә, аныӊ ничектер чиләнеп, төсе белән башка төшеннән аерылыбрак торган кырыена юнәлде. Тимер таяк туфракка бик ансат керде дә нәрсәгәдер төртелеп шып туктады...

Икмәк капчыклары имән бүрәнәләр белән әчләнгән иркен чокырга салынган иде. Елтырлар ул икмәкне озак еллар буе шунда яшереп сакларга ниятләнгәннәр иде булса кирәк. «Ә бәлки тагын да ачлык ел килер дип өметләнгәннәрдер әле», — дип уйлады Газзә.

Ирләр авыр капчыкларны баздан чыгарганда, Газзә аркасы белән үк Кашапныӊ көйдергеч карашын тоеп торды.

Шул ук көнне Нургатаныӊ да яшергән икмәген табып алдылар. Авыл икегә — бер-берсе белән килешмәс дошманнарга бүленде.

## Йолдызлар биешә

Шомырт чәчәк аткан чак иде.

Ай, ул Имәнленеӊ шомыртлары! Булды микән берәр авылда андыйлар! Өй буйларында, ындыр түрләрендә, урман аланнарында алмагачлар кебек ялгыз-ялгыз да, таллар кебек куерып та үсәләр иде алар.

Шомырт агачлары Имәнленеӊ бизәге генә түгел, байлыгы, куанычы да иде. Язларын алар барча җан иясен хуш ис белән сихерләп, ак күбеккә күмелеп чәчәк аталар, җәй уртасында авыл халкын тәмле җимешләре белән сыйлыйлар иде. Ул чакта агач башларында бала-чага чыр-чу килә, аларныӊ ерык авызлары кап-кара була. Яшь кызлар, киленнәр бергәләшеп шомырт җыярга чыгалар, сөйләшәләр, көлешәләр, җырлашып алалар, урамнан узган егетләр койма аша гына алардан авыр тәлгәшләр алалар һәм иреннәре белән һәр җиләкне сак кына аерым өзеп кабалар — әйтерсеӊ лә сөйгән ярларын үбәләр. Еш кына егетләр кызларга юан агачларны иешергә ихатага ук керәләр.

Бергәләшеп шомырт җыю Имәнленеӊ үзенә бер матур бәйрәме иде ул.

Моннан соӊ да, яӊа поселокта да шулай булыр микән? Авыл күчә, шомыртлары да күчәр микән? Әгәр шомыртлары шундый күп, мул чәчәкле, хуш исле булмаса, ул инде Имәнле булмый, Газзәнеӊ туган авылы була алмый...

...Ул елны Газзә шомырт чәчәк атканын беренче тапкыр бөтен гүзәллеге, хуш исе, кабатланмас аклыгы һәм сафлыгы белән тойган иде.

Әйе, нәкъ менә шомырт чәчәк аткан чакта аларныӊ авылына егерме биш менче — Донбасс шахтеры Исмәгыйлов Вәгыйз килгән иде.

Каравыл өе бик кечкенә дип, халыкны Хәкимҗан абзый өенә җыйдылар. Беренче итеп Исмәгыйловка сүз бирелде. Аныӊ кыяр кебек озынча, ничектер күгәребрәк торган йөзен чибәр дип булмый иде, әмма

житди, шул ук вакытта ягымлы да булган карашы сөйкемле итә, бөтен кыяфәтеннән, кием-салымыннан, крестьян халкыннан аермалы булarak, искиткеч җыйнаклык, пөхтәлек бөркелеп тора иде. Кискен-төгәл хәрәкәтләренә караганда, ул солдат боткасын да шактый ашаган булырга охшый иде.

Аның кырларда, мәйданнарда сөйләп күнеккән тавышы өчен авыл өе бик кысан иде булса кирәк, ул үз тавышын киметергә тырыша, якын гына утырган халыкка, хезмәт кешесенә гади, үз итеп дәшә белә иде. Аны керфек тә какмый, кымшанмый тыңладылар.

— Искечә яшәү мөмкин түгел хәзер, — диде ул. — Җирне ата-баба ысулы белән эшкәртә торган булсагыз, һәркайсыгыз үз кишәрлегендә тырманып ятса, сез күпме генә икмәк үстерә аласыз? Бала-чаганың тамагы туйса, чәй-шикәрлек, күлмәк-ыштанлык сатсагыз, шуңа бик канәгать булачаксыз инде, шулай бит?

— Ходага мең шөкер итәриек,— диешә агайлар.

— Шул-шул менә! Ә эшчеләр, шахтерлар ни ашар? Донбасста бүгенге көндә дә әле ипине карточка белән генә бирәләр. Ә шахтерларга көч-куәт күп кирәк, чөнки алар тимер эретү өчен күмерне күп чыгарырга тиеш. Ә тимер тракторлар, комбайннар ясау өчен кирәк. Без сезгә машиналар бирербез, ә сез безне икмәк белән тәэмин итәрсез. Эшче белән крестьянның бәхете, киләчәге бер-берсенә аерылгысыз бәйләнгән. Аерым гына мул тормыш корып булмый, хуҗалыкны бергәләп күмәкләшеп күтәрергә кирәк...

Тормышны, дөньяны күп күргән, читтән килгән кеше булганга кызыксынып тыңлады халык Исмәгыйловны. Аннан соң сүз белән Газзә урыныннан торып басты. Унлы лампа яктысында йөзләре ачык күренгән алгы рәттән алып, тонык кына шәйләнгән арткы рәткә хәтле күз йөртеп чыкты да, сөйли башлады ул.

— Иптәшләр! Безгә күмәк хуҗалык оештыруның ил өчен, халык өчен никадәр кирәкле эш икәнен әле генә бик яхшылап аңлаттылар. Безнең авылның күп кенә кешеләре бу эшне башлап җибәрү өчен күп көч тә куйдылар инде. Менә без ширкәт оештырдык. Ширкәт ул — күмәк хуҗалыкка беренче адым бит. Моны фәкыйрьләр генә түгел, урта хәллеләр дә аңлый башлады. Безнең ширкәткә урта хәлле өч хуҗалык керде.

Халык Газзәне дә бик зур игътибар белән тыңлады. Чөнки ширкәткә кергән кешеләр бик матур, күңелле итеп, нәкъ үз вакытында бергәләшеп чәчүне үткәрделәр. Җирне янәшә алдылар, бергәләшеп, кая нәрсә чәчәргә кирәклеген хәл кылдылар, солы, борай, тары чәчәргә, бераз бәрәңге утыртырга булдылар.

Чәчү әйбәт узсын өчен, Газзә бик нык тырышты. Атлар көр булсын, яхшы каралсын, нык ашатылсын, сабан-тырма тәртипкә китерелсен, чәчүлек орлык әйбәт чистартылсын — моны Газзә көн саен тикшереп, карап тора иде. Шуның өстенә әле ул күмәк эшне ничек тә булса күңеллерәк, ямьлерәк итәргә тырышты. Бер басуда бергәләшеп берничә кеше эшләячәк бит. Шулай булгач, аларга басуда ук кайнар аш пешерергә кирәк. Анысына атлыгып торган пешекчесе дә табылды — Хәкимҗан абзыйның яшь хатыны Шәмсеҗиһан аш-суга бик оста, бик өлгер булып чыкты.

Беренче көнне сабанга төшкәнне Газзә дә, башкалар да олы бәйрәм кебек көттеләр. Шаулашып, көлешеп, өч атка утырып, бөтен авылны яңгыратып басуга чыгып киттеләр. Ызаннарга бүленеп телгәләнмәгән киң басуны өч ат рәттән тезелеп сөрде, биш агай бер-бер артлы киң селтәнеп чәчтеләр. Бала-чага, йомшак туфракта абына-сөртенә, куыша-шаярыша чәчүчеләрнең тубалларыннан, иген уңсынга юрап, орлык белән бергә сибелгән йомыркаларны җыйды.

Чәчүдә бергәләшеп эшләгән кешеләр үзара аеруча якынаеп, дуслашып киттеләр. Аларда, әйдәгез әле, менә шушылай яңача яши алуыбызны, аның рәхәтлеген күрсәтик әле, бөтенесе кызыгырлык булсын, дигән теләк яши иде.

Ә халык аларның бу эше ничек барып чыгасын бик зур кызыксыну белән күзәткән. Шуңа күрә, гәрчә ширкәтнең эшләре ничек барганын һәммәсе энәсеннән-җебенәчә бик яхшы белеп торсалар да, Газзәнең сүзен барысы да бик кызыксынып тыңладылар.

Ләкин Газзә өчен бөтенесеннән дә куанычлырагы — Әхтәмнең соклану, хуплау, горурлану белдергән карашы булды. Димәк, Газзә үз эшен дөрес алып бара, сүзен кеше күңеленә ятышлы итеп сөйли ала, үзен дәрәҗәсенә лаек рәвештә тота ала.

Җыелыштан соң Газзә һәм тагын берничә агай Исмәгыйлов белән шактый гына сөйләшеп утырдылар.

Ниһаять, Газзә кайтырга чыкты. Имәнленең болай да мәйдан кебек киң урамы — аны Хәкимҗан абзый бер үлчәгәч, йөз илле адым дигән иде — төн караңгылыгында тагын да киңрәк сыман тоела иде. Күк йөзе төпсез, карасу-зәңгәр, эре йолдызлар үтә күренмәле болытлар аша да чекерәешеп карап торалар. Әгәр дә Газзә аягы белән җиргә катырак басса, талпынып күк гөмбәзенә хәтле күтәрелер, теләсә, йолдызларны чуерташлар кебек учына җыеп алыр кебек тоела иде.

Киң урамда Монтазиманың хәрәмлектә йөреп, өенә кайтмыйча коймa янына яткан ак кәҗәсеннән гайре бер җан иясе юк, кайдадыр этләр өреп куя да, Коры елгада бакалар кычкыра. Дөньяны шомыртның хуш исе баскан. Газзә — шул гүзәл галәмнең, җирнең-күкнең берсәнбер уяу күзәтчесе, шаһиты, хуҗасы — тәне белән һаваның сафлыгын тоеп, аяклары белән яшь үләннең терелеген, йомшаклыгын сизеп, күзләренә тылсымлы дөньяның шәүләләрен сендереп бара.

Югары очтан гармун тавышы ишетелә башлый. Газзә шул көйгә атлый:

> Һай, дусларым, дусларым ла,
> Дусларым, дус-ишләрем...

Өй буйларындагы ак шомыртлар аның ишетелер-ишетелмәс җырын тын калып тыңлыйлар:

> Сез дуслардан аерылгач,
> Ялгыз башым нишләрем...

Коры елга башындагы киң мәйданга җиткәч, Газзә адымнарын тизләтә, ул каядыр ашкына, омтыла, болай гына басып бара алмый, гармун көенә биеп китә:

> Һай, дусларым, дусларым ла,
> Дусларым, дус-ишләрем...

Яр буендагы өянкеләр арасыннан бөтерелә-бөтерелә үтә ул. Өянке ябалдашлары аның белән бергә бөтерелә, чокыр төбендә яздан кипми калган суда йолдызлар бии...

> Һай, дусларым...

Җыр шунда өзелде. Күк белән җирне тоташтырып биегән йолдызлар, карт өянкеләр, сандугачлар җыры, гармун моңы, Газзә үзе — бөтенесе берьюлы караңгы базга чумгандай юкка чыкты.

Күпме һушсыз яткандыр ул — белмәде. Күзен ачкач та иң беренче күргәне йолдызлар булды. Бу юлы алар башны әйләндереп уңга-сулга чайкалалар иде. Газзә чалкан ятканлыгын аңлады. Кузгалырга тырышып, эре-салкын әрекмән яфракларын тартып өзде. Янбашы юешлән-

гәнен сизде. Кулын күлмәгенә ышкып, чыланган бармакларын күзе янына китерде. Бармаклар кара иде. «Кан...»

Бүрәнәләр буйлап ничек үрмәләп чыккандыр, ярдан ничек менеп, ишекне ачкандыр, Вәҗһетдин абзый Хәкимҗан абзыйның атын җигеп кайтканчы, Фагыйлә: «И ходаем, кыз балаларга пычак күтәрәләр бит, ничек ходай ормый бу кабахәтләрне!» — дип каргана-сукрана Газзәнең җәрәхәтен бәйләгәнче күпме вакыт үткәндер. Һәрхәлдә, тиз генә таң атмады. Арбада ястык өстендә яткан Газзәне йолдызлар, бер кабынып, бер сүнеп, озата бардылар.

...Ә бер айдан Газзә ике катлы агач больница янында, кояшта җылынган кыйшык эскәмиядә Әхтәм белән янәшә утырып тора иде. Койма буендагы шомыртларның тәлгәшләре тулып карала башлаган, песи тарылары арасында кырт-кырт килеп тавыклар чүпләнеп йөри, чыпчыклар чыркылдаша. Газзәнең бөтен җанын-тәнен үлемнән исән калган кешедә генә була торган җиңеллек, яшәү шатлыгы биләп алган. Ул шомыртларга, чыпчыкларга, койма кырыендагы усал кычыткаННарга елмая, үзе шытырдатып балтырган сабагы чәйни, юа ашый. Әхтәм алып килгән күчтәнәч — Имәнле урманы сыйлары — бигрәк тансык, бигрәк тәмле икән. Кызның исәргән башында: «Әгәр больниска эләкмәсәм, кайчан әле Әхтәм белән шушылай көпә-көндез икәүдән-икәү рәхәтләнеп утырырыем? Кайчан ул миңа юа белән балтырган алып килерие?» — дигән уй туа. Ул үз күңелен аңлап бетерми, Әхтәм белән бик күрешәсе килгән чакларда да үзенең нилектәндер куркып, ул очрашуларны булдырмас өчен качып йөргәнен инде онытКан да.

— Басуларның чүбен утадык,— дип сөйли Әхтәм. — Син бер дә борчылма, бөтенесен җайлап эшлибез. Ургыч машинагыз белән безгә дә булышырсыз әле, дип әйтүчеләр күп. Аның өчен күпме хак сорасын син терелеп кайткач хәл итәрбез дип торабыз.

Әхтәм ап-ак йон оекбашы белән өр-яңа чабатасына карап тынып кала. Аның оекбашы да, чабатасы да керсез, мөгаен, егет юл буе ялан аяк килгәндер дә, Биекъярга кергәч кенә аягына киенеп куйгандыр. Әхтәм чәч җибәрә башлаган, күнегеп җитмәгәнгә булса кирәк, салам төсле чәчен ике куллап һаман сыпыргалап тора.

— Мин дә комсомолга керәм, — ди.

— Син әллә кайчан комсомолда булырга тиешле кеше инде, Әхтәм.

Әхтәм, башын күтәреп, кыенсынып та, якын итеп тә елмая — аның ике бит очы уелып керә. Аннары Газзәнең башына уралган марляга карап тагын җитдиләнә.

— Терелдәм инде хәзер, — ди Газзә. — Миңа пычак тирән үтмәгән бит, күлмәк саклап калган. Башка гына каты сукканнар. Баш кына төзәлеп җитми әле.

— Кем суккан соң? Кем? — Әхтәм сорамый, таләп итә.— ГПУлар шуны да белмимени?

— Белә алмадылар шул. Кемнән шикләнәсең дип миннән дә әллә ничә кат килеп сорадылар инде. Кемнән шикләним?

— Елтырлар ул көнне Аксуда туйда булганнар,— диде Әхтәм уйланып. — Бөтен авыл халкы шартлатып әйтеп тора. Үзем барып белештем. Сабирҗан мулла да шунда никах укып, сыйланып яткан.

Газзәнең күңеленнән кайнар дулкын уза. «Әхтәм, Әхтәмкәем, син әле анда барып йөрдеңмени?»

— Әйе, шулай диләр шул, — ди Газзә. — Миңа тикшерүче әйтте.

— Барыбер алар кулы уйнаган монда, алар гына! — дип кайнарланып сикереп тора Әхтәм. — Бүтән кем булсын? Мин авылның очыннан-очына бөтен кешене җиде кат иләк аша үткәреп чыктым инде. Шулар эше генә бу. Бер дә башканыкы түгел.

— Соң үзең әйтеп торасың бит, алар авылда да булмаганнар дип.

— Һи, андый эшне Елтыр үз кулы белән эшлиме соң? Учактан утлы күмерне кеше кулы белән көрәргә остарып беткән инде ул! Берәрсен яллагандыр әле! Котырткандыр, сатып алгандыр! Мин уйладым инде, уйладым!

— Кемне? Кем яллансын андый эшкә? — диде Газзә соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп һәм Әхтәмнең бу эшне шул кадәр якын алуына чиксез сөенеп.

— Бәлки башка авылдандыр. Шул ук Аксудандыр. Әә бәлки үзебезнең Имәнледән үктер. Мин табам әле ул ерткычны! Барыбер эзенә төшәм!

Шул хәтле үчлелек, ярсу белән әйтә ул боларны, Газзә гаҗәпләнеп кала. Ул Әхтәмнең мондый үҗәт, кызу канлы икәнен белми иде әле, гармун белән узганда егетнең күңеле урамнарга сыймаган моң дәрьясы белән тулы, анда башка тойгыларга урын юк дип ялгышкан икән ул.

Шәфкать туташы Газзәне ашарга чакыра, болай да озак утырдың, өзлегерсең, ди. Егет белән кыз вакытның тиз үтүенә, әйтәсе килгән сүзләрнең әйтелми калуына эчтән генә уфтанып, аерылыша алмый торалар.

— Тагын ни алып килим? — ди Әхтәм.

— Берни дә кирәкми. Монда Зиннур абый көн саен килеп тора. Серебров та килгәли.

Ләкин егетнең сүрелгәнен күреп, сүзенең «син килеп йөрмәсәң дә ярый иде» дигән сымаграк килеп чыкканын абайлап, Газзә:

— Шомырт алып кил, — ди. — Пешә torгандыр бит инде.

— Каралып килә инде. Мондагы кебек.

Ул больницага керә дә тәрәзәдән егетне күзәтеп тора. Әхтәм тузанга басмас өчен, юл кырыеннан, чирәмнән эре-эре атлап китеп бара. «Миңа кадаган кешене чыннан да табар микән?» — дип уйлый Газзә куркынып та, сокланып та.

...Юк, белә алмады Әхтәм җинаятьченең кемлеген. Ул бары тик Газзәнең үзенә генә билгеле булды.

Көзге караңгы бер кичтә Газзәне авыл советына чакыртып алдылар. Районнан милиционер килгән икән. Озын буйлы, аз сүзле, кырыс кыяфәтле бер кеше иде. Ул Газзәгә таныкнамасын күрсәтте дә:

— Мине Махас Сираҗиев йортына алып барыгыз, — диде.

Өстән вак яңгыр сибәли, аяк асты чупыр-чупыр килә иде. Милиционер рус кешесе иде, аны-моны сорашмады, үзе дә берни әйтмәде. Газзә алдан, кырыс кеше аның артыннан тавыш-тынсыз бардылар.

Аларны күргәч, Махас агарынып сәкедән күтәрелде, ләкин Газзә көткәнчә үк аптырамады, берни сорамады. Дәшми-тынмый ныклап киенә башлады. Әле бүреге, әле бияләе кулыннан төшеп кенә аның каушаганын, кулы калтыранганын сиздереп куя иде. Өйдәге бөтен кеше — тынып калган балалар да, ни әйтергә белми мич буенда өнсез басып торган Монтазима да, милиционер да аны күзәтәләр иде.

— Кая, ашарга берәр нәрсә төйнә әле,— диде, ниһаять, Махас хатынына. Шунда гына Монтазима, һушына килгәндәй, кая басарга белми бәргәләнергә тотынды:

— Ай, Газзәкәем, кая алып китәсез? Ни өчен, ни булган?

— Белмим бит, Монтазиматти. Мин бу кешегә юл күрсәтеп кенә килдем.

— Районга ук алып китмиләрдер бит! Сәвиткә генә алып барып сөйләшәсездер?

— Кая, бирәсеңме берәр нәрсә, юкмы? — дип аның сүзен бүлдерде Махас. Әйтерсең лә ул үзен кая алып барасыларын белә иде.

Газзә, тәрәзә янагына сөялеп хәрәкәтсез калган үсмер малай Гарифның күзләрен күрмәс өчен, карашын түрдә, сәкедә гү-гү килеп яткан Гайнанга төбәде. Гарифның күзләре Газзәнең бөтен күңелен айкарга тырышып: «Ни өчен? Әйт! Син беләсең бит? Кая алып китәсез

сез безнең әтине?» — дип ялварып карыйлар һәм бу карашның көче таш бәгырьле кешене дә тетрәндерер иде шикелле.

Нәфис йөзле, тирән карашлы, һәр йөз чалымында әчке хисләре чагылып торган малай бу тынчу, кысан өйгә һич тә ятышмый, ул бирегә һичбер гөнаһсыз җәзага тартылып, кемнеңдер гаделсез хөкеме нәтиҗәсендә, башка бер иркен, якты, мул тормыштан китереп ташлангандыр сыман тоела иде. Соныннан Газзә аңа охшашлы малайларны танылган рәссамнарның портретларында күрде. Аның өнсез сорауларына җавап бирми мөмкин түгел, ләкин Газзәнең аңа әйтер сүзе юк иде, чөнки ул милиционерның Махасны нинди максат белән алып китүен чыннан да белми иде.

Урамга чыккач, милиционер эре-эре атлап алдан китте, ә Махас караңгыдан курыккан бала шикелле Газзәгә якын ук елышты. Урамның ике ягындагы йортлар, яңгырдан иңгәндәй, ерак, кечкенә булып күренәләр, дөнья шомлы тоела иде. Газзәгә ямансу, бик ямансу булып китте.

— Кхм-кхм, — дип тамак кырып куйды Махас. «Кая алып барасыз, дип сорар инде», — дип уйлады Газзә аның сүз башларга җыенганын сизеп. Ләкин Махас һич көтмәгәндә Газзәнең саулыгын сораша башлады:

— Ничек соң, инде терелеп җиттеңме? Сызланмыйсыңмы?

— Юк, Махас абзый, сызланмыйм, терелдем инде, — дип җавап бирде соң дәрәҗәдә сәерсенгән Газзә. Махасның беркайчан да аның хәле белән кызыксынганы юк, гомумән, алар бик аз сөйләшәләр. Фәкыйрь кеше буларак, Газзә аны комитет эшенә тартырга тырышып карады, ләкин Махас комитетка килсә дә берәр ярдәм сорарга яисә ярлылыгыннан, хасталыгыннан зарланырга гына килә, бер эшкә дә катнашмый иде.

— Бик олы гөнаһым бар бит әле минем, Газзә,— диде Махас пышылдап. — Син теге... үзеңә чәнчегән кешеләрне беләсеңме?

— Каян белим инде, Махас абзый, ГПУ да тикшерде, таба алмады бит.

Махас аңа тагын да ныграк елышты, терәлеп үк бара башлады.

— Мин ул эшнең башында торган кеше бит, — диде.

Яңгыр урынына кайнар су коелгандай булды, караңгылык тагын да куерды.

— Ничек... син?

— Мин шул... Гөнаһы миндә...

— Ә ни өчен? Ни начарлыгым тиде минем сиңа? Миндә ни үчең барые?

Шактый ук кычкырып әйтелгән бу сорауга Махас ашыгып, пышылдап җавап бирде:

— Үчтән түгел... Ачу саклаудан булган эшмени... Нужа бит... Нужа батыра адәмне гөнаһыга...

Әхтәм әүлия икән, сүзе раска чыкты. Махасны бу эшкә Елтыр Кашап белән Сабирҗан мулла яллаганнар икән. Мулла: «Шул иблис токымының җанын җәһәннәмгә олактырсаң, урының җәннәттә булыр»,— дип хәер-фатихасын биргән, Кашап аның балалары астына җәяргә тире, бодай, ат бирергә вәгъдә иткән.

— Коры елга аркылы ялгыз йөргәнеңне беләдерием инде, — дип сөйләп китте Махас ашыгып.— Шунда сагалап тордым. Бер кулымда пычагые, икенчесендә арба кендеге. Беренче көнне үзеңне күргәч, кулаягымның җегәре китте, юлыңа аркылы төшә алмадым, уздырып җибәрдем. Икенче көнне тагын чыктым. Өянке артында басып торам, төн якты, күрерсең дә сыман. Ә син җырлый-җырлый тырык-тырык сикергәләп кайтып киләсең. Күзең җирдә түгел, агач башында. Кизәндем

кизәнүен, тик ходай тәгалә кулымның җегәрен тагын алган, каты җәрәхәтләргә ирек бирмәгән.

Газзәнең күңеленә Гөлзәйнәпнең коллык психологиясе турында сөйләгән нәфрәтле сүзләре килеп төште. Күңеле белән кол кеше гомере буе үзе кол булып яшәп кенә калмый, ул көчен-сәләтен, җанын, вөҗданын сатып, теләсә нинди җинаять кылырга да сәләтле була икән! Менә нинди куркыныч нәрсә икән ул күңел коллыгы!

Шул кичне үк милиционер, олау алып, Махасны районга алып китте.

Ник гаебен таныды икән Махас? Газзә бу хакта күп уйланды. Ул, күрәсең, үзен шул җинаяте өчен кулга алырга килгәннәр, дип уйлагандыр. Шуңа күрә, алдан Газзәнең күңелен йомшартып куеп, җәзасын киметүне өмет иткәндер.

Ләкин ул бөтенләй башка җинаятьтә гаепләнгән булып чыкты. Биекъяр элеваторында бер төркем кеше, икмәк тапшыру турында язган квитанцияләр сатып, хөкүмәтне алдап, талап ятканнар икән. Ул квитанцияләрне Елтыр Кашап белән Сабирҗан мулла да сатып алганнар, ә үз икмәкләрен яшереп спекулянтларга сатканнар. Һәм ул икмәкнең күбесен Махас аркылы саттырганнар икән. Тикшерү вакытында аларның Кызыл Армия сафларында сугышып йөрүләре турында ялган документлар ясаганнары да фаш булды. Әмма Газзәгә һөҗүм итү вакыйгасы ачылмый калды. Шунлыктан Газзәнең үзен судка да, тикшерүче янына да чакырып тормадылар.

Ләкин бу нәрсә аның башыннан һич тә чыкмады. Махасның сатылуы, шул хәтле җан газаплары алып, шундый зур җинаятьләргә баруы аңа нәрсә китергән? Шул сорауга җавап табасы килә иде аның.

Түзмәде, бер иртәне Махаслар ишегалдына барып керде ул. Салам түбәсе иләк урынына су үткәрә торган тәбәнәк, кыеш лапаста үзенә таныш алашаны — Елтырлар алашасын күргәч, ул туктап калды, ачы елмайды: «Ә менә атлы булганнар бит! — диде.— Сүзендә торган икән Елтыр! Үзен кулга алганчы биреп калдырган!».

Ләкин өй эчендә атлы булдык дип сөенүче дә, гомумән аны искә алучы да юк иде. Газзәне күрүгә Монтазима кәкрәйгән, каралган куллары белән күз яшьләрен сөртеп, кычкырып еларга кереште. Ә Гариф, әтисен кулга алганнан бирле өеннән чыгып та карамаган үсмер малай, теге кичтән бирле тәрәзә турыннан да кузгалмагандыр! Газзәне күрүгә парланган пыялага таба борылды. Күз яшен күрсәтми иде, ләкин аның ныгып җитмәгән тар җилкәсеннән, юка муеныннан ук никадәр бәхетсез икәне, нинди зур кайгы, гарьлек кичергәне күренеп тора иде.

Газзә аларны кызганырга, үзен бөтен нәрсәне гафу итүче фәрештә сыйфатында күрсәтеп, үз-үзе алдында мактаныр өчен дип килмәгән иде. Һич юк. Ләкин өйдә ярдәмсез, туйдыручысыз яткан бала-чаганы, гаҗизлеге чиктән ашкан Монтазиманы, бигрәк тә бер гаепсезгә тар иңнәрен күтәрә алмаслык хурлык йөге астында сыгылып төшкән Гарифны күргәч, тирән уйга батты. Чыннан да, ул фәкыйрьләр комитеты председателе, ул ширкәт председателе, ул комсомоллар җитәкчесе, аннан башка бу балаларга, Гарифка беркем дә ярдәм итә алмый иде.

— Сабыр, Монтазиматти,— диде ул.— Артыгын җебеп төшмә, балаларны аякка бастырасын уйла. Син әйбәтләп кенә фәкыйрьләр комитетына гариза яз...

— И-и, безне анда якын китерәләрме соң хәзер! Совет дошманы дип балаларның да күзен ачырмаслар...

— Комитетта барын да үзем сөйләшермен,— диде Газзә.— Балаларны ач калдырып булмый. Менә атыгыз да бар икән хәзер...

— И ул ат белән нишлик без! Аның бит рәтле йөгәне дә юк, арбасы да, сукасы да! Үзе әйләнеп кайтканчы җанын асрата алсак шул инде!

Монтазима Газзәгә өметләнеп карады: әйтерсең лә комитет председателе Махасның кайчан әйләнеп өенә кайтасын белә иде!

— Ярый, минә Гарифны ширкәт эшенә тартырбыз,— диде Газзә. — Ә син укуыңны калдырма,— диде малайга тавышын күтәрә төшеп.— Гөлзәйнәп апаң әйтә, дәрескә килми, ди. Ярамый алай!

Гарифның җилкәләре тетрәнеп куйды.

...Газзә Махасның серен беркемгә дә ачмады. Ләкин ипи белән законсыз сәүдә иткән өчен аңа, Елтыр Кашапка, Сабирҗан муллага, башкаларга җәзаның зурысын бирделәр. Мулла семьясы, Мәгъсүмә белән Салый — судта аның гаебе ачылмаган иде — конфискациядән соң, йортларын ташлап читкә китеп бардылар.

Бер елдан авылга Махас Сиражиевның үлүе турында хәбәр килеп төште.

## Моңлы көнбагыш чәчкәсе

Көз. Коры елга буендагы өянкеләрдән берән-сәрән сары яфраклар төшкәли. Кыям абзый бакчасында алмалар беткән. Урман яшеллегенә бизәк булып, сары каен таплары төшкән. Һавага пәрәвезләр оча, урам буйлап каңгылдаша-каңгылдаша канат җәйгән тук казлар йөгерә.

Көз. Әбиләр чуагы. Авылның тук, канәгать, рәхәт чагы. Ак рәшә пәрдәсе аркылы җирне томанлы гына җылыткан кояш, йокымсыраган-дай ваемсыз кыяфәт белән, әкрен генә офык сызыгына таба төшеп бара. Көндезге эш беткән, кичкесе башланмаган әле. Карчыклар капка төпләрендә бияләй бәйләп, дөнья хәлләрен сөйләшеп утыралар. Ир-ат бүрәнә өсләрендә тәмәке пыскыта. Көтү каршыларга киткән бала-чага урман буенда әүмәкләшеп ята.

Менә алар, нидер күреп, дәррәү олы юлга таба чаба башладылар. Юлдан велосипедка атланган берәү килә икән. Аяклары тәгәрмәчләрне әйләндерә, үзе гармун уйный, тузан туздырып чапкан малайларны, һау-һулаган әнчекләрне артыннан җиткерми, «Алмагачлар» белән урамны яңгыратып, очраганнарга баш игәләп, югары очтан түбән очка уза.

— Театр килә! — дип кычкыра үзе.— Театр!

Ул да түгел, югары очта җигүле атлар күренә. Арбаларда, төеннәр, тартмалар арасында, хатын-кыз, бала-чага утыра, ә арттан бераз йончыган, ләкин шат чырайлы ир-ат җәяү атлый.

Бер сәгатьтән, артистларны фатирларга урнаштыргач, Газзә, Гөлзәйнәп, әлеге гармунчы-велосипедчы абзый уку өендә, ягъни Сөбхиямал әбиләрдә, киңәш-табыш итеп утыралар инде.

Агайның исеме дә үзенә лаек икән — сәер, ят исем, ләкин бер әйтүдә хәтердә кала торган — Шункар. Минзәләдән үзе оештырган труппаны алып килгән.

— Әйбәт зал табыгыз миңа, кызлар, — ди ул. — Бөтен авыл сыярлык булсын.

Шункарның киң бите шадра, авызы зур, тешләре тигезсез. Ләкин әллә нинди сөйкемле сөягә бар үзенең, кешене авызына гына каратып тота белә һәм аның шул шадра йөзенә карап, зур авызыннан чыккан сүзләрен тыңлаган саен тыңлыйсы килеп тора, ирексездән күңелдә бер шуклык туа. Яхшыдыр Шункар абзыйның театры, сүз дә юк, әмма бөтен авылны сыйдырырлык залын каян табасы?

Җыелышларда мәчетне клуб итү турында ничә тапкыр сүз кузгатып карадылар. Ләкин «мәчет, клуб» дигәнне ишетүгә агайларның йөзенә кирелек бәреп чыга, алар дәшмиләр дә, кул да күтәрмиләр. Сабирҗан мулла кулга алынганнан бирле мәчет буш тора, ә җыелыш җыеп халык белән иркенләп сөйләшергә, яшьләргә күңел ачарга бина юк.

— Бу чаклы томана халык та булыр икән, — дип янә кызды Гөлзәйнәп.— Киреләнсәләр киреләнерләр икән!
— Сүзегезгә ышандыра белмисез, димәк,— ди Шункар ягымлы да, серле дә елмаеп.
— Ходай каргышыннан куркып дер калтырап тору аларның канына сеңгән инде, — ди Гөлзәйнәп.
Башка чара юк — театрны әлеге шул уку өендә куярга карар кылдылар. Сәкесе — сәхнә, идәне — зал. Артистларның артык исе китмәде, мунчада да уйнаган бар безнең, дип кенә җибәрделәр.
Беренче көнне килгән халык өйгә сыйды. Артистлар башта кыска-кыска гына ике күренеш уйнадылар, шуннан соң тамашаның иң кызыгы башланды.
Менә сәке-сәхнәгә, озын кармак сабы тотып, тишек эшләпә кигән, чалбар балагын тез тиңентен сызганып куйган ялан аяк берәү чыкты. Шадра йөзенә гаҗәп җитди кыяфәт биреп, кармагына «теф-теф» төкерде дә, чуар чаршау артына «салды». Аннары гәүдәсен көянтәдәй бөгеп, зур дикъкать белән «балык капканын» көтә башлады. Зур авызын ачып бер сүз әйткәне юк әле — ә халык чыдый алмый көлә, халыкка кызык.
Менә, ниһаять, балыкчы кискен хәрәкәт белән киң селтәнеп кармагын тартып алды, авызын ачып, хәйран калып, капкан «балык»ка текәлде. Аннары табышын халыкка күрсәтеп:
— Бу ни бу? — дип сорады. — Ни капкан минем кармакка?
Ә кулында ике-өч бөртек каурый. Халык сулу да алмый аны күзәтә.
— Ә-ә, Гыйздениса казларының каурые бит бу! Үзен фәкыйрь күрсәтү өчен, бар булган каз-үрдәкләрен ашык-пошык суеп, юкка чыгарып бетергән. Ун баш каз белән унбиш бала үрдәктән менә шушы каурыйлар гына калган! Кирәкми миңа мондый балык! Гыйзденисаның үзенә булсын!
Кинәт өй тетрәнеп киткәндәй булды — унлы лампа куыгы эчендә ут бии — халык тәгәрәп көлә.
Ә «балыкчы» берни ишетми, күрми, кармагын тагын чаршау артына ыргыта. Халык көлеп туймаган әле, ләкин тыела, тагын ни әләгерен көтә.
— Бусы ни тагын?
Кармакта — кып-кызыл алма.
— Ә-ә-ә! Алма Кыямының бакча җимеше бит бу! Күлмәгемнең якасы муеныма әләгеп калса да, колхозга кирәсем юк, башкаларда эшем юк, алма пеш, авызыма төш дип бакчамда гына ятачакмын, дип сөйли икән. Әйдә, Кыямның үз авызына төшсен бу алма! Кирәкми безгә мондый балык.
Халыкның шаркылдап көлүенә тагын түшәм күтәрелгәндәй була. Һай, ди халык, оста да инде, барысын да каян белеп бетергән, рәхмәт төшкере!
Тик Газзә генә артына борылып карый да, ишек турыннан борылып, башын иеп чыгып киткән Маһруйны күреп ала. Әтисе бер дә уку өйләренә йөрергә, комсомоллар белән аралашырга кушмый иде, бу юлы да, мөгаен, качып кына килгән булгандыр. Газзәнең күңелендә үкенүхисе кузгала. Их, Шункар абзыйга Алма Кыямы турында әйтәсе калмаган, ди ул. Артист Имәнле хәлләрен Гөлзәйнәп белән Газзәдән сорашып белгән иде бит...
Ул арада «балыкчы» кармагы белән тутыккан йозак тартып чыгарган.
— Бу нәрсә? Ә! Мәчет ишегенә салынган йозак бит бу! Халыкны кертмәс өчен, безнең ише артистларны якын да җибәрмәс өчен асып куелган! Буш торса торсын, имеш, тик халыкка хезмәт итмәсен! Шулай

уйлый кайберәүләр. Кирәкми безгә мондый балыклар! Әллә кайчан су төбендә аларның урыны!

Инде монысыннан көлү кайсыларына бик үк яхшы да түгел кебек. Ләкин бер көләргә көйләнгән авыз үзеннән-үзе ерыла, балыкчы да,хәерсез, көлмәс жиреннән көлдерә...

Икенче кичне тамашага җыелган халыкны өйгә берничек тә сыйдырып булмады. Курмәгәненнән алда күргәне килеп утырган, хатынкызга, бала-чагага урын калмаган, кайсы, муенын сузып, ачык ишектән карый, кайсы тәрәзәдән башын тыккан.

Тамаша беткәч, Газзә, урыныннан кузгалып, сәхнәгә менеп басты:

— Инде, иптәшләр, шушындый күңелле театр куйган өчен, безнең күңелләрне күтәргән өчен артистларга рәхмәт белдереп кул чабыйк.

— Рәхмәт яусын!

— Дөрес, дөрес!

— Тагын килсеннәр, — диеште халык.

— Китмәсеннәр әле! Иртәгә дә куйсыннар! Без монда күбесен күрә дә алмадык! — дип кычкырды өй алдыннан берәү.

Форсатны ычкындырырга ярамый иде, Газзә Шункарга карады, Шункар — Газзәгә. Артист алга чыгып басты:

— Без халыкка хезмәт итү юлында көчне кызганмыйбыз,— диде.— Без үзебез дә театрны бөтен кеше каравын телибез. Ләкин бу нәрсә бүгенге көндә Имәнледә мөмкин булмады. Чөнки артистларга иркенләп чыгыш ясарлык бинагыз юк икән. Карагыз инде үзегез: шушындый җирдә куелырга тиешме театр?

Барысы да, өйнең кысанлыгын, бөркүлеген шунда гына белгәндәй, як-якларына каранып башларын иделәр.

Газзә җыелыш ачып бер генә мәсьәләне — элекке мәчет бинасында клуб ачу мәсьәләсен генә куйды. Каршы кул күтәрүчеләр булмады түгел, булды, ләкин алар берән-сәрән генә иде.

...Күмәк хуҗалыкның беренче зур җыелышы яңа клубта узды. Яшьләр аңа бик тырышып әзерләнделәр. Газзә, Гөлзәйнәп, Хәкимҗан абзый малае Габдулла, Гариф көннәр буе клубтан чыкмадылар.

Районнан Зиннур Гомәров, Серебров, Исмәгыйлов, землемер, агроном килгәндә, мәчет эче танымаслык булып үзгәргән иде: бөтен җир чистартып юылган, сәхнә ясалып, аңа озын өстәл куелган, түргә ак кәгазьгә кызыл буяу белән «Күмәк хезмәт яңа тормышка илтә» дигән лозунг язылган иде. Анысын Гариф язды — искиткеч пөхтә, тигез язды ул хәрефләрне. Залга халык утырыр өчен озын эскәмияләр ясап куелган иде.

Кич җитүгә унлы дүрт лампаны, куыкларын өр-яңадан чистартып, кабызып җибәрделәр.

Тыштан килеп кергән кешеләр бер мәлгә хәйран калып, елмаеп, я баш селкеп, я телләрен шартлатып куялар иде.

Халык каршында утырып, күп кешеләр белән берьюлы җитди сөйләшергә күнегеп килгән Газзә дә ул көнне нык дулкынланган, хәтта каушаган иде. Беренчедән, сәхнә биеклегенә күтәрелеп, халыктан ерагаеп утыру үзе бик тантаналы, рәсми тоелса, икенчедән, бу көнне Газзә үзенең зур эшенә йомгак ясый иде — чөнки җыелышта ширкәт урынына күмәк хуҗалык — колхоз төзү мәсьәләсе хәл ителәчәк иде.

Газзә, торып, ирексездән бераз калтыранган тавыш белән ширкәтнең ничек эшләгәнен сөйләде, милкен барлап чыкты. Агайлар сүз дәшмиләр, ләкин канәгать икәнлекләре йөзләреннән үк күренеп тора иде.

Аннары Зиннур Гомәров халыкка күмәк хуҗалыкның уставын укып чыкты. Мөгаллимнең крестьян күңелен аңлавы монда нык сизелде. Ул күмәк хуҗалыкка чәчкеч-ургыч, тырма-сабан ише эш коралларының һәм атларның, чәчүлек орлыкларның гына берләштереләчәген басым ясап әйтте. Нилэр буласын алдан ук сизенеп торган диярсең, агайлар-

ның кат-кат сорауларына һич иренми, ялыкмый җавап биреп, йортларның, ихаталарның, кош-кортның, сыер-сарык һәм мал-туарның һәркемнең үз кулында калачагын берничә тапкыр аңлатты.

Бары шуннан соң гына уставны тавышка куйдылар. Агайларның барысы да авыр эштән бирчәйгән кулларын колакларыннан чак кына югарырак күтәреп, үзләренең хуплавын белдерделәр. Күмәк хуҗалыкка җитмеш кеше керде.

Инде Газзә, өстеннән авыр бурыч төшкәндәй, җиңеләеп киткән иде. Инде үзе белән янәшә урындыкта залга төбәлеп утырган Бориска куанычын белдереп, елмаеп караган иде. Иртәрәк җиңеләеп киткән булып чыкты.

Агроном белән землемер чыгышыннан соң идарә сайланды. Председатель сайлар вакыт җитте. Әле беркем авыз ачарга өлгермәгән иде, бөтенесе уйга калган кебек иде: күрәсең, моны беркем дә алдан исәпләп куймаган иде. Шул чак Хәкимҗан абзый урыныннан күтәрелде.

— Газзәне баш итеп куярга кирәк, — диде ул тыныч кына итеп.— Ширкәттә әйбәт эшләде, халыкны тыңлата белә. Эшләсен, әйдә.

Газзә үз колакларына үзе ышанмады. Шул хәтле зур хуҗалыкка баш булыргамы? Булмас, булмас... Алайса нигә бөтенесе аңа карыйлар? Нигә Әхтәмнең күзләре шулай зур ачылды, йөзе үзгәрде?

Газзә эсселәнеп йон шәлен башыннан шудырып төшерде, аннары олы агайлар каршында ялан баш утыру килешмәгәнен искәреп, шәлен кире тартып куйды. Зиһенен җыярга тырышып урыныннан кузгалды:

— Абзыйлар... — диде. — Зур эш бит, олы кеше кирәктер монда... Мин яшь әле. Белемем дә җитәрлек түгел, хуҗалыкны алып баруда тәҗрибәм дә юк...

— Син сынатмыйсың, беләбез!

— Булса шул яшьләр кулыннан гына килә дә инде мондый эш!

— Уңганлыгың бар, грамотаң безнең ише генә түгел, — дип шаулаштылар агайлар.

Инде мәсьәләне хәл кылынган санап, кайсылары шаярыша да башлады:

— Хәкимҗанны куйыйкмы әллә? Ярамас, бар булган солыны үз биясенә ашатып бетерер.

— Үзең генә баш буласыңмы әллә?

Кинәт арткы рәттән яңгыраган тавыш бөтен шау-шуны басып китте:

— Дөрес! Газзә апаны куярга кирәк! Газзә апаны!— дип ярып салды.

Кара, Гариф бик тыйнак күренә иде, әйтер сүзе булганда шәрран ярып кычкыра да белә икән.

Аның бу тавышы еллар аша Газзәнең бөтен гомеренә ишетелерлек булып яңгырады. Шул көннән председательгә яше-карты олылап «Газзә апа» дип дәшә торган булды. Иманледә моңарчы берәүгә дә «апа» дип дәшмиләр, өлкәннәрне «түти» дип атыйлар иде. Ә «апа» — тоткан урыны, җаваплылыгы, дәрәҗәсе белән олы кешене белдертә торган сүз дип кабул ителде булса кирәк.

Инде яңа хуҗалыкка исем кушарга кирәк иде. Төрле тәкъдимнәр булды: «Якты юлга», «Алга», «Кызыл Иманле»...

— «Яшь көч»! — диде аяк өсте басып Әхтәм. — «Яшь көч» дип атыйк!

Агайлар сагаеп калдылар. «Яшь көч»? Бу ни дигән сүз? Колхозга картлар да керә бит! Ләкин шундук барысының да йөзләре ачылды. Колхозда өлкән яшьтәгеләр дә булса ни. Монда тормышның яшьлеге һәм көче турында сүз бара бит. Булсын! Яшь булсын, көч булсын!

Әхтәмнең тәкъдиме барысының да күңеленә хуш килде.

Җыелыштан соң идарә членнары киңәшергә калдылар. Хәкимҗан

абзый, Вәҗһетдин абзый, авылның тагын берничә мөхтәрәм кешесе сәхнәдәге өстәл тирәли тезелешеп утырдылар.

— Хөрмәтле агайлар, — диде Газзә. — Сез миңа бик зур ышаныч белдердегез. Мин бу эшне бары тик сезнең ярдәмегез белән генә, сезнең тәҗрибәгезгә, акылыгызга таянып кына ерып чыга алачакмын.

Ә кичектергесез хәл итәсе мәсьәләләр күп иде. Атларны, инвентарьларны кая җыярга? Фураж каян алырга? Тырма-сукаларны рәтләргә кемнәрне кушарга?

Хәзергә Елтыр Кашапның буш ихатасын күмәк хуҗалык өчен файдаланырга карар кылдылар. Атларны карау өчен җаваплы итеп комсомол Әхтәм Һадиевны билгеләделәр.

Сөйләшү озакка сузылды. Ләкин озатам дигән кешенең түземе җитә икән. Газзә урамга чыгуга, аның ике ягына ике егет килеп басты. Хәкимҗан Габдулласы белән Гариф.

— Сез нишләп урамда килеп сарып йөрисез әле?

— Бүген безнең чират, — диде Гариф Газзәгә аңлаешсыз ниндидер горурлык белән.

— Нинди чират ул тагын?

— Сине озатып куярга,— диде Гариф. Тагын нидер әйтмәкче иде, Габдулла чеметеп алды инде әллә үзен, ярты сүздә туктап калды.

Ләкин Газзә бу «чират»ның серенә төшенгән иде инде. Ул төннәрен җыелышлардан ялгыз кайтырга туры килгәндә артында аяк тавышлары ишеткәли иде. Баштарак Газзә куркып әйләнеп карангалады, соңрак аңлады: яшьләр аны саклый иде, аңа тагы кемнең дә булса һөҗүм итүеннән куркалар иде... «Их, Гариф, әгәр белсәң... әгәр дә син белсәң... Хәер, белмәвең мең яхшырак...». Башка кичләрдә Газзәне күбесенчә Әхтәм озата иде. Ләкин малайлар бу тантаналы көндә үз чиратларын аңа бирергә теләмәгәннәр, ахрысы. Газзәнең ачуы килә башлады:

— Бар, кайтып китегез! — диде ул үртәлеп. — Мине каравыллап йөрисе юк!

Малайлар арттарак калдылар, ләкин Газзә аларның аяк тавышларын өенә кайтып җиткәнче ишетеп барды.

Ярый әле, гашыйкларга очрашырга көн саен диярлек җай чыгып тора, алар һәр кичне клубка киләләр иде. Артист Шункарның теләге тормышка ашты, клуб ишегеннән йозак алып ташланды, чын театрдан үрнәк алып, авыл яшьләре үзләре дә спектакль куярга әзерләнә башладылар. «Беренче театр» пьесасын сайлап алдылар. Аңа декорация ясау, кием-салым булдыру, рольләрне ятлау язга хәтле сузылды. Газзәнең сәхнәдә әллә ни осталыгы табылмады — аңа суфлер вазифасын тапшырдылар.

Инде, ниһаять, иртәгә спектакльне халыкка күрсәтәбез дигән кичне Газзә клубка барыннан алда килеп лампаны яндырып куйды. Сәхнә артын каплап торган чаршауга суфлер өчен махсус тишек ясалган иде, тик, урындыкка утыргач, Газзәнең аңа буе җитми икән. Ул, урындыкка нәрсә куйыйм икән дип эзләнеп йөргәндә, сулуы кабып, Мәһруй килеп керде.

— Син нишләп монда йөрисең, Газзә?

Аның тавышында борчылу, аптырау ярылып ята иде.

— Репетициягә килдем менә. Әллә бер-бер хәл булдымы?

— Син белмисеңмени?

— Нәрсәне?

Мәһруй җавап бирмәде, икеләнеп калгандай булды. Аннары ниндидер карарга килгәндәй, катгый итеп:

— Әйдәле минем белән, — диде.

— Кая?

— Әйдә. Барыйк, аннары күрерсең. Әйдә инде, гомеремдә бер генә тапкыр сүземне тыңла инде!

Ничек итсә итте Мәһруй, Газзәне мәҗбүрән алып чыгып китте. Газзәгә кызык та иде, шул ук вакытта Мәһруйның куркуы, шомлануы аңа да йокты. Караңгы урамда кар шыгырдаган тавыш та бик ерακка ишетелә, ә Мәһруй йөгерә-атлый бара, Газзәне дә ашыктыра иде.

Аларның капкасына борылгач, Газзәнең гаҗәпләнүе чиктән ашты. Ник алып килде Мәһруй аны үз өйләренә болай ашыгып?

Кыям абзый өйдә юк иде. Мәһикамалтти кызын тиргәп каршылады:

— Кирәкмәгән эшкә кысылып йөрисең шунда,— диде.— Атаң ачуланыр!

Мәһруй ишек төбендә икеләнеп калган Газзәне эчкә, түр өйгә алып кереп китте.

Алар кышын алгы өйләренә генә ягалар, шунда гына торалар, шунлыктан түр өйләре баз шикелле салкын иде. Мәһруй анда чыра яндырып керде дә, мич башына менде. Газзәне дә янына чакырды. Чыра сүнде, алар икесе бер паласка төренеп, бер-берсенә елышып, караңгыда бераз тын утырдылар.

Мәһруйның тәне калтырый, ул еш-еш сулыш ала иде. Ниһаять, ул ярсып пышылдап, Газзә өчен һич көтелмәгәнчә сүз башлады:

— Минем дә сезнең белән бергә буласым килә, Газзә! Кырда бергә эшләр идем, уку йортына йөрер идем! Болай кешедән ким булып йөрүнең читенлекләрен белсәң икән? Өстәвенә театрында да көләләр тагын! Әти колхозга кермәгәнгә мин гаеплемени? Минем дә сезнең кебек буласым килә!

Менә сиңа мә! Көнбагыш чәчкәседәй нык, сәламәт, ата-ана кочагында кадердә генә үскән бердәнбер бала элекке батрак, ятимә Газзә язмышына кызыгып яши икән!

— Соң алайса үзең кер колхозга! Гариза яз да кер! — диде Газзә.

— Әти риза түгел бит! Колхоз дигәндә җене каршы тора! Бакчамны кумәкләштерерләр дә харап итәрләр, дип курка! Аңа карышып булмый бит!

Кыям абзыйның җимеш бакчасы — күмәк хуҗалык оештыру чорында тиз арада хәл итеп булмаган күп мәсьәләләрнең берсе иде. Чыннан да, нишләтергә аны? Ихата дип үзенә калдырсаң, уставка каршы килү була — мәйданы зур. Кисеп алабыз, дисәң, Кыям кулын кистерергә риза, әмма бер төп агачын да бирергә риза түгел.

Җыелышларда бу мәсьәләне кузгаткалап торучылар булса да, Газзә ашыгу ягында түгел, чөнки җирне яраткан, үсемлекләрне яраткан, тынгы белмәс, эшчән ул кеше белән кайчан да булса уртак тел табудан өметен өзми иде.

Катлаулы мәсьәлә иде бу. Мәһруй да кызганыч. Ләкин моны башка җирдә дә сөйләшеп була иде бит! Аның өчен генә салкын, караңгы өйнең мич башына менеп утыру ник кирәк? Җитмәсә, клубка яшьләр җыелгандыр, репетицияне башларга күптән вакыт.

— Сүзең шул гына идеме? — диде Газзә. — Мин китим әле.

— Сиңа моннан чыгарга ярамый, Газзә.

— Нишләп?

— Әхьяр абыйларда аерым хуҗалыклар җыелган иде. Гәзит укыйлар, колхозны таратырга кирәк, дип сөйлиләр. Комсомолларның арт сабагын укытып авылдан куарга кирәк, диючеләр дә бар. Синең исемне дә кычкырдылар анда.

Газзә шунда барын да аңлады. «Уңышлардан баш әйләнү» дигән мәкаләне ул газетадан көндез үк укып чыккан иде. Ләкин артык борчылырга сәбәп тапмады, чөнки монда язылган хаталарның күбесе бездә ясалмады бит дип, үз-үзен тынычландырды. Ул бу мәкаләне халыкка

киләсе җыелышта укып, аңлатып бирергә кирәк дип уйлап куйган иде. Димәк, ул аңлатканны көтеп тормаганнар...

Анда колхозга каршы коткы тараталар, ә Газзә монда мич башында качып ята булып чыгамыни инде? Ә халыкка дөреслекне кем аңлатыр?

Ул паласны селтәде дә мич башыннан идәнгә сикерде. Нидер шытырдап сынды, уң аяк ниндидер йомшак нәрсәгә кереп батты. Газзә йон оегын сыпырып, иснәп карады. Бал! Ул бал кисмәгенә баскан! Кыям абзыйның күз карасыдай саклап торган балына!

— Балыгызны харап кына иттем бит, Мәһруй! Баттым!

— Бәхетең мулдыр,— диде Мәһруй көлеп. Ул, күрәсең, Газзәнең әзгә булса да тоткарлануына шат иде.

Чыра яктысында бал тәпәнен рәтләп ябып куйдылар. Бер чүпрәк кисәге белән оекны чистарттылар. Газзә чабатасын кире кия башлады.

— Нишлисең син? — диде Мәһруй сәерсенеп. — Әллә китмәкче була инде?

— Халык янына барырга кирәк, Мәһруй, дөреслекне аңлатырга кирәк.

— Алайса мин дә синең белән,— диде Мәһруй кисәк кенә.— Бергә барабыз!

Кызлар алгы өйгә чыкканда, Кыям абзый үзе кайтып керде. Йонтәс сары кашлары астыннан Газзәгә сөзеп кенә карады да:

— Урамга чыгып йөрмәгез,— диде.— Халыкның таралган чагы.

— Таралдылар дамыни инде? — дип сорады Газзә борчылып.

— Ник, әллә сез дә шунда барырга җыендыгызмы? Сез генә җитмәгән, ди, анда. — Ул башын иеп торган Мәһруйга авыр итеп карап алды. — Әнә сезнең бер камсамулыгыз, Һади малае, сөйләп карамакчые анда. Тәрәзәдән көчкә чыгып ычкынды...

Газзә, аның сүзен тыңлап та бетермичә, урамга йөгереп чыгып китте. Юл уртасыннан килгән кешенең Әхтәм икәнен ул ерактан ук таныды. Алар бер-берсенә таба ашыктылар. Икесенең дә йөрәк түрендәге хисләре кайнап чыккан иде. Әхтәм кызны кочагына алды да дөньяның бөтен афәтләреннән саклагандай итте.

— Газзә... Газзүгем, мин сине эзләп йөри идем, — диде.

— Мин дә... — диде Газзә.

Караңгы төн ялтырап киткәндәй булды, ике күңел өмет, ышаныч, шатлык белән тулды.

Алар төн салкынын да сизмичә, аерыла алмыйча, озак сөйләшеп тордылар.

Төннең-төн буе иртәгесен кешеләр белән ничек сөйләшәсен, аларга нинди дәлилләр китерәсен, аларның күңелен ничек кузгатасын уйлап чыкты Газзә.

Таң белән колхоз өенә — элекке Кашаплар йортына — барып утырды. Аны гына көтеп торгандай, иртүк берәм-берәм агайлар килә башлады. Ләкин Газзәнең сүзләрен күңел биреп тыңлап торучы булмады. Алар председатель каршына өстәлгә гариза китереп салалар да, я почмакка, я идәнгә карап, пошмый гына көтеп торалар: Газзә кайчан сүзен бетерер дә гаризага кайчан кулын куяр. Бары тик майлы коймак кебек ялтырап торган түгәрәк чырайлы, ияк очына ябыштырып куйган төсле кечкенә сары сакаллы Әхьяр гына аның сүзен күзенә карап тыңлады. Ләкин тыңлап бетермәде:

— Син, Газзә, кичер инде, вакыт тарые,— диде.— Сөйләшкән чаклар булыр әле. Кулыңны куй да Әхтәмгә әйт, бияне бирсен.

Бер көн эчендә суырылып калган Әхтәм ул көнне уналты атны элеккә хуҗаларына тоттырып җибәрде.

Көндез Гөлзәйнәп кереп чыкты. Төнлә кемнәрдер клубның ишеген

ватып кергәннәр, мич тимерләрен алып юкка чыгарганнар, утыннарын Коры елгага чыгарып ыргытканнар, лампаларын алып киткәннәр икән.

Кичке якта ишектән Хәкимҗан абзый килеп кергәч, Газзә иң элек аның кулына карады: бу йортка бүген бөтен кеше гариза күтәреп керә иде.

— Фу-у, — диде Хәкимҗан абзый. Аның чал керә башлаган түгәрәк сакал-мыегы арасыннан пар йомгагы бөтерелеп чыкты. — Таракан катырасызмы әллә? Нишләп суыкта утырасың? Утын бар аркылы.

Ул кире чыкты, болдырдан аның:

— Әхтәм улым, утын алып кер әле! Мичкә ягып җибәрик! — дип кычкырганы ишетелде.

Бераздан алар янган мич каршында өчесе утыралар иде инде. Ялкын телләре күңелле биешә, чытырдап очкыннар чәчри, эссе һава бит очларын, күшеккән кулларны рәхәт җылыта иде. Хәкимҗан абзый бүреген салып түбәтәен артка шудырган, бишмәт төймәләрен ычкындырган, утка текәлгән килеш, ашыкмый гына, ягымлы итеп сөйли:

— Игенне бер көнне чәчеп, икенче көнне уракка чыгып булмый,— ди. — Әле аның тишелгәнен дүрт күз белән көтеп аласың, утыйсың, карыйсың. Анда да әле ул елы килсә генә уңа. Корылык булмаса, боз сукмаса гына.

— Хәзер ничек чәчәсебезне дә белеп булмый бит әле, — диде Газзә хәсрәтле көлемсерәп.

— Тормышта һәрнәрсә шулай. Иген иккән шикелле. Үз вакыты белән генә җитлегә. Син ашыга дип кенә вакытыннан элгәре үсми ул.

Нәкъ шул чакны, Хәкимҗан абзыйның сүзен раслагандай, әкрен генә ишек ачылды, Маһруй, җырлагандай сузып:

— Керергә ярыймы? — дип сорады.

Ул да булмады, ишекне шарт итеп ачып, Монтазима килеп керде.

— Моңарчы кыенсынып торадырыем, алып килергә байлык юк бит,— диде ул.— Ил җилкәсендә көн күрмәкче була бугай бу хәерче диярсез дип куркадырыем. Инде байлар калхуздан качып киткән, безнең ише хәлсезләр генә калган дип сөйлиләр. Болай булгач, мине үзегезнең янга алыгыз инде. Кешегә генә салынып ятмабыз, алла боерса. Гарифым да кул арасына керерлек булды инде.

— Атыгызны китердегезме? — дип сорады Әхтәм.

— Әй, хәләл мал булмады ла ул безгә, — дип кулын селтәде Монтазима. — Ат асрау буламы соң миннән! Ашатырга азыгы юк, янына бара алмыйм, көе юк. Үзең генә барып алып кил инде син аны.

Иртәгесен Әхтәм белән Гариф туры алашаны Коры елга буеннан табып алып килделәр. Тирес өеме тирәсендә чемченеп йөри икән бичара хайван. Хәкимҗан абзый аның тырпаеп торган кабыргаларын сыпыргалады да:

— Моны рәткә кертү өчен, ай-һай, күпме азык кирәк! — диде.

— Әнә, Гариф Әхтәмгә ярдәм итсен, — диде Газзә. — Башка атларны карарга да булышыр.

Малайның шатлыктан балкыган йөзен күреп аның бу эшкә атлыгып торганын аңлады.

Тормыш Хәкимҗан абзый сүзләрен раслады. Кызулык белән колхоздан чыгып киткән кешеләрнең кайберләре кире керде, язгы эшләргә керешкәндә, «Яшь көч»тә ике дистәгә якын хуҗалык бар иде инде. Әхтәм белән Гариф атларны бик тырышып караганнар, хәтта «Монтазима»ны да тырма тартыр хәлгә китергәннәр иде. (Беренче елларны колхоз атларын шулай элекке хуҗаларының исемнәре белән атап йөрттеләр, «Әхьяр», «Хәкимҗан» дигән бияләр бар иде. Бер-ике елдан гына, исләренә килеп, аларга башка кушамат тактылар.)

Клуб та тиз арада тәртипкә китерелде. Кичәләр элеккедән дә күңеллерәк үтә башлады.

Менә алар Октябрь бәйрәменә әзерләнәләр. Гөлзәйнәп һәр бәйрәмне театр куйгандагы шикелле нык хәзерлек белән җиренә җиткереп үткәрергә тырыша, кайчак юкка да артыгын борчыла иде. Ул егетләрдән лозунглар яздыра, шигырьләр ятлата, бөтен яшьләрне сафка тезеп, җыр өйрәтә. Әхтәм гармунын сыздырып җибәрә, егетләр, кызлар җыр башлыйлар:

Байлар йортны салдылар
Чыгарып балконнарын;
Сөбереп түктек Николайның
Чыгарган законнарын.

— Бердәмрәк! Дәртлерәк! — ди Гөлзәйнәп кулын селтәп. Әхтәмгә борылып: — Сузма-сузма, өздеребрәк уйна! — ди.

Машина килә пар белән,
Эче тулы мал белән;
Капиталга каршы барыйк
Интернационал белән.

Репетициясе үзенә күңелле, урамнан җырлап узулары тагын бер гомер. Махсус шул демонстрация өчен диярсең, бәйрәм көнгә җир каткан иде, аякка су үтәсе юк, җил туктаган, авылны галәм салкынныннан ышыклап, күк йөзенә юрган булып соры болыт ябылган. Ә яшьләр саф-саф тезелеп урамнан үткәндә балкып кояш чыккандай була. Алар клубтан чыгып басалар да югары очка таба баралар.

Камалов Галәветдин алга йөгереп чыга да: «Яшәсен колхозлар!» — дип кычкыра. «Ура!».. Капка төпләренә басып, тәрәзә пыялаларына борыннарын терәп калучыларны шаккатырып, горур басып узалар: карагыз! Күрегез! Көрәшчеләр килә, җиңүчеләр килә, Әхтәм уйнаган дәртле көйгә басып килә!

Биек тауның башларында
Тезелеп үскән әнисләр;
Тезелеп үскән әнис кебек
Яшәсен коммунистлар!

Ә кич клубта концерт. Шункар труппасына охшатып театр кую. Анда барыннан да уздырганы — Гөлзәйнәп. Ак кофтасы өстеннән озын кара толымнарын күкрәгенә салып, ике кул бармакларын бер-берсенә чалыштырып, сәхнә алдына ук килеп баса да күкрәк тавышы белән җырлап җибәрә — яшьләрнең иң шаяннары да тын алмыйча, җырчыга ияреп моң дәрьясында йөзәләр. Ә Донбасстан кайтып кына төшкән Таҗетдинне инде сөйләп торасы да юк — ул үзенең кайда утырганын да оныткан.

Барысы да Гөлзәйнәп әзерләгәнчә, ул дәфтәренә язып куйган план буенча барды. Тик кичәнең ахырында гына алдан уйламаган бер тамаша булып алды. Анысын Таҗетдин шахтер куйды.

Өстендә шәһәрчә ыспай тегелгән костюм, чалбар балаклары ялт итеп торган хром итек кунычларына тыгылган. Утызга җитеп килсә дә, киң җилкәсе, нык муены белән яшь-җилкенчәктән бераз аерылып торса да, мин арада өлкән бит дип артык вәкарь саклап маташмады, уртага сикереп чыкты да:

— Уйна әле, күрше, без бии торганнарын! — диде һәм китте биеп, китте биеп, Әхтәмнең бармаклары гына чыдасын! Авылда булмаганча кыланып, тезләренә, табаннарына, идәнгә учы белән суга-суга, үкчәләре белән киндер тукмаклаган тавышлар чыгарып бии бу.

— Их, минә минем шушылай итеп, хром итек киеп, Елтырлар турыннан биеп узасы килгән иде, — диде ул, тып итеп соңгы тапкыр басып куйгач.

— Нишләп Елтырлар турыннан гына?

— Әз биеткәннәр немә әллә?

— Әйдә, сөйләп җибәр, — диештеләр яшьләр.

Таҗетдин сәхнә кырыена җәйлап утырды, барысы да аңа сырыштылар. Бары тик Гөлзәйнәп кенә читтәрәк калды, ләкин ул да бөтен игътибарын шахтер егет сөйләгәннәргә юнәлткән иде, тик аны кешегә сиздермәскә генә тырыша үзе.

— Без яшь чакта клуб юк иде, әмма эчтә җан бар иде, — дип сүз башлады Таҗетдин. — Шулай Биекъяр җыены житеп килә, Харис дус белән безнең эчтә ут уйный бит, егетләр. Ник дисәгез, җыен базарына барып, күңел ачып кайтасы килә, ә өскә кияргә рәтле киемебез юк. Күлмәк-ыштан түзәрлек, тик менә аякларда чабата. Мыек чыгара башлаган егет башыбыз белән җыен базарында чабата киеп йөрү гарьлек бит инде! Нишләргә? Харис атын тапты, тарантасны Елтырдан сорап торырга булдык, әйдә, дибез, бер очтан аякка киеп торырга да бирәр нәрсә алып торабыз. Барыбер йөз суы түгәсе. Сорадык. Елтыр каршы килмәде. Өеннән икебезгә бер кием галош чыгарып тоттырды бу. Хакын хәзер үк сорамыйм, ди, хәлегезгә керәм, ди, печәнгә төшкәч, эшләп түләрсез, ди. Киттек без икебезгә бер кием галош киеп. Уңы — Хариста, сулы — миндә, Харис — уң аягын, мин — сулын тарантас кырыеннан салындырып куйдык, галошлар елык-елык килә, бу нинди бай малайлары диярсең! Хәтәр кәттә барып кердек базарга. Инде нишләргә, анда сыңар аяк белән йөреп булмый бит! Таптык чарасын. Харис галошларны киеп әйләнеп килгәнче, мин, аякларымны печәнгә яшереп, тарантаста утырам. Ул килгәч, галошларны мин киям, ул тарантаска менә. Шулай итеп, алмаш-тилмәш бәйрәм итеп, күңел ачып кайттык без. Елтырга тарантасын да, галошын да исән-имин кайтарып тапшырдык. Әзмекүпме вакыт үткән иде, Елтыр безне печән чабарга чакыра — тарантас белән галошны алып торган өчен хакын түләгез, ди. Түләдек, кая барасың! Тарантас өчен — биш көн, галош өчен ике көн — барысы бер атна буе Елтыр болынында бер караңгыдан икенче караңгыга чаклы тир түктек. Мәңге онытылмаслык итте Елтыр галошны! Шул чакта ант иткән идем, аягыма шәп итекләр алып киеп, турыннан биеп үтәрмен, дигән идем. Булмады!

— Элегрәк кайталар аны!

— Әллә кайда йөрмиләр!

— Син кайтканны көтеп торсаң, безгә дә мәңге галош эләкмәс!

Яшьләр шаулаша, көлешә. Гөлзәйнәп тыенкы гына елмаеп, сәхнә артында югала.

Тик нигәдер бу кичне искә алганда, Газзәнең күңел хатирәләрендә, җәйге елга суына килеп кушылган салкын чишмә кебек, үзенә бер аерым, ямансу агым да бар. Маһруйның яшькелт күзләреннән саркыган моң, сагыш ул.

Маһруй, гадәтенчә, җыр-уенга катнашмый, күзгә ташланмаска тырышып, почмакта дәшми-тынмый гына утыра. Эштә берәүне дә артыннан җиткермәгән бу кыз — колхозда аның турында көлтәне ургыч артыннан калышмый бәйләп бара дип сөйлиләр. Ә менә уен-көлкегә осталыгы юк.

Урыныннан кузгалмый, тавышын чыгармый утыра Маһруй клубта, ләкин Газзә аны бер генә минутка да онытмый, чөнки көнбагыш чәчәгенең һәр вакыт бер кояшка — гармунчыга карап торганын сизә, белә. Маһруйның йөзе Әхтәмнең һәр сүзеннән, һәр хәрәкәтеннән үзгәреп тора — моны күргән Газзәнең йөрәге чәнчеп-чәнчеп ала.

Ул чакта клубта чисталыкны, тәртипне саклау бурычы яшьләргә чиратлап йөкләтелә иде. Бу кичне ул эш өчен Маһруй җаваплы булып чыкты. Менә кичә тәмамланды, халык тарала башлады. Инде ишек төбендә тәмәке тарткан булып торган Таҗетдин дә, ниһаять, Гөлзәйнәбен көтеп алды, алар артларыннан гыйшык сөреме калдырып, чыгып киттеләр, клуб эчендә бары өч кеше генә калды. Әхтәм гармунын тартмага

салып маташа, Газзә аны көтә, Маһруй, тәмәке төпчеге калмасын дип, почмакларны караштырып йөри.

Утны сүндереп, өчесе бергә чыктылар, ишекне бикләгәч, нишләргә белми, уңайсызланып калдылар. Маһруй белән Әхтәм югары очта торалар, Газзәнең фатиры түбән очта иде.

— Әйдә, Газзүк, Маһруйны озатып куябыз...

— Кирәкмәс! — Маһруйның тавышы сынып киткәндәй булды. — Мин үзем генә... Үзем генә!

Ул йөгереп китте дә караңгыда югалды. Бераз вакыт дөп-дөп килгән аяк тавышлары гына ишетелеп торды.

Алар икесе җай гына атлап, Коры елгага таба киттеләр. Әхтәм, абына күрмә дип, Газзәнең беләгеннән тотып алды. Шул минутта алар моңсу көнбагыш чәчкәсен оныттылар.



## «Бигрәк матур пар икән...»

Нигә бу яшьлекнең гел кояшлы көннәре белән йолдызлы төннәрен генә искә төшерәсе килә икән?

Менә тагын күңел күзе алдында кояшлы көн, Газзә югары очка таба, моңарчы авылда ишетелмәгән гөрелдәү тавышы ягына йөгерә. Урамның урта бер җиреннән, күз күрмәгән җан иясе шикелле бөтен дөньяны ду китереп, трактор килә, авылга беренче трактор килә! Аның алдыннан да, артыннан да, янында да малайлар чаба, якын килергә куркып читтән генә этләр өреп кала, карчык-корчык «әстәгъфирулла»-сын укый, агайлар «бу ни эш кырыр тагын» дип мыегын сыпыра.

Ә Газзәнең күзе тракторда түгел, аның руленә ябышкан, тузан аша балкыган йөзле, зәңгәр күзле тракторчыда. Әхтәмне моннан өч ай гына элек укырга җибәргәннәр иде, әнә кара, тимер атка атланып, урамны дер селкетеп кайтып та керде! Ай, зур кеше булган Бармаксыз Һади малае, уңга-сулга карамый, председатель янында да, туктап та тормыйча, керфеген сирпеп сәламләп кенә узып китте, Газзә үзе генә аның кызарынганын сизеп калды.

Басу кырына җиткәч кенә, туктап, талчыккан кыяфәт белән ашыкмый гына җиргә төште Әхтәм. Аны шундук яшьләр, аннары салмак атларга тырышып килгән агайлар сырып алдылар, тракторын капшарга, үзенә мең төрле сорау яудырырга керештеләр.

— Барыгыз әле, аяк астында чуалмагыз, — диде Хәкимҗан абзый малай-шалайга.— Урам буйлап пырлап узу зур эш түгел, сөреп күрсәтсен әле ул безгә!

Тимер атның ничек итеп җир сөргәнен барысының да тизрәк күрәсе килә иде.

— Сабанга утырыгыз бераерегез, — диде Әхтәм.

— Кем соң инде сабанга утырып йөри! — диде Хәкимҗан абзый Әхтәмнең шуны да белмәгәненә ачуы чыгып. — Син дә утыр, мин дә утыр, сабанны да тартсын! Бик күп китә бит ул тракторга! Авырга килә!

Ни җитди кыланырга тырышса да, Әхтәм бу сүзләрдән көлми түзә алмады. Ә башкалар аның ник көлгәнен аңламады. Чыннан да сабанга утырмыйлар, аның янында йөриләр бит инде!

— Күрсәт нишләргә кирәген,— диде Хәкимҗан абзый.— Сабанны үзем карармын!

Газзә якынрак килеп:

— Бригадир кешегә сабанга ябышып йөрү килешеп бетмәс, Хәкимҗан абзый, — диде. — Аннан башка да эшең җитәрлек. Сабанга берәр яшьрәк кешене утыртырбыз.

Ул як-ягында «мине әйт!» тә «мине әйт!» дип ялынып караган егетләрне күрде. Инде Галәветдинне әйтәм дип авызын ачкан иде, егет

үзе дә, аның әйтәсен сизеп, тракторга таба бер-ике адым ясаган иде... Шул чак Газзәнең карашы, хатын-кызлар төркемендә, арттарак торган Маһруйның күзләре белән очрашты. Көнбагыш чәчкәседәй якты бу йөздә кызыгу да, ялвару да, өметсезлек тә ярылып ята иде. Газзә, аның тылсымына бирелгәндәй, берничә секунд шул күзләргә ихтыярсыз карап торды. Бүгенге куанычлы көндә ул һәркемнең, шул исәптән Маһруйның да, шат булуын тели, аны сөендерү Газзәнең ташып чыккан бәхетен тагын да арттырачак иде.

— Сабанга кызларыбыздан берсен утыртыйк без, — диде Газзә. — Кызларыбызның иң алдынгысын, уңганын. Әйдә, бу эштә дә сынап карасын үзен. Маһруйны утыртыйк сабанга. Ризамы син, Маһруй?

Маһруйның тулы иреннәре тетрәнде, ләкин берни әйтә алмады. Ул керфекләрен түбән төшерде. Хатын-кыз шаулашып:

— Бар инде! Чык тизрәк! Югыйсә берәр егет менеп утырыр! — дип, аны төрткәләп алга чыгардылар.

Әхтәм аңа эшнең асылын аңлата башлады. Сипкелләре чәчрәп сибелердәй пешеп чыккан кыз аны әллә аңлады, әллә юк.

Хәер, Әхтәм үзе дә шактый ук каушаган иде бугай. Трактор чыгымчы ат шикелле уңга-сулга боргаланды, беренче буразна кәкре-бөкре чыкты.

— Туктат! Туктат! Җирне харап итәсең! — дип трактор гөрелтесен күмеп кычкырды Хәкимҗан абзый.

Китте көлү, китте шаяру. Әхтәм, буразнага борылып карарга оялып, башын иеп утырды. Инде ничек итеп бу трактор дигән хайванны буразнаны бозмаска өйрәтергә? Тотындылар киңәш-табыш итәргә. Ахырда җирнең аргы башына, ак яулык тоттырып, Галәветдинне бастырып куйдылар. Әмма трактор ак яулыкка да туп-туры барырга теләмәде. Ниһаять, Хәкимҗан абзый:

— Туп-туры минем арттан бар, — дип, кулларын артка куеп, сызганган балаклары астыннан чыгып торган каралган балтырлы, бирчәйгән үкчәле ялан аяклары белән салмак кына басып, җир буйлап китте. Хәкимҗан абзый җеп сузгандай туры йөри иде инде. Трактор да, аның эзеннән чыгарга курыккандай, туп-туры китте.

Алар шулай җирне әллә ничә кат әйләнделәр: алдан Хәкимҗан абзый, аның артыннан Әхтәм, Маһруй утырган сабан, алар артыннан бала-чага, ир-ат, хатын-кыз. Трактор әйтерсең лә рулен тоткан Әхтәмгә түгел, җир буйлап салмак кына атлаган авыл агаеның ихтыярына буйсына иде.

Шактый ук сәер, ләкин шул ук вакытта гаҗәп зирәк, акыллы кеше иде ул Хәкимҗан абзый. Әгәр андыйлар белән чын мәгънәсендә яхшы мөнәсәбәт урнаштыра алмаса, аларның киңәшенә, акылына, тәҗрибәсенә таянмаса, ай-һай ла, Газзә ялгыз гына эшне уңышлы алып бара алыр идеме икән!

Хәкимҗан абзый колхозның агрономы да, землемеры да, лабораториясе дә иде. Басуларның аркылысын-буен адым белән үлчи, чутын ялгышмас өчен, балагы сызганган күксел ыштан кесәсенә кура сындырып тыгып бара иде — ул уку-язуга өйрәнә алмады. Идарәгә кайткач шул кураларын өстәлгә чыгарып куя һәм кайсы басуның ничә гектар икәнен төп-төгәл итеп әйтеп бирә. Шунда ук:

— Менә бу ястык җиргә көл кертсәк иллә дә әйбәт булыр иде, рәхмәт төшкере, — ди. «Ястык җир» дигәне, аныңча, озынчарак басу дигән сүз иде.— Ә Таштүбәгә тирес кирәк, тирес. Кыштан анда ныклап кар тотарбыз моннан ары. Язгы су ашый аның ашын.

Аның киңәшен тотып кайчан да булса ялгышканын хәтерләми Газзә. Хәкимҗан абзый киңәшен тотып, алар, авыл картларын, бигрәк тә колхозга каршыларын, яхшы атларга утыртып, «Яңа тормыш» совхозына җибәргәннәр иде. Күмәк тормышның нәтиҗәләрен үз күзләре белән

күргәч, бөтенләй үзгәреп кайтты агайлар. Хәкимҗан абзый үзе дә бик нык уйланып йөрде аннан соң. Бер көнне алар Газзә белән икесе басуларны карап кайтырга чыккан иде. Таштүбәгә менделәр, Хәкимҗан абзый, көрәнсу учы белән күзләрен кояштан ышыклап, тирә-юньгә карады да иркен сулыш алып:

— И-их, бу җирләрне бер кулга туплап, эшнең рәтен белеп кенә алып барсак! — диде. — Бөтен халыкны алпавыттай баетып булырые үзе дә. Өстәлдән күмәч, өстән ефәк төшмәсие.

Хәкимҗан абзыйның бу изге максатына табигать үзе дә теләктәшлек күрсәтә иде кебек. Июль башында, игеннәр өлгереп кенә килгәндә, бик хәтәр давыл чыгып, боз яуды. Авыл халкының йөзеннән елмаю качты. Тик бер генә нәрсә халыкка юаныч бирде: күпме игеннәрне кара туфракка әйләндергән шул афәт, ни хикмәттер, «Яшь көч»нең басуларын читләтеп узган иде.

Ләкин ел ничек кенә яхшы килмәсен, табигать ничек кенә мәрхәмәтле булмасын, игенченең маңгай тире таммаган туфракта ашлык каерылып уңмый. Ә алар халыкны эшкә күтәрә белделәр. Хезмәтне оештырганда Хәкимҗан абзый кебекләрнең сабыр акылы, төпле сүзе белән Газзә кебекләрнең яшьлек ашкынуы бергә кушылды.

Клуб мәйданында һәр яз саен чәчүгә чыгар алдыннан маневрлар уза иде. Атларны кыштан ук аерым кешеләргә беркетеп куялар, һәркем үзенә беркетелгән малны карый, ашата, чистарта, сбруен әзерли, сабан-тырмасын ремонтлый. Чәчү алдыннан хәтта председатель үзе дә районга җәяү йөри, аңа да ат бирмиләр иде.

Ул ике бригада арасында купкан ярышны хәзер елмаймыйча искә төшереп тә булмый. Ярыш кына булмады ул — җан-фәрман узышуга әйләнде. Китте алар арасында көнчелек, дәгъвалашу — чыдап кына тор! Бодай утарга чыккан беренче бригада хатыннары көн яктырганчы басуга килеп җитсәләр, ни күрсеннәр: күрше бригада җирендә шәүләләр бар икән! «И, Хәкимҗан бригадасы эшкә тотынган да», — диләр. Көнчелекләре куба боларның. Якынрак килеп карасалар, «күрше бригада» дигәннәре ызандагы шайтан таякларының шәүләсе икән. Кояш чыккач эшкә килгән Хәтирәне, соңга калгансың дип, басуга кертмәгәннәр иде. Ни үгетләп карады Газзә хатыннарны, ни аңлатты, бер юлга гафу итик, олы кеше бит, диде. Тыңламадылар. Бичара Хәтирәттә, күзен алъяпкыч белән сөртә-сөртә, хурлык юлыннан атлагандай бөрешеп, авылга кире кайтып китте...

Берничә елдан «Яшь көч»нең даны башкалага ук барып җитте. Бер заман авылга, өч арбага төялеп, әллә ни хикмәтле аппаратлары белән кино төшерүчеләр килде. Алар яздан үткәрелгән маневрны тагын кабатларга мәҗбүр иттеләр. Клуб янындагы баганага асылган иске сабан төрәненә Хәкимҗан абзый нәкъ яз көнендәгечә итеп таяк белән зыңгылдатып китереп сукты, егетләр һәркайсы үзләренең җигүле атларын китереп бастырдылар, өлкәннәр һәркемнең атын, сбруен, сабан-тырмасын тикшереп чыкты, эш нормаларын белүен ачыкладылар. Иң яхшы дип табылганнарга бүләкләр — күлмәклек ситса, кызлар әзерләгән сөлгеләр тапшырылды.

Киночылар хикмәтле аппаратларын әле фермага, әле клубка ташыттылар, авыл урамнарын, яңа йортларны төшерделәр. Әхтәмнәрнең яңа өен сурәткә алыр өчен генә дә ярты көн азапландылар. Хәтирәттине аптыратып бетерделәр. Басуга барганда Хәкимҗан абзыйга итек киярга куштылар, кызларның яулыгын борынгыча итеп бәйләттеләр.

Игътибарның иң зурысы Маһруйга эләкте. Әхтәмнең тракторы киночыларның аппараты каршында ике көн әрле-бирле йөрде. Әхтәмне рульгә, Маһруйны сабанга утыртып кына түгел, алар янына Хәкимҗан абзыйны бастырып та — киңәшләшәләр, имеш! тракторчы белән плугарь башларын-башка тигезеп, моторга иелгән хәлдә дә — ремонтлый-

лар, янэсе! төшерделәр. Газзәнең колагына сыек гәүдәле яшь оператор егетнең, Әхтәм белән Маһруй турында: «Бигрәк матур пар икән!» — дигән сүзләре чалынып үтте...

Дөрес, председательнең үзенә дә аерым көн багышланды. Газзә гөжләп торган аппаратның җансыз күзенә карап, бик озак сөйләде, басу уртасына чыгып, башаклар учлап, елмаеп басып торды. Элегрәк Газзә тәкъдиме буенча ясалган күчмә кыр станнарына, күчмә балалар яслеләренә бардылар, аларны да сурәткә алдылар. Ләкин, аңа калса, бу күренешләр Маһруй төшкәнгә карагаңда кызыксызрак иде шикелле.

Егет хәзер МТСта эшли, авылдан-авылга йөри, ә «Яшь көч»кә килсә, аңа плугарь булып Маһруй чыга. Аны бу эшкә башта Газзә үзе тәкъдим итте, кыз аңа атылып тора, шунлыктан бу кагыйдәне хәзер үзгәртеп булмый иде. Кышын Әхтәм Биекъярда трактор ремонтлый, ул авылга кайткан чакларда председатель я җыелышта, я Аксуда утырышта була.

Алар бер-берсен күреп туймадылар, бер-берсенең күңелләрен аңлап, белеп бетерә алмадылар.

Көнлдә бер көн — Әхтәмне армиягә алдылар. Гармунчының хәле мәгълүм: армиягә китүче егетләр аңсыз бер адым да атламыйлар. Әхтәм кичләр буе табыннарда утырды, төннәр буе урам әйләнде.

Газзә, бер иркенләп сөйләшми дә калабыз, ахры, дип курыккан иде. Ләкин Әхтәм сөйгәнен оныта торган егет идеме?

— Онытма мине, Газзүк, — диде. — Хат язып тор. Көт, яме! Үзеңне нәчәлник санап, миңа ким итеп карама!..

Ни сөйли ул? Шундый сүз әйтергә ничек теле әйләнә? Ничек инде ул Газзәдән ким булсын, ничек Газзә алай уйлый алсын? Әнә бит ул нинди зур, нинди көчле! Кулларының куәте йомшак итеп орынганда да сизелә, күзләренең нуры караңгылыкны яктыртып сирпелә. Үзеңне шул кеше янында көчсез, кечкенә итеп тою, аның синең хакка җанын фида кылырга әзер торуын белү, аның күзләренә кояшка карагандай үрелеп карау, шул ук вакытта аның сиңа буйсыначагын сизү нинди бәхет! Әхтәмнең татлы сулышыннан баш әйләнә, аяк астында җир бишектәй тирбәлә...

— Көтәм... Әхтәм... көтәм... — дип пышылдады Газзә.

Иртәгесен ул, олаулар югары очтан чыгып урман юлына кереп киткәнче, капка төбеннән карап калды. Аннары идарәгә кереп урынына утырган гына иде, ишектә Маһруй күренде.

— Газзә, мине мытыеска җибәр инде син, — диде.

— Нишләп алай? Колхоз эшеннән туйдыңмыни?

— Мин тракторны өйрәндем инде, ремонтлый да беләм,— диде Маһруй аның соравына җавап бирмичә.— Барып сынавын гына тапшырам да, рульгә утырам. Анда безнең тракторны белер-белмәс кешегә бирсәләр, бер җайдә юкка чыгарып ташларлар...

Әйе, шулай, «безнең трактор» диде ул.

Ике кыз бер-берсенең күзләренә туп-туры карап тордылар. Алар икесе бер егетне көтәчәкләр иде. Тик Маһруй болай гына түгел, аның тракторын саклап, аның эшен дәвам итеп торачак.

Газзә аның юлына аркылы баса алмады. Үз кулы белән МТС директорына үтенеч язып җибәрде.

Ләкин өчпочмаклы хатлар бары тик аңа — Газзәгә генә килеп торды. Адресы кәкре-бөкре хәрефләр белән сызгаланган ул хатларны Газзәгә китереп биргәндә, почтальон Бармаксыз Һади, салам төсле керфекләрен аска төшереп, астан гына елмая иде. Нихәтле генә бозып язса да, ата үз улының кулын танымыймы соң?

Егетнең хатлары сагыну-сагыш белән тулы, ул «кайтыр көннәрне санап торам», «кайту белән туйлар ясап, бергә булырбыз, син каршы булмассың бит, Газзүгем?» — дип яза торган иде.

Газзәнең җаваплары озын була, әмма сөйләр сүзләре хат битләренә барыбер сыеп бетми иде. Ул хатлар «көтәм, сагынам» сүзләреннән бигрәк, үз башыннан кичкән онытылмаслык вакыйгалар, куанычлар белән тулы була иде. «Әхтәм, җаным, Татарстан республикасына Ленин орденын тапшырган тантаналы җыелышта безнең «Яшь көч»не дә мактап телгә алдылар. Менә үзең укып кара, газетасын да салам. Син тәкъдим иткән исем еракларга яңгырады бит, Әхтәм!» «Әхтәм, синең тракторыңда Маһруй эшли хәзер, әле МТСта беренчелекне алганын ишеттем!» Күңелендәге көнчелек хисен җиңеп монысын да язды Газзә. Маһруйга карата гадел булырга тырышты. Әхтәм белеп торсын, ул мактасын өчен шулай тырышып эшли иде бит инде ул кыз! Ярый әле, Газзәнең үзенең дә мактанып, горурланып эшләре җитәрлек иде. «Әхтәмем, әле Казаннан кайтып кына төштем дә, синең хатларыңның өчесен берьюлы алып укыдым. Минем кайтканымны көтеп ятканнар. Куаныч өстенә куаныч булды. Мин колхозчы ударникларның Беренче бөтен Татарстан съездына катнаштым, Әхтәм! Менә кара, карточкамны да җибәрәм. Күрәсеңме мине, Калинин бабай янында ук диярлек утырам!..» «Әхтәмем! Әле һаман үз бәхетемә үзем ышанып җитә алмыйм: өлкә конференциясендә мине партия съездына делегат итеп сайладылар. Мин Мәскәүгә, съездга барачакмын, Әхтәм!»

Ә менә съездга баруларны тасвирлап язып бирү өчен хатларга салырлык кәгазь битләре генә җитмәде. Аларның бөртеген дә онытмыйча, Әхтәм белән очрашкач сөйләрмен дип, Газзә аерым дәфтәргә язып барды.

Поездда баруларны, иге-чиге күренмәгән Мәскәү каласының шаугөр килеп торган, күз күреме җитмәс, озын, киң урамнарын, андагы хикмәтле машиналарны, Кызыл мәйданны, Кремль курантлары авазын, Мавзолейны, Зур театрны... Кремль капкасыннан, аннары Зур Кремль сараендагы утырышлар залына елга кебек тоташ агым булып кергән халыкны... Элекке патша сарайларының зиннәтле бүлмәләрен, залларны... Съездда Татарстан делегациясенең, орденлы республика вәкилләре буларак, президиумга якын ук утырганын... Барыннан да бигрәк, үзенең президиумга менеп, Калинин белән сөйләшкәнен...

Утырышлар вакытында, исемнәре, рәвешләре күптән таныш җитәкчеләрнең һәр хәрәкәтен, йөз чалымнарын, үз-үзен тотышын хәтеренә сеңдерергә тырышып, керфек кагарга куркып утырды Газзә.

Тәнәфес игълан ителеп халык залдан чыга башлагач, ул агымга каршы, президиумга таба китте. Сталин, Орджоникидзе, Ворошилов, Куйбышев, Калинин сөйләшә-сөйләшә президиумнан чыгып баралар иде. Газзә һаман якынрак килә, һаман аларны күзәтә. Аның карашын сизде бугай, Калинин борылып карады, чак кына елмаеп, бер кешене чакырып китерде дә, залга ымлап нидер әйтте, Ворошилов белән сөйләшеп алды.

Газзә артыннан тагын бер делегат кыз килә икән, ул:

— Сине Калинин чакыра, — дип пышылдады.

Газзә аңа борылмый гына пышылдап җавап бирде:

— Нишләп мине чакырсын ул! Мине белми-танымый да ич ул...

Ул Калининның күзлек аркылы елмаеп аңа карап торганын үзе дә сизә, ләкин һаман ышанып җитә алмый, минем арттагы берәр кешегә елмаядыр дип уйлый иде. Ул арада Калинин белән сөйләшкән теге яшь егет президиумнан йөгереп төште, Газзә янына килде һәм җитди, итагатьле итеп шома чәчле башын иеп:

— Сезне Михаил Иванович чакыра, — диде.

Газзә президиумга таба китте. Залдагы бар халык, алай гына да түгел, Илнең бөтен кешесе бу минутта гел аңа гына карап торадыр сыман тоелды. Баскычтан менгәндә, аның башында бер генә уй булды: «И ходаем, сөртенеп егылмасам гына ярар иде!»

— Исәнмесез! — диде ул, каушаганын сиздермәскә тырышып, ләкин тавышының кирәгеннән артык көчле яңгыраганын тоеп, югалып калды.

— Исәнмесез, саумысыз, — дип, күзләрен кысып елмайды Калинин. — Сез Татарстаннан бит әле?

Һәм кулы белән ишарәләп, Газзәгә урын күрсәтте, үзе аның каршысына утырды.

— Әйе.— Газзә яны белән урындык кырыена утырды.

— Кем булып эшлисез әле сез?

— Колхоз председателе. — Аннары сүзен: — «Яшь көч» колхозы председателе, — дип төзәтте.

Калинин күңелләнеп Ворошиловка борылды:

— Ишеттегезме? «Яшь көч» колхозы председателе! — Аннары тагын Газзәдән:

— Ничә ел эшлисез инде? — дип сорады.

— Бишенче ел китте.

— Көч җитәме соң?

— Тырышабыз, Михаил Иванович.

— Ә үзегезгә ничә яшь?

— Егерме ике.

— Яшь шул әле сез.

Михаил Иванович, иелә төшеп, ай-һай дигәндәй, сынап карады. Соңыннан, бу минутларны исенә төшергәндә, Газзә ул чакта мин Калинин күзенә ниндирәк булып күрендем икән, дип кат-кат уйлана, үзенең шул чактагы кыяфәтен күз алдына китерергә тырыша иде.

Газзә буйга зур үсә алмады. Шуңа күрә, нык, таза булса да, ул беренче карашка яшүсмер кебегрәк кенә күренә иде. Күп вакытын кырда, саф һавада уздырганга, аның түгәрәк бит очлары гадәттә янып тора, ә президиумга менгәндә тәмам пешеп чыккан иде. Колак яфраклары турыннан тигезләп киселгән куе, кара чәче шома итеп артка тарап куелган иде. Өстендә акка вак зәңгәр бизәк төшкән бумазн күлмәк белән зәңгәр кофта, аягында өр-яңа кара ботинкалар.

— Авыр түгелме соң «Яшь көч» дигән зур хуҗалык белән җитәкчелек итүе? — дип сорады Калинин.

— Өйрәнеп киләм инде.

Калинин аннан колхоз хәлләрен сораша башлады: узган елны күпме уңыш җыйганнар, күпмесен хөкүмәткә тапшырганнар, калганын ничек бүлгәннәр.

Очлы сакаллы, озынча, җыйнак йөзле, үткен һәм ягымлы карашлы бу олуг кеше янында Газзә авылның могтәбәр агайлары белән, Хәкимҗан абзый белән сөйләшкәндәй, үзен иркен сизә башлады. Михаил Иванович үзе дә авылдан, крестьян гаиләсеннән чыккан бит, шулай булу гаҗәпмени.... Газзә инде, русча бик үк дөрес сөйли белмим дип куркуын да оныткан, әмма әйтергә теләгәнен мәгънәсен төгәл, аңлаешлы итеп җиткерергә тырыша. Ул арада фотограф йөгереп килеп аларны рәсемгә төшереп алды, Газзә янына республика җитәкчеләре килеп бастылар.

— Колхозчыларны тынлатып буламы соң? — дип сорады Калинин, шаяртып әйткәндәй генә итеп.

Газзә житди җавап бирде:

— Тыңлыйлар, Михаил Иванович. Коммунистларның абруе югары бездә.

Калинин республика җитәкчеләренә карап:

— Укытырга кирәк бу кызны, — диде.

Газзәнең күңелен үтәли күргәндәй итте ул — чөнки зур мәктәпкә кереп, нигезле белем алу — кызның күптәнге хыялы иде.

Кичен гостиницага кайткач, ул боларның барысын да көндәлек дәфтәренә бәйнә-бәйнә теркәп утырды. Ләкин язганнар гына һич җитмәс, Әхтәмгә барыбер күбесен телдән сөйләп бирергә туры киләчәк иде.

Авылда аны сәке өсте тулы хат көтә иде. Аның артыннан ук үкчәсенә басып диярлек килеп кергән почтальон Һади абзый, исәнлек-саулык та сорамыйча, гадәттәге елмаюны да онытып, тагын бер букча конверт бушатты.

— Инде үзең кайткансың икән, аллага шөкер,— диде.— Моннан ары бу хатларны ташырга ат бирерсең инде. Мин генә күтәрерлек түгел.

Газзә бер конвертны алып ачты, икенчесен. «Исәнмесез, миңа таныш булмаган Газзә! «Комсомольская правда» газетасында сезнең Калинин белән кара-каршы утырып төшкән фоторәсемегезне күрдем дә, язмый түзә алмадым. Мин сезнең яшьтәге бер кыз...» — «Исәнмесез, Газзә! Рөхсәтсез хат язуым өчен гаеп итмәгез. Мин солдат, быел хәрби хезмәтемне тәмамлап кайтам. Сезнең авылга барыр өчен, кайсы станциядә төшеп каласы?..»

Бу өем арасыннан Әхтәмнең хатларын Газзә көчкә табып алды, ул, бичара, этисеннән сер яшерәм дип, конвертка адресларны кулын бозып яза, ә үз адресын бөтенләй күрсәтми иде. «Озакламый кайтам, Газзүгем, кавышыр көннәргә озак калмады, туйга әзерләнә тор», — дип язган иде егет.

Ә кызны, съездда күргәннәрен-кичергәннәрен сөйләтеп, авылданавылга йөртә башладылар. Әхтәм өчен генә дип бөртекләп язылган истәлек дәфтәре кат-кат укылды, кадерле истәлек җыелышларда күп сөйләнде, тик аларны күңел теләгәнчә итеп Әхтәмгә сөйләргә генә насыйп булмады.

Газзә сөйгәненең армиядән кайтканын да каршылый алмады. Чөнки нәкъ шул көнне Биекъяр МТСында чыгыш ясарга киткән иде.

Икенче көнне кичкә таба ул Биекъярдан кайтып килә иде. Хәкимҗан абзый элекке «Монтазима», хәзер «Байкал» кушаматлы атны үз көенә җибәргән, арба тәгәрмәчләре инде бозланып чыраган юлдан күңелле генә тәгәри иде. Инде авылга җитәбез дигәндә, яфраклары саргайган яшь каеннар арасында, шинель чабуларын җилбәгәй җибәргән солдат күренде.

— Исәнме, Хәкимҗан абзый! — дип кычкырды да, тарантас басмачасына менеп, Газзәгә ике кулын сузды ул.

— Кайттым бит, Газзүгем!

— Әхтәм! Исәнме, Әхтәм!

— Каршы чыктым менә. Күңелем сиздe син кайтасын!

Ул Газзә белән янәшә утырды. Әйтер сүзләр бик күп иде, тик бу минутта икесе дә дулкынланудан ни дияргә белми югалып калдылар. Юл да бик кыска тоелды, исләренә килгәнче, авыл очына барып та җиткәннәр.

— Мин үзебезнекеләргә туйга әзер торыгыз дип әйттем инде, — дип пышылдады Әхтәм.— Кич килермен, сөйләшербез.

Шулай дип, өйләре турында сикереп төшеп калды.

Караңгы төшкәч, алар тагын Коры елга өянкеләре төшенә чыгып бастылар. Әхтәмгә әйтәсе сүз ничаклы гына авыр булмасын, аны кичектерү мөмкин түгел иде, чөнки егет үзе ашыктыра, әйдә бүген үк безгә, дип, ай-вайга куймый иде.

— Мин укырга китәм, Әхтәм,— диде Газзә авырлык белән.— Миңа укырга кирәк.

Әхтәм башта аны аңламый торды:

— Ничек инде укырга? Кая китмәкче буласың? Ә вәгъдәләрең? Ә хатларың? Көтәм дигән сүзләрең? Алар барысы да ялганмыни?

Газзә: «Ул бит ике-өч елга гына, аннары кайтам мин», — дип сөйгәненең күңелен йомшартмакчы булды.

— Кайтырлык та булгач, ник китәсең алайса? Авылда эшләү өчен генә белемең җитә бит синең! Юк-юк, син миңа дөресен сөйләмисең. Нидер яшерәсең, нәрсәдер боргаланасың? Әйтәм аны, олау-олау хат

килә, диләр, юкка гына түгел икән. Үскәнсең инде алайса, культурный егет сайламакчы буласың!

Алар берсе дә араны кырт өзәргә теләми иде, билгеле. Ләкин шул ук вакытта бер-берсен аңлый да алмадылар. Ул кичне икесе дә тыелырга тырыштылар, киләчәккә өметне тәмам кисәргә берсенең дә йөрәге җитмәде. Шуңа күрә артык озак бәхәсләшергә тиеш түгеллеген аңлап, үпкәләшүләрне артык тирәнгә җибәрмичә, рәнҗүләрне эчкә йотып аерылыштылар.

Ә аннары алар бер-берсенең сүз башлавын, яки һич булмаса, сүз башларга берәр сәбәп табуын көтеп, шактый вакыт очрашмыйча, сөйләшмичә йөрделәр.

Ул арада колхозның исәп-хисап җыелышы килеп җитте. Анда председатель итеп Газзәне түгел, Таҗетдинне тәкъдим иткәч, күпләр гаҗәпкә калдылар: Газзәнең укырга китәсен бик әз кеше генә белә иде әле. Иң элек кайнар Вәҗи чәчрәп чыкты:

— Укыды бит инде, бик күп укыды Газзә, — диде. — Аксуга да йөрде, курсыга да барды! Урысчасын дисеңме, татарчасынмы, сөйли башласа теле-телгә йокмый. Аның чаклы укыган бармы бездә тагын? Булыр, каян булсын ул!

Аның сүзен җөпләп:

— Үзебездә генә укысын, крәчин табып бирербез!

— Радиодан укысын!

— Килеп укытыгыз Газзә апаны! — дип кычкырыштылар.

Хәкимҗан абзый торып баскач кына тынычланды зал.

— Яшьләрнең күтәрелә торган заманы, каршы торып булмас инде, җәмәгать, — диде ул. — Без инде аны хезмәтенә лаек хөрмәт белән озата да белик. Нәрсә белән эшне башлап җибәргән идек без колхозда беренче язны? Ун пар ат белән. Ун пар! Ә хәзер тайларыбыз гына да дүрт дистәдән артык әнә. Басуларга сортлы иген чәчәбез, күпме кеше яңа йорт салып керде, күпме абзар-кура җиткерелде: икмәк амбарлары, ат абзарлары, тавык, сыер, куян фермалары... Колхозның умартачылыгы, яшелчәчелеге, күчмә кыр станнары, яслесе бар. Бөтенесенә прсидәтелнең көче керде. Рәхмәт әйтик аңарга!

Дәррәү кул чаптылар. Ул да булмый, клуб ишеген каерып ачып, тигез сафлар белән, бәйрәмчә киенгән, кызыл галстуклар таккан пионерлар килеп керде. Сәхнәгә чыгып бастылар, тотындылар залны яңгыратып шигырь укырга, җырлар җырларга. Барысында да Газзә мактала, аңа дан җырлана, аңа саубуллашу сүзләре әйтелә. Газзәгә бераз уңайсыз да, моңсу да, йөрәк сөенечтән, аерылышу сагышыннан талпына, сызлана.

Таҗетдин Гөлзәйнәпкә аның китәсен алдан ук әйтеп куйган, Гөлзәйнәп исә, гадәтенчә, бу кичкә бик ныгытып әзерләнгән икән.

Җыелыштан соң яшьләр Газзәне озата барды, гадәттәге сизгерлекләрен югалтып, аларны Әхтәм белән икәүдән-икәү калдыру тиешлеген онытып, алар озак шаулашып тордылар. Ниһаять, кинәт исләренә килеп көлешә-көлешә таралыштылар.

... Коры елга өянкеләре тәмам диярлек шәрәләнеп калган, кара ботак араларыннан гына ерак, тынсыз, битараф йолдызлар карый иде.

Әхтәм шинель кесәсеннән папирос алып кабызды, йотылып бер-ике суырды да, аны җиргә ташлап, күн итек үкчәсе белән туфракка изеп басты.

— Газзә, Газзүгем, — диде егет кызның иңнәреннән тотып һәм иелеп күзләренә карады. — Әйдә, киттек безгә, Газзүк. Аннары уйларбыз калганын.

— Әхтәм!

— Соң алайса, әйдә язылышып кайтабыз.

— Юк инде, ничек инде... Мәнә мин укып кайтыйм башта. Ике ел гына бит.

Әхтәм үрсәләнеп өянкегә сөялде. Тагын папирос чыгарды.

— Бер китсәң кайтырга китмисең инде. Сине монда җибәрәләрме соң! Анда сине тотып калырдайраклар миннән башка да табылыр!

— Ни сөйлисең син, Әхтәм! Ничек телең бара!

— Нәрсә, әллә дөрес түгелме? Ә ник соң син миңа болай суындың! Бөтенләй бүтән кеше булгансың бит, танырлык та түгел. Алыштырып куйганнармыни!.. Газзә! Газзүк! Әйт сүзеңне! Соңгысын әйт! Кайтасыңмы минем белән? Я Аксуга барыйкмы?

— Әйтәм бит, Әхтәм, алай булмый бит!

— Булмыймы? Шушымы синең соңгы сүзең? Соңыннан үкенмәссеңме?

— Әхтәм! Аңла!..

— Аңладым инде! Хуш! Миңа рәнҗеп калма! Үзеңә үпкәлә!

Ах, әгәр шунда Газзә аңа йөрәген ачып күрсәтә алган булса! Бәгырькәйләренең ничек пәрә-пәрә килгәнен аңлатып бирә алса!

Ләкин Әхтәм ашыгып-ярсып китеп барды, ә Газзә аны туктатырлык сүзләр таба алмады.

... Иртәгесен ул көн буе яңа председательгә эш тапшырып, фермалар, абзарлар, ындыр табаклары буйлап йөрде. Көн буена, элекке гадәтне куып, аңа йомыш белән килә тордылар.

— Газзә апа, теге фермага алынган түбә калае акчасына кул куй әле!

— Газзә апа, тагын өч сыер ташланды!

— Газзә апа!..

— Яңа председатель белән сөйләшегез, — ди Газзә.

— Газзә апа, синең илле ситныр ипиең амбарда ята бит әле. Аны кайчан аласың?

Ул елны хезмәт көненә сигезәр кило икмәк тигән иде.

— Мин аны алып китә алмам инде. Күп балалы семьяларга бүлеп бирегез.

— Болай гына булмый, Газзә апа, документ кирәк!

— Хәзер, ризалык язып бирәм.

— Газзә апа, Әхтәм Аксуга барырга өч ат сорый.

— Нишләп алай бик күп? Өчәү?..

— Егетләр озата бара икән. Язылышырга баралар бит.

— Ничек, язылышырга?

— Кичә Маһруй Әхтәмгә ябышып чыккан. Бүген туйлары.

Газзәнең күз аллары караңгыланып китте.

— Иң яхшы атларны бирегез, — дигәндә сүзләрен гадәттәгечә ышанычлы тавыш белән әйтергә, сер бирмәскә тырышты. — Гөлзәйнәпкә әйтегез: туй олауларын матурлап бизәсеннәр!

Төн урталарында Газзә ялгызы гына югары очтан әйләнеп кайтты. Гадәттәгечә урта юлдан түгел, коймa кырыеннан сак кына атлап барды. Мәктәп коймасына ышыкланып, каршы яктагы такта түбәле яңа йортның балкып торган тәрәзәләренә бик озак карап торды. Ә тәрәзәләрдә көләгәләр уйный, җыр, көлешү ишетелә, кемнәрдер калын тавыш белән сөйләшеп, ишек төбендә тәмәке көйрәтә.

Менә кинәт өздереп гармун уйнап җибәрде:

Һай, дусларым, дусларым шул,
Дусларым, дус-ишләрем...

Туй гөрли, шатлык ташый, кемнәрдер иң бәхетле минутларын кичерә, ә урамда, караңгыда, коймага ышыкланып, тавышын чыгармаска тырышып кыз елый иде:

Сез дуслардан аерылгач,
Ялгыз башым нишләрем...

... Иртәгесен иртүк Хәкимҗан абзый ат җигеп, Вәҗһетдиннең яңа капкасы төбенә килеп туктады. Күрше-күлән тарантас янына җыелды. Вәҗһетдин абзый Газзәнең бөтен милеген сыйдырган бәләкәй сандыкны тарантаска чыгарып куйды, печәнне йомшарткалады. Урамнан чыгып киткәндә, авыл очындагы йортка каерылып бер карады Газзә. Ләкин ишегалдында кеше-кара күренми, ә тәрәзәләр ак пәрдә белән капланган иде.

Алар урманга керүгә урап-урап кар ява башлады.

— Бәхетле юлга чыгуыңдыр, мөгаен,— диде Хәкимҗан абзый.— Кара әле, нинди матур итеп ява, рәхмәт төшкере! Кар бик кирәгие басуларга, һай, кирәгие!

Олы юл кар пәрдәсе артына кереп югала барды.

## «Нишләттегез минем этине?»

Юкә чәчәгенең баллы исе аңкыган салкынча җиләс бер кичтә Газзә белән Борис кинодан кайтып баралар. Борисның иңбашыннан гына булган Газзәгә баштарак аңа җайлашып йөрү кыен иде — ничек кенә тырышса да, ул аның эре адымнары көенә атлый алмый, әледән-әле тыракларга мәҗбүр була иде. Ләкин бу җәйдә алар инде бер-берсенең көен алганнар, Борис ваграк, Газзә эрерәк атлый — алар үзләре дә уйлап тормастан бер хәрәкәт белән, җаннарында ниндидер бер тынычлык тоеп кайтып баралар иде.

Борисы янында булганда, гомумән дөньяның түгәрәк булуыннан туган бер канәгатьлек хисе белән яши иде Газзә. Алар арасындагы мәхәббәт хисе дә, дөрләп кабынып, шик һәм көнләшү ялкыннары белән бәгырьне көйдерә торган булмады, алар бер-берсенә дусларча якынлаштылар һәм тыныч кына кавыштылар.

Партия мәктәбен тәмамлаганнан соң Газзәне Биекъярдагы тракторчы-механиклар мәктәбенә Партия белеме нигезләрен һәм СССР Конституциясен укытырга җибәргәннәр иде. Аны мәктәпнең комсомол секретаре да итеп сайладылар, ул көн саен диярлек райкомга бара торган булды һәм анда эшләүче Серебров белән аларга еш очрашырга туры килде. Элекке танышлык тиз яңарды, алар очрашкан саен сөенү хисе кичерә торган булдылар, озак та үтми, дуслашып киттеләр. Кичке утырышлардан соң Борис аны озатып куя иде.

Алар гыйшык сүзләре сөйләшмәделәр, ләкин икесе дә бер-берсенең күңелләрен аңлаганны сизәләр иде.

Бердәнбер кичне Борис:

— Син дә ялгыз кеше, Газзә, мин дә ятим, әйдә бергә яшик. Бер-беребезне күптән беләбез бит инде, начар яшәмәбез дип уйлыйм,— дигәч, кыз моны дулкынланып, шул ук вакытта көтелгән тәкъдим кебек кабул итте.

Кияүгә чыгу — тормышта була торган үзгәрешләрнең иң зурысы, бу борылыш кыз кешегә шатлык кына түгел, җан газаплары да алып килә. Ләкин Борис Газзәне каушау-куркулардан, рәнҗешләрдән саклап кала белде, ул аның тормышына бик табигый килеп керде.

Газзә бик бәхетле иде ул чакта. Мәктәптә гаҗәп яратып, мавыгып эшли, яшьләргә дә, укытучыларга да сүзе үтә иде. Колхозда тупланган тәҗрибәсе, игенче күңелен аңлау, зур коллективлар белән сөйләшә, эш йөртә белү — Газзәнең хезмәтендә болар бик ярдәм итте.

Бөтен ягы килгән бу түгәрәк, тигез тормышта, офыктан күкрәп-яшьнәп күтәрелгән кара болыт шикелле, радио аша, газета битләрен-

дә килгән хәбәрләр генә тынгысызлап, җанны борчып тора иде. Германиядә фашистлар котырынып сугышка әзерләнәләр. Көнчыгышта Япония Маньчжурияне басып алды, Испаниядә республикачылар фашистларга каршы канлы көрәшләрдә чигенергә мәҗбүр булдылар.

Тракторчы-механиклар мәктәбендә укучыларның күбесе армия хезмәтен тәмамлап кайткан егетләр, алар бу хәбәрләрне бик борчылып кабул итәләр, алда каты көрәшләр торганны яхшы аңлыйлар иде. Һәркайдагы кебек үк, мәктәптә хәрби хәзерлеккә зур игътибар бирелә, ворошиловча төз ату ярышлары үткәрелә иде.

Борисы янында Газзәнең күңеле бу борчулардан ял итеп, тынычланып торгандай була иде. Бу зур, гадел, туры сүзле, шул ук вакытта кайгыртучан, сизгер кеше янында аңа бернинди куркыныч та янамас һәм ул хатынын беркайчан да ялгыз калдырмас шикелле иде. Шундый җан тынычлыгы кичереп, иренең көчле беләгенә таянып, аның көенә эре-эре атлап, кинодан кайтып килә иде Газзә. Урамда сирәк кенә янган электр утлары күзне алыштыра, барча нәрсә үзенең рәвешен үзгәрткәндәй күренә иде. Газзә каршыларына килгән кешегә бөтенләй игътибар итмәде. Узгынчы аларга юл бирмәде, читкә тайпылмады, киресенчә, Газзә ягына авышкандай итеп, яны белән ышкылып, каты терсәге белән бәреп узды, теш арасыннан гына Бориска сәлам бирде. Газзә аңа күтәрелеп карады да сискәнеп Бориска елышты. Бу шома йөз белән, бу үчле елтыраган күз карашы белән тагын да очрашырмын дигән уйның аның башына да килгәне юк иде.

— Син бу кешене каян беләсең? Кем ул? — дип сорады Газзә Бористан.

— Сезнең авыл малае бит. Белмәскә. Потребсоюзда бухгалтер булып эшли, курслар тәмамлап килде.

Газзә башка сорашмады, күңелендә купкан яшьлек хатирәләрен кузгатмаска тырышты. Үткән-беткән, Елтырның аны кодалап йөрүе, аңа аркаланып милекләрен саклап калырга тырышулары, Салыйның аны хур итәргә маташуы, икмәк белән законсыз сату итүләре, Махасның беркемгә ачылмаган сере — нигә бу җәрәхәтләрне кузгатып, Борис күңеленә дә яра салырга? Ярамый, диде Газзә үзенә. Йөрәк астында тыпырчынган җан иясен тоеп, тагын бер кат катгый уйлап куйды: ярамый. Бориска гына түгел, аннан да бигрәк ул хатирәләрне кузгатып, үзенә дулкынланырга ярамый.

Һәм ул барысын да онытырга, сүзне икенчегә борырга тырышты. Борис:

— Сезнең авылдан юньлелек белән китмәгәннәр иде алар китүен, ләкин ул чакта Салихҗанның гаебе табылмады бит, кеше әтисенең кылганнары өчен җаваплы түгел...— дип, Газзәнең фикерен ишетмәкче булып әйткән иде, хатыны елмаеп:

— Беләсеңме, без бәлки көзгә хәтле дә көтмәбез әле, бәбине алданрак алып кайтырга туры килмәгәе... — диде.

— Нишләп алай? — диде Борис куркынгандай.

— Ашыктыра бит, тизрәк синең куеныңда ятасым килә, ди, тыпырчына...

Алар икесе дә күңелсез очрашуны онытгылар. Ничектер Салый да башка аларга очрамады. Ләкин Салый аларны онытмаган икән...

Көз җитте. Укучылар каникулдан кайтты. Егетләр-кызлар басуларда эшләп, тазарынып-ныгып килгәннәр, бит-куллары кояшта каралган, чәчләре уңган, аксылланган. Басу киңлекләрендә трактор гөрелтесен күмеп сөйләшергә күнеккән тавышлардан озын коридорлар, биек класс бүлмәләре яңгырап тора. Һәркем үзен оясыннан пыр тузып чыккан, ләкин әле бер урынга ныклап сарырга өлгермәгән умарта күче сыман хис итә. Мәктәптә эшнең күңелле дә, ыгы-зыгылы да чагы. Күңелдән өлкән

курс укучыларын сагыну да бар, беренче курска килгән укучыларга өмет белән, «Я, сез кем буласыз инде!» дип сынап карау да бар.

Беренче курс группаларының берсендә, исемлек буенча укучылар белән танышканда, Газзәгә таныш фамилия очрады.

«Сираҗиев Гариф!»

Арткы рәттән гимнастерка кигән егет ялт итеп торып басты да, парта астыннан күн итек үкчәләрен бер-берсенә бәреп куйды:

— Мин!

— Гариф! Син дә монда килдеңмени? Ә ник моңарчы күзгә-башка күренми йөрисең?

— Сезгә аркалана димәсеннәр өчен, Газзә апа!.. Газзә Кәримовна...— дип төзәтте сүзен авызы колакларына җиткән яшь солдат.

Газзә, урта буйлы гына булса да, нык бәдәнле, нәфис йөзле егеткә карап соклануын яшерә алмады. Гарифта әтисенең дә, әнисенең дә чалымнары бар шикелле, ләкин якты күзләренең туры, ихластан каравы, күңеленең дәрте, хәрәкәтләренең төгәллеге аны бөтенләй башка кеше, аларга охшамаган кеше иткән.

— Мин танышларымнан күбрәк таләп итәм, танышлык хакына,— диде Газзә.

— Сезнең холыкны беләбез,— диде Гариф, иң кырыс таләпләргә әзер икәнлеген сиздереп.

Ул дәресне Газзә аеруча күтәренкелек белән, аеруча рухланып үткәрде. Гариф белән дәресләрдә, коридорларда очрашканда аның күңеле күтәрелеп китә иде, ул егетне тиз арада үзенең ярдәмчесе итте, аны лозунглар язарга, классларны, коридорларны бизәргә чакырды. Гариф аның яшьлеген искә төшерә, авыл клубында кичергән онытылмас кичләрдәге кебек талпыну тудыра иде.

Кызганычка каршы, мөнәсәбәтләрдәге бу эчкерсезлек озакка бармады.

Гадәттә Газзә мәктәпкә бер ярты сәгать алдан килергә, чиста итеп юылган, җылы итеп ягылган коридорлардан ялгызы гына үтәргә ярата иде. Аңа эшләве шактый кыенлашкан, түгәрәкләнгән гәүдә баскычлардан, коридорлардан элеккечә җиңеллек белән очып кына йөрергә мөмкинлек бирми, шуның өстенә бәби ялына киткәнче, күп эшләрне очлап чыгасы килә иде.

Болытлы, җилле, күңелсез бер иртәдә, мәктәпкә килгәндә, ул капка төбендә басып хәрәкәтсез торган солдат киемле кешене күрде, якынрак килгәч, фуражкасын маңгаена батырып кигән бу кешенең Гариф икәнен таныды.

— Гариф! Ни булды сиңа? Нишләп болай торасың?

Егетнең чыраеннан кан качкан иде.

— Сине көтәм менә, — диде ул карлыккан тавыш белән, үзе күзләре белән маңгай астыннан сөзеп, нииндидер аңлаешсыз нәфрәт белән карады.

— Ни булды?

Гарифның карашы Газзәне өтеп ала иде шикелле, бу караш астында хатын үзен салкын су астына кергәндәй хис итте. Егет як-ягына каранды, урамның ике очыннан да мәктәпкә килүчеләр күренә иде инде.

— Урыны ул түгел. Әйдә әле, тегендәрәк!..

Алар киң ишегалды түрендә тезелеп торган тракторларның берсе артына барып бастылар. Сәер иде Гарифның бу кыланмышлары, бик сәер иде, ләкин аның нинди сорау бирәчәген Газзә һич чамалый алмый иде.

— Дөресен генә әйт әле, Газзә апа, нишләттегез сез минем әтине, ә?

Газзә бер мәлгә өнсез калды. Үләрен белә иде, әмма мондый сорауга җавап бирәсен белми иде ул.

— Әйт, нишләттегез?

«Гариф, синең әтиең... Миңа пычак кадаган иде...» дип ничек әйтәсең? Ничек бу гөнаһсыз егеткә шул хәтле аяусыз хакыйкатьне ачып, аның бәгыренә пычак кадыйсың? Аннары... Газзәнең моны исбат итәрлек дәлилләре кая да, шаһитлары кайда?

— Нишләп әле син моны миннән сорыйсың, Гариф? Каян синең башыңа килде бу уй?

— Ә ул уйның минем башымнан чыкканы да юк! Син килеп алып киттең бит минем әтине! Безнең күз алдында! Милиционер белән! Кая куйдыгыз сез аны?

— Гариф, син аны хөкем иткәннәрен беләсең. Аның төрмәдә үлгән хәбәре килде ләбаса!

— Шулаймы? Ул үлде дә җаным тынды, дип йөрисең инде син болай булгач, ә? Юк инде, дөреслек җирдә ятмый ул, кайчан да булса калкып чыга. Кыңгыр эш кырык елдан соң да беленә... Син әләкләп илтеп тыккансың бит аны төрмәгә! Ипи белән сәүдә итте дип ялган бәла тагып! Миңа пычакны да шул кадады дип барып әйткәнсең! Бер гаепсезгә! Фәкыйрь кешене! Аннары безгә яхшатланып йөрдең. Ә мин, сарык, сине алла урынына күреп йөрим!

— Гариф! Туктале! Кем әйтте сиңа моны? Нинди әләк? Мин судта булмадым да бит!

— Әйттеләр инде! Күзне ача торган кешеләр бар! Сез бит кешеләрне төрмәгә илтеп тыгарга яки авылдан куарга остарып беткән булгансыз. Ә үзегез яхшатланып, читтә дә кала белгәнсез!

— Гариф! Гариф! Тукта, тыныч кына аңлашыйк!

Ләкин кая ул! Гариф төн буе йокламыйча газапланып, Газзә белән сөйләшәсен алдан ук уйлап, кызганнан-кызып куйган, аңа тынычлан дип әйтү дөрләп янган учакка тамчылап су сибү белән бер иде.

— Белеп тор, мин бу эшне болай калдырмам, әтинең үчен алырмын, ятимнәр күз яше төшми калмый ул! — дип янады Гариф.

Кичен Газзә Бориска — гомерендә беренче кешегә — Елтыр Салый белән булган хәлләрне, Махасның ничек серен ачканын ачыктан-ачык сөйләп бирде.

— Аңлашыла-а, — диде Борис сузып. — Кашап малае әтисеннән ерак китмәгән икән алайса. Үзенә кирәкне кеше кулы белән эшләргә оста икән.

Алай да Борис бу очракта артыгын борчылырга, кайгырырга урын тапмады. «Суд документларын күтәрербез дә, барысы белән дә егетне әйбәтләп таныштырырбыз, — диде ул. — Мин үзем иртәгә ул документларны күтәртү чарасын күрермен әле. Кайбер шаһитларны да табарбыз. Аңлатырбыз егеткә!» Шул ук вакытта ул да Газзәгә һөҗүм вакыйгасын сер итеп саклау ягында иде.

Ләкин Гарифны икенче көнне ук ул документлар белән таныштыра алмадылар, чөнки кирәкле кешесе каядыр киткән булып чыкты. Ә ул көнне мәктәптә комсомолның отчет-сайлау җыелышы үтәргә тиеш иде.

Президиумга менеп, җыелышны ачып җибәргәндә, залда иң алгы рәттә утырган, күз төпләре күгәргән, талчыккан чырайлы — күрәсең йокламаган булса кирәк — Гарифны күреп, Газзәнең йөрәге жу итте. Нәрсәдер булыр, хәсрәттән башын җуяр дәрәҗәгә җиткән бу егет нинди дә булса күңелсезлек китереп чыгарыр кебек иде.

Ләкин җыелыш барган саен Газзә әкренләп тынычланды. Гариф президиум сайлаганда да кымшанмады, Газзәнең отчет докладын да идәнгә караган килеш тыңлады, фикер алышканда да сүз сорамады. Комитетның эшен яхшы дип тапканда, кулын күтәрмәде, әмма каршылыгын да әйтмәде.

Инде куркыныч узды дип уйлаган иде Газзә. Инде егет ташып чыккан ачуын тыйгандыр, дип өметләнгән иде.

Комитетның яңа составын сайлый башлагач, Гариф кинәт сикереп торды да рәтләр алдына чыгып басты:

— Минем иптәш Кәримовага бер соравым бар,— диде.

— Рәхим ит,— диде җыелышны алып баручы укучы Степан Меркулов.

— Менә иптәш Кәримова үзенең фәкыйрьләр комитеты председателе, аннары колхоз председателе булып эшләгән чаклары, кулаклар тарафыннан яраланып больницада ятулары турында классларда сөйләп йөри. Ләкин үзе кем яралаганын әйтми. Безгә менә хәзер чын дөресен әйтеп бирсен иде ул! Кем яралаган икән аны?

Сорауга туры җавап бирергә кирәк иде. Газзә җыелыш алдында беренче мәртәбә ялган сүз әйтте:

— Иптәшләр, мин үземә кем һөҗүм иткәнен белмәдем, чөнки шунда ук һушымны җуйган идем, — диде.

Гариф, аңа күзләрен кыса төшеп, сынап карады.

— Алайса сез, миңа кулаклар һөҗүм итте, дип ничек әйтә аласыз?

Газзә бу сорауга берничек тә җавап бирә алмый иде.

— Ә бит сез ул гаепне бер кеше өстенә өйгәнсез инде. Фәкыйрь кеше өстенә.

Гариф кинәт залга борылды да:

— Кәримова, Кәримова дип ах итәсез дә, беләсезме соң сез аның чын йөзен? — диде. — Без бер авылдан. Минем әтием фәкыйрь кеше иде. Гражданнар сугышыннан яраланып кайткан кызылгвардияче. Без алты бала идек. Әнием көнлекчелеккә эшләп алган икмәкне генә ашап тордык. Бер төнне менә шушы кеше — Кәримова безнең өйгә милиционер китереп, әтиемне алып киттеләр. Шуннан соң без аны күрмәдек. Алты бала ятим үстек. Әйтсен менә Кәримова: ни өчен кулга алдылар минем әтине? Мин үзем дә аны моңарчы белми идем. Хәзер белдем: минем әтине Кәримова яласы буенча кулга алганнар, ул, миңа Сиражиев һөҗүм итте, миңа шул пычак кадады, дип аның өстенә нахак бәла яккан! Менә кем ул сезнең мактаулы секретарегыз! Икейөзле, кара эчле кеше ул! Ә сез яңадан да комсомол комитетына сайламакчы буласыз!

Зал тып-тын калды. Бөтен күзләр бу коточкыч гаепләүгә каршы сүз әйтүен, бу гаепләрне юкка чыгаруын көтеп, Газзәгә текәлделәр. Хәзер дәшми калу һич ярамый иде. Газзә бөтен көчен җыеп, аягүрә торып басты.

— Әйе, — диде ул, — мин Махас Сиражиевны кулга алганда аларның өенә бардым. Чөнки ул чакта мин фәкыйрьләр комитеты председателе идем, район үзәгеннән килгән милиционер миннән аның өен күрсәтүемне үтенде. Ләкин ни өчен кулга алынды ул — анысын миңа әйтүче булмады, мин Сиражиевның судында була алмадым, мин аның өстеннән беркайчан, беркемгә дә, бернәрсә дә сөйләмәдем. Беркайчан да! Ул бөтенләй башка эш белән хөкем ителде. Ул байларга яшерен икмәк сатуда булышкан өчен гаепләнде. Нәрсә өчен, ничек, комсомолец Сиражиевка бөтенесе аңлатылыр, суд документлары күрсәтелер.

— Сез хәзер аңлатыгыз! Бөтен кеше алдында! — дип кычкырды Гариф.

— Ләкин мин шуны әйтергә тиешмен: Сиражиевның әтисе чыннан да фәкыйрь кеше иде. Ул сыйнфый аңы җитешмәгәнгә күрә, башкалар коткысына бирелеп кенә ялгышкан булса кирәк. Бу очракта мин үземне чыннан да гаепле саныйм, мин, фәкыйрьләр комитетының җитәкчесе һәм комсомолка буларак, ул кешенең аңын үстерергә, аңа дөрес юлны күрсәтергә тиеш идем. Кызганычка каршы, тәҗрибәм җитмәү сәбәпле, мин ул катлаулы, ләкин изге, мөһим бурычны үти алмадым... Әгәр комсомоллар кирәкле дип табалар икән, ул суд материаллары белән комитет та таныша алыр, дип уйлыйм...

— Иптәшләр, Сиражиев биредә иптәш Кәримова өстенә ифрат зур гаеп ташлады.— диде Меркулов, икенче курс студенты, актив комсомол. — Ләкин, минемчә, үз сүзен расларлык нигезле дәлилләр китерә алмады. Шуңа күрә мин Кәримованы комитетка сайларга тәкъдим итәм. Шул ук вакытта комитет Сиражиев әйткәннәрне җентекләп тикшерсен һәм тикшерү нәтиҗәләрен киләсе җыелышта хәбәр итсен.

Сайлау вакытында Газзәгә каршы бер тавыш бирелде.

Икенче көнне ул мәктәпкә бара алмады. Борис аны яктырганчы ук больницага илтте, кичкә Газзә сигез айлык кыз тапты.

Ә тагын ике көннән аны сестралар бүлмәсенә чакырып чыгардылар. Ак халатын иңбашына гына салган таныш түгел ир уртасы кеше:

— Мин тикшерүче булам, — дип кесәсеннән таныкнама чыгарып күрсәтте. — Гариф Сиражиев турында белгәннәрегезне сөйләгез әле.

— Ни булды? Нишләде Гариф?

— Сезнең хәлегез бик авыр түгел диделәр диюен. Ләкин алай да бик авырга алырга тырышмагыз..

— Я инде, әйтегез тизрәк!

Тикшерүче бер-ике сүз белән генә аңлатып бирде: Гариф Сиражиев ату ярышлары вакытында бер винтовканы алып киткән дә туп-туры потребсоюзга барып, бухгалтер Салихҗан Кашаповка аткан.

— Тигәнме? — дип сорады Газзә агарынып.

— Ә сез ничек уйлыйсыз? — диде тикшерүче көлемсерәп.

— Ату ярышларында аннан уздыручы юк иде...

— Монда да кулы калтырамаган. Туп-туры йөрәгенә эләккән.

Газзә чын дөресен сөйләп бирде. Гарифның яшьтән үк гомуми эш өчен атылып торганын, актив комсомол, намуслы кеше булганын. Ләкин аның этисе серен барыбер ачмады.

Ул кире мәктәпкә әйләнеп кайтканда, анда Гариф юк иде инде.



## Өмет

Сугышның өченче кышы. Алар Биекъярдан Имәнлегә баралар. Газзә бер чабуын кемдер кисеп алган толыпка төренеп үрәчәле чанага утырган да, Хәкимҗан абзыйның иелгән җилкәсенә текәлеп, сагышлы уйларга чумган.

Каршыда юл уртасында тынып калган СТЗ тракторы күренде. Янында җан иясе булмаганга, ул салкын, ятим, кызганыч тоела, ярым ач, арыган, янбашларын бәс сарган алашаны карга батырып, ул тимер тауны әйләнеп узарга кирәклеге алдан ук эчне пошыра иде. Житмәсә, трактор артына озын бүрәнәләр тагылган икән әле.

Якынрак килгәч, тракторның ташландык түгеллеге беленде. Аның астыннан олтан салган кара итекләр күренә иде. Сырган чалбарыннан, куныч бер җирдән ямаулы итегеннән Маһруйны таныды Газзә.

— Нәрсә, тартмыймыни, рәхмәт төшкере? — дип сорады Хәкимҗан абзый.

Маһруй трактор астыннан, цирк артисты шикелле оста итеп, аркасы белән шуышып чыкты.

— Бераз ялындыра шул, — диде. — Трактор алаша түгел, аны киндерә белән бәйләп куеп булмый.

— Әйдә безнең белән кайтыйк. Кирәк әйберенне тимерчедән ясатып алырсың.

— Аны кырда калдырып булмый бит инде. Ничек тә рәтләргә не.

Ярый әле артык салкын түгел, җил тынган иде. Күз бәйләнә башлагач кына, Газзә белән Маһруй кәкре тимер белән моторны әйләндерергә керештеләр. Янып-пешеп, тиргә төшкәч кенә кабыздылар тракторны.

Трактор тере җан иясәдәй калтырана, аннан аркага җылы бәрә, ә Маһруй, талчыккан йөзенә хәсрәтле кыяфәт чыгарып, карашын еракка, караңгылык пәрдәсе каплый башлаган офык сызыгына текәгән иде.Ниләр уйлый икән ул? Еллар авырлыгынмы? Ни кадерләп кенә, карап кына торткан тракторының тузуынмы? Ә бәлки Әхтәмен искә алгандыр?

Газзә сорамады, Маһруй әйтмәде. Алар ул минутта, мөгаен, икесе бер кешене уйлаганнардыр — Әхтәмне. Маһруйны күргән саен Газзәнең үзәген өзеп, яшьлек мәхәббәте искә төшә иде.

Ул аны соңгы тапкыр кырыгынчы елның кыш башында күрде. Җиргә кар яткан гына чак, шушындый ук җылы, болытлы көн иде. Газзәне мәктәптән дәресеннән чакырып чыгардылар. Ул иңенә пальтосын салган килеш кенә ялан баш атылып чыкты, капкага җиткәч, тез буыннары йомшарып, туктап калды.

Капка төбенә ике ат килеп туктаган, чаналар тирәсендә Имәнле егетләре тора иде. Арттагысыннан Әхтәм сикереп торды, батырып кигән бүреге астыннан зәңгәр очкыннар сирпеп, Газзәнең йөрәген көйдереп алгандай итте.

— Исәнме, Газзүк, — диде. — Исәнме һәм... Хуш.

— Кая китәсез болай?

— Ерак китәбез, Газзүк. Ак финнәргә каршы барабыз.

— Ә Маһруй кая соң? — дип сорады Газзә.

— Хатыннар белән авылда ук хушлаштык, Газзүк.

Алар бер-берсенә кулларын биреп, аерыла алмый тордылар. Егетләр алгы чана янына җыелып нидер сөйләшәләр, бөтен дөньяда алар икесе генә калган шикелле иде, ләкин... ни сөйлисең андый минутларда, ут эченә китеп барган кешене ничек юата аласың?

— Исән-сау йөреп кайтыгыз инде, Әхтәм, җиңеп кайтыгыз. Тиз арада исән-сау күрешергә насыйп булсын.

— Күрешергә язсын, Газзә!

— Күрешербез әле, Әхтәм...

Күпме тордылар алар шулай күзгә-күз карашып — белмәде Газзә. Менә аларның куллары аерылды, Әхтәм үрәчәгә янтаеп чанага утырды, кулына гармунын алды, бакаларына баскалап, ыңгырашуга охшаш авазлар чыгарды, шул тавышка кушылып:

— Сугыш сугыш бит ул, кемнәрнең газиз башкайлары ятып калыр, кемнәр кайтыр — анысын әйтеп булмый... — диде.

Аннары кинәт гармунының кызыл күрүген бөтен киңлегенә җәеп, каерылып, ярсулы, кыска көй уйный башлады, үзе дә кушылып җырлап җибәрде:

> Сандугачым, сайрый-сайрый
> Керми китәсеңмени?
> Бер аерылгач, күрешүләрне
> Өмет итәсеңмени?..

Егетләр чаналарга сибелде, кемнәрдер хушлашып Газзәнең кулын кысты, ул кемнәргәдер хәерле юл теләде. Атлар кузгалды, Әхтәмнең җырын башкалар күтәреп алды:

> Сандугачның, мескенкәйнең,
> Канаты каерылган;
> Бер без генә түгел инде
> Ярыннан аерылган...

Киттеләр авылның асыл егетләре... Китте Әхтәм... Шул очрашу соңгысы булган икән... Күп тә үтмәде, Газзә Әхтәмнең үлү хәбәре килгәнен ишетте.

Маһруй авылда тол калган хатыннарның беренчесе булды. Сугыш башлангач күп тә үтмәде, аның бердәнбер кызы дөнья куйды, шулай итеп, гөрләп торган тигез тормыш кинәт җимерелде.

Шул хәсрәтләрне кичергәч, Маһруй көнбагыш чәчкәсеннән бигрәк яшен суккан, ләкин корымаган, ян-ягыннан яшел ботаклар чыгарып, имгәнеп үсеп киткән өянкегә ошап калды: нәфисләгән, чибәрләгән югалтты, ямьсезләнде, тупасланды, ләкин ныклыгы, тазалыгы, эшкә дәрте артты гына шикелле. Аның иренә, баласына булган бар мәхәббәте тракторга күчте. Әхтәмнең тракторына беркемне дә якын китерми, үзе карый, үзе майлый, үзе генә ремонтлый иде. Запчастьларга ни кытлык чакта да аның тракторы беркайчан да тик тормады, озаклап ватылып ятмады. Ул МТСның иң нык тerәге санала, районда абруе гаҗәп зур иде, җыелышларда президиумнан төшми, ләкин һаман майлы киемнән, калын чалбардан йөргәнгә, кеше күзенә бик күренмичә, арткы рәттә утырырга тырыша иде. Халык арасында аны, ярату катыш көлеп, «Эшлекле Маһруй» дип йөртәләр. «Эшлекле Маһруйның эше рәхәт, аңа тракторы булса шул җитә, ир кирәкми», — дип тә җибәрәләр иде. Маһруй үзенең хатын-кызлыгын да онытты кебек, ел әйләнәсендә чалбарын салмый, адымнары эреләнде, хәрәкәтләре элекке җиңеллеген югалтты, дала җиленнән бите каралып, сипкелләре күренмәс булды, салкыннан, тузаннан тавышы карлыкты. Алай да кеше карамый түгел иде үзенә. Төрле авылларда йөри, танышлары күп, уңган үзе, вакчыл түгел, начарлыгы белән даны чыкмаган — хәтта сугыш елларында сүз кушучылар булды аңа. Аксуның сугыштан яраланып кайткан Ибраһим аны хатынлыкка сорап караган. Ләкин Маһруй ризалык бирмәгән.

... Томанлы офыкка карап, ниләр уйлады икән Маһруй?

Газзәнең Маһруйга үз моң-зарларын сөйлисе килде. Ничек итеп яңгырлы кичтә Борисын озатканын... Пристаньда кайнап-болганып торган халык арасында, аның күкрәгенә капланып, бергә яшәгәндә күңелендә тәкърарланган, ләкин ниндидер ахмак кыенсыну аркасында сөйгәненә әйтергә кыймаган назлы сүзләрне әйтергә ашыкканын...

— Бәгырькәем, җаным, күккүзем, бердәнберем... Зинһар, исән-сау кайт, синсез мин яши алмыйм... — дип бәйләнешсез сүзләр пышылдаганын...

Борисның күзгә карап:

— Газзә... Газзә! Баланы сакла, Ландышны исән-сау үстер, — дигәнен, соңгы тапкыр аның кайнар, дымлы иреннәренең тәмен тоюын... Аннары пароходның әкрен генә борылып, караңгылыкка китә башлагач, үзәк өзгеч итеп ыңгырашкандай, ипрәп кычкырып куюын... Аның саран утлары күздән югалганчы, үзенең тайгак яр башында назлы сүзләр пышылдап торганын һәм бары тик шунда гына чыннан да Борисны яратканын һәм ансыз бәхетле яши алмаячагын бөтен тирәнлеге белән аңлавын...

Барысын-барысын сөйлисе килде Газзәнең. Ләкин сүзләр нигә? Ике хатын, ике солдатка, бер-берсенең уй-сагышларын сүзсез дә аңлыйлар иде бит!

Трактор артыннан Хәкимҗан абзыйның тамак кыргалаганы ишетелде.

— Кхм-кхм! Кузгалыйк булмаса! Караңгыга калабыз! Ат та туңа!

Алар икесе ике якка таба киттеләр. Трактор, бүрәнәләрен сөйрәп Биекъярга таба кузгалды, тик торудан туңган алаша Иманлегә таба юыртты.

Хәкимҗан абзый, чанага ян белән утырып, ераклашкан тракторга шактый озак карап баргач:

— Я хода, әле дә чыдый бу хатын-кыз дигәнең, — дип көрсенеп куйды.

— Чи ит утта янмый бит, Хәкимҗан абзый. Чыдау бер хәл, эшләргә кирәк бит. Менә мин дә вәкил булып авылдан-авылга йөрим. Кызымны да атнага бер генә күрәм кайчак.

— Караучысы юньле булса ярый ла!

— Караучысы әйбәт. Борисның туганнан туган апасы Ауди түти карый. Тик барыбер ана йөрәге түзми шул.

— Ә иреңнән хәбәр бармы соң?

— Юк, Хәкимҗан абзый. Киткәннән бирле бер генә хаты килде. Менә өченче ел инде, ник бер хәбәре килсен, ичмасам.

— Хәбәрсез йөргәннең өмете бар әле. Әнә, Махас малаеның да ике ел хәбәре югые, кайтты да килде авылга... Тагын китте.

Әйе, кайткан иде шул Гариф. Газзә янына да кергән иде.

— Сине анда бер солдат чакыра, — дигәнне ишеткәч, райкомдагы бүлмәсеннән коридорга атылып чыккан иде Газзә. Уң кулын ак чүпрәк белән муенына аскан, шинель, фуражка кигән кеше, үкчәләрен бер-берсенә шакып, кисәк борылгач, Газзә үз күзләренә үзе ышанмыйча, каушап калды. Гариф... Ни әйтер ул Газзәгә?

— Исәнме, Газзә апа. — Егет корыч төсле күзләре белән туп-туры карап, күрешергә аңа кул сузды.

— Исәнме, Гариф, саумы? — Газзәнең әйтер сүзләре тамагына төер булып утырды. — Каян әле син болай?..

— Фронттан, Газзә апа. — Гариф яралы кулына ишарәләде. — Бераз ремонт ясап килергә дип җибәрделәр. Бусы икенче яралану инде. Башта санбатта гына ремонтлап чыгарганнар иде.

— Күптәнме? Фронтта диюем.

— Башыннан ук диярлек, Газзә апа. Башта төрмәдән, үз теләгем белән штрафбатка. Медсанбаттан чыккач, пехотага. Хәзер менә танковый частька сорарга исәп.

Газзә егетнең олыгаеп, тәмам кырысланып киткән йөзеннән күзләрен ала алмый торды. Тел очында торган мең сорауның берсен дә әйтә алмады.

— Дошман белән күзгә-күз очраштык без анда, Газзә апа, — диде Гариф. — Анда барысы да аермачык, дошман кайда да, дус кайда. Теге чакта гына саташып йөрелгән. Син рәнҗемә, Газзә апа. Ә дошманга атканыма мин үкенмим...

Газзәнең күнеле тулды. Ул кыенсынып башын иде, егет итәгать саклап, тәрәзәгә таба борылды.

Бераз тынычлангач, Гариф, кесәсеннән нидер эзләгән булып, шинель сәдәфләрен ычкындырып җибәрде. Аның гимнастеркасында «За отвагу» медале ялтырап күренеп китте. Газзә егет өчен сөенгәнен, горурланганын күз карашы белән генә аңлатты.

Ул чыгып киткәч, Газзә тәрәзәдән озак карап калды. Башын югары күтәреп, җиргә нык басып бара иде Гариф — Газзәнең авылдашы, шәкерте, сугышчы...

— Ир солтаны булып житешкән Махас малае, — диде Хәкимҗан абзый Газзәнең уйларын белгәндәй.— Тагын китте ут эченә. Яшәп туймас чаклары бит, югыйсә. Эх, әрәм дә булалар инде балакайлар... Тик дөмектерерләр дошманны, барыбер җиңәрләр. Гөлләр кебек күкрәп яшиселәрегез булыр әле. Яшь бит әле сез. Ирләрегез кайтыр. Өметегезне генә өзмәгез.

Ләкин картның юатуы дөрескә чыкмады — Борис сугыштан әйләнеп кайтмады.

Шул ук кышның ахырында Газзәгә иренең соңгы сәламен житкерделәр. Ул сәламне аңа култык таягына таянган ябык чырайлы солдат китерде. Аның күзен күрүгә, Газзә кайгылы хәбәр китергәнен аңлады, алай да тиз генә өметен өзәсе килмәде. Бәлки яралангандыр, башы исәндер, дип күңелендәге шомны басарга тырышты. Зиһене таралып, ул ишек төбендә үк солдатның сүзен көтә иде.

— Утырып сөйләшик, — диде солдат карлыккан тавыш белән.

Таякларын стенага сөяп, ботинкаларын җайсыз сузып, озаклап утыр-

ды. Дүрт яшьлек Ландыш әнисенең итәгенә ябышып, ят абыйга куркынып карады.

— Борисның кызы шушымыни инде? — Солдат кесәсеннән конфет алып кызчыкка сузды.

— Ал, кызым, ал абыеңның күчтәнәчен!

Ә күңеленнән: «Әйт инде, әйт тизрәк дөресен!» — дип ялварды Газзә, үзе хәбәрнең иң аянычын ишетүдән курыкты.

— Миндә Борисның әманәте бар иде,— диде солдат.

— Үзе... Үзе кайда соң ул?

Әманәтне исән кеше генә җибәрә ала лабаса!

— Кырык беренче елны без бергә чолганышка эләктек, — дип сөйләп китте солдат аска карап. — Чолганыш хәлләрен сөйләп-аңлатып кына булмый инде аны. Төрле частьтан җыелган халык, яралылар күп, үзебезнекеләрнең кайда икәнен белүче юк. Элемтә булдырырга кирәк иде. Безне, өч кешене, фронт сызыгы аша чыгарга җибәрделәр. Элемтә булдыру өчен. Шунда миңа Борис ике хат биргән иде, фронт сызыгы аша чыккач, почта белән җибәрерсең дигән иде. Ул хатлар икесе дә сезгә иде. Берсенә Имәнле адресы язылган иде, икенчесенә шушы адрес, Биекъярныкы. Без фронт аша бик авырлык белән чыктык. Беребез шунда ятып калды. Атналар буе дошман тылында йөрергә туры килде. Тәүлекләр буе муеннан баткакта, саз эчендә яттык. Кәгазь нәрсә, хәтта аяк чолгаулары, кием-салым череп өстән коелды. Сезгә дигән хатлар да шунда юкка чыкты. Кем белә бит аның шулай буласын!

Газзә солдатның сүзләрен томан аша тыңлагандай, ерактан килгәндәй генә ишетте. Ниһаять, алар безнекеләр ягына чыкканнар, тиз арада отрядка кире кайтырга сугышчан бурыч алганнар. Бу солдат, элемтә урнаштыргач, хатлар алышу мөмкинлеге булыр дип уйлаган, ашыгычлык белән Газзәгә үзе хәбәр җибәрергә өлгермәгән. Ләкин ул кире әйләнеп кайтканда отрядта Борис булмаган инде... Партизаннар арасына провокатор үтеп кергән икән... Дөрес, аның кара йөзен тиз ачканнар, ләкин ул аңарчы тугыз разведчикны дошман кулына биреп өлгергән. Тугыз кеше арасында Борис Серебров та булган.

Бу урында солдат тынып калды. Газзә аңа нинди дә булса сорау бирү түгел, сулыш та ала алмады.

— Мондый хәбәр китерү ифрат авыр миңа, — диде солдат, ниһаять. — Ләкин мин мәрхүм алдында бурычлы. Шунысы хак, Борис беребезгә дә йөз кызыллыгы китермәде. Тугыз кеше арасында бер генә хыянәтче дә булмаган, фашистлар ни генә кылансалар да, алардан сер ала алмаганнар... Тугызын тиң авыл урамына тезеп асканнар.

— Тугызын дамы? — дип кайтарып сорады Газзә.

— Тугызын да, — диде солдат.

«Ләкин син анда үзең булмагансың, — дип әйтергә теләде Газзә. — Ә бәлки берәрсе качып котылгандыр? Бәлки берәрсен бутаганнардыр?.. Китапларда шулай да язалар бит!»

— Берничә көннән безнең партизаннар ул авылга һөҗүм ясаганнар, барысын да дардан алып, урманга алып кайтып, үз куллары белән күмгәннәр. — Солдат Газзәнең әйтелмәгән соравына шулай дип җавап бирде. — Бергә сугышкан кешене бутау мөмкин түгел. Ул туганыңнан газиз була...

— Каберен... беләсезме?

— Без килеп житкәндә отряд икенче урынга күчкән иде инде. Связнойлар аркылы көчкә эзләп таптык...

Ландыш, әнисенең итәгенә капланып, елап җибәрде.

— Елама, кызым, елама! Әтиең еларга кушмаган, ул еламаган! Еларга һич ярамый иде. Күз яшьләрен йотып, Борисны, Әхтәмне,

илнең миллионнарча асыл егетләрен харап иткән дошманнан үч алу өчен, аны җиңү өчен нык булырга кирәк иде...

Һәм алар — Маһруйлар, Газзәләр, Хәкимҗан абзыйлар, Гарифлар — бирешмәделәр, кайгы-хәсрәттән сыгылып төшмәделәр.

Бик көттереп килде ул җиңү.

Ләкин барыбер килде.

Менә Газзә яулыгын болгап, урам буйлап йөгерә, очраган бер әбигә дә, сабыйга да кычкыра уза:

— Сугыш бетте! Сугыш бетте!

Менә ул басу юлына чыга, тыны кысылып, егәре бетсә дә хәл алырга туктамый, Таштүбә өстенә йөгерә. Анда Маһруй тракторы, якында гына сабанчылар, тырмачылар, ат куучы, ат чистартучы малайлар, аш пешерүчеләр...

Газзә трактор өстенә үрмәләп менә. Әле тиз генә сүз әйтә алмый, яулык болгый. Як-яктан җир буйлап сибелеп, аңа таба халык йөгерә. Сүзсез дә аңлыйлар, беләләр: сугыш беткән, сугыш беткән!

Алай да бу тантананы болай гына, сүзсез генә үткәреп булмый.

Газзә сулышын җыеп, халык көткән сүзне башлый:

— Туганнар! Дуслар! Авылдашлар! Без җиңдек! — ди. Һәм ут эченә кергән ир-егетләр турында, Берлинга барып житкән баһадирлар турында, тылда үз-үзен аямыйча эшләгән солдат хатыннары турында сөйли. Яшьләрнең йөзендә чиксез шатлык балкый, тол хатыннар тавышсыз гына елыйлар.

Сүзен тәмамлагач, инде кешеләр бер-берсе белән сөйләшер хәлгә килгәч, Газзә әкрен генә атлап, Таштүбәдән төшеп китте. Коры елга буендагы гөлҗимеш төбенә җиткәч, җиргә йөзтүбән капланып, күз яшьләренә ирек бирде. Җиңү шатлыгы, ирен югалту хәсрәте, яшь гомернең үткәнен аңлау, мәхәббәтнең кабатланмасын тою — бөтенесе бар иде бу яшьләрдә.

Аның янына Маһруй килеп утырды. Башын югары күтәреп, төпсез зәңгәр күктә сайраган тургайны эзләгәндәй итте. Җилдә каралган яңаклары буйлап бер-бер артлы тәгәрәшкән тамчыларны сөртмәде.

Газзә бер үлән өзеп алды. Үлән дигәне сары чәчкә булып чыкты. Сары чәчкәләр, кояштан коелгандай, яшел чирәмгә куе булып сибелгән иде. Газзә беренчесе янына икенчесен өзде, сабакларын китереп бәйләде. Бала чакта Коры елга буенда бозау саклаганда өйрәнгән һөнәрен исенә төшереп, такыя үрергә кереште. Башына киде. Урыныннан кузгалып, тагын чәчкәләр җыйды, тагын бер такыя үрде. Анысына Маһруйның яшьлеген, мәхәббәтен, сагышын, өметләрен үргәндәй итте. Дустының башыннан кепкасын салдырды, пинжәк кесәсеннән тарак алып, кыска итеп киселгән, чуалган чәчен тарады. Сирәк кенә көмеш җепләр катнашкан булса да, Маһруйның чәче һаман куе, дулкын-дулкын булып, кояш яктысында алтынсу төскә кереп, елкылдап тора иде. Сары чәчкәләрдән үрелгән такыя кигәч, Маһруй элеккечә көнбагыш чәчкәсенә охшап калды.

— Кара, Маһруй, сиңа такыя бик килешә икән!

— Такыя килешер чаклар үткән инде!

Газзә аңа кырыс кына:

— Бу чалбарыңны эштән кайтуга салып куя торган ит! — диде.

— Хатын-кыз күлмәкләре юк шул миндә.

— Табарбыз. Бүген үк кичке җыелышка күлмәк киеп кил. Президиумда балкып утырырсың.

— Танымаслар, — диде Маһруй.

— Өр-яңадан танышсыннар синең белән. Безнең яшиселәр бар әле.

Газзә яшьтәшен кулыннан тотып торгызды. Алар әкрен генә авылга таба киттеләр. Алар менә ничәнче тапкыр инде тормышларын өр-яңа көйгә салып яши башларга тиешләр иде.

* * *

— Газзә апа! Сезме соң бу?

— Мин бу. Мин.

— Нишләп монда ялгыз утырасыз? Без анда Ринатны аптыратып бетердек инде, ник кунакны юл уртасында ташлап кайттың, дибез.

Вәҗһетдиннең соңлап кына туган кызы Рәхилә нәкъ әнисе төсле иде. Сузыбрак, йомшак итеп сөйли башласа, Фагыйлә дип торырсың. Газзә апа аның битендә чекерәешеп торган миңнәрен караңгыда да күргәндәй булды.

— Мин үзем төшеп калдым, — диде Газзә.

— Мин дә соңарып кайттым бүген. Училищеда җыелыш булды. Тагын җәйге эшләр турында сөйләштек. Быел да бульдозерчыларны, скреперчыларны завод төзелешенә җибәрәбез бит.

Рәхилә кайчандыр Газзә апа эшләгән тракторчы-механиклар мәктәбендә — хәзерге авыл профтехучилищесында укыта, шунда ук партоешма секретаре булып эшли. Ул Газзә апа янына утырды да:

— Ә сезне зерә дә яратып калганнар, — диде. — Бигрәк матур сөйлисез инде, Газзә апа.

— Баштан кичкәнне сөйлим инде. Менә әле үткән гомерләрне искә алып утырдым. Авылны бүтән күрә алмам бит инде.

— Ә мине, мине искә алдыгызмы соң, Газзә апа?

— Колхоз төзегән еллар искә төште әле. Аннары сугыш еллары. Сез бөтенләй башка чор кешеләре бит, Рәхилә...

— Белмим инде, сез ничектер, ә мин үзем үткәннәрне уйласам, һаман сезне искә төшерәм. Гомеремнең күп истәлекле вакыйгалары сезнең белән бәйле булып чыга.

— Ай-һай, син яшь бит әле,— диде Газзә апа, шикләнеп.

— Әле былтыр гына классташлар бергә җыелган идек. Мәктәптә укыган елларны, сугыш вакытын искә алып утырдык. Олыгаеп барабыз бит инде без дә, Газзә апа, әллә кемнәр булып беттек. Әхьяр абыйның Дамиры полковник әнә. Ул да кайткан иде. Бала чакны искә төшерүгә, кырык өченче елны Биекъярга барганыбыз искә төште. Гөлзәйнәп апа: «Газзә апагыз сезне классыгыз белән кунакка чакыра», — дигәч, колакларыбызга ышанмый торган идек. Ач, кайгылы вакыт, әле беребезнең, әле икенчебезнең әтиләре һәлак булу турында хәбәр килеп тора. Ә сез шул чакта да балаларның күңелен күрүне кайгырткансыз. Төенчекләргә кайсыбыз бер умачлык он, кайсыбыз бер-ике бәрәңге тыгып киттек бит ялан аяк тәпи-тәпи. Кыр уртасында учак ягып ашарга пешердек. Биекъяр ул чакта авыл иде бит, хәзерге белән чагыштырып та булмый. Ләкин, ай-яй, матур күренгән иде ул безгә. Пристане, элеваторы Кама буйлары бер могҗиза булып тоелган иде. Без анда истәлеккә карточкага төштек, кинога кердек. Сезнең идәндә тезелешеп кунып чыккан идек. Чынаякларыгыздан чиратлап чәй эчкән идек, хәтерлисезме?

Юк, боларны Газзә апа онытмаган иде.

— Әй, күңелле дә булган иде соң, — диде Рәхилә. — Әле Дамир да әйтә, күпме йөрдем, күпме күрдем, әмма шул Биекъярга барган кебек рәхәт сәяхәт булмады, ди.

Рәхилә тыенкы гына көлеп куйды. Үзенең институт тәмамлап, СПТУга кайткан гына чакларын искә төшерде. Ул чакта Газзә апа яңадан шунда кайтып укыта башлаган, партоешма секретаре булып сайланган иде. Нәкъ шул елларны училище бик нык киңәйде, ашханә, мастерскойлар төзелде, яңа кабинетлар булдырылды. Аларын Газзә апа да яхшы хәтерли, онытырлык кына булмады, артыннан армый-талмый чабарга, ташчы булып та, буяучы булып та эшләргә туры килде. Ул елларны чирәм җирләр өчен тракторчыларны укыттылар, училищега

имәндәй таза ирләр килеп тулды. Арада бар иде шундыйлары, берәүнең сүзен тыңламас, беркемгә баш бирмәс кебекләр иде.

— Мин дер калтырап тора идем шулар алдында,— диде Рәхилә.— Әсезне ни хикмәттер тыңлыйлар иде бит шулар. Сүзегездән чыкмыйлар иде. Күп нәрсәгә өйрәндем мин сездән ул чакта. Ни генә искә төшсә дә, уйларым һаман сезгә барып тоташа. Хәтерлисез микән, Гайнан белән өйләнешкән елларны бозылышып киткән идек без. Шунда сез булмасагыз, минем язмыш белмим кая борылыр иде икән. Көннен көнендә сезгә барып елый идем. Гайнан чирәм җирләргә үк китеп барган иде бит. Шунда сез миңа: «Үчләнмә, ачуын китерергә тырышма, алиментка бирмә», — дип киңәш иттегез. «Матур итеп, барын да аңлатып хат яз, ул анда, чит җирдә, инде суынгандыр, синең бер сүзеңне генә көтә торгандыр», — дидегез. Сүзегез хак булып чыкты бит, Газзә апа. Гайнан минем хатларыма бик матур итеп, озын-озын хатлар язды, аннан соң үзе кайтты. Бездән тату яшәгән кеше юк хәзер.

Рәхилә тагын көлеп куйды. Аннары:

— Бәй, мин һаман үземне сөйлим. Ландыш ни хәлләрдә яши соң? Ник авылны күрергә кайтмады? — диде.

— Балалар мәктәптә бит әле. Үзе диссертациясен язып утыра.

— Монда кайтыгыз сез, Газзә апа. Бөтенләйгә кайтыгыз. Безнең Биекъярда химикларга да, механикларга да эш җитәрлек бит хәзер. Ире механик бит әле аның?

— Үзләре карарлар тагын, — диде Газзә. — Мин олыгайдым инде. Тамырдан күчеп йөрүләр авырайды.

— Әй, Газзә апа! Сез сөйлисезме соң моны, әллә мин генә ялгыш ишетәмме! Исән чакта тормышны гел яңартып торырга үзегез өйрәттегез бит инде сез безне! Сездән башланган эш булды бит бу!

Рәхилә тагын тыенкы гына көлеп куйды. Аннары, Газзә апаның сүз куертасы килмәгәнен сизеп, тынып калды. Алар зур заводлардан авыл өстенә төшкән яктылыкка карап, тын гына утырдылар.

---

## Фәнис Яруллин

### Без — беренчеләр

Без — беренчеләр,
Иң беренчеләр.
Беренчеләргә
Юл җиңел булмый.
Барлык сынауны,
Чокырны, тауны
Үтәргә кирәк
Сыгылмый, сынмый.

Бүгенге көнгә
Килеп җиткәнче
Әзме кыйналдык,
Әзме сыналдык?!
Кыйналган саен,
Сыналган саен
Ныгыды безнең
Дуслык, туганлык.

Хәлсезләтәм дип,
Тәгәрәтәм дип,
Ач күзле ачлык
Янәп карады.
Бишектә килеш
Буарга теләп,
Дошман яулары
Камап карады.

Безнең үлемгә
Сусаган җаннар
Алдан ук безгә
Ясин чыктылар.

Су кирәк чакта
Авызыбызга
Пычак очында
Агу тыктылар.

Хәйлә белән дә,
Ялган белән дә,
Мәкер белән дә
Тиделәр җанга.
Без өстен булып
Хәйлә-мәкердән
Изге эш өчен
Бардык гел алга.

Безгә янаган
Аждаһаларның
Башлары инде
Җирдә череде.
Ач күзле ачлык
Корсагын уып
Чикләр аркылы
Чыгып йөгерде.

Без сынмадык та,
Сыгылмадык та,
Көрәштек, җиңдек —
Без беренчеләр.
Җирдә, тарихта
Ирекле, азат
Ил төзүчеләр,
Иң беренчеләр!

## Фаил Шәфигуллин

### Кызыл мәйдан аша

Ленин янына барам Мавзолейга,
Дип шатланып йөргән Шәмсине
Атып үтерделәр кара төндә,
Кайнар йөрәгенә ук тиде...

Кулак ядрәләре өзгән төнне
Хыялларын ярлы Шәмсинең:
«Әти,— диде улы яшь аралаш,—
Дәвам итәм юлың мин синең...»

Михнәтле һәм авыр булды бу юл,
Каршылыклар туды мең төрле.
Шәмси төзеп бетермәгән иде,
Улы колхоз төзеп бетерде.

Сөрде, чәчте, урды... Җирдәшләре
Сөеп әйтте аңа барысы да:
«Мәскәүне,— дип,— әйдә, бер күреп кайт,
Намусың ак Ленин каршында».

Һәм ул китте... Китте еллар аша,
Солдат булып китте ул анда.
...Мең тугыз йөз кырык бернең көзе
Дөрләп яна иде җиһанда.

Кар өстендә тимер эри иде,
Кургаш эри иде ярада.
Артта Мәскәү иде, алда — үлем,
Ут иде, ут... кая карама.

Батальонда алар җидәү калды...
Аннан дүртәү...
Мәскәү бер генә.
Мәскәү — Ленин, Мәскәү — ил йөрәге,
Бирмәс алар аны беркемгә!..

Егылды ул чалкан... Җиңү җиле
Кардан йолдыз ясап очырды.
Баш очында Мәскәү... Кара көйгән
Дошман танкы аяк очында.

Еллар үтте... Хыялларның Мәскәү
Иң изгесе булды, иң ныгы.
...Кызыл мәйдан аша Мавзолейга
Кереп бара Шәмси оныгы.

## Зиннур Насыйбуллин

### Корыч коя кеше

Нидән тора корыч?
Коелган ул
Ышанычтан, якты өметтән.
Кеше аңа изге хыялларын,
Ачы тирен кушып эреткән.

Бәхет сыман, якты очкын чәчеп,
Домналарда кайнап аккан ул;

Әмерена әзер, дигән төсле,
Формаларга агып каткан ул.

Сыйфатлары асыл,
Чыныккан ул
Суынып та, утта янып та.
Нәрсә ясасаң да була аннан
Уенчык та, авыр танк та...

Кеше аңа асыл сыйфат биргән,
Кеше!
Шуңа күрә корыч нык.

Тирен кушып корыч коя кеше
Ясар өчен сабан, уенчык...
Корыч коя кеше,
Корыч калкан
Кисен өчен җирдә тынычлык.

## Фәннур Сафин

### Безнең хакта хак сүз

Безнең чорның дәртле йөрәгедәй
девоннарда тибә җир каны...
Яшьлек һәм нур тулы замана бу,—
я, читләтеп кара син аны!..

Аның белән ярыша алыр бары
килер буын, килер гасырлар.
Ак сөлгесен җилдә җилфердәтеп
яшь батырлар чыгар, ак җырлар.

Дәрт тудырыр яңа калаларны,
көмеш юллар җирдә сузылыр.
Ул чакта да тарих битләрендә
безнең хакта хак сүз шул булыр:
— Октябрь!

Ал яулыклы гүзәл — төзүче кыз
дәртле бер җыр башлар — безнеңчә!..
(Җир котыпка әверелер сыман
гел акылга гына төренсә...)

...Хыялымда туган давылларны,
дулкыннарны куеп учыма,
уйга талып, озын еллар аша
карап торам гүя шул чорга...

## Шамил Анак

### Һәр көнне, һәр сәгатьне

Һәр көнне, һәр сәгатьне —
Ленинча яшәргә
Һәр җыелышка, утырышка,
биш минутлык летучкаларга хәтта —
онытмаска!
Ленинны дәшәргә.

Кешеләр каршына чыгып
сүз сөйләрдән алда —
Киңәш итәргә Ленинга:
юкмы сүзеңдә ялган.

Һәр китапны, мәкаләне,
хәтта иң кечкенә иншаны
күрсәтергә Ленинга —
укырлармы ышанып.

Бөтен шикләр, сораулар белән,
иң авыр, иң җитди мәсьәлә буенча
Мөрәҗәгать итәргә Ленинга —
ничек икән Ленин уенча.

Ленин белән башларга көнне,
онытмаска Ленин үрнәген,
Ленинча, чигенми бер адым,
яуларга кешелек үрләрен.

## Габдрахман Әпсәләмов

# ЯКТЫГА ТАБА

ХИКӘЯ



Һаман, һаман гомерем тауларын актарам. Алар Каф таулары яки Урал таулары кебек биек түгел, шулай да еллар байтакны өйгән икән. Гомеремнең һәр мәлен көн саен битен биткә язып барасы калган! Аннары нәкъ киресен уйлап куям: ул чагында болай ук кызык булыр идеме икән ул гомер турында уйлану? Мин бит вакыйгаларның меңнән берен генә искә алам. Еллар — иләк, истәлекләрне чүп-чардан арындырган, иң салмаклары гына төптә калган. Таулар актарганда шуларга игътибар итәсең. Аның бөтен кызыгы да шул табылдыкларда бугай. Шуннан соң ихтыярсыздан уйлап аласың: хәтер, хәтер, әгәр син булмасаң, кешеләр ничек яшәр иде дөньяда?!

Хәзер мин, биек таш йортның балконында, югарыдан түбән таба карап утырам. Көн кояшлы, жылы. Күңелдә әллә нинди истәлекләр актарыла. Алар мине борчымый, барысы да бик табигый һәм шулай булырга тиеш кебек. Ләкин кеше бер вакытта да булганга гына канәгать түгел. Түбән төшеп кояшлы урам буйлап тагын бер үтәсем килә. Алай булгач, урамыгыз бик мәшһүрдер, дип уйлый күрмәгез. Гади урам ул. Революциягә кадәр аны, кимсетеп булса кирәк, «Собачий» дип йөрткәннәр, әйләнә-тирәсендә тагын «Кошачий», «Кочетов» дигәннәре дә булган. Хәер, мин алар турында уйламыйм. Бу урамнан кайчандыр Алеша Пешков — булачак Максим Горький үтеп йөргән, ул турыда уйласаң да ярый, ичмасам! Пешков килеп йөргән һәм дусты Плетневка прокламацияләр басарга булышкан йортта хәзер мемориаль мәрмәр такта бар. Аннары, тарихның шаяруы дигәндәй, шул йортның күршесендә... Шарашкин фабрикасы гөрләгән. Белмәс тә идем, кулыма «Мәгълүмат» дигән бер иске китап эләкте. Ул 1907 елда чыккан. Анда Шарашкин фабрикасының игълан-рекламациясе дә бар. Шарашкин арба-чаналар белән эш иткән. Бу бәлки «Шарашкин конторасы» дип яман аты белән кереп калган Шарашкин фабрикасы түгелдер, башкадыр, әмма картлардан сораштырганым бар, «нәкъ шул үзе!» диделәр алар.

Ә гомер үтә икән. Әле моннан берничә ел элек мин утырып торган балконнан шул Шарашкин фабрикасының мәңгегә тып-тын калган ишегалды да күренә иде — монда бит бер-ике катлы агач йортлар гына, ә безнең йорт бераз читтәрәк, үзе тау башында, алты катлы. Аның балконыннан караганда әйләнә-тирәдәге ишегаллары уч төбендәгедәй күренә, ә Казан үзәгендәге беренче ундүрт катлы кунак йорты йөзек кашы кебек ялтырап тора иде. Хәзер инде без бирегә күчеп килгәч утыртыл-

ган агачлар шул хәтле куе булып үскән, яшел яфраклар арасыннан күршедәге бер-ике катлы агач йортлар да, хәтта ундүрт катлы кунак йорты да күренми, нәкъ яшел утраудагы кебек яшибез. Тик бишенче, алтынчы катларда башкарак манзара ачыла: елга вокзалы, Идел, пароходлар... Ә без өченче катта торабыз, безнең балконны агачлар каплаган. Монда кайчакта балалар гына шау-гөр килә, ләкин алар да күбрәк Эрмитажга сугыла. Анда агачлар, бакча, тирән-тирән чокырлар — уйнар өчен тагын ни кирәк!

Мин кешеләр күзеннән яшеренгән балконда утыруыма рәнҗемим, ә ара-тирә үтеп киткән кешеләргә карап сокланам гына.

Кайчандыр, кичә генә булган кебек, киң туган илебезнең ерак төньягын да, ерак көнчыгышын да гизгән, Норвегия фиордларында, Япон диңгезе ярында басып торган, «и на Тихом океане свой закончили поход» дип җырлаган бер солдатның ишегалдыннан үтүче кешеләргә балконнан гына сокланып торуы әллә ничек сәеррәк тә тоела. Әйе, тормыш абзаң мәгърур кешене ничек кенә сынамый, нинди генә хәлләргә китереп куймый. Менә шунда инде кешене хәтәр рух төшенкелегеннән хәтер дигән могҗиза саклый. Забойга төшкән шикелле, тагын гомереңнең таулары астына кереп китәсең. Анда, кабердәге кебек, дөм-караңгы түгел, якты, киң, иркен, кайсы тарафка китсәң дә юл ачык, картлар әйтмешли, дүрт ягың кыйбла. Ник? Син илең, кешеләр өчен ниндидер яхшы нәрсә эшләгәнсең. Шуңа синең гомер мәгарәләрең якты, вөҗданың тыныч.

Мин революциягә хәтле тудым, иске тормышның биш-алты елын күреп өлгергәнмен, ләкин аларны да, нәни чакка туры килгәнгә, хәтерләмим. Менә үсмер чагым хәтердә нык сакланган. Мин зур нәрсәләр турында сөйләргә базмыйм, ул безнең бүгенгебез. Менә шул зур эшләргә ничек хәзерләнгәнемне рәхәтләнеп әңгәмә кылыр идем.

Бу вакытта без авылдан китеп шәһәрдә тора башлаган идек. Шәһәрнең дә ниндиендә әле — Мәскәүдә! Караңгы авылдан соң зур калага эләккән, русча ипилек-тозлык та белмәгән «татарчонок»ның хәле нинди икәнен язмасам да чамалыйсыздыр инде. Мәскәү урамнары зур, якты, күңелле, матур, әмма тел белмәгәч, якты урам да караңгы булып күренә, үз тыкрыгыңнан арырак китсәң, адашасың да. Дөрес, яшь чакта барысына тиз ияләшәсең, зиһен үткен, җорлыгың да була. Менә якты, шау-шулы, күңелле урамнан подвалга кайтып кергәч (без подвалда тора идек), бер мәл миңгерәүләнгән акылыңны җыя алмыйча торасың. Нигә шундый зур, биек калада кешеләр баз сыман подвалда яшиләр, дип аптырашка каласың. Тәрәзә янына килсәң, аннан көн яктылыгы бераз төшә, ләкин урам күренми. Тәрәзә каршыннан таушалып беткән ботинкалар, галошлар, кайчакта күн яки киез итекләр ләштер-лоштыр үтеп китәләр, әйтерсең шул иске аяк киемнәре үзләре генә йөри. Саташмыйммы дип күзләреңне дә йомасың. Әмма син саташмыйсың, син бары тик подвалда, яртылаш җир астында, шунлыктан тыштагы кешеләрне күрмисең, аяклары гына тәрәзә каршында кыймылдый.

Тора-бара шул аяк киемнәренә карап, безнең тәрәзә каршыннан кемнәр үтеп торуын да чамалый башладым. Әгәр әкрен-әкрен генә киез итекләр ләштерди икән, бу карт кеше узып бара, биек үкчәле ялтыр ботинкалар, тегү машинасы кебек, ашыга-ашыга текелди икән, бел, бу яшь, чибәр хатын-кыз. Калын олтанлы күн итек булса — бусы инде эшче, җылы каталар кигәне булса — укытучымы, профессормы. Балаларның исә олтаннары гына ялтырый. Аларны күзәтү хәтта беркадәр кызык тоела. Син көлеп җибәргәнеңне дә сизмисең. Тәрәзә яныннан тормыш агыла.

Мәктәпкә йөри башлагач, әлеге тәрәзә төбе минем язу өстәлем булып китте. Хикмәт шунда, без алты бала, әти-әни, барлыгы сигез җан шул унбиш-уналты метрлык бер бүлмәдә торабыз. Бер аш өстәле, аерым аерым язу өстәле юк. Аш өстәле тирәсендә энеләр-сеңелләр, я өлкәннәр

сөйләшеп утыра, ә мин тәрәзә янына килеп басам. Тәрәзә төбе шактый киң — иске йортлар калын стеналы бит — тик урындыкка утырсаң тәрәзә төбеннән баш түбәң генә күренә. Шунлыктан мин басып торам, шулай укыйм, шулай язам, шулай уйланам. Бүлмәдәге шау-гөргә исем китми, аны сизмим дә. Тик тәрәзә төбендә дә гел эшләп булмый, ятар вакыт җитә. Яткач, билгеле инде, утны сүндерәләр. Минем исә йоклыйсым килми. Мин, китапларымны күтәреп, кухняга чыгам. Анда да кеше йоклый, утны сүндерәләр. Ләкин тыштагы ишек башында төннен-төн буе ут яна. Аның яктысы кухня тәрәзәсенә төшә. Дөрес, урам утының яктысы укыр өчен караңгы, әмма әмәлен табасың. Безнең аш пешерә торган зур алюмин кастрюль бар. Шуны көндез ялт иттереп чистартам да, кичен тәрәзә төбенә яткырып куям. Тыштагы лампочканың нурлары анда чагылгач, ярыйсы якты булып китә. Шулай итеп мин, берәүгә дә комачауламыйча, рәхәтләнеп китап укыйм. Китап иллә кызык, син урын җайсызлыгын онытасың, барысы да шулай булырга тиеш дип уйлыйсың. Кайчак, уйга да чумасың, бала башына сыймаса да, тормыш турында фикер йөртәсең. Билгеле, синең фикерләрең беркатлы, балаларчарак. Югары катларда, иркен бүлмәләрдә тору шәптер ул, дисең? Бер үзеңә кечкенә генә бүлмәң дә булса! Тәрәзәңне ачар идең дә, таң сызылганын күзәтер идең. Авылда таңнар сызылганын карап торганым бар, Мәскәүдә дә таңнар матур буламы икән?

Безгә кайчагында таныш-белешләр килеп йөри иде. Алар арасында Бакый абзый дигәне ешрак була. Кызыл йөзле, уртачадан озынрак буйлы. Аны ни өчендер төс алмаштырмас Бакый диләр иде. Күрәсең, кордашлары янында ул һаман яшь, һаман шаян, өстәвенә, һәрдаем мандолина чиертә — әлсерәгән карт димәссең шул аны.

Бакый абзый үзе безнең авылныкы түгел. «Иде»неке. Хәер, «Иде» дигән авыл гомумән юк бугай. Безнең яклардагы Темников дигән авылны татарлар Төмән дип йөртәләр. Ул борында гаскәр бирәмлеге — «мең»нән алынган икән. Шул Төмән кешеләре сөйләгәндә «иде» дигәнне бик күп кулланалар, ә безнең авылның сөйләм телендә «иде» бөтенләй аз. Күрәсең, шул нәрсә безнекеләргә сәер тоелган һәм алар Төмән халкына «Иде»некеләр дип кушамат такканнар.

— Бакыйулла, — диде кухня ишеген ачып тыңлап торган колгасар Бәлхия әби, — шулай оста чиертергә кемнән өйрәндең? Баскан урыныңда егылып китәрдәй буласың әмән. Мисле сандугачлар сайратасың бит, бахыркаем. Монда бит имгә дә юк ул сандугач кошчыгы.

— Дөп-дөресен әйтәсең, Бәлхия тутакай.

— Әй, әйтмә инде шул тутакай дигәнеңне, яратмыйм.

— Килгән саен әйтмәм дим дә, телдән ычкынып китә бит, каһәр.

— Борчак сибәргә дисәң «Иде» халкы оста инде ул. Әйт инде, кемнән өйрәндең бу маһирлыкка? Әллә кызлар тәрәзәсен шулай чиертә идеңме?

— Булгандыр инде яшь чакта, Бәлхия тутакай... Аһ, тагын онытып җибәрдем. Уклау белән түбәгә генә сукма. Ә кыллар чиертергә мин сандугачларның үзләреннән өйрәндем. Кешеләр моңа өйрәтә алмый.

— И әйтерсең дә инде, Бакый мәләвен,— Бәлхия абыз, авызын яулык очы белән каплап, көлеп җибәрде. — Ичмасам, чөгендер кебек кызыл йөзеңнең бер генә тамыры бирсәк селкенсәче. Бу явыл алдый дип белергә.

Бакый абзыйның кызыл йөзе шундый җитди — тораташтан кискәнмени.

— Егет чакта минем аю биеткәнне онытмадыңмы әллә, Бәлхия тутакай? Сезнең авылга да баргалый идек бит. Аю биеткән егеткә көләргә дә, куркырга да һич ярамый. Аю: «Аю хәтле аюдан көлә бит бу адәм кисәге»,— дип уйлый да ачулана. Аю ачуы бик яман ул, алла күрсәтмәсен. Шуннан өйрәнеп калган бәндәң.

— И мәләвен, Хуҗа Насретдин ишәге кебек уңнан да, сулдан да алдыйсыңмы?
Бакый абзый бу юлы да көлми.
— Бәлхия тутакай, — ди ул бик җитди итеп, — сезнең авылда ишәкләр ике аяклымыни?
— Син, мәләвен, дүрт аяктан да алдарга телисеңме?
— Дөнья булгач, бар гыйлемгә дә өйрәнергә кирәк, тутакай. Китап шулай куша.
— Я, ярый, телеңә салынма. Аю биеткәндә дә бу кадәр тел биетәсе булмагансың әле.
— Аю биеткәндәме, кызлар күзләгәндәме, тутакай? Кызларның чаршау үтә бармак янауларын да сизә идек без.
— Мәскәүдә аю биетмисеңдер бит? Булмаса, Атаулла абзыйның аючылар турындагы бер җыруын әйттереп җибәр әле. Нигәдер берсәк тыңлыйсым килә. Күңелем чәбәләнә.
— Атаулла абзый кебек гаярь егетләр кызлар күңелен берсәк чәбәләндерә белә иде шул. Гомер онытылмавы гаҗәп түгел.
— Ярар, юк нәрсәләргә төрттермә, ату башың сыер ялаган кебек тап-такыр булыр.
Бакый абзый җитди, һаман көлми.
— Аючылар янына сыерлар якын килми иде, курка иде. Хәзер бу миңа үземә дә куркыныч түгел. Барыбер бабай.
— Җитмештән узгач егет булыр идеңме? Туемсыз!
— Бетте, Бәлхия тутакай, хатыннарны сүз белән җиңеп булмый.
Бакый абзый аеруча бер дәрт белән мандолинасын чиертә башлады. Аның бераз дулкынлануын борын яфракларының дерелдәп-дерелдәп китүе генә сиздерә иде.
— Җыруын да җырларгамы, тутакай? — Бәлхия абызның баш кагуын күргәч, бик моңлы итеп сузып җибәрде:

Аючылар, баручылар, зур барабан кагучылар...

Ишек янагына сөялгән Бәлхия карчык гүя онытылды. Күңеле әйтерсең әллә кайларга — яшьлегенә кайтып китте, монда, подвалда, күзге яфрак кебек кибеп беткән озын гәүдәсе генә калды. Башка вакытларда ул тавышсыз гына көлә дә, Бакый абзыйның мутлануына: «И мәләвен!» дип, бер сүз белән җавап та кайтара иде, бүген үзенең дә йөзе тораташка әверелгән кебек. Хәтта Бакый абзыйның күз кысып каш сикертүе дә — моны ул карт буйдакның әдәпсезлеге итеп саный иде — уйларыннан аера алмады.

Мулла кызы мунча яга, аючы тәрәзәдән бага...

Шуннан соң гына Бәлхия абыз:
— И мәләвен, Бакыйулла! — дип бүлмәдән чыгып китте. Бу минутта аның күңелендә нинди уйлар тугандыр, нинди катлаулы хатирәләр кузгалгандыр — белсәң иде! Юк шул, кеше күңеле караңгы, бигрәк тә яшьлекләре без белмәгән чакларда — аю биеткән заманнарда үткән карчыкларныкы.
Былтырлары микән, без бөтен гаиләбез һәм күршеләр белән — Бәлхия абыз аларның кардәше иде — циркка бардык. Бәлхия абызны да алдык. Анда аюлар күрсәтәләр иде.
— Шул аюларны карарга гына барсам барам, ә эчке күлмәктән генә оялмыйча халык алдына чыккан хатыннарын багарга аяк та атламас идем, — диде Бәлхия абыз. Ә цирктан кайткач, исәпкә калып, бер мәл утырды да, башын селкә-селкә: — И ходайның заманалары, хәзер аюлары да башкача бии, авызларына чылбыр да бәйләмәгән. «Аюхан бабай, Атаулла ничек мунча чабына?» дип сорасаң, белми дә торганнардыр әле!

Безнең заманда аюдан: «Атаулла ничек мунча чабына?» — дип, нинди юләр сорасын? Элек сораганнар. Аю тәпие белән корсагына суккалап алгач, рәхәтләнеп көлгәннәр дә, бу — тамаша саналган.

Бакый абзый әле байтак вакыт мандолина чиертте, миңа, тәрәзә янына баскан малайга, борылып та карамады. Аның каршында мин мәгъсүм бала гына идем шул. Мин еламсырап мышный башлагач кына — хәтерем калгандыр инде — игътибар итте.

— Син нәрсә анда курай уйныйсың әле? — диде ул үчекләп. — Борыныңны салындырма, уйга да чумма. Уйны әнә Бәлхия тутакайлар уйласын, аларның уйлары күп. Малайларның күге аяз, алар кояшка үреләләр. Дөнья матур, дөнья киң. Сагышланырга ничү. Менә әле сезгә килгәндә генә күрдем: күктә яраплан оча! Гаярь егет атланган аңа, аючы түгел. Син дә шундый гаярь егет булырга хыяллан. Хәзер яшьләр заманы. Тик башта укы, белем ал. Тырышкан гына ташка кадак кагар.

Бакый абзыйның сүзләрен аңлап бетермәдем, кадак дигәне нәрсә ул тагы, шыпмы? Шуңа күрә тәрәзә каршында кыштырдау ишетелгәч:

— Кирзай кустым килә! — дип кычкырып җибәрдем. Кирзай абзыйның үзен, билгеле, күрмәдек, ләкин мин кешеләрне аяк киемнәреннән танырга өйрәнә башлаган идем инде. Кирзай кустымның бер галуш башына ак ямаулык ябыштырылган.

Ул чакта мин Кирзай кустымның чын исеме шулай дип уйлый идем, ә ул аның кушаматы булган икән. Соңыннан өлкәннәргә кушамат белән дәшкән өчен эти-әнидән шактый эләкте. Ләкин Кирзай абзыйның бик мәзәк итеп «кустым, кустым» дип сөйләве телдән төшмәде. Башкалардан беркем дә алай итеп сөйләми, ул гына. Кирзай — кире кеше, кире беткән. Аңардан теләсә нәрсә — акны кара дип сөйләвен дә көтәргә була. Тик безнең якта Кирзай дигәндә кешенең тоташ кире ягын гына күз алда тотмыйлар, аның тагын нинди-дер уңай сыйфаты да була. Кирзай абзыйны яраталар да иде. Минем үземә әлеге шул «кустым» сүзендә дә нәрсәдер бар шикелле тоела иде.

Бервакыт, әле авылда торган чакта, Кирзай кустым өйләнергә җыена. Туй — авылда зур вакыйга. Һәркем яшьләрнең бәхетле, тату, илкүз алдында ким-хур булмауларын тели. Ак сакаллы кешеләр төпле киңәшләр бирергә ашыгалар. Авылның Әгъзам исемле бер хөрмәтле карты Кирзай егет янына да килә.

— Күзле-башлы булырга җыенасың икән дип ишеттем, улым, — диген карт. — Бик яхшы, бик күркәм эш. Тик борынгылар: юлга чыксаң — юлдашың, йорт салырга булсаң — күршең турында уйла дигәннәр. Хатын алырга булсаң, бигрәк тә унга-сулга кара. Ник дисәң, бик авырга килгәндә, юлны ялгыз-ярым да үтеп була, күршедән бурычка алып, һич булмаса, йортыңны сатып та котыласың, ә яман хатыннан ничек котылырга?!

— Бик хикмәтле сүзләр әйттең, Азам абзый. Кул-аягың сызлаусыз булсын, озак яшә, яшьләргә акыл өйрәт. Акылны акчага алып булмый, — дигән Кирзай бик әдәпле кеше сыман.

— Картлар сүзен аяк аска салып таптамавың бик яхшы, улым. Белмәссең бит, синең алда бәлкем Хозыр Ильяс басып тора торгандыр.

— Амин, Азам абзый, шулай.

— Синең буең пәтәнә[1] булса да, акылың таман, җырудан да ходай буш итмәгән үзеңне. Төннәрен урамда җыруыңны ишетәбез. Ходай тәләнең рәхмәте киң шул ул.

— Юк, Азам абзый, менә бу урында ходай бирсәк махы биргән, буйны артык пәтәнә иткән.

---

[1] Пәтәнә — карсак, тәбәнәк.

— Чү, ахмак, ходайга тел тидерергә ярыймы соң! — Әгъзам бабай кулындагы озын таяк белән ачуланып җиргә төрткән.

Кирзай үзенекен кабатлаган:

— Мин, Азам абзый маем, бик тидермәс идем дә, күзле кешеләр минем пәтәнә икәнлекне үзләре күрәләр бит.

— Әдәм күзе — ботак тишеге. Син берсәк кенә хәйлә ит: хатынны да үзең кебек пәтәнәдән ал. Икегез дә бер тигез булгач, кешеләр, болар пар килгән икән, дип уйларлар. Ә берең мондый, — Әгъзам карт таягының яртысын күрсәтте, — икенчең болайга китсә, — карт кулын таягы башына күтәрде, — кычкырып көләрләр.

— Пәтәнәләрдән дә көләләр түгелме, хөрмәтле Азам абзый? Безнен очта һаман җырлыйлар бит:

Шакир синен хатынын бүдәнә,
Балаклары җирдән сөрәлә...

— Ә син, егет булсаң, аларны тыңлама. Башка җыру тап.

— Булды, рәхмәт, Азам абзый, бүгеннән болай әйттерә башлыйм:

Буй белән су үлчәмиләр,
Акылың булсын, майгынам!

— Әй, юләр, монысы да пәтәнә кызлар турында ич! Торна кызлар турында рәтле җыру да юк.

— Ник булмасын, бар, Азам абзый, менә дигән шәп җырлар. Ялганласам, җир йотсын. Әгәренки миңа гына ышанмасаң, Зәмзәмбану түтәштән сора. Ул әйтеп бирер!

Зәмзәмбану түтәш — Әгъзам бабайның үз хәләл җефете, Бәлхия абызлар күршесе. Бер чишмәнең суын эчкәнгәдер — озын буйлы. Картайгач болай да буйга мактана алмаган Әгъзам бабай җиргә тагын да чүгә төшкән, ә хатыны әйтерсең турайган гына. Элек тә усал телләр Әгъзам абзыйның теңкәсенә тигәннәр булса кирәк, хәзер дә күзен ачырмыйлар. Шуңа күрә ул буйга үзеннән зур кызга өйләнергә җыенучы егетләр турында ишетсә, авылның очына кадәр киңәш белән килми калмый. Күп очракта аның киңәшен кабул итәләр, кайчак ходай каргаган пәтәнәләр дә туры килә.

— Чүпрәк башлар сүзен сөйләп йөрергә мине кем дип беләсең, улым, — диде Әгъзам карт, бик каты ачуланып.

— Хозыр Ильяс дип беләм, Азам абзый. Үзең шулай әйттең бит,

— Тфү, пәтәнә Кирзай! — дип ачуланып төкерә дә акны-караны күрмичә китеп бара. Менә шуннан соң Кирзайга әлеге кушамат тагылып калган ди.

Бүлмәгә тагын Бәлхия абыз килеп керде. Аны күрүгә Бакый бик җитди итеп:

— Бәлхия тутакай, озын гомерле булырсың, Кирзаең килә, — диде. — Галушы башына ак төшкән, тәрәзәгез каршыннан узып киткәнен күрдек.

— Җитте инде сиңа шаяртырга, «Иде» мәләвене. Бая тутакай дип бәгыремне ашадың, хәзер Кирзаң, имеш...

— Шаярту уемда да юк, тутакай, ә түтеш дип әйтергә нигәдер телем бармый, картайтасым килми.

Ишектә звонок шалтырады.

— Әнә, тизрәк ишек ач. — Бәлхия абыз чыгып киткәч, Бакый абзый миңа борылды. — Ә син, күгәрчен баласы, артыңа әйләнмә, сабагыңны укы. Без ни сөйләмәбез, кирәклесен дә, кирәксезен дә. Без шул яртылаш җиргә сеңгән подвал кешеләре, гомеребезне дә шунда очларбыз, ахрысы. Ә син үсәсе кеше.

Бу сүзләрнең дә мәгънәсен мин бик үк аңлап бетермәдем, мин аңа әзер түгел идем әле. Билгеле, соңыннан алар турында бер генә уйламам, ә хәзер үз сүземне әйтергә ашыктым.

— Бәлхия абыз Кирзаең дип әйткәнне яратмый, ул пәтәнәшем, иксүзем, өрмәгән җиргә утыртмам үзенне, ди.

Бакый абзый зурлар арасына тыгылуымны яратмады бугай.

— Ну-ну! — диде иреннәрен алга сузып. — Балалар гына болай әйтәләр ич.

Миңа Бакый абзый һаман үчекли кебек тоелды.

— Кирзай абзый балакай түгелме әллә? — дидем үзсүзләнеп. Бәлкия абыз аңа гел пәтәнәшем, балакаем, дип әйтә.

Бу юлы Бакый абзый күзеннән яшь чыкканчы көлде.

— Ну, энем, Аюхан бабаңнан уздырдың. Сау гына бул.

Кирзай абзый бүлмәгә кергәндә дә көлә иде әле ул.

— Нәрсә болай чыркылдыйсың, Аюхан абзый, гомердә булмаганны? Әллә көләгең кузгалдымы?

— Көлмәс җирдән көләрсең, брат. Монда Аюхан абзаңнан уздырып җибәрәләр.

— Ә мин әллә «Иде» хөрәсәненә биш тиен урынына бер тәңкә көмеш ташладылармы дип уйладым. Кайчак аючыларга күктән дә бәхет ява бит.

— Анысы элекке заманнарда булгалый иде, хәзер юк. Менә синең эшең хәзер дә майлаган кебек бара... Бәлхия тутакай янында озаграк юандың, әллә бөккән белән сыйладымы үзеңне?

— Гаиптән килгән хәләл җефетен сыйларга тиеш тә ул.

— Булмас, алдыйсыңдыр ла, кәтәнә кордаш.

— Ышанмыйсыңмы, Бакый кустым? Корсагымны ялап кара.

— Башта Сандыну мунчасына барып, корсагыңны сабынлап юдыр.

— Аннан эш тормас, тик башта сәмәнеңне түлә. Атна саен мунчага барырга минем байлык юк.

— Корсагың кешенеке төсле булса, ичмасам. Акча кызганыч.

— Ә син каруланма, кустым. Сдачасына мин мунчадан соң елы сыра эчәрмен. Бик килешә ул минем корсак шәрәфкә. Ә савабын сиңа яздырырмын.

— Кычатна көнсез язмыйлар, ә кычатна көн мөслимгә хәмер эчәргә ярамый.

— Хәйләсен белсәң, ярый. Мин кружканы сул кулыма тотармын, гамәл дәфтәренә язып баручы фәрештәләр күрми дә калыр.

— Һай, пәтәнә Кирзай, бар бул да сау бул.

— Рәхмәт, кустым, яхшы сүзеңә, берүк акчаңны Бәлхушка биреп калдыр. Икенче тапкыр сорап вакланасы булмасын.

— Син болай да валчык кына ич.

— Аючылар шул валчыкны да икегә ярырга маташа.

Бакый абзый, бераз көлемсери төшеп, күз кырыйлары белән Кирзайга карап торды.

— Син, пәтәнә, берсәк арыгансың түгелме?

— Берсәк кенә булса безгә нипачем. Иртән бер пассажирга вокзалдан бәләкәй арба белән әйберен илтергә туры килде. Таганкага. Кайтып килә идем, урамның икенче ягыннан багана буе бер сакал кычкыра үземә: «Әй, малайка, бире кил». Бардым. Авызын ачып миңа карап тора, сүзен әйтә алмый.

— Гафу ит, — ди аннары, — мин малайка дип уйладым...

— Ничава, — мин әйтәм. — Ни эшләргә кушасың, мин мигом.

— Алайса, булдыра алсаң, әнә шул чүп-чарны йорт артындагы чокырга илтеп ташла. Арбаң белән.

Көнлекченең беләсең, эш туры килсә, йокламый. Башта болай гына тотынган идем, аннары бишмәтне дә салып ташладым. Җан тиргә батып өч сәгать эшләдем. Телем сузылды берче.

— Алай икән, аю биеткәнсең икән. Бүген инде Сухаругә дә бара алмассың.

— Бармый калырга ярамый. Бакый кустым, көн саен безгә мондый бәхет эләкми. Ходялар [1] кичерәк кил дигәннәр иде. Палаткаларын чистартырга, тегесен-монысын ташырга. Алар буш итми.

— Талчокка кагыла алмассың инде.

— Талчокны да әйләнеп үтмибез, Бакый кустым. Базар ябылыр алдыннан юньле тавар очрап куя кайчакта.

— Бая Бәлхия тутакай миңа туемсыз дигән иде, менә кем ул туемсызның туемсызы!

— Ни хәл итәсең, кустым, өлешебезгә тигән көмешебез.

Бакый абзый да ничектер бик җитди итеп, аз гына да шаяртмыйча:

— Әйе, өлешебезгә тигән көмешебез, — диде.

Сандугачлардан музыкага өйрәнгән, урман иясе аюны да биергә күндергән Бакый абзыйлар, көнлек кәсеп белән тереклек итүче, торыр өчен үз почмагы да булмаган, ләкин тормыш диңгезен барыбер тубыктан санаган, мәзәк яраткан, ах-ух килә белмәгән карсак Кирзай абзыйлар мәңге подвалларда торырлармы икән? Юк, алай булмаска тиештер бит. Бакый абзый дөрес әйтә торгандыр: хәзер яңа заман килә, — дип уйладым.

Мин һаман балконда утырам, тышта һаман кояш көлә. Чалт аяз күктә йөзгән нурлы кояшка, аннары ак юл сызып киткән реактив самолетка карап алам да үзалдыма елмаям. Ярты гасырдан артык вакыт үткәч, шуларны искә төшерермен дип кем уйлаган. Юк, гомерем тауларын бушка актармыйм шикелле. Хәзергә әллә ни кыйммәтле мәгъдәннәр тапканым булмаса да, эзләгән таба диләр бит.

1977

[1] Ходя — кытайлар.

## Нури Арсланов

### Аяз булсын тирмәң

Октябрьга алтмыш. Яшь ягыннан
Алты яшькә генә олы мин —
Унҗидедә Кышкы сарай алган
Батырларның, димәк, улы мин.
Броневикка баскан юлбашчының
Азатлыкка оран салганын,
Ачкан чагын гасырларның чынын,
Сурәтләвен гаҗәп алдагын...
Күреп түгел, ерак кайтавазны
Ишетеп менә безнең көннәрдә
Бүгенгечә аңлаучылар азмы
Төрле илдә, төрле телләрдә!
Никадәрле михнәт узды баштан
Бу алтмыш ел гомер эчендә:
Булды ачлык, борчу, хәттән ашкан
Азабын да күрдек, үчен дә.
Үч алдылар аклар, Антанта да
Җәеп салган булды ауларын:
Кронштадттан алып Тын океанга
Олактырдык дошман яуларын.
Халкым камап килгән кара яуның,
Каршысына чыгып басты да:
Кырык биштә явыз фашистларның
Без китердек муенын астына!
Шул сугышта кулга корал алып
Мәйдан тотканнарның берсе мин:
Язалмадым канга каләм манып,—
Солдат идем — горур — күрсенмим.
Тик исемнән чыкмый һәлакәтләр,
Онытып булмый күргән кыенны.
Тетрәп торды илләр, мәмләкәтләр,
Кан коелды, җаннар кыелды...
Мин табынам хакка-акка гына,
Тынычлыкның йөгерәм каршына,—
Мин тынычсыз кирәк чакта гына...
Хәер, кирәк миңа барсы да:
Кирәк миңа Корваланнар ирке,
Азатлыгы испан халкының:
Көтә Кеше өлешенә инде
Көмешен генә түгел,— алтынын!
Кирәк миңа — бер кем булмасын ким
Яшәү бәхете өлешен җыйганда,

Җылап туса тусын, бер кем ләкин
Яшәмәсен җылап җиһанда!

Эшсез дә юк, ач та, надан да юк,
Азат, тигез бездә һәр кеше.
Тулымы соң бәхет? Һаман да юк!..—
Чишелмәгән Җирнең язмышы.
Бездә генә әйбәт булган белән
Тынычланмый бер дә җаныбыз.
Җир толпарын алтын тезгененнән,
Әй халыклар, үзегез алыгыз!
«Алма пеш тә авызыма төш!»кә калсаң,
Ирешеп буламыни теләккә:
Ризык тәмле — тәмен белеп капсаң,—
Тик хезмәттә — сый да, хөрмәт тә!
Киләчәктә? Киләчәктә булыр
Тик дүрт кенә сәгать эш көне.
Ә шагыйрьнең егерме дүрткә тулыр,—
Тынгысыз ул, рәхмәт төшкере.
Ычкындырмас өчен, шагыйрь генә,
Илһам килгән кыйммәт чакларын,
Бозса бозар, матур килер көндә,
Социалистик хезмәт шартларын...
Яшь ягыннан Бөек Октябрьдан
Алты яшькә генә олы мин.
Ни әйтсәң дә, күрәсене күргән,
Октябрьның шагыйрь улы мин.
Туган илем! Һәрни булса синнән,
Язмышны тик сиңа бәйләдем:
Аяз булсын күгең — зәңгәр тирмәң,
Яшел булсын җирең — җәйләвең!

## Корваланнар кайта

Чили компартиясе җитәкчесе
Луис Корвалан Советлар иленә кайтты.

Дөнья тынычлыгы фашистларны
Тагын каныктыра:
Балтасыннан корбаннарның каны
Тагын тамып тора.

Тыпырчына алар — баскан җире
Утлы таба сыман,—
Илләр ирке ала газраилне
Тотып якасыннан:

Кул-аягы арынып тышавыннан,
Чыга камалганнар.
Төп иленә, үлем кочагыннан,
Кайта Корваланнар.

## Ябып булмый

Лорка жыры, Хара гитарасы,
Куньял[1] рәсемнәре авазда́ш:
Өчесендә дә көрәш манзарасы,
Өчесе дә юлдаш, замандаш.

Фашист коллыгында чигеп азап
Кемнәр генә башын куймаган!..
Төрмәләрдә Куньял рәсем ясап
Үлем белән озак уйнаган.

Уйнаган ул авыр язмыш белән,
Тоткынлыкны артка этәргән,—
Ил кайгысын рәсемнәрдә биргән,
Ишләренең рухын күтәргән.

Лорка жыры өзелә, ә Хараның
Гитарасы сына зинданда,—
Тик чыңлый жыр, тавышы гитараның
Өзелмәгән — яңгырый жиһанда.

Ә Куньялның исәнлектә ирешә
Рәсемнәре дөнья күрмәгә:
Дауда туган сәнгать дауга дәшә,
Ябып булмый аны төрмәгә.

## Өмет өзмәсә

Африкадагы хәзерге Мозамбик иленә сәяхәтче Васко да Гама беренче тапкыр 1498 елда килә. Шуннан бирле Мозамбик Португалия колонистлары коллыгында була. 1975 елда бәйсезлек ала.

Васко да Гама аяк баскан көннән
Мозамбикка коллык тагылган:
Гүзәл илдә ятлар хөкем сөргән,
Шәраб эчкән зәнки[2] багыннан.

Шәраб белән канын эчкән алар
Ак күңелле кара халыкның,—
Аһ-зар белән тулган тыныч ярлар,
Хыялы да үчкән хаклыкның...

Заман авыша хакыйкатькә таба,
Хәзер инде хәлләр үзгәчә:
Биш йөз елдан соң да ирек ала
Икән халык — өмет өзмәсә.

---

[1] Гарсиа Лорка — фашистлар төрмәсендә һәлак булган испан шагыйре.
Виктор Хара — Чили жырчысы. Фашистлар концлагеренда үтерелә.
Алвaро Куньял — Португалия коммунистлар партиясе житәкчесе.
Аның төрмәдә ясаган рәсемнәре 1977 елда, Советлар илендә, альбом булып басылып чыга.

[2] Зәнки — кара тәнле кеше, негр.

## Кояшына карап

Әле күптән түгел зарлы-моңлы
Туган иле тарга,
Куньял кебекләрнең урыны булды
Төрмәләрдә, дарда...

Португаллар күтәрделәр байрак,
Уйлар иркенәйде:
Исте җилләр, океан торды кайнап
Һәм тар ил киңәйде.

Киңәйде ил — фашист буып токкан
Кысасыннан арынып,
Күтәрелде, бар булгандай юктан,
Азатлыкка табынып.

Азатлыкка табынып Вириат та[1]
Римга каршы торган,
Канатланып очкан акбүз атта,
Баскыннарны кырган.

Бүген дә ул Салазар өрәгенә
Бармак яный сыман:
— Моннан ары азапланып йөрмә!
Чыктым тарихымнан —

Күтәрелдем, узганнардан китеп,
Илем күкләренә,
Рухым керә, заманнарны үтеп,
Халкым күкрәгенә!

Португалия бүген — давыл кичереп
Исән калган кораб —
Бара әкрен, төннән юлын күчереп,
Кояшына карап!

## «Фуэнтеовехуна»[2]

Парламент тарафыннан Испания коммунистлар партиясе һәм профсоюзлары легальләштерелү уңае белән.

Көн китер, җил, испан күкләренә,
Болытларны ку да.
Ярларыннан ташый, күтәрелә
«Фуэнтеовехуна».

---

[1] Вириат — халык каһарманы, гади көтүче, соңыннан полководец. Моннан ике мең еллар элек баш күтәргән Лузитания (Португалия) кабиләләренең юлбашчысы.

[2] «Фуэнтеовехуна» («Сарыклар чишмәсе») — испанлы бөек язучы Лопе де Вега әсәре. Шул исемдәге авыл кешеләре, баш күтәреп, үзләренең командоры — феодалны үтерәләр. Судта алар: «Кем үтерде?» дигән сорауга, барысы бердәм булып: «Фуэнтеовехуна» дип җавап бирә.

Фашистларның командоры китте
Ташлап куләгәсен,—
Варислары белә инде илне
Халык күтәрәсен.

Шуңа алар өстән, сак кыланып,
Бушаталар тезген.
Ә «Тезген,— ди ирек сөйгән халык,—
Булыр кулда безнең!»

Җир селкенә Мадрид, Гренадада,
Тетри Барселона...
Туфан булып җәелә Испаниядә
«Фуэнтеовехуна».

## Ветераннар

### ЖЫР

Ветераннар, ветераннар,
Мәҗлес корып утырганнар,—
Сөйләшәләр тәмләп үзара:
— Карт солдат булса да, кара,
Күзләреннән яшьләр тама,
Күңеле нечкәдер шул, йомшара...

Мыекларын бора-бора,
Хикәятен бәян кыла
Кашларына кар яуган солдат:
— Игәү белән кырындык без,
Төтеннәрдә кызындык без,
Исән калдык... язмышны алдап.

Мәйдан тотып без көрәштек,
Фронтларда калды яшьлек:
Яшьлекне без яуда үткәрдек.
Ташкыннар, силләргә кердек,
Илләр, җирләр айкап йөрдек,
Сөякләрдән һәйкәл күтәрдек.

Ветераннар, ветераннар,
Кайталмый калган корбаннар
Хөрмәтенә алыйк тостларны.
Сафлар сирәгәя бара,
Гамьнәр тирәнәя бара,
Онытмагыз исән дусларны.

## Күли-Чурлар кебек

Кешнәсә дә тетрәп Кара-гизем,
Тыйнакланган шактый ярсулар...
Бәйгеләрдә алдан килә идем,
Инде мине кемнәр каршылар?!

Алышынган күпме өзәңгеләр,
Тезгеннәрем корау-ямаулы...
Сагышларым үтә үзәгемә,
Кемләр бәйләр йөрәк ярамны?

Шул ярамдыр, ахры, җан уятып,
Төшермәүче мине иярдән.
Ялгыз түгел, күрәм, ат уйнатып,
Яшь егетләр миңа ияргән.

Төшләремдә һаман сугыш күрәм,
Истән чыкмый, хәер өндә дә...
Калсын әйдә алар эчләремдә,—
Кирәге юк аның кемгә дә.

Кирәге юк килер буыннарга
Мәйданнарда егылып баш кую.
Ләкин х ә я т диган изге дауда
Кирәк ярсу, кирәк ашкыну!

Ир ирешкән икән атка менеп,
Сөңге алып, калкан кияргә,—
Сиксән яшьлек Кули-Чурлар[1] кебек
Ул үләргә тиеш иярдә!

## Була күрсен иде

К е ш е — гаҗәп зур җан табигатьтә,
Мәңге яши, мәңге эзләнә.
Үз алласын җиңеп чыга хәтта:
Ул тотынса — дөнья үзгәрә.

Әлбәттә, ул лаек яхшы атка,
Кулларыннан киләдер һәр эш!
Шул куллардан фәкать яхшы якка
Була күрсен иде үзгәреш.

1977

---

[1] Кули-Чур — I һәм II Төрки хәканәт полководецы. Карт батыр сиксән яшендә сугыш мәйданында һәлак була.

## Нәби Дәүли

### Мадам Клод трагедиясе

Парижда 87 яшьлек карчык мадам Клод угрылыкта гаепләнеп хөкемгә тартылды. Судта ул үзенең авыр тормышы турында сөйләп, «Мине бу җинаятькә ачлык мәҗбүр итте», диде. Суд моны искә алмый һәм Клод бу хурлыктан өендә газ белән агуланып үлә.

*Газета хәбәрләреннән*

I

Син Парижда тудың, мадам Клод,
Ул көнеңне Париж белмәде.
Исемеңне беркем ишетмәде.
Француз кызын
Франция
«Кызым!» димәде.

Үсеп җиттең, зифа, матур булдың,
Анаң сиңа бәхет юрады.
Бусагадан атлап өлгермәдең,
Сиңа тормыш...
Инде салды үзенең тозагын.

Иргә чыктың, инде ана булдың,
Инде үзең бишек янында.
Балаларың синең үсә торды,
Китә торды,
Үлә торды сугыш ягында.

Кем булмадың, нинди эш тотмадың.
Газапларны сүзсез кичердең.
Күз яшеңне йөзем ширбәтенә
Куша-куша,
Франциягә шәраб эчердең.

Хакым бардыр сиңа, мадам Клод,
Анам кебек кешем дияргә.
Франциянең Эйфель манарасы
Тиеш иде
Синең алда башын ияргә.

Еллар узды, узды яшьлек чагың,
Сиңа язмыш бәхет бирмәде.
Үз илеңдә ятим хатын идең,
Француз кызын
Франция сөя белмәде.

2

Бүген иртән Париж урамнары
Йокысыннан тетрәп уянды —
Газетада хәбәр чыгарганнар,
Дөнья купты,
Радиолар шаулап улады.

Нәрсә булган, нинди шом куркыта?
Полиция аяк өстендә.
Телевизор — киң экран ачык:
Гайбәтләрдән
Фил кадәрле рәсем төшерә.

— Көпә-көндез кичә бер кибеттән
Бер каракны тотып алганнар.
Европада, имеш, ул карактан
Гангстерлар
Илле елга артта калганнар.

Беркайчан да, әле беркайда да
Мондый карак, имеш, булмаган.
Сиксән җиде яшьлек мадам Клод,
Күз алдында,
Кул астыннан балык урлаган.

Уен түгел, өч йөз грамм балык...
Нинди хурлык, нинди явызлык?
Хөкемдарлар тиеш моның өчен
Ул карчыкка
Кигерергә тимер авызлык...

Мадам Клод исеме телдән төшми,
«Оялмыймсың?» диләр карчыкка!
Беркем әйтми ләкин, ничек итеп
Тузүләре мөмкин ачлыкка?

3

Суд алдына басты мадам Клод
Сиксән җиде яше тулганда.
Бүген аны бөтен Париж күрә, —
Күрмәделәр
Ач, ялангач, ялгыз булганда.

Ник урладың? — диеп сорамыйлар,
Нигә син ач? — диеп тормыйлар.
Ә банкирлар нигә судта түгел?
Алар түрдә.
Францияне бергә урлыйлар.

Хурлык, имеш, бу түбәнлек, имеш,
Бу — кара тап француз йөзенә...
Син җавап бир инде, мадам Клод,
Судьяларның
Авыз ерып әйткән сүзенә.

— Мин хурлыкны сездән күбрәк аңлыйм.
Әфәнделәр, белеп торыгыз:
Сез законнар уйлап чыгарасыз,
Законнардан
Акча ясый сезнең кулыгыз.

Мин мең кабат сездән инсафлырак,
Нәселләрем белән, тумыштан.
Мин кулларым белән, җаным белән,
Саклап тордым
Францияне үзен хурлыктан...

Бу сүзләрең синең соңгы күкрәү
Булды шунда — бу суд залында.
Җәберләнгән ана исеменнән,
Мадам Клод,
Шаһит булдың илең алдында.

## 4

Суд тиз узды, әшне тиз тоттылар,
Япмадылар сине төрмәгә.
Сиңа калды бары рәхмәт әйтеп,
Судьяларга,
Озын гомер, саулык теләргә.

Унбиш көнлек җәза — шартлы хөкем,
Каян килеп, кая китмәгән!
Үз өең дә синең, мадам Клод,
Начар түгел,
Таштан өйгән кара төрмәдән.

Утыра бир түзеп тыныч кына,
Борчымаслар сине биредә.
Закон сиңа ирек, хөрлек бирде.
Ә төрмәдә
Сиңа кирәк икмәк бирергә...

Көн дә узды, инде төн дә җитте,
Син ялгызың шыксыз бүлмәдә.
Франция үзе тиеш иде
Гомер хакын,
Хезмәт хакын сиңа түләргә.

Ул турыда Париж уйламый да,
Ресторанда Париж типтерә.
Шәраб эчә, матур кызлар коча,
Ачлык белән,
Кайгы белән сине киптерә.

Оныттылар сине, мадам Клод,
Булганмы син, җирдә торганмы?
Хөкемдарлар алды эш хакларын,
Алар хәзер
Көтә инде яңа корбанны.

5

Я, нишлисең инде, мадам Клод?
Елар идең, чыкмый яшьләрең.
Франция синең өчен түгел,
Син, тол хатын,
Франция өчен яшәдең.

Нахак сүзләр хөкем карарында:
«Карак» исеме сиңа тагылды.
Шул сүзләрне юк сүз итәр өчен,
Синең карар
Үз кулларың белән язылды.

Тимер мичтән зәңгәр ут агыла.
Сиздермичә буа газ исе.
...Әле генә кеше бар иде бит...
Әле генә
Бу дөньядан китте ул кеше.

Бүлмәң — тынлык, күршеләрең йоклый.
Язмышыңны алар белмиләр.
Газ акчасын кемнән түләтергә?
Синнән дисәң
Үлгәннәрне судка бирмиләр.

Син Парижда тудың, мадам Клод,
Бишегеңне Париж күрмәде.
Үлемеңне беркем ишетмәде,
Француз кызын
Франция сөя белмәде.

Ә мин уйлыйм сине, мадам Клод,
Синең илдән ерак якларда.
Нахак сүздән, түбән исемнәрдән
Мин сүз алдым
Намусыңны синең якларга.

Хакым бардыр сине, мадам Клод,
Анам кебек кешем дияргә.
Франциянең Эйфель манарасы
Мәңге тиеш
Синең алда башын ияргә.

1976

## Галимҗан Латыйп

### Тополь

Соңлабрак кайттың, кордаш,
Туган-үскән йортыңа.
Анда бары лепер-лепер
Ялгыз тополь утыра.

Кайда булдың, озак йөрдең?
Онытмагансың икән!..
Монда бары чордашлардан
Син исән дә, мин исән.

Сагынды. Төшләрендә гел
Күрде сине әткәең.
Бар, кадерлә, бар, бер юат
Аның соңгы ядкарен.

Хәер, инде ни файда бар
Үксеп бе́р елавыңнан.
Без болай да гаҗиз аның
Сагышлы җырларыннан.

Давылда чайкала гына,
Җил тынса, башын ия.
Саргайды, сагышланды ул
«Ник кайтмый?» дия-дия.

Әткәң алтын кеше иде,
Бер үпкә белдертмәде.
Бер кемнән синең исемгә
Яман тел тидертмәде.

Бала күңеле далада шул,
Ата күңеле балада.
Кемнеңдер нигезе бетә,
Кемнекедер яңара.

### Чишмә тазартучы картлар

Малай чакта эчкән суларымны
Мин аксакал булгач тапмадым.
Хәтеремдә ялларыннан сыйпап
Сугарганым күлем атларын.

Ат тоягы баскан эзләр дә юк,
«Салкын чишмә» дигән сүзләр дә юк.

Ул чишмәләр челтер-челтер килеп,
Белмим инде, күпме еллар аккан.
Кая киткән чишмә тазартучы,
Тынгы белмәс, җитез куллы картлар?

Чишмәләре күмелеп калган кебек,
Күмелгәннәр, ахры, үзләре дә.
Гореф-гадәт, кылган изгелекләр
Сакланалар күңел түрләрендә.

Язмышынаниләр язган икән
Буын аша килер буыннарның?
Ни булса да, барыбер без җаваплы
Иртәгәсе өчен бу дөньяның!

## Читтә түгел

Карпат итәгендә ак чәчәкләр,
Карпат түбәсендә ак карлар.
Якты көннәр өчен кайнар каннар
Ак карларга кушылып акканнар.

Якташларның яткан урынын күрдем,
Читтә түгел алар, уртада.
«Оныклары нихәл, үсәләрме?»—
Дигән сыман зәңгәр ут яна.

Чал Карпатның чалый имәннәре
Давылларда аумый, нык тора —
Беркайчан да аяк бастырмам дип
Дошманнарны туган йортыма!

## Кояшлы язларда

Кояшлы язларда,
Саламлы абзарда
Яратам тавыкның
Пыранлап, кытаклап
Оядан төшкәнен.
Ялгашка йөгереп,
Иң алдан өлгереп,
Борынын күтәреп,
Сусап су эчкәнен.

Авылның ямендә,
Чишмәләр түмендә
Каз-үрдәк тавышы,
Әтәчләр тавышы
Бар ул бар, мин беләм.
Бәбкәләр артыннан
Чал чәчем туздырып,

Күңелем белән мин
Һаман да йөгерәм.

Мин авыл малае
Булганга күрәме,
Сагынам, яратам
Авылны һаман да,
Ниндидер нәфислек,
Гадилек, гүзәллек,
Тылсымлы, ягымлы
Зур бер көч бар анда.

## Уралда уйлану

Урап-урап йөрим Уралны.
Әй, урманы аның, урманы!
Бер түбәнгә төшә, бер менә
Әкияттәге кебек юллары.

Нарат исләренә кушылып,
Челтер-челтер ага чишмәләр.
Таш өстенә басып, кушучлап
Кемнәр аның суын эчмәгән.

Кая барсам — хезмәт! Ямь генә!
Нәрсә капсаң — шифа, тәм генә!
...Бу кадәре гүзәл җирләрне
Биргән аңа дөнья мәңгегә.

## Керә көз минем күңелгә...

Күтәрелер-күтәрелмәс
Иртәнге томан тышта.
Үтте ыспас яңгырлары,
Көз килде, көннәр кыска.

Чаган яфрагы сап-сары —
Өлгергән лимон төсле.
Кайлардан ала бу дөнья
Шул кадәр үзгәрешне?

Үткән ел әле бу вакыт
Урамнар яшел иде.
Һавалар йомшак, зәп-зәңгәр,
Күкләрдә яшен иде.

Җәе — җәй, кышы — кыш чаклар
Бик сирәк була хәзер.
Табигать көйсез кияүдәй
Көйсезләнергә әзер.

Керә көз минем күңелгә
Сары чикләвек сыман,
Башлана минем язларым,
Башлана менә шуннан.

**Мәрди Рафиков**

# БЕР ДИСТӘ МИФТАХЕТДИНОВЛАР

1



Кызык кына бу дөнья: юлга чыктыңмы — кешеләр белән очрашасың. Очрашасың да дуслар булып аерылышасың. Минем поезд да станцияне артта калдырып һәм бергәләп юл кыскарткан дус-ишләрне алып китеп барды. Соңгы вагоны әнә генә бормада югалды. Хәзер анда агачлар гына чайкала. Алар килгән кунакны сәламли кебек тоела. Бәлки китеп барган дусларны озатып шулай итәләрдер. Хәер, яшел җиләннәре үзләре белән, ни кылсалар да була.

Ә мин, юл кешесе, күксел тузан сырган автомашина кабинасына, мыек та төртмәгән шофер янына кереп утырдым. Егетнең теле бик юма да, бик чарлы да булып чыкты. Сораша, сөйли. Тәмам үз итте, мин дә яратырга өлгердем. Шофер егет белән очраштым — тагын дус табылды. Хәзер үз итеп сорашам:

— Сезнең авылда нинди осталар яши?

— Ипи үстерүчеләр.

— Тагын?

— Музыкалы гаилә бар. Бөтенесе дә скрипкада өздерә. — Ул, гаҗәпләндеме икән дигән сыман, миңа күз төшереп алды. Аннары өстәп куйды:— Тагынмы? Тагын скульптура әсәре иҗат итүче һәвәскәребез бар. Кеше сынын коеп куя.

Хәзер инде сорарга да кирәкми. Шофер егет тәмам ачылып китте, авылының үзенчәлеге, байлыгы, тормышы турында ләззәтләнеп сөйли:

— Янә безнең Чынлыда казлар бик күп. Унбиш меңгә җитә диләр. Дүрт көтүгә туплап көтәбез. Ә сезнең каз көтүе күргәнегез бармы?

Ул җавап та көтмәде, үз алдына хихылдап куйды.

— Бездә казлар күп, ә Бизнәдә кызлар...

Район советы башкарма комитеты председателе Аркадий Владимирович Николаев белән сөйләшкәндә тузанлы машина кабинасында шо-

фер белән шушы әнгәмә искә төште. Башлык кеше Татар Бизнәсе авылына барырга җыена икән. Җитәкченең авылда эше бетмәс, билгеле. Ләкин ул мине бүтәнгә ымсындырды.

— Татар Бизнәсендә тагын бер хатын Герой ана исеменә лаек булды. Мифтахетдиновлар семьясында. Котларга кирәк булыр үзен,— диде райбашкарма председателе, Указны күрсәтеп. Шофер әйткән авыл ләбаса, кызлары, бала-чагасы күп җир. Күрәсе иде ул бай төбәкне, ишле гаиләләрнең тормышын карыйсы иде. Эшле дә, ашлы да, шатлыклы дадыр андый семьялар.

Ымсынуым, күңел җилкенүем Аркадий Владимировичка иреште бугай. Ул мине үзе белән алды. Кызыклы очрашуга өметләнеп юлга чыктык.

Иген өлгергән чак. Юлы да басулар аша сузылган. Карап баруы бик күңелле. Арышны теземнәргә салып киткәннәр. Күпер кебек ята. Люцерна печәнен җыеп эскертләргә өйгәннәр. Борчак басуында тузан күтәреп комбайннар эшли. Уңышы ничек икән?

Шактый бардык. Машина калкулык өстенә килеп чыкты. Аста авыл җәйрәп ята. Елганың ике ягына урнашкан.

— Татар Бизнәсе,— диде шофер гидлар кебек итеп.— Елгасы да Бизнә атлы.

Карасана, таныш елга ләбаса бу. Чувашстанның Шымыршы урманнарында йөрүем искә төште. Җәелеп һәм шаулап аккан су кичкән идек. Очлары күккә тигән наратлар арасында бик матур иде ул. «Бизнә елгасы» диделәр. Менә кайдан агып килгән икән ул. Җыры мондагы челтер чишмәләрдән, камышлы инешләрдән башлана икән. Авыл аның нәкъ шул аһәңен тыңлау өчен ярына, тугаена утыргандыр да инде. Мәктәпне дә аның чишмәле ярына салганнар, агачлар арасына сыенган бикалары бик матур күренеп тора. Мондагы кешеләр үз авыллары белән мактаналардыр. Хәер, туган җире турында беркем дә яман сүз әйтмәс!

Аркадий Владимировичның эше шактый күп булып чыкты. Мәшәкатьләнеп йөри торгач кич җитте. Көтү кайтты. Тын торган урам беркавым ду килеп алды. Авыл өстенә әчкелтем күксел тузан күтәрелде. Бу — кечке авылның матурлыгы, аның тормышында һич артык булмаган бер бизәк иде.

Мифтахетдиновларга барырга җыенабыз. Өйләрен югары очта диделәр. Малай-шалай күрсәтеп үк бирде. Бер яклы урамның башында ук чишмәле чокырга койрык белән утырган йорт. Тәрәзәләре өйлә кояшына караган. Тәрәзә каршысында киң басу җәелеп ята. Еракта, офык сызыгы булып, урман күренә.

Урыс капканы шыгырдатып ачабыз. Безне яшь кенә хатын-кыз каршылый. Чибәрлеге бөтен. Чәчен, юл салып, ике якка тараган. Сөйкемле күзләре өстендә кыз-кыркын хыялланган нечкә кыйгач кашлар. Бите тигез булып кояшта янган, йөзенә бик килешле. Күлмәгенең җиңнәрен сызганып җибәргән: эш кешесе булуы сизелеп тора. Герой ананың, мөгаен, олы кызыдыр.

— Исәнмесез!

— Бик әйбәт әле. Әйдәгез, узыгыз!

— Әнигез өйдәме?

Кыз дигәнебез күзен тутырып безгә карый. Йөзендә гаҗәпләнү билгесе күренә.

— Бәй, минем әни күптән үлде ич инде.

Хәзер без аптырап калдык. Аркадий Владимирович миңа, мин аңа карыйм. Менә көлкегә каласың булса. Тәки йортны бутаганбыз. Мифтахетдиновлар урынына әллә кемгә килеп кергәнбез түгелме? Бу малай-шалайга ышанып эш итсәң...

— Гафу итегез. Безгә монда Герой ана семьясы тора дигәннәр иде. Мифтахетдиновлар.

— Бәй, Герой ана мин булам ич инде. Рәйсә мин, Мифтахетдинова.

Кем уйлаган шулай килеп чыгар, бу яшь хатын ун бала анасы булыр дип. Яңадан сүз башладык.

— Исәнмесез! Герой ана исеме бирелү белән чын күңелдән котлыйбыз үзегезне, иптәш Мифтахетдинова. Тормышыгыз тигез булсын, улкызны батыр итеп үстерегез!

— Котлавыгыз өчен дә рәхмәт, теләгегез өчен дә.— Рәйсә рәхәт бер елмаеп куйды. Аннары, алдан кыстамавына уңайсызланган сыман, куллары белән болдырга күрсәтеп сөйли башлады:— Бәй, ник монда басып торасыз әле. Өйгә керегез. Хәзер чәй куеп җибәрәм. Әле оланнар белән яңа гына басудан кайттык. Борчак чабарга барган идек. Дүрт гектарны ялт иттердек. Сабагы галәмәт озын. Уңышы әйбәт чыгар.

Аны тыңлый-тыңлый болдырга күтәреләбез. Ә күз алдында басу җәйри. Аның бер кишәрлегендә киек казлар кебек тезелешеп Мифтахетдиновлар борчак чаба. Ана кеше, чалгысын җайлы гына селтәп, алдан бара. Эшләгәндә сүз кирәкми, оланнар чалгыны әниләре кебек тотарга, теземне тигез итеп салырга тырышалар. Ана кеше үз үрнәге белән өйрәтә оланнарын, бер-береннән калышмаска күнектерә. Тәмам ныгымаган беләк өчен озын сабаклы борчакны егуы авырдыр. Аның каравы, әни белән бергә. Авырлыгы онытылыр, рәхәте күңелгә сеңәр. Алар өчен чын тормыш менә шунда башлана. Аналары юкка гына барын да басуга җыеп килмәгән. «Өйрәнсеннәр, хезмәт тәмен татысыннар, ул тәм тормышта һәрчак кирәк булачак»,— дигәндер. Ә әниләр сүзе йөрәккә ята ул, рухны нык канатлы итә.

Тагын Рәйсәгә карыйм. Аның битен кояш нурлары менә кайда сыйпаган икән. Ул балаларына дәрес биргән. Тормыш дәресе, хезмәт дәресе!

Иркен верандага үтәбез. Стенага ранжирлап элгечләр кагылган: бер, ике, өч... Аста аяк киемнәре: дүрт, биш, алты... Тузанлы кием өйгә керми — тәртибе шул. Пөхтәлек, чисталык үрнәге. Ана шулай күнектергән. Оланнарның һәркайсы эш киемен буе җиткән элгечкә элә. Иң өстәгесе әлегә буш. Бригадир этиләре — Әсәдулла — әле эштән кайтмаган. «Җәзбә таягы» белән борчак җирен үлчәп йөридер, я комбайнчылар янында кайнашадыр. Кайткач, пинҗәген югарыдагы элгечкә, Рәйсә киемнәре белән янәшә элә, җинел түфлиен идәнгә, пинҗәге астына куя. Ә иң түбәндәге элгеч буш түгел инде. Анда — Рәшит күлмәге, эшләп кайткан, тирле күлмәк. Ул — дүртенче классны бетергән малай — басуда эшләүчеләргә чишмәдән салкын су китереп торган. Борчак чабучы әнисенә дә илткән, бригаданың бүтән кешеләренә дә. Җинел арбага җигелгән җирән кашка белән басуны аркылы-торкылы иңләгән. Шулай нәни башы белән икмәк басуында хезмәт әлифбасының беренче битен ачкан, гомергә күңелендә калырлык рәхәт кичергән.

Бусагадан атлаганчы ук гаилә тормышы белән күпмедер танышырга өлгердек. Файдалы хезмәтне яшәү кагыйдәсенең башына күтәргәннәр Мифтахетдиновлар, аңа егәрлек, шатлык, бердәмлек, куәт мәгънәсе биргәннәр. Рәйсә ханымны тыңлаганда чорыбызның олы педагогы Надежда Константиновна Крупская сүзләре искә төшә. «Балаларны кече яшьтән шулай тәрбияләргә кирәк ки, алар бергәләп яшәргә һәм эшләргә өйрәнсеннәр». Ә ул тәрбия стенага беркеткән шушы гади элгечтән дә башланадыр, баланы тулы, җанлы тормыш белән яшәргә һәм эшләргә күнектерүдә ата-ана өчен вак-төяк юктыр. Олы тормыш, дөньяга шатлыклы караш үзе менә шушы вак-төяктән бөреләнәдер. Тәпи баскан бөтен балаларын урак өсте басуына алып барган ана үз күңелендә әлеге яшәү кагыйдәләрен йөртә һәм сөекле оланна-

рына кучерергә телидер. В. Г. Белинский әйткәнчә, тәрбия — бөек эш: аның белән кешенең язмышы хәл кылына.

Безне өйдә хәйран тамаша көткән икән әле. Бусагадан атлавыбыз булды — бала-чага сырып алды: бер дистә Мифтахетдиновлар. Алты малай, дүрт кыз. Бишектән төшеп яңа тәпиләгән шомырт күзле (тьфүтьфү, күз тимәсен!) Зөлфиягә тикле каршыга баскан. Сәламлиләр, кызык итеп, олыларча, кул бирәләр, туктаусыз «Исәнмесез, абый»ны кабатлыйлар. Ие, борынгылар дөрес әйткән, ишле гаиләдә ятсыну юк. Өстәл янына ук чакыралар.

Утырган идек, тагын сырып алдылар. Бер-берен бүлдереп сорашалар: кайдан килдегез, нишләп йөрисез, сез торган җирдә ниләр бар? Җавап биреп кенә өлгер.

— Без,— ди Аркадий Владимирович,— әниегезне котларга районнан килдек. Әниегезгә Герой исеме бирелде.

Бүлмә гөр итеп алды. Аннары кызларның берсе, кулын чәбәкләп, тавышны басты:

— Туктагыз, үзем әйтәм. Беләбез, әни турында әти гәзитеннән укыдык.

Шаяртып куям:

— Сез шулай газета да укыйсызмыни?

— Укыйбыз, укыйбыз.

Теге кыз, мине тыңлагыз дигән сыман, мәктәптәгечә, кулын күтәрде.

— Тәзкирә, Шәүкәт, Рәшит, Әмир «Яшь ленинчы» һәм «Ялкын» алалар. Наил, мин, Камил зурлар инде. «Татарстан яшьләре»нә язылдык.

— Ә әтиегез газетасы нинди?

— Әти үзе дә дәү, газетаның да дәвен, «Социалистик Татарстан»ны алдыра, белергә теләсәгез. Чүпрәледә чыккан газетаны да укый. Әни белән бергә укыйлар.

Шушы балаларның йотлыга-йотлыга сөйләүләрен тыңлыйбыз, ә күз алдыма бүгенге картлар килеп баса. Алар бот чаба, «хәзерге яшьләр белеп туа»,— диләр. Белмичә, бер семьяга әнә никадәр газета-журнал килә. Олысына да, кечесенә дә бар. Шул матбугат белән йортка нихәтле яңалык, хәбәр керә. Бер гаиләдә укучылар конференциясе, дискуссия-фәлән, кичә үткәрерлек.

Картлар сүзенең тагын бер мәгънәле ягын искәрәм. Патша Россиясе Татар Бизнәсе крестьяннарына томаналыктан, ачлык-хәерчелектән үзгә бер нәрсә дә бирмәгән. Тормыш ямен белмичә, сыкранып яшәгәннәр. Тик аларны Бөек Октябрь, Совет власте гына хәерчелектән, ялангачлыктан тартып алган һәм бүгенге шатлыклы тормышка китергән. Теләсә кайсына кер — муллык бөркелә. Октябрь биргән таза тормыш Герой ана семьясында да ачык чагыла. Монда җәмгыять сулышы, аның йогынтысы бөтен яктан үтеп кергән. Гаиләдә алты укучы, дүрт комсомолец. Үзе бер оешма. Пионерлар да, октябрят та бар. Менә нинди ячейка Мифтахетдиновлар семьясы! Комсомол җыелышы, пионер сборы үткәрергә, тәртип, әхлак, уку турында уртага салып сөйләшергә була. Гаиләгә бу байлыкны да Совет власте биргән.

Монда мохтаҗлык юк. Хезмәтле йортта, бүгенге шартларда, аның ни икәнлеген дә белмиләр. Урамга чыгып чапкан балалар чыр-чуы басылгач, Рәйсә белән шул темага гәп сатып алабыз.

— Ишле семья — тамаклы семья, диләр бит. Кыенлыгы сизелмиме?

— «Ашлы семья» дип тә әйтәләр,— ди Аркадий Владимирович, мина кушылып.— Таза эшлиләр, ипле ашыйлардыр.

— Анысы бар,— ди Рәйсә елмаеп.— Үсә торган чаклары, пешереп кенә өлгерт. Әле кичә генә тугыз дәү икмәк салган идем, өч көнгә

житмәс.— Аннары шунда ук шаяртып ала: — Икмәк пешерү өчен генә дә елга йөз пот он чак була. Оланнар, шөкер, эшләгәндәгечә таза ашыйлар.

Ананың ярым шаяртып сөйләгән бу сүзләрендә чиксез шатлык сизелә, аның «ашасыннар, ныгып үссеннәр, ризыкка кытлык юк» дигән фикерен тоясың. Шул хакта төпченсәң, мөгаен, җавабы да әзер: «Күп итеп шикәр чөгендере үстерәбез, балалар белән бүтән эшләрдә катнашабыз. Оланнарның һәркайсы кул арасына керә, яшьтән үк икмәклек эшли»,— дияр.

Төпчену артык. Рәйсә табынны үзенчә «сүтә»:

— Шикәрне, дөрес, нормага салдык. Ирек бирсәң, гел икмәк белән шикәр түшиләр, көнгә биш кило җитми. Ә хәзер норма: семьяга көнгә бер кило, вәссәләм.

Бер килограмм... Елга егерме өч потка якын. Менә нинди ишле гаиләнең табыны! Сөт-катык, ит-май, яшелчә дә күп тотыла. Шуңа күрә дә ана шатлык белән: «Мохтаҗлык юк!»— ди. Элеккеге бизнәләләрнең төшенә дә кермәгәнне бүген гади нәрсә итеп сөйли. Ничек алга киткәнбез, никадәр үскәнбез!

Стена буйлап караватлар тезелгән. Һәркайсында мамык мендәр, кулдан чиккән җәймә. Малайларның бүлмәсе аерым икән. Җыештырырга гына өлгер. Иркә бала үстергән аналарның зарын хуплардай буласың. «Әле ярый икәү генә, ун булса нишләр идем?»— дип әйткән икән бер хатын. Исемә төшкән шул сүзләрне Рәйсәгә ирештерәм. Ул күзләрен тутырып, кашын сындырып миңа карый, менә хәзер: «Ул хатын безнең авылныкы түгелдер. Бездә бүлнискә чапмыйлар, бала да яраталар, сәламәт тә яшиләр»,— диләр төсле. Кырык яшенә кадәр ун бала тудырган һәм кызлар чибәрлеген саклаган хатын шулай әйтергә хаклыдыр да. Ләкин Рәйсәнең үз сүзе бар. Ул сынган кашын турайтып, йөзенә элеккеге ягымлылыгын сирпеп җибәрде дә:

— Әле ярый унау булганнар, ике белән ни эшләр идем,— диде шаяртып.

— Аңласаң — аңла, төшенмәсәң — авызыңа су кап та мәгънәсен төшендергәнне көт. Ә мәгънәсе бик гади: аз балалы семьяда күп эш ата-ана җилкәсенә төшә, ә ишле гаиләдә йорт эшләрендә балалар катнаша, бер-берен өйрәтеп, бер-беренә булышып яшиләр. Рәйсәнең кызлары тегә, чигә, ямый белә. Керне дә үзләре юалар, йокы бүлмәсен дә үзләре җыештыралар. Малайлар да үз бүлмәләренә үзләре хуҗа. Йортта эшлиләр, мал-туарга да шефлык итәләр. Ә ата белән ана — остазлар — оста тәрбияләре, тормыш итәргә өйрәтүләре белән гаиләгә шатлык та, муллык та, заманча матур гадәтләр дә китерәләр. Әсәдулла белән Рәйсә ата-ананың шул программасын шактый тулы үтәгәннәр. Ә программа гади һәм зурдан: тәрбия, кешегә аң һәм кирәкле мәгълүматлар бирү белән бергә, аңарда хезмәткә сусау ялкынын дөрләтүне, хезмәттән башка бәхетле тормыш булмавын төшендерүне күздә тота. Без, ата-аналар, балаларны тулы җанлы һәм эшчән, шатлыклы һәм мул тормышка әзерлибез. Герой ана семьясында алгы планга шундый тәрбияне куйганнар.

Ишегалдында күңелле тавышлар ишетелде. Рәйсә бөтен игътибары белән шунда текәлә. Йөзендә чиксез шатлык. Ул нидер әйтте. «Уйнап туйдылар, ахры, кайталар»,— дигәндер, мөгаен. Чөнки шунда ук ашыга-ашыга табын әзерли башлады. Балалар, шуны сизгәндәй, өйгә кереп тулдылар: бер дистә Мифтахетдиновлар тагын безнең каршыда. Әй, рәхәт чигеп уйнаганнар да инде. Йөзләреннән шатлык чәчрәп тора. Әй, син бала чак, бала чак! Иреннәрдә бетмәс елмаю, күңелләрдә җуелмас тынычлык. Кем сагынмас шундый бала чакны, кем хупламас аның уеннарын, шатлыклы тамашаларын?! Кайсыбыз бала чак хати-

рәләрен йөрәгеннән чыгарып ташлар?! Булмас андый хәл. Хәзер түгәрәк табында ун чынаяктан хуш исле чәй эчүче кече Мифтахетдиновлар да канатланырлар, зур хезмәт коллективларына кушылырлар, ә төп нигездә, ата-ананың һәрчак жылы кочагында үткәргән көннәрен, бала чак уеннарын, аның сөйкемле инстинктын күңелләренә якын йөртерләр.

## 2

Быел, сигез елдан соң, юл тагын Чүпрәле районының «Йолдыз» колхозына китерде. Жан тартты дуслар янына, алар белән кабат очрашырга ашкынды. Кышның тиктормас, кеше сукмагына көртләр салып йөдәтүче шук феврале иде. Фатирга Мифтахетдиновларга туктарга булдым. Анда, өй жылысыннан башка, күңелне эретерлек дуслык жылысы да бар иде. Ул жылы Герой ана семьясында беренче очрашу вакытыннан сакланган иде.

Таныш авыл — Татар Бизнәсе кышкы киемен бөркәнгән. Елгасы боз астында, суык зынжырына илтифат итмичә, тын гына агадыр. Ә ярындагы чишмәсе сыркым куәтенә чыдаша алмыйча, өскә бәргән, урамга боз булып жәелә, гүя кышның үзен сынап карый.

Югары очка күтәреләм. Таныш басу жәелеп ята. Юрганы ак, жөйле: механизаторлар тракторлар белән йөреп сырганнар. Югарыдан түбәнгә дә үткәннәр. Аркылыга, урманга таба да узганнар. Ә ул офык читендәге урман яшь егетнең мыегы кебек күренә — кучкыл, сызылып киткән. Янына барсаң, сузан агачлы дәү нәрсәдер әле.

Урыс капканы икеләнмичә ачам дисәм, арттан кычкырып туктаттылар:

— Мифтахетдиновлар яңа йортка күчте, монысында малае тора.

Тәрәзәләре басуга караган бер канатлы урамнан биек өйне күрсәттеләр. Төп йорттан түбәндә, бер нигез аркылы. Ә төп нигезне ата белән ана олы уллары Шамилгә бүләк иткән. Шофер. Өйләнгән. Ике кыз бала үстерә. Яшь гаилә илгә бала, ата-анага шатлык китергән. Ризыклары, тәүфыйклары белән булсын! Бала чак елмаюы иреннәрендә гомергә калсын!

Күңелем белән оныкларга теләк сайлыйм, ә үзем Әсәдулланың яңа өй ишеген шакыйм. Йортын зур итеп корган: бишпочмаклы, янә тагын үзе бер өй хәтле кушымта. Анысының моржасыннан төтен ургый. Ташкүмер төтене. Анда пар казанындыр. Мөгаен, кухня да шунда. Хәзер авылда өйләрне шулай корырга тырышалар. Тузаны да читтәрәк, сөреме дә борынны борчымый.

Ишек ачылды. Бусагада тәбәнәк буйлы, киң жилкәле, түгәрәк битле таза ир басып тора иде. Кул биреп исәнләштек. Ул:

— Мифтахетдинов,— диде, үзе белән таныштырып. Бригадир Әсәдулла үзе икән. Теге чагында, Аркадий Владимирович белән килгәч, көтеп ала алмаган идек. Чибәр, ягымлы кеше булып чыкты. «Ачык чырай — такта чәй» диләр ич, эретеп жибәрә. Әсәдулла белән ишектән үк сөйләшә-сөйләшә керәбез. Кызык, гафу үтенә.

— Теге вакытта,— ди,— соңгарак калып кайттым шул. Бригадирның эше бетәме соң аның. Кунаклар янына кайтмады дип, күңелегездә авыр йөртмәссез инде шәт.

Мин хужаны тынычландырырга итенеп көлеп куям, «андый хәлләр үзебездә дә була» дим.

— Аның каравы, бүген иркенләп сөйләшербез. Кич безнеке.— Әсәдулла, шулай дия-дия, өс киемен салырга булыша. Үзе Рәйсәне ашыктыра: — Сиңәйтәм, табынны кара, юл кешесе чәй сагынгандыр.

Мул әзерләнгән табын янына утырдык. Рәйсә чынаякларга хуш исле чәй агызды да:

— Сез эчә торыгыз, мин кызларны озатып керим,— дип күрше бүлмәгә чыгып китте. Әсәдулла канәгать елмаеп куйды:

— Авыл клубына концерт куярга баралар.

Ул беравыктан, кадерле нәрсәсен оныткан шикелле искәреп, өстәлгә «Чистай чәен» утыртты, чыраен сыта-сыта касәләргә агызды.

— Нәрсә-нәрсә, ә монысына хирысланып булмады. Биш ел зимагурлыкта йөргәндә дә өйрәнмәдем,— диде гафу үтенгән сыман.— Без Рәйсә белән утыз ел бергә яшибез. Шәһәрдә дә эшләп карадык. Казанда бергә кинопленка фабрикасының нигезен салдык. Әмма хәмергә күңел үсмәде. Шөкер, оланнар да шушы нәмәстәне үз итмәделәр. Эчмиләр дә, тартмыйлар да: чат үзем.

Тыңлавы рәхәт. Шундый атага охшаган балалар бәхетледер. Оланнарын аек акыл белән яшәргә өйрәткән ата-ана олы җандыр. Дөньяның аракысына, тәмәкесенә җирәнеп караган гаилә хәсрәт белми, бәла аны читләтеп үтәдер.

— Сез, барса, күтәреп җибәрегез,— диде Әсәдулла.— Без аны табынга кунак-мазар өчен генә куябыз. Ихтыяры.

Өстәл, өстәл! Кем сине аякка күтәргән! Шундый матур сөйләшүләр өчен дә түгәрәк икән ләбаса син! Нигъмәтең янында акыл да тора икән!

Рәйсә керде.

— Киттеләр әле, ни кылып кайтырлар. Үзләренчә бик куанып йөриләр инде.— Ул шатлыгын уртаклашты да тагын чәй белән кыстый башлады. Вареньесын мактап алды. Үз бакчаларында үскән татлы җимештән кайнаткан.

Сүз балаларга күчте. Бер ишесе канатланырга өлгергән, ата-ана җылысын алып мөстәкыйль тормышка киткән. Әсәдулла таныштырып чыга:

— Шамил армиядән кайткач өйләнде, Илмира атлы укытучы кызны алды. Улым шофер булып эшли, күршедә йортлары. Камил дә солдатта булды. Хәзер гаиләсе белән Магаданда яши, төзүчеләр бригадиры.

Әңгәмәгә Рәйсә кушыла:

— Кызыбыз Рәфика шахтер егет Фатыйхка кияүгә чыкты. Тулада яшиләр, бик матур торалар.

Әсәдулла берьюлы өч бармагын бөгә:

— Наил белән Әмир — солдатта. Рәшитне дә язга армиягә озатырга торабыз. Әлегә колхозда эшли,— ди солдат атасы эчке бер горурлык белән.— Бүтәннәре укыйлар. Каникулда әниләре белән колхозда эшлиләр.

Таң калам. Мифтахетдиновлар икмәк үстерә. Мифтахетдиновлар кала төзи, завод сала, күмер чыгара. Мифтахетдиновлар ил саклый. Мифтахетдиновлар укый. Бер дистә. Семья байлыгы, ил байлыгы!

Герой ана гаиләсенә көн саен берничә хат килә. Оланнардан, кияү һәм киленнәрдән. Рәйсә бүген килгән бер хат алып бирә. Әмир җибәргән. Болай башлана, «Сезки минем өчен якын булган әти белән әнигә, братым Шәүкәткә һәм сеңелләргә кайнар солдат сәламнәрен җибәрәм...» Җылы язган. Фоторәсеме бар. Десантчы. Гвардия значогын таккан. Горур утыра, батыр карый. Чын совет солдаты! Илен дә, намусын да, Октябрь биргән матур, бәхетле тормышын да аяусыз саклар!

— Хатны иртәгә язармын инде.— ди Рәйсә үзалдына.

— Хатлар язарга вакыт артамы соң?

Рәйсә бераз гаҗәпләнде булса кирәк, ул миңа тутырып карады.

— Бәй, олан ич ул,— диде аннары.— Оланга ананың һәрчак сүзе бар.

Ие, гажәпләнгән, ул «бәй» сүзен шундый чакта гына әйтә бугай. Ләкин бу мизгелдә мин бүтәнне уйлыйм. Солдат Мифтахетдинов постта тора, солдат Мифтахетдинов походта йөри, характер ныклыгы, нервлар киеренкелеге таләп ителгән хәрби йомышлар үти. Шул чагында ана кулы белән язылган, аның җылы сүзе-нәсихәте белән тулы хат килеп төшә. Ә әни исен, аның сөйкемле күз карашын, тик аналар гына сайлый белгән изге теләкне алып килгән хаттан да кадерле нәрсә бармы икән?! Солдат Мифтахетдинов яңа көч алгандай була, авыр хәрби хезмәт, мөгаен, җиңеләеп китә.

Рәйсә чәйне яңартып җибәрде. Аннары район газетасын караштырырга кереште. Беравыктан безгә дә яңалык турында хәбәр итте.

— Карале Тәслияне, районда иң алда бара икән. Сыерларыннан никадәр сөт сауган. Молодец!

— Кем Тәслиясе?

— Шәйдуллиннарныкы.

— Булыр, булыр, яшьтән хезмәтне күреп үскән кыз.

Мифтахетдиновлар шулай гәпләшеп алдылар. Ул сөйләшү минем хәтерне дә уятты.

«Йолдыз» колхозына тәүге килүемдә ишле семьялар турында сүз кузгаткан идек. Бармакларны бөгә-бөгә Герой аналарны санныйбыз. Ике кулның бармаклары җитмәде. Болары — тулы кавалер. Ә Герой анага кандидатлар никадәр. Бер колхозда менә нинчаклы байлык!

Шунда партком секретаре Харис Шәйдуллин хәйләкәр көлемсерәп әйтеп салды:

— Мин дә Герой ана семьясында яшим ич.

Менә тамаша. Партком секретаре белән азмы-күпме танышлыгым бар. Байтактан әшли. Сугышта да булган: күкрәге тулы орден, медаль. Ә монысы яңалык иде. Ишле, хезмәтле семья төзегән. Игенче һәм терлекче, ветфельдшер һәм агроном — бары да бар. Хет бер гаиләдән комплекслы бригада оештыр. Уңганнар да икән, исемнәре бөтен районга киткән. Менә кемнәр үсә хезмәткә нигезләнгән һәм чын тәрбия алган күп балалы семьяда. Сокланып туя алмассың.

Мифтахетдиновлар газета белән мавыккан арада өйне күзәтәм. Бай, зәвыклы. Шәһәр квартираларыннан ким төше юк. Тәрәзә каршында басу җәелеп ятмаса, авыл өендә утыруыңны да абайламассың.

Әсәдулла минем төпченеп каравымны шәйләде, ахры, аңлатырга булды:

— Телевизорны колхоз бүләк итте. Бригада белән шикәр чөгендере үстереп беренчелекне яулаган идек. Рәхмәт, хөрмәтләделәр. Бүтәннәре — оланнар бүләге.

Менә ул семьяда балаларны оста тәрбияләүнең кайтавазы. Ул йортка кадерле реликвия, шатлыклы истәлек булып кергән. Әтисенә илле яшь тулгач, Шамил радиола бүләк иткән, өй котлап стенага зиннәтле келәм элгән. Камил яңа өйнең түренә сервант куйган. Ә Наил суыткыч белән котлаган яңа нигезне. Бер дистә Мифтахетдиновларның һәркайсы ата-ана өенә ямь өстәгән. Нәниләр үзләре атап иҗат иткән кул эшләре белән шатландырганнар.

Әсәдулланы тыңлыйм, ә күңелем шуны кабатлый: һәр гаиләнең нык урнашкан гадәте була. Шул гадәт, мәһабәт агачка көч бирүче тамырлар шикелле, семьяны бердәм, куәтле итә, тормышны бизи, рухны ныгыта. Мифтахетдиновлар да бәйрәмнәрдә бергә җыелалар, түгәрәк табында гәпләшәләр. Ул-кыз, ата-ананы хөрмәтләп, күчтәнәчен алып килә, җылы сүзен, мөстәкыйль тормышка, олы хезмәт коллективларына туры юл күрсәткән өчен рәхмәтен калдыра.

Мифтахетдиновлар бәхетле. Ләкин кеше дөньяга бәхет өчен генә килми. Бәхете-куанычы үзенә. Ул, уйлап карасаң, үз тормышы белән бүтән кешеләрнең тормышын баету, җәмгыятькә ниндидер файда ки-

терердәй мөмкинлекләрен, сәләтен ачар өчен туа. Кешенең бәхете дә, зурлыгы да менә шул сәләтне күрсәтә һәм бүләк итә белүдә. Рәйсә кызларын клубка озатканда да шулай уйлап калдым. Нәни кызлар, бер семьядан өчәү, клубка җыелган кешеләргә нәни генә сәләтләрен бүләк итәргә киттеләр. Ә менә хәзер дөнья каласын алгандай шатланып кайтып керделәр. Рәйсә сикереп үк торды, киемнәрен салырга булыша, үзе шелтәләгән итенә:

— Бигрәк озак тордыгыз, сагынып беттем үзегезне.— Нәниләрнең аркаларын рәхәт бер кагып ала да җайлап сораша башлый:

— Кызык булдымы соң? Оялмадыгызмы? Зурлар да килгән идеме?

Кызлар өчәү берьюлы җавап бирәләр:

— Әй, кызык булды да инде!

— Каты итеп кул чаптылар!

— Сәхнәгә чакырып кына торалар!

Баланың шатлыгы ташыганда ана битараф кала алмыйдыр, аның күңеле, үстергән җимеше белән ләззәтләнгән бакчачыныкы кебек, куанычлы хисләр белән тула һәм йөрәккә ятышлы рәхәтлек кичерәдер.

— Сез нишләдегез соң?

— Тәзкирә апа белән Гөлсинә апа биеделәр, җырладылар. Мин шигырь сөйләдем.— Җавапны Зөлфия бирә. Аңа гаҗәпләнеп карыйм. Бик тиз үскән ләбаса. Теге килүемдә бишектән төшеп яңа тәпиләгән иде. Ә хәзер апалары, иптәш кызлары белән концерт куеп йөри. Икенче класслар исеменнән чыга сәхнәгә Рәйсәнең төпчек кызы.

— Нинди шигырь сөйләдең, кызым? Әйтеп күрсәт әле.

— Әй, оялам.

— Кемнән?

Зөлфия шомырт күзләре белән миңа текәлә. Әй сабый, шушы кыланышың белән дә матур бит син. Бу оялуың үзең белән бергә тыйнаклык булып үсәр. Ә тыйнаклык һәр вакыт кирәк. Ул кешене бизи, бигрәк тә кызларны.

Ләкин Зөлфиянең нәни сәләтен монда да күрсәтәсе килә иде. Ул әнисенең итәгенә утырды, колакларына үрелде, юри безгә ишетелерлек итеп пышылдый башлады:

Дөнья белән танышулар
Башлана китаплардан.
Ленин бабай да кершкә
Китап тотып атлаган.

Әнисе Зөлфияне чупылдатып үбеп алды.

— Бигрәк матур икән. Кем язган соң аны, кызым?— Нәни кыз аны концертка әзерләнгәндә үк кат-кат сөйләгәндер. Ана кеше үзе дә күңелдән өйрәнеп житкәндер. Алай да төпчеген, күңелен үсендереп, күккә күтәрергә булды. Зөлфия дә, миннән тартынуын онытып, чаяланып китте.

— Марс абый Шабаев язган. Әле китапның солдат белән бергә сугышка кергән төше дә бар. Укыйммы?

Шигырьнең калган өлешен итәктән төшеп укыды Зөлфия. Укыды да апаларына ымлады:

— Хәзер алар җырлап күрсәтсен. Ие бит, әни.

Кызларның берсе, уртанчысы, Зөлфиягә авызын турсайтып, күзен шелтәле кыса төшеп карады. Аның күзләре: «Үзең такылда, без кечкенә түгел инде»,— дип әйтә төсле иде.

— Ярар, кызым, уртәмик,— диде Рәйсә.— Абыең интернаттан ялга кайткач җырлатырбыз әле.

— Мин дә шигырь сөйләрмен, әни, яме?

— Сөйләрсез, кызым: син дә, Шәүкәт абыең да. Концертны өйдә куярбыз.

Ә бу чакта телевизор каршына утырган Әсәдулла зәңгәр экрандагы тамашаны онытып, «әртист» кызларына карый иде. Аның йөзендә бала чакның иренгә кунган елмаюын хәтерләткән куаныч балкый.

Бер кич. Бай кич. Көндәлек калырлык кич. Барысы да куандыра: тормышлары да, гаиләдә әхлак-тәрбиянең куелышы да. Тормышның һәр мәшәкатен балаларның характерын ныгытуда файдаланалар. Гаиләдә оланнарны әйберләр дә, вакыйгалар да тәрбияли. Ата-ана шулар ярдәмендә күңелгә йогынты ясый.

Тормыш төрлесен күрсәтә. Семьяның төрлесе бар. Ләкин язылмаган бер закон: балаларны тәрбияләү — изге һәм җитди эш. Алар, А. С. Макаренко әйткәнчә, гүзәл гражданнар, яхшы әтиләр һәм әниләр булып үсәргә тиеш. Ләкин бу әле бөтенесе дә түгел: безнең балалар — ул безнең картлыгыбыз. Дөрес тәрбия — ул безнең бәхетле картлык, начар тәрбия — ул булачак кайгы, ул безнең күз яше, ул бүтәннәр алдында, бөтен ил каршында безнең гаебебез.

Тәрбиянең тик шундые хәерле. Мифтахетдиновлар моны нык үзләштергән. Монда бер дистә оланнан чын кешеләр үсә.

Өйдә тын. Тәрәзә артында да уылдау юк. Көрт сөргән җил, мөгаен, аргандыр. Күчереп йөрткән карын Мифтахетдиновлар икмәк үстергән басуда да калдыргандыр. Калдырса, икмәк тагын була инде, өйләргә муллык өстәлә.

Ә иртәгә көн матур булыр, кояшлы булыр. Әсәдулла да «эш күп, иртәрәк торырмын» диде. Мин дә иртәрәк кузгалырмын. Нишләмәк кирәк, язмыш шулай: кешеләр белән очрашасың — дуслар булып аерыласың.

Ә балалар мыш-мыш килеп йоклыйлардыр. Герой ананың бәхетле җаннары! Октябрьның кадерле балалары!

Чүпрәле, 1977 ел

Искәндәр Абдуллин

# ХӨСӘЕН ЯМАШЕВ АВТОБИОГРАФИЯСЕ

Татар телендә большевистик матбугат туу тарихын өйрәнеп, архив фондларында эзләнүләр безне күп кенә кызыклы ачышларга китерде: татар публицистикасы, иҗтимагый фикер тарихы өчен кыйммәтле документлар, шул исәптән беренче татар большевигы Х. Ямашевның моңарчы галимнәр күзеннән читтә яткан дистәләрчә документлары табылды. Алар ялкынлы революционерның уку дәверен, хезмәт ияләре арасында марксизм-ленинизм идеяләрен тарату, «Урал» газетасы һәм аның брошюраларын чыгару тарихын һәм гомеренең соңгы чорын тирәнрәк һәм тулырак итеп күз алдына китереп бастыралар.

Шулар арасында иң әһәмиятлеләре — Х. Ямашевның 1909—1911 елларны Беренче Казан ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына имтиханнар тапшырган вакытта язган өч автобиографиясе. Аларның беренчесен ул 1909 елның 6 апрелендә[1], икенчесен 1910 елның 5 апрелендә[2], ә соңгысын, үләренә нәкъ бер ел кала, 1911 елның 23 мартында[3] язган.

Яңа табылган документлар ялкынлы революционерның тормыш юлы һәм эшчәнлегенә нинди ачыклыклар кертә соң?.. Без, мәсәлән, Х. Ямашевны сигез яшеннән генә укый башлаган, димәк, ул мәдрәсәне тәмамламыйча, аның җиденче сыйныфыннан — исәгуҗидан (логиканың беренче өлешен өйрәнә башлагач) киткән дип беләидек. Хәлбуки, автобиографиясеннән күренгәнчә, ул биш яшеннән укый башлаган, мәдрәсәнең тулы курсын үткән һәм хәтта бер ел дөньяви, рус-татар мәктәбенә йөрергә дә өлгергән икән. Болар исә Х. Ямашев биографиясендә киткән фактик төгәлсезлектән котылырга ярдәм итеп кенә калмый, булачак революционерның белем дәрәҗәсен билгеләү өчен дә әһәмияткә ия. Өстәвенә Х. Ямашев мәдрәсәдә һәм укытучылар мәктәбендә үзе укыган фәннәрне санап чыга һәм хәтта аларның ничек укытылу дәрәҗәсенә дә туктала. Автобиографияләрне укыгач, Х. Ямашевның 1902—04, 1908—11 еллардагы эшчәнлеге дә ачыграк, конкретрак күз алдына килеп баса, яңадан-яңа кызыклы фактлар ачыла. Автобиографияләр революционерның үз тормышындагы вакыйгаларга мөнәсәбәтен ачыклау ягыннан да кызыклы.

Бер үк вакыйгаларны сурәтләүгә карамастан, аларның күләме һәм эчтәлекләре төрлечә: беренчесе — биш, икенчесе — өч, өченчесе ике биттән тора. Соңгы икесе, аерым абзацларны искә алмаганда, нигездә бер-берсен кабатлый, ләкин эчтәлекләре ягыннан беренчесеннән аерылалар. Шуңа күрә укучыларга беренче ике автобиография тулысынча, ә соңгысыннан алдагыларын тулыландырырлык өлешләр генә китерелә. Автобиографияләр, рәсми кәгазь буларак, патша законнары таләп иткәнчә, русча язылганнар. Аларны тәрҗемә иткәндә Х. Ямашевның татарча язылган хезмәтләрендәге кайбер тел-стиль үзенчәлекләрен сакларга тырышылды.

[1] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы, 87 фонд, 6 тасвирлама, 7922 эш берәмлеге, 22—24 кәгазьләр.
[2] Шунда ук, 7939 эш берәмлеге, 75—76 кәгазьләр.
[3] Шунда ук, 7965 эш берәмлеге, 263 кәгазь.

* * *

Мин 1882 елның 6 гыйнварында Казанда, сәүдәгәр гаиләсендә туганмын. Беренче, балалык елларым да Казанда узды. Мин әнием тәрбиясен адым, аның тәэсире гомумән бик көчле булды, ә әти, сәүдә эшләре белән Казаннан еш кына китkәләп торганга күрә, мине тәрбияләүдә аз роль уйнады. Биш яшемдә мине мәдрәсәгә бирделәр. Ул елларда әле мөселман мәдрәсәләрендә шәкертләр өчен бик авыр булган иҗек ысулы берлән укытсалар да, беренче кышта ук татарча укый һәм язарга өйрәндем. Мәдрәсәдә барлыгы ун ел укыдым (бу исәпкә «Мәрҗания» мәктәбендә укыган вакыт та керә — И. А.), гарәп телен өйрәндем (мәдрәсәдә аңа туган телгә караганда күбрәк әһәмият итәләр иде), шулай ук исламият (ислам дине нигезләрен), Коръән һәм Мөхәммәт хәдисләре буенча иҗтимагый тормыш кагыйдәләрен, мантыйк (логика), ислам тарихы, гыйльме хисап (арифметика) һәм җәгърафиядән гыйлем тәхсил калдым.

Мәдрәсәдәге тормыш шартларының начарлыгы (мин анда торып укыдым һәм өйдә бары тик бәйрәм көннәрендә генә була идем), шәкертләрнең һәм мөгаллимнәрнең үз-үзләрен тупас тотулары миндә мәдрәсәгә карата мәхәббәт хисләре уятмадылар. Мөгаллимнәрнең укыта белмәүләре һәм күпчелек фәннәрнең тормыш өчен яраксызлыгы да мәдрәсәгә нәфрәт хисләремне арттыра төштеләр.

Мәдрәсәне тәмамларга бер ел кала мөгаллимнәремнән берсе мине, өстән-өстән булса да, җәгърафия һәм гыйльме хисап фәннәре белән таныштырды. Мин шунда гына безгә мәдрәсәдә укыткан фәннәрдән тыш башка фәннәр дә барлыгын белдем. Җәгърафия һәм гыйльме хисапны өйрәнүгә ташландым, әмма кул астымда, җәгърафия картасы һәм төрекчә берничә элементар дәреслекләрдән башка, берниндә кулланмалар юк иде. Шул ук вакытта бер ел чамасы, анысы да өзек-өзек кенә, рус-татар ибтидаи мәктәбендә укыдым.

Әти мине сәүдә эшенә әзерләргә тели иде һәм, сәүдәгәрләр өчен рус телен белү кирәклеген аңлап, мәдрәсәне тәмам иткәч, миңа рус репетиторы яллады; әмма ул рус репетиторы берлән рус телен өйрәнү бик акрын барды, чөнки мин русча бик начар аңлый идем.

Шуннан соң әти мине җирле Татар укытучылар мәктәбенә бирде. Бу ноябрь ахырларында булганга, мәктәпкә укыту округы попечителенең рөхсәте берлән генә алдылар. Классташларым инде өч-дүрт ай элек укый башлап, бик алга киткәннәр, өстәвенә аларның барысы да бу мәктәпкә рус-татар ибтидаи мәктәбен тәмамлап килгәннәр иде. Шуңа күрә минем кебек рус теле берлән бөтенләй диярлек таныш булмаган кешегә алар артыннан куып җитү кыен булды. Ләкин боларның берсе дә күңелемне мәктәптән сүрелдермәде. Бу мәктәптә уку-укытуның куелышы мәдрәсәдә белем алудан шул кадәр нык аерылып тору мине таңга калдырды, мин үз тормышымны аннан башка күз алдыма да китерә алмас булдым: мәктәпкә ике сәгать алда килеп утыра, уку әсбапларын сокланып карый һәм дәресләремне әйтеп бетергесез дәрәҗәдә бик нык яратып хәзерли идем.

Ләкин, рус телен начар белгәнгә, мин беренче класста ике ел утырдым. Әмма икенче елны инде сизелерлек дәрәҗәдә алга киттем һәм тиздән класста беренче укучылардан санала идем.

Беренче класстан икенчегә күчкәч, әти, рус телен җитәрлек үзләштердең дип, мине мәктәптән алырга теләде. Ләкин тагын бер генә елга булса да укырга мөмкинлек бир дип ялваруларымнан соң, ул мине мәктәптә калдырырга мәҗбүр булды. Өченче һәм дүртенче класспарда инде аның теләгенә каршы диярлек укыдым.

1902 елны мин мәктәпне тәмамладым һәм өйләндем. Әти мине, бернәрсәгә дә карамастан, сәүдә эшенә өйрәтергә карар кылды. Ә үзем, ничек кенә булмасын, университетка керергә теләдем.

1902 елның көзеннән, репетитор яллап, гимназиянең сигез классы өчен имтиханнар тапшырырга әзерләнә башладым. Әти миңа, укырга мөмкинлек калдырмас өчен, акча бирмәде. Шуннан соң мин репетиторга дигән акчаны дәресләр биреп таба башладым. Бу, әлбәттә, минем өчен бик авыр — көн саен алтышар сәгать укучылар берлән шөгыльләнергә, өстәвенә хатынымны гимназиянең дүрт классы өчен имтиханнарга әзерләргә, репетиторга йөрергә һәм үз дәресләремне хәзерләргә кирәк иде!

Кыш шулай үтте. 1903 елның маенда әти, әгәр укуымны дәвам итәргә уйлыйм икән, ул вакыт өйдән чыгып китәргә кушты. Дәрес биреп таба торган акчага гына икебезгә — миңа һәм хатыныма — яшәп булмаганлыктан, өстәвенә ул минем үз дәресләремә зыян китерәчәген дә уйлап (ә бу дәресләр тормышымның бердәнбер максаты иде), мин, киләчәк кышны бары тик имтиханнарга әзерлек берлән генә үткәрергә җитәрлек дәрәҗәдә акча булдырырга ниятләп, җаен эшләргә булдым. Шундый ният берлән, Мәкәрҗә ярминкәсенә киттем һәм анда конторщик булып урнаштым.[1] Ярминкә бетәр алдыннан, өйдән, әти бик каты авырый, дип хат, ә берничә көннән аның үлеме турысында телеграмма алдым. Ихтыярсыздан Казанга кайтып, әтинең эшләрен үз кулыма алырга мәҗбүр булдым.

Әтинең башка компаньоннар берлән уртак утары һәм мануфактура сәүдәсе бар иде. Утар компаньоннарның берсе карамагында, ә сәүдә эшен агайларым алып бара. Шуңа күрә миңа әтидән калган малны гына ачыкларга кирәк, ә аннан соң укуымны дәвам итә алачак идем. Һәм шулай эшләдем дә. 1904 елның язында, хуҗалык мәшәкатьләреннән арынып, тагын укырга керештем һәм, туктап торуларны искә алмаганда, 1907 елның көзенә кадәр имтиханнарга әзерләнүемне дәвам иттем. 1907 елның көзендә Казан университетының юридик факультетына ирекле тыңлаучы буларак укырга кердем һәм бер үк вакытта өлгергәнлек аттестаты өчен имтиханнарга әзерләнүемне дәвам иттем; ләкин 1908 елның гыйнварында авырып киттем. Авыруым бик көчле булганга, докторлар миңа коньякка китәргә киңәш иттеләр. Мин шулай эшләдем дә. Бераз савыга төшкәч, былтыр көз көне мин тагын имтиханнарга хәзерләнә башладым һәм аны шушы көнгә кадәр дәвам иттем.

Хөсәен Ямашев. Казан,
1909 елның 6 апрель көне.

Нәкъ бер елдан соң Хөсәен Ямашев икенче автобиографиясен яза.

* * *

Мин Казанда тудым. Миңа бирелгән тәрбия таза тормышлы, ләкин интеллигент булмаган татар гаиләләрендә бирелә торган шаблон тәрбиядән бернәрсә берлән дә аерылмады: акыл һәм физик яктан дөрес үсешкә җитәрлек игътибар бирелмәде. Әти, ел тәүлегенең күп өлешен сәүдә эшләре берлән Самара һәм Саратов губерналарында үткәреп, өйдә даими рәвештә булмаганга күрә, мине бик дини һәм йомшак, сизгер күңелле әнием тәрбияләде.

Биш яшемдә мине мөселман уку йортына — мәхәллә мәктәбенә — бирделәр. Бу — Россия мөселманнары арасында дөм караңгылык-каралык хөкем сөргән сиксәненче еллар иде. Җәмгыятьтә мәгърифәткә ихтыяҗ күренми. Һәм мәхәлләдә (бигрәк тә шәһәрләрдә) мәктәпләр булса да, аларны бары тик дини максатлар өчен генә ачып торалар, аларда хәтта татар теленә дә кимсетеп карыйлар иде.

Бәхеткә каршы, миңа үз буын кешеләреннән бераз алдынгырак мөгаллим туры килде. Ул бераз гына булса да тарих һәм арифметикадан хәбәрдар иде.

Өч-дүрт елдан мин мәдрәсәгә — мөселман яшьләре урта һәм югары белем ала торган уку йортына күчтем. Бирәдә гарәп һәм фарсы телләрен өйрәндем, гыйльме гакаид[2], фәлсәфи кәламия (схоластика), шәригать (мөселман хокукы) фәннәрен, гыйльме бәлагать вә фәсахәт[3] үзләштердем. Бу мәдрәсәләр XVI—XVII гасыр коньяк-көнбатыш Русь дини мәктәпләренә (бурсаларга — И. А.) бик нык охшаганнар иде. Ләкин аларга (90 еллардагы татар мәдрәсәләренә — И. А.) бу вакытта заман рухы кагылган — мәктәпләргә реформа ясау кирәклек фикере уянган иде инде.

Укытыла торган фәннәрнең санын акрынлап арттыра бардылар, мәдрәсәдә укуымның соңгы елларында безгә җәгърафия, гыйльме хисап, тарих һәм татар теле укыта башладылар. Ләкин бу яңалыклар гына яшьләрнең белемгә омтылышын канәгатьләндерә алмады, укучы татар яшьләре рус мәктәпләренә күчә башладылар. Мин дә

---

[1] Бер үк вакытта ул тәрҗемә белән шөгыльләнеп тә акча табарга мәҗбүр була: 1903 елны Казанда И. Поповның «Йорт хайваннарының выставкасы нигә кирәк» исемле брошюрасын русчадан татарчага тәрҗемә итеп чыгара.

[2] Гыйльме гакаид — дин гыйлеме (богословие).

[3] Гыйльме бәлагать вә фәсахәт — матур, төзек сөйләү гыйлеме (стилистика).

**шулай эшләдем: «җирле татар укытучылар мәктәбенә укырга кердем һәм аны 1902 елны тәмамладым.**

**Укытучылар мәктәбендә укытыла торган фәннәр күп түгел, өстәвенә алар махсус характерда иде, ләкин без биредә беренче мәртәбә схоластикадан арынган белем ала башладык. Бу исә бездә (дини уку йортларында тәрбияләнгән яшьләрдә) белемгә сусауны арттырды. һәм үзебезне, берничә авырлыкларга да карамастан, университетта укырга хәзерли башладык. Шушы максаттан чыгып, 1902 елның көзеннән мин, репетитор белән, гимназия курсы өчен имтиханнарга әзерләнергә керештем. Ләкин эти аның профессиясен — сәүдә эшен — ташларга карар кылуымнан риза булмаганга, минем эшләр шактый акрын барды. Бер елдан эти үлде, һәм минем алда этинең эшләрен бетенләйгә туктату яки аның эшен дәвам иттерү мәсьәләсе килеп басты. Әнием һәм туганнарымның бик нык каршы торуларына да карамастан, беренче юлны сайладым. Әтинең эшләрен бетергәч, яңадан имтиханнарга хәзерләнергә керештем, ләкин үпкә авыруы башлану мине икe тапкыр һәм шактый озак вакытка укуымны ташларга мәҗбүр итте.**

**Ниһаять, әзерләнүемне ахырга кадәр җиткерә алдым һәм былтыр яз көне Беренче Казан ирләр гимназиясендә өлгергәнлек аттестатына имтиханнар тапшырдым. Бу имтиханнарны тулысынча тота алмау сәбәпле тагын бер елымны гимназия курсын үзләштерүгә багышладым. һәм менә быел яз икенче мәртәбә өлгергәнлеккә имтиханнар тотарга керешәм.**

**Казан, 1910 елның 5 апреле.**
**Хөсәен Минһаҗетдин углы Ямашев.**

Хөсәен Ямашевның үз кулы белән язылган әлеге автобиографияләр, барыннан да бигрәк, аның XIX йөз ахыры татар иҗтимагый һәм рухи тормышына тирән характеристикасы һәм милли буржуазия күкләргә күтәргән мәктәп реформасына шул заманда биргән большевистик, принципиаль бәясе белән әһәмиятле. Бу автобиографияләрдән белемгә сусаган алдынгы татар яшьләренең революциягә килү юллары да ачык күренә.

Алтмышынчы еллар буржуаз реформаларыннан соң Россиядә барган кискен социаль-экономик үзгәрешләр татар халкының иҗтимагый фикеренә һәм культура, мәгърифәт үсешенә дә зур йогынты ясый. Урта гасырлардан бирле яшәп килгән һәм башлыча дини белем бирүгә, коры схоластикага гына корылган уку-укыту системасы инде заман таләпләренә җавап бирә алмый. Әмма милли буржуазия, аны тамырдан үзгәртү урынына, бераз дөньяви фәннәр кертү белән чикләнеп, шул ук дини белем системасын калдыруны кирәк таба. Табигый, практик тормыштан аерылган бу ярым-йорты реформа заман таләпләренә дә туры килми, чын, фәнни белемгә сусаган аңлы татар яшьләрен дә канәгатьләндерә алмый.

Җәдит мәдрәсәләрендә дә коры фәлсәфә чәйнәү, мәгънәсез бәхәс алып бару (мөсахәбәдән) һәм ятлаудан аерыла алмыйлар, шәкертләрнең кешелек намусларын таптау, коточкыч изү, таяк дисциплинасы элеккечә үк хөкем сөрә. Үзенең икенче автобиографиясендә Хөсәен Ямашев аларны рус дини мәктәпләре (бурсалар) белән чагыштыра. Чынлап та, Г. Ибраһимов, М. Гафури, К. Тинчурин тасвирлаган татар мәдрәсәләре Н. Г. Помяловский сурәтләгән бурсалардан инҗил урынына корьән укытылу белән генә аерылса аерылгандыр.

Ә бит Хөсәен Ямашев заманында иң алдынгы һәм үрнәк саналган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсен тәмамлаган була! Шик юк, татар мәдрәсәләре көнчыгыш телләреннән, дин фәлсәфәсеннән, исламияттән җитәрлек белем биргәннәр. Ләкин алдынгы татар яшьләре дөньяви фәннәр үзләштерергә, техника, юстиция, медицина, биология һ. б. белгечлекләр буенча махсус белем алырга омтылганнар.

Тарихның законлы агышы, капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе патриархаль тормыш йокысында изрәгән татар җәмгыятен уята, аны үз орбитасына бөтереп алып китә, җәмгыять тормышындагы политик һәм экономик үзгәрешләр белемгә сусаган, алдынгы фикерле татар яшьләрен яңа тормыш шартларында үз урынын эзләргә мәҗбүр итә, аларны, шул исәптән Хөсәен Ямашевны да, дөньяви мәктәпләргә китерә.

Рус булмаган милләтләр өчен ачылган уку йортлары арасында алдынгылардан саналган Татар укытучылар мәктәбендә барлык фәннәр К. Д. Ушинский методы белән

укытылу, күргәзмә әсбапләрдан киң файдалану, физика, химия кабинетларында, мәктәп обсерваториясендә шөгыльләнү Хөсәеннең дә дөньяга карашын тамырдан үзгәртә. Коры ятлау, мәгънәсез сүз көрәштерү һәм схоластикадан туйган яшүсмер өчен бөтенләй яңа дөнья ачыла. Х. Ямашевның «без бирердә беренче мәртәбә схоластикадан арынган белем ала башладык» дигән нәкъ менә шул турыда сөйли.

Татар укытучылар мәктәбе беркетмәләренә Хөсәен Ямашев һәм аның сабакташлары, көрәштәшләре Гафур Коләхметов, Галимҗан Сәйфетдинов, Борһан Юскаев һ. б. булачак революционерлар укыган дәреслекләрнең тулы исемлеге дә теркәлгән.[1] Ул дәреслекләрнең авторлары — А. Н. Бекетов, Г. Н. Потанин һ. б. — һәркайсы материаль дөнья күренешләрен һәм процессларын фәнни материалистик позицияләрдән торып аңлаткан, фәннең яңа тармакларына нигез салган күренекле галимнәр. Бу дәреслекләр чын фән нигезләрен өйрәтә, дөньяга материалистик караш тәрбияли, Х. Ямашев һәм аның көрәштәшләре аңында, һичшиксез, зур борылыш ясый.

Шуңа күрә рус дөньяви уку йортларында чын фән нигезләре белән коралланган татар яшьләре үзләренең дөньяга карашлары һәм белем дәрәҗәләре белән татар дини җәдит мәдрәсәләрендә укучы яшьтәшләреннән күп өстен торганнар. Шуңа күрә татар телендә большевистик матбугатка нигез салган, татар хезмәт ияләрен марксизм-ленинизм тәгълиматы белән таныштырган беренче татар большевикларының рус уку йортларыннан чыгуы очраклы түгел.

А. Н. Островский пьесаларындагы бер сыңык икмәк, бер тиен акча өчен бер-берсен чәйнәп өзәргә әзер торган комсыз сәүдәгәрләр дөньясы Х. Ямашевка да таныш була. Бу коточкыч изү, җәбер, золым дөньясыннан котылу юлларын Х. Ямашев һәм аның иптәшләре социал-демократик түгәрәкләргә йөреп, яшерен марксистик әдәбият укып табалар. Унтугыз яшьлек Х. Ямашевның «Шәһәрдә һәм авылда яз күренешләрен чагыштыру» темасына язган иншасында җәмгыятьнең сыйныфларга бүленеше турында сөйләве моңа ачык мисал[2].

Татар укытучылар мәктәбендә уку «бездә (дини уку йортларында тәрбияләнгән яшьләрдә) белемгә сусауны арттырды. һәм үзебезне бернинди авырлыкларга да карамастан университетка укырга хәзерли башладык», — ди ул 1910 елны язган икенче автобиографиясендә.

Ә тормыш аның юлына киртәләрне шактый күп корган! 1902 ел. Кулда Укытучылар мәктәбен бик яхшы билгеләренә генә тәмамлау турында таныклык. Әмма ул университетка керү өчен хокук бирми (инородецлар өчен ачылачак мәктәпләрнең хокукларын билгеләгән патша чиновниклары бу турыда онытмаганнар!) Димәк, гимназия курсы өчен имтиханнарга әзерләнергә кирәк. һәм Хөсәен Ямашев ике ел буена, әтисенең ихтыярына каршы килеп, аның битәрләвенә, әзәрләкләвенә, ачлы-туклы тормышка дучар итүенә дә карамастан, имтиханнарга әзерләнә.

1904 елны аның әтисе үлә. Язмыш егерме бер яшьлек егетне ике юл чатына бастыра. Беренче юл белән китсә — ул әтисенең сәүдә эшен үз кулына алып, бернинди мохтаҗлык күрмичә тыныч, бай тормышта яшәячәк. Ә икенче юл — ач-ялангач торып, төрле авырлыклар күреп булса да белемгә омтылу, университетка укырга керү, илгә, халыкка файдалы кеше булу.

Ул икенче юлны сайлый. Бу турыда Хөсәен Ямашевның түбәндәге (шулай ук моңарчы билгесез) документы тулырак сөйли:

«Казан укыту округы попечителе Галиҗәнабләренә Самара губернасы Бөгелмә өязе Әлмәт волосте крестьяны Хөсәен Минһаҗетдин улы Ямашевтан гариза: гозеремнең нидән гыйбарәт икәнен аңлатудан элек шушы гариза белән турыдан-туры бәйләнештә булган тормышымдагы кайбер моментларга тукталып китүне кирәкле саныйм.

Мин унбиш яшемә кадәр мөселман мәктәбендә укыдым. Әти мине бары уналты яшемдә генә Татар укытучылар мәктәбенә бирде. 1902 елны укытучылар мәктәбе курсын бик яхшы билгеләренә тәмамлап, өлгергәнлек аттестатына хәзерләнә башладым [...] Миндә югары белемгә омтылыш шул кадәр көчле иде [...], ниһаять, әзерләнүемне ахырга кадәр җиткерә алдым һәм былтыр яз көне Беренче Казан гимназиясендә өлгергәнлеккә имтиханнар тапшырдым. Борынгы рус әдәбиятын начар белгән-

---

[1] ТАССРның ҮДА, 142 фонд, 1 тасвирлама, 1 эш берәмлеге, 136—139 кәгазьләр.
[2] Шунда ук, 34 эш берәмлеге, 51 кәгазь.

**гә, бу имтиханнарны тапшыра алмадым һәм тагын бер елымны гимназия курсын үзләштерүгә багышладым. һәм менә быел яз шушы гимназиядә икенче мәртәбә өлгергәнлеккә имтиханнар тотарга керештем. Язма имтиханнарның барысын һәм физика, космография, законнар белеме, психология, логика буенча телдән имтиханнарны тапшыргач, мин авырып киттем һәм врачлар киңәше берлән имтихан тотуны туктатырга тиеш булдым.**

**Әйтелгәннәргә нигезләнеп, Сез Галиҗәнабләрдән: беренчедән, Казан укыту округы каршындагы имтихан комитетында миңа көзен өлгергәнлеккә имтихан тотарга рөхсәт итмәссезме һәм, икенчедән, инде уңай билгеләр алган фәннәр буенча имтиханнардан азат итмәссезме икән дип үтенүне үземә мәртәбә саныйм.**

**Казан, 1910 елның 1 июне. Хөсәен Минһаҗетдин углы Ямашев.**

**Адрес: Казан, Нагорная урамы. Әминев йорты».** [1]

1911 елның 23 мартында язган өченче автобиографиясендә ул гомеренең соңгы елларына тагын бер ачыклык кертә:

**«Үпкә авыруы башлану мине ике мәртәбә һәм шактый озак вакытка укуымны ташларга мәҗбүр итте.**

**Ниһаять, мин үземнең әзерләнүемне ахырга кадәр җиткерә алдым. һәм мин менә ике мәртәбә өлгергәнлеккә имтихан тоттым һәм ике очракта да уңышсызлыкка очрадым».**

Эш, әлбәттә, Х. Ямашевның әзерлеге йомшак булуда түгел. «Әгәр чиркәү теле булган иске славян теленнән имтихан тоту мәҗбүри булмау аны борынгы рус әдәбиятын белүдән дә азат итә дип уйламаган булса иде, — ди Беренче Казан ирләр гимназиясе директоры Казан укыту округы попечителенә 1910 елның 10 июнендә җибәргән доклад язуында, — ул (Х. Ямашев — И. А.) бу имтиханнарны былтыр ук уңышлы гына тоткан булыр иде [2]. Гимназия администрациясенең үз эшенә салкын карап, тиешле аңлатмалар бирмәвеннән килеп чыккан бу уңышсызлык Х. Ямашевның университетка керү теләген сүрелдерми. Ул рәттән ике ел имтихан тота.

Әмма ачлык-ялангачлык, мохтаҗлыклар (күп кенә чыганаклардан билгеле булганча, ул бар тапкан акчасын газета һәм брошюралар чыгаруга тотып бетерә, хәтта соңгы тиенен дә белагә тарган иптәшләренә бирә торган була), полициянең эзәрлекләве, «Урал» брошюраларын чыгарган өчен тикшерү һәм суд эше дүрт ел буена дәвам итү, үпкә авыруыннан җәфа чигү үзен тагын бик нык сиздерә. Чираттагы имтиханга Х. Ямашев «көчле нерв авыруы нәтиҗәсендә имтиханнар тотуын туктатырга тиеш» дигән рәсми врач белешмәсен тотып килә. Патша чиновникларын исә авыру кешенең язмышы кызыксындырмый. Х. Ямашев имтиханнарны яңадан тапшырырга мәҗбүр була һәм үз максатына тагын бер елдан соң гына ирешә.

Хөсәен Ямашев автобиографияләрендә үзенең революцион эшчәнлеге турында бер сүз дә әйтми. һәм бу аңлашыла. Өлгергәнлеккә аттестат алу өчен имтиханнар тапшыручы, югары уку йортына укырга яки дәүләт учреждениесенә эшкә керүче кеше, патша законнары буенча, губернатордан политик «ышанычлылык турында белешмә» алырга тиеш була. Ялган паспорт белән яшәгән (полициягә тапшырылырга тиешле документларында ул үзен 1889 елны туган, Самара губернасы, Бөгелмә өязе, Әлмәт волосте крестьяны дип атый) һәм социал-демократик «Урал» брошюраларын чыгарган өчен суд тикшерүе астында булган Х. Ямашев үзенең революцион эшчәнлеге турында сөйләү, аның университетка керү хыялын чәлпәрәмә китереп кенә калмыйча, РСДРПның Казан һәм Уфа комитетларында алып барган яшерен революцион эшчәнлеген ачыклауга китерәчәген һәм хәзерге бәйләнешләренә куркыныч тудырачагын яхшы аңлаган.

1909 елның 9 апрелендә Беренче Казан ирләр гимназиясе директоры имтихан тапшыручыларның «ышанычлылыгы турында белешмә» һәм имтиханнар тапшыруга рөхсәт сорап Казан губернаторына мөрәҗәгать итә. Әмма ел саен имтиханнар тапшыру һәм «ышанычлылык турында белешмә» сорау, күрәсең, «иминлек сакчыларының»

---

[1] Шунда ук, 92 фонд, 2 тасвирлама, 12358 эш берәмлеге, 164 кәгазь.
[2] Шунда ук, 7939 эш берәмлеге, 294 кәгазь.

колагын тондырган. Жандарм идарәсе начальнигы тиешле мәгълүматлар җыюны үзенең яшерен агентларына тапшыра. Һәм менә «патша хәзрәтләренең бер тугрылыклы хезмәтчесе» — охранканың түләүле агенты жандармериягә соңгы вакытта политик түгәрәк оештыру белән билгеле Х. Ямашевның Саратовта ниндидер политик эш буенча тикшерү астында булуын хәбәр итүне үзенең «изге бурычы» дип саный.

1911 елның 13 сентябрендә, Хөсәен Ямашев инде университетка укырга кергәч, Казан губерна жандарм идарәсендә түбәндәге документ пәйда була:

**«1911 елның 13 сентябре, Саратов губерна жандарм идарәсе начальнигына. Яшерен.**

**Миндә булган мәгълүматларга караганда, Саратов шәһәрендә политик характердагы эш буенча тикшерүгә яки сорау алуга 30 яшьлек социал-демократ Хөсәен Ямашев тартылган. Шул сәбәпле Сез Галиҗәнабләрдән Ямашев чынлап та Сезнең тарафтан тикшерүгә яки сорау алуга тартылдымы дип сорауны үземә мәртәбә саныйм. Әгәр тартылган икән, ни өчен тартылуы һәм Сездә нинди мәгълүматлар булуы турында рәхим итеп хәбәр итмәссезме!**

**Казан губерна жандарм идарәсе начальнигы»** [1].

Әмма Саратов губерна жандарм идарәсендә Х. Ямашевны белмиләр. Чөнки аның «Урал» брошюраларын чыгару буенча Оренбургтан җибәрелгән эше Саратов губерна жандарм идарәсендә түгел, ә Көньяк Урал һәм Идел буена урнашкан берничә губернадагы аеруча куркынычлы политик эшләрне тикшерә торган Саратов Суд Палатасында карала... Бюрократик машинаның катлаулыгы кай вакытта файда да иткән!

Сүз уңаеннан шуны да әйтергә кирәк, Саратов жандармнары кирәге чыгар әле дип, күрәсең, Х. Ямашевның исемен аерым карточкага теркәп куярга онытмыйлар. Ә Саратов Суд Палатасы Х. Ямашев эшен үз утырышларында 1912 елның 6 сентябренә кадәр, ягъни Х. Ямашев үлгәннән соң да каравын дәвам итә! [2]. Патша ялчыларының кансызлыгына гаҗәпләнми мөмкин түгел.

...Еллар үтә. Беренче рус революциясенең баррикада сугышларыннан безне хәзер җитмеш елдан артык вакыт аера. Гомерләрен ирек өчен, халык бәхете өчен корбан иткән революция каһарманнарының героик көрәшен чагылдырган мәкаләләр, яңадан-яңа китаплар чыга тора. Ләкин дәүләт архивларында, музейларда, китапханәләрдә һәм шәхси кулларда әле эзлисе, табасы документлар да гаять күп. Егерменче еллар башында Түбән Идел буе край архивында Х. Ямашевның суд эше сакланган булган. Тарихчыларга 300 битлек шул калын эшнең берничә бите генә билгеле. Алары да күчермәләр буенча гына. Татар телендә большевистик матбугат ничек барлыкка килүен чагылдырган бу тарихи документларның хәзер кайда саклануы билгесез. РСДРПның Казан, Уфа, Оренбург комитетлары чыгарган татарча прокламацияләрнең дә берничәсе табылмаган. 1902 елны Хөсәен Ямашев һәм Гафур Коләхметов «Татар укытучылар мәктәбе безгә нәрсә бирде?» дигән темага инша язган булганнар. 1910—1911 елларны Х. Ямашев «Рус әдәбияты һәр вакыт акыллы киңәш бирә торган трибуна булды», «Михаил Васильевич Ломоносовның тууына 200 ел тулу көннәрендә ни өчен яхшы сүз белән искә алырга тиешбез?» дигән темаларга инша язган. 1912 елның 14 мартында Х. Ямашев «Гасыр» китапханәсенә татар мәктәпләре турында үзе язган китап кульязмасын тотып килә һәм шуны кулында тоткан килеш үлә. Әмма бу кульязмаларның язмышы хәзергәчә билгесез. Кемнәрдәдер Х. Ямашев һәм аның көрәштәшләренең аерым фотолары, хатлары да ята булыр...

Кыскасы, галимнәрне яңадан-яңа эзләнүләр, революцион көрәшнең билгесез сәхифәләре көтә.

ooooooooooooooo

---

[1] Саратов өлкәсенең дәүләт архивы, 53 фонд, 1 тасвирлама, 6 эш берәмлеге, 2 том, 194 кәгазь.

[2] Шунда ук, 9 фонд, 1 тасвирлама, 2573 эш берәмлеге, 17 кәгазь.

# ТАТАРСТАНДА ОКТЯБРЬ ТАРИХЫННАН...

Данлыклы революционер, халыкара коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе, Төркия коммунистлар партиясен оештыручыларның берсе — Мостафа Сөбхи кулләргә яхшы билгеле. Ялкынлы көрәшченең шактый гомере безнең илдә үтә, нәкъ менә Россиядә ул революцион көрәшнең бердәнбер дөрес юлын — большевизмны таба.

1910 елдан Төркия социалистик партиясе члены Мостафа Сөбхи 1915 елда Уральскида РСДРП сафларына кабул ителә. Бөек Октябрь революциясеннән соң ул яшь Совет дәүләтен ныгыту, аны дошманнардан яклау эшенә бөтен көчен һәм сәләтен бирә. 1918 елның башында В. И. Ленин Декреты белән Үзәк Мөселман комиссариаты төзелгәч тә Мостафа Сөбхи шунда эшкә билгеләнә, халыкара пропаганда бүлеген җитәкли.

Эш буенча Мостафа Сөбхигә илнең күбрәк милли районнарында — элекке Төркестанда, Кырымда, Кавказда булырга туры килә. Андагы җирле халыкларның хезмәт ияләрен социализм өчен көрәшкә туплауга күп көч куя, пролетар интернационализм лозунгларын пропагандалый.

Мостафа Сөбхи берничә мәртәбә Идел буенда, шул исәптән Казанда да була. Әдәбиятта, мәсәлән, аның Үзәк Мөселман комиссариатында эшләве, 1919 ел башында татар телен фәнни эшкәртү максаты белән Казанда конференция оештыруга куйган эшчәнлеге, Мөселман комиссариаты каршындагы гыйльми һәйәтне җитәкләве шактый киң яктыртылган.

Эзләнүләр алып барганда күптән түгел бу юлларның авторы Мостафа Сөбхинең Самарада (хәзерге Куйбышев шәһәре) булуы турында яңа мәгълүматларга юлыкты. КПСС Үзәк Комитеты янындагы марксизм-ленинизм институтының Үзәк Партия архивында Мостафа Сөбхинең бер хаты саклаган (17 фонд, 65 тасвирлама, 399 эш, 11 бит). Ул 1919 елның 13 декабрендә язылган һәм Самарадан Мәскәүгә РКП(б) Үзәк Комитеты секретаре Елена Дмитриевна Стасовага җибәрелгән.

Хаттан күренгәнчә, Самарада Мостафа Сөбхи РКП(б) Үзәк Комитеты һәм Коммунистик Интернационалның Башкарма комитеты җибәрүе буенча Төркестанга барышлый туктый. Мостафа Сөбхи хатында Мәскәүдән Самарага 15 көн баруы, килеп җиткәч авырып китүе турында яза. Шулай да революционер актив эшчәнлеген туктатмый. Көнчыгышка караган мәсьәләләр белән җитди шөгыльләнә: төрек, фарсы, һинд һәм башка көнчыгыш халыкларыннан төзелгән интернациональ отрядларда политик тәрбия алып баруны оештыра, алар белән эшләүгә политик хезмәткәрләр туплау чараларын күрә.

Бу вакытта Самарада Төркестан халыкларына интернациональ ярдәм күрсәтү өчен татар һәм башкортлардан формалашкан хәрби частьлар да күп була. Мостафа Сөбхи шул гаскәрләр арасында зур эш алып бара. Мәсәлән, 1919 елның 27 декабрендә ул Самара шәһәренең татар һәм башкорт җәмәгатьчелеге алдында махсус доклад белән чыга. «Идел һәм Урал буе татар-башкортлары арасында Сөбхи доклады» дип исемләнгән бу документ Мәскәүдәге Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш Үзәк Дәүләт архивында табылды. Күренекле төрек революционеры

үзенең чыгышында 1917 елның Февраль буржуаз революциясеннән соң татарлар һәм башкортлар арасында җәелеп киткән шактый көчле милли азатлык хәрәкәтенә анализ ясый. Ул Февраль революциясеннән соң җылы яңгыр артыннан гөмбәләр кебек калкып чыккан төрле милли оешмаларның буржуаз асылын ачып сала, халкыбызның турылыклы улы Мулланур Вахитов инициативасы белән оештырылган Мөселман Социалистлар комитетының эшчәнлегенә югары бәя бирә. Шунда ук Сөбхи Милләтләр эше буенча Халык Комиссариаты янында В. И. Ленин тәкъдиме белән оештырылган Эчке Россия Мөселманнары Комиссариаты (искәрмә: соңрак ул — Үзәк Мөселман комиссариаты, Үзәк Татар-Башкорт комиссариаты дип тә йөртелә) эшкә башлаган вакыттагы гомуми обстановканы тасвирлый, комиссариатка йөкләнгән бурычларның «бик әһәмиятле һәм кыен» булуларын аңлата, аның төрле милли-буржуаз оешмаларга, аларның контрреволюцион эшләренә каршы көрәшен яктырта. Мостафа Сөбхи беренче Совет автономиясе проекты — Татар-Башкорт Совет Социалистик Республикасы — мәсьәләләренә дә киң кагыла. Шул уңайдан кузгалган фикер көрәшен күрсәтә.

Докладта авторның татар һәм башкорт партия кадрларының формалашуы турындагы фикерләре дә игътибарга лаек. Алар арасында килеп чыккан кайбер каршылыклар һәм тайпылышларны Мостафа Сөбхи нигездә бу работникларның яшьлеге һәм тәҗрибәсезлеге белән аңлата.

Шул ук вакытта ул милләтчелек ягына булган һәртөрле тайпылышларга кискен каршы чыга. Докладчының бу турыда әйтелгән фикерләре гаять кызыклы һәм әһәмиятле. Ул барлык халыкларның якты киләчәге өчен илебез халыкларының дуслыгын тагын да ныгытырга кирәклеген әйтә, аларны Коммунистлар партиясе байрагы тирәсендә берләшергә чакыра: «Татарларга, башкортларга, үзбәкләргә, кавказлыларга һәм гомумән Россиянең көнчыгыш халыкларына,— дип яза Мостафа Сөбхи,— имин яшәү өчен, әгәр дә көч һәм куәтләре таянырлык берәр нигез бар икән, ул — фәкать РКП(б) белән тыгыз бердәм эшчәнлек, бер революцион фронт».

Мостафа Сөбхинең шушы докладында әйткән кайбер фикерләре хәзерге халыкара эшчеләр һәм коммунистик хәрәкәт өчен дә бик актуаль яңгырыйлар. «Әгәр дә ул хәзер халыкара форманы кабул иткән партия белән (искәрмә: автор большевиклар партиясен шулай дип атый — Х. Р.) кулга-кул тотынып тыгыз элемтәдә эшләмәсә, Көнчыгышта булган бер генә оешма да Европа империализмына җитди йогынты ясый алмаячак». Халыкара революцион хәрәкәттә бердәмлек кирәклеген күренекле интернационалист әнә шулай кискен куя һәм бу юлда Коммунистлар партиясенең тоткан урынын югары бәяли.

Доклад гражданнар сугышы чорында язылган. Коммунистлар партиясе илне революцион үзгәртеп кору өчен дә кискен көрәш алып барган чак бу. Күп милләтле Россиядә милли мәсьәләне халыклар дуслыгы нигезендә хәл итү юлында партия зур эш башкара. Буржуаз милләтчеләргә каршы аяусыз идеологик көрәш алып бару белән бергә, большевикларга еш кына революцион лагерьда килеп чыккан каршылыкларны да чишәргә туры килә. Мостафа Сөбхи докладында бу мәсьәләләр дә берникадәр чагылыш тапкан. Әмма алар барысы да материал белән танышканда укучыдан тарихилык принцибын күздә тотуны таләп итә.

Доклад текстының тәрҗемәсе түбәндә кайбер кыскартулар белән бирелә [1].

**Идел буе татар һәм башкортларының хәзерге хәрби-революцион оешмаларын ачык итеп күз алдына китерү өчен, аларның Февраль революциясеннән соңгы тарихына берникадәр күз салырга кирәк. Февраль революциясеннән соң... вак милләтләр арасына үзидарә һәм политик ирекләр лозунгысы ташлангач, татар-башкортлар оеша башладылар, Идел һәм Урал буенда авылларга кадәр милли Советлар төзелде. Төрле армияләрдәге мөселман солдатларыннан аерым полклар төзелә башлый, аларга параллель рәвештә мөселман хәрби оешмалары барлыкка килә. Шушы гражданский һәм хәрби учреждениеләрнең үзәге булып Уфада Милли мәҗлес яки парламент, Казанда Бөтенроссия Хәрби бюросы тора. Әлеге оешмаларга кадетлар, мень-**

---

[1] Документның сакланган урыны: Мәскәү, Октябрь революциясе һәм социалистик төзелеш Үзәк Дәүләт архивы, 1318 фонд, 1 тасвирлама, 155 эш, 30—31 битләр.

шевиклар, уң эсерлар, дин башлыклары, икенче төрле әйткәндә, буржуаз һәм соглашатель (буржуазия белән килешүчәнлек политикасы алып баручы — Х. Р.) партияләрнең вәкилләре керен тула. Октябрь переворотына кадәр гасырлар буе изелеп килгән татар-башкорт халык массалары бу оешмалар тарафыннан күпертелеп вәгъдә ителгән иреклэрдән исертелгән булалар.

Шуңарчы Идел һәм Урал буе татарлары арасында, Мөселман Социалистлар комитетыннан башка, сул революцион оешмалар булмый. Бу оешма Петроград студенты, социал-демократ большевик буларак танылган Мулланур Вахитов тарафыннан төзелә. Анда сул эсерлар да катнаша. һәм оешма, эшчеләрнең сул агымын җитәкләп, көчле хәрәкәт оештыру юлында эшли.

Октябрь революциясе башында, башка мөселман депутатларыннан аерылып, Мулланур Вахитов... Галимҗан Ибраһимов һәм үзенең партиялелеге белән билгеле булган Шәриф Манатов «учредилка»ны большевиклар белән бергә ташлап чыгалар. Шуннан башлап татар-башкортлар арасында сул эшчеләр агымы көчәя...

Хәзер сул агымның җитәкчеләре алдында, милли хәрәкәтне социаль революция белән яраштыру юлы аркылы, милли учреждениеләрне, милли республика проектын бөтенләйгә юк итү өчен, (искәрмә: докладчы бу урында милли буржуаз оешмалар һәм алар планлаштырган автономия турында сөйли — Х. Р.) яңа лозунглар, массаларга яңа революцион учреждениеләр бирү бурычы килеп баса. Шушы максат белән Мулланур Вахитовка Петроградта Мөселман эшләре буенча Үзәк комиссариат оештырырга тәкъдим ителә.

Шулай итеп, бу комиссариат һәм башка политик оешмаларның «мөселман» дигән исеме бөтен мөселман эшләрен бер юнәлешкә, Октябрь революциясе белән бер эздән җибәрү өчен үзәкләштерү ихтыяҗыннан килеп чыга. Шул ук вакытта ул Кавказда, Төркестанда, Идел буенда, Уралда мөселманнар арасында көчле дини агым булуын, һәм шулай ук җирле татар-башкортларның үзләрен «мөселман» дип атауларын күздә тота.

Җыеп әйткәндә, Мөселман эшләре буенча Үзәк комиссариатка йөкләнгән вазифалар бик әһәмиятле һәм кыен булалар.

Үзәк комиссариат урыннарда губерна комиссариатлары оештырган вакытта, Уфада Милли мәҗлес актив эшкә керешә. Хәрби бюро мөселман частьларына инструкцияләр җибәрә һәм Казанда, Болакның сул ярында, татарлар арасында «Болак арты республикасы» игълан ителә. Үзәк комиссариат алдына контрреволюция җимеше булган бу кечкенә «республиканы» һәм шулай ук Милли мәҗлесне, хәрби учреждениеләрне таркату бурычы килеп баса. Сүз уңаенда Хәрби бюро карамагындагы мөселман солдатларының саны 40 меңнән артып китүен дә әйтергә кирәк.

Үзәктә Мулланур Вахитов, Казанда... Сәидгалиев һәм башка татар большевиклары Керенскийдан калган барлык милли оешмаларны тараталар, кан түгүләрсез генә «Болак арты республикасы» юк ителә. Бу вакытта Үзәк комиссариат инициативасы, Ленин һәм Сталин ризалыгы белән, Совнарком тарафыннан Татар-Башкорт Совет Республикасы турында Положение чыга, Кызыл мөселман частьлары оештыру мәсьәләсе карала.

...Татарларга, башкортларга, үзбәкләргә, кавказлыларга һәм гомумән Россиянең Көнчыгыш халыкларына имин яшәү өчен, әгәр дә көч һәм куәтләре таянырлык берәр нигез бар икән, ул — фәкать РКП(б) белән тыгыз бердәм эш, бер революцион фронт. Әгәр дә хәзер бөтендөнья күләмендә танылган партия белән кулга-кул тотынып һәм бердәм элемтәдә эшләмәсә, Көнчыгыштагы бер генә революцион оешма да Европа империализмына җитди йогынты ясый алмаячак. Бу нигезләрне аңлаучы һәм үзенең фикерләрен РКП(б)ның һәм халыкара революцион хәрәкәтнең омтылышы һәм политикасы белән берләштерергә тырышкан коммунист кына үзенең фикерләвендә һәм эшләрендә, һичшиксез, азатлыкка лаеклы революционер.

Инде, Идел һәм Урал буенда яшәүче татар халкы арасындагы революцион хәрәкәткә кыскача күзәтү ясаганнан соң, түбәндәге нәтиҗәләрне чыгарырга мөмкин:

1) Татарлар арасында Октябрь вакыйгаларыннан башланган хәрәкәт бүгенге көндә тарихи яктан төпле нигезләнгән масштаб алды.

2) Социаль революция күзлегеннән караганда, татар коммунистлары Көнчыгышта алдынгы көч әһәмиятенә ия булып торалар...

**5) Бу алмашыну чорында Россия Совет хөкүмәте бюрократизм белән дә интегә. Шуның өчен дә яшь татар коммунистлары арасында, бигрәк тә алар белән сул эсерлар фетнәсеннән соң безнең лагерьга күчкән элекке сул эсерлар арасында, теге яки бу җаваплы постка билгеләү мәсьәләсендә берникадәр конкуренция, вак интригалар бар. Татар пролетариатына күп санда политработниклар кирәк булуын искә алып, бу яшь коммунистлар эшенә саклык һәм игътибар белән карарга, аларның бер-берсенә булган жалобаларына азрак әһәмият бирергә кирәк.**

**6) Тәҗрибәле һәм сәләтле революционерлар дип танылган татар коммунистларына җаваплы постлар биреп, алар ярдәмендә халык массалары арасыннан яңа көчләрне эшкә өйрәтү һәм тәрбияләү бүген җитәкче урыннарда торган коммунист иптәшләрнең революцион бурычы булып тора.**

**7) Билгеле булганча, социаль революция һәм коммунизм нәтиҗәдә кешеләрне мул тормышка, югары культурага ирештерергә тырышалар. Шунлыктан татар эшчеләренә һәм кызылармеецларына моны аңлату өчен барысын да эшләргә кирәк. Бу — Көнчыгышта революцион хәрәкәтнең уңышы өчен беренче шарт. Бу алдынгы мөселман революцион көчләре, Көнчыгышның ерак өлкәләренә хәрәкәт итеп (искәрмә: бу урында Мостафа Сөбхи Кызыл Армия сафларында тугандаш Урта Азия халыкларына интернациональ ярдәм миссиясе белән хәрәкәт итүче татар-башкорт частьларын күздә тота — Х. Р.), үзләренең культурасы һәм инанганлыгы белән Көнчыгыш халыкларының күп гасырлар буе дәвам иткән Европа империализмының коллыгыннан котылу, якты тормышка ирешү ышанычын көчәйтерләр.**

**М. Сөбхи. Самара, 27. XII, 1919 ел.**

...Докладның язылуына 60 елга якын вакыт узган. Шуңа карамастан, анда куелган кайбер мәсьәләләрнең куелышы бүген дә игътибарга лаек. Бигрәк тә халыклар арасындагы дуслыкны ныгыту проблемасы мәсьәләләре. Икенче яктан, Халыкара коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәтенең күренекле эшлеклесе Мостафа Сөбхинең татар һәм башкортлар арасындагы революцион хәрәкәткә карашы, аерым фактларга һәм вакыйгаларга конкрет бәя бирүе методологик яктан да әһәмиятле һәм ул милли мәсьәләне, культура тарихын өйрәнүче галимнәребезгә, һичшиксез, файдалы булачак. Ул шулай ук киң катлам укучылар өчен дә кызыклы материал, әлбәттә.

**Язманы журнал өчен әзерләүче һәм кереш сүз авторы —**
**тарих фәннәре кандидаты**
**Р. ХӘЙРЕТДИНОВ.**

## Мигъдәт Яһудин

# КАЛИНИННЫҢ ТАТАРСТАНГА КИЛҮЕ

*Бу истәлекләрнең авторы Мигъдәт Яһудин Саратов өлкәсе, Балаков районының Яңа Елүзән авылында 1904 елда ярлы крестьян гаиләсендә туа. 1915 елда әтисе үлеп киткәннән соң, үн яшьлек Мигъдәт үз көнен үзе күрә башлый: авыл байларының балаларын карый, хуҗалык эшләрен башкара, ялчы була.*

*1921 елда Мигъдәт Яһудин комсомолга керә һәм бер төркем яшьләр белән Карл Либкнехт исемендәге шикәр заводына эшкә китә. Ә 1923 елда Кәттә-Курган шәһәрендә яшәүче абыйсы янына күчә. Анда мамык чистарту заводында эшли һәм 1924 елда шунда партия сафына кабул ителә.*

*1925 елда ул Казанга, хәрби-политик мәктәпкә укырга җибәрелә. Монда ике ел укыганнан соң профсоюзларның Әгерҗе район советы председателе булып эшли, 1928 елда В. И. Ленин исемендәге 40 нчы номерлы химия заводына партия эшенә күчерелә. 1929 елда Татарстан АССР Хезмәт халык комиссары итеп билгеләнә. 1929—1935 елларда ул партия өлкә комитеты бюросы члены, партия өлкә комитеты секретаре, Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты һәм Президиумы члены, аннан Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Председателе итеп сайлана.*

*Авыл хуҗалыгындагы төп эшләрне — чәчү, урып-җыю, орлык салу эшләрен башкарып чыгудагы, дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәүдәге, колхозлар һәм совхозларны ныгытудагы уңышлары өчен СССР Үзәк Башкарма Комитеты карары белән 1934 елда Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы илебезнең иң югары бүләге— Ленин ордены белән бүләкләнә. Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитетының 1934 елның 17 июнендә үткәрелгән IV сессиясендә бу олы бүләкне, Республика Үзәк Башкарма Комитеты Председателе буларак, Мигъдәт Яһудин кабул итеп ала.*

*Партия һәм совет органнарында эшләгәндә Мигъдәт Яһудин партия һәм дәүләт эшлеклеләре, шул нәүбәттән Михаил Иванович Калинин белән очраша. Аның түбәндә укучыларыбызга тәкъдим ителә торган истәлекләре әнә шундый очрашуларга нигезләнеп язылган.*

*РЕДАКЦИЯ.*

Партия өлкә комитеты һәм республикабыз хөкүмәте Украина ССРның Днепропетровск өлкәсен социалистик ярышка чакырырга карар чыгарды. Бу вакытта партия өлкә комитеты секретаре булып М. Разумов, Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы Председателе булып К. Абрамов иптәшләр эшли иде.

Украина Коммунистлар Партиясе Үзәк Комитеты тугандаш ике республика колхозлары һәм совхозларының бу инициативасын яхшы дип тапты. Ике арада төзелгән социалистик ярыш килешүендә колхозларны һәм совхозларны ныгыту, 1933 елда авыл хуҗалыгы эшләрен уңышлы үткәрү, бөртекле культураларның, тамыр азыклар-



*Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты Председателе*
*М. Яһудин эш кабинетында, 1933 ел.*

ның уңышын күтәрү, терлекчелекне, кошчылыкны үстерү мәсьәләләре каралган иде. Әлеге килешү алдынгы колхозчыларның беренче республика съездында расланды. Съезд 1933 елның язында булды. Анда катнашу өчен Украинаның Днепропетровск өлкәсе делегациясе дә чакырылды. Партия Үзәк Комитеты бу вакыйгага зур әһәмият бирде һәм, Татарстан партия өлкә комитетының, республика хөкүмәтенең үтенечен канәгатьләндереп, съездга Михаил Иванович Калининны җибәрде.

Бу вакытта республикада язгы чәчүгә хәзерлек эшләре бара иде. Ул эшләрнең бөтенесе дә: «Язгы чәчүгә хәзерлекне колхозчыларның Беренче республика съезды ачылуга төгәллик!» дигән лозунг астында башкарылды.

Михаил Иванович Калининны каршылау өчен Татарстан һәм Чувашстан автономияле республикалары чигендәге станциягә юл тоттык. Һәркайда кулларына лозунглар, флаглар күтәргән эшчеләр, тимер юлчылар, якын-тирә авыллардан җыелган колхозчылар, укучылар... Алар арасында кадерле кунакны каршыларга килгән Чувашстан вәкилләре дә бар.

Менә көтеп алынган минутлар якынлаша. Дүрт вагонлы составтан торган махсус поезд станциягә килеп туктый. Без, партиянең Чувашстан өлкә комитеты секретаре, Чувашстан Халык Комиссарлары Советы Председателе һәм мин, Михаил Иванович Калинин утырып килгән вагонга керәбез. Һәркайсыбыз Михаил Иванович һәм аны Татарстан чигенә кадәр озата килгән Чувашстан АССР Үзәк Башкарма Комитеты председателе иптәш Никитин белән күрешәбез.

— Яшермим, иптәш Яһудин, Михаил Ивановичны, безгә тукталып, Чувашстан җирендә бераз кунак булырга үгетләп караган идем, — диде Никитин минем белән күрешкәндә, — ризалаштыра алмадым. Сез безгә караганда бәхетлерәк: ул сезгә колхозчы крестьяннарның Беренче съездына бара.

Әңгәмә артык озакка сузылмады. Берникадәр вакыттан соң без чуваш дуслар белән саубуллаштык.

Берничә минуттан поезд акрын гына кузгалып китте. Тәрәзә янына басып, бераз вакыт тугандаш Чувашстан җирендәге нарат урманнарына карап сокланып бардык. Мин царизм белән көрәштә утлар-сулар кичкән профессионал революционер, Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты Председателе белән ике арада әңгәмә башланыр минутларны көттем.

Михаил Иванович икебезгә дә берәр стакан чәй китерергә кушты да миңа сорау белән мөрәҗәгать итте: «Я, иптәш Яһудин, авыл халкы, аерым алганда татарлар тормышында нинди яңалыклар бар?»

Мин аңа авылдагы үзгәрешләр, гасырлар буена хезмәт ияләрен изеп килгән иске стройны җимереп, республикада яңа, коллектив хуҗалыклар төзелүе, съезд алды көннәрендә башта колхозларда авыл хуҗалыгы эшләренә йомгак ясауга, аннары район үзәкләрендә алдынгыларның тәҗрибә уртаклашуларына багышланган җыелышлар уздырылуы турында сөйләдем. Ул җыелышларда катнашу өчен урыннарга республиканың җитәкче работниклары да җибәрелгән иде. Миңа төп халкы нигездә татарлардан торган Минзәлә районында булырга туры килде. Михаил Иванович Калинин белән әңгәмә вакытында мин шунда үткәрелгән җыелыш хакында искә алдым...

Анда район советы башкарма комитеты председателе авыл хуҗалыгы елы йомгаклары турында доклад ясады. Докладта колхоз эшен сөеп башкаручы алдынгы кешеләр турында сөйләү белән беррәттән, экономик яктан йомшак колхозларның артта сөйрәлүе, коллектив хуҗалыкларның экономик-политик үсешенә аяк чалучы аерым җитәкчеләр һәм колхозчылар булуы тәнкыйть ителде.

Менә доклад буенча фикер алышулар башланды. Кырык яшьләр тирәсендәге бер колхозчы хатынның:

— Чыгып сөйләргә мөмкинме? — дигән сүзләрен ишетәм.

— Рәхим итегез, — ди аңа председатель. Әлеге ханым трибунага күтәрелә.

— Иптәшләр, — дип сүз башлый ул яңгыравык тавыш белән. — Безнең колхозда дуңгызчылык фермасы оештырылган иде. Хәзергесе көндә кырык баш ана дуңгыз хуҗалыкка ит, май заданиеләрен һәм акча салымнарының бер өлешен капларлык керем бирә. Мин сезне дә үз колхозларыгызда шундый фермалар оештырырга чакырам.

Аны бүлдермичә тыңладылар. Әгәр дә шундыйрак сүзләрне ул колхозлар төзелгәнчегә кадәр сөйләгән булса, дингә ышанучы авылдашлары, һичшиксез, аңа ябырылган булырлар иде.

Михаил Иванович, сүземне бүлдереп, сорап куйды:

— Ә татарлар дуңгыз ите ашыймы?

— Бик сирәкләре генә, — дип җавап кайтардым мин.

— Һәм ирексезләргә кирәкми дә. Ә чыгыш ясаган ханым колхозның экономикасын күтәрү өчен дуңгыз үрчетүнең файдалы икәнлеген бик дөрес әйткән.

Шулай сөйләшеп бара торгач, вакытның узганлыгы сизелми дә калды. Поезд Казан вокзалына килеп туктады. Безне партия өлкә комитеты бюросы һәм Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты членнары, шәһәр предприятиеләре коллективлары вәкилләре каршылады. Бераздан, машиналарга утырып, партия өлкә комитетына юнәлдек.

Съезд тагын бер көннән ачылырга тиеш иде. Михаил Иванович аны үткәрү планы белән танышты һәм Казаннан утыз-кырык чакрым ераклыктагы Арча районының кайбер авылларында булырга теләге барлыгын әйтте. Бу якларга ул 1919 елда Кызыл Армия колчакчыларны куган чорда Коммунистлар Партиясе Үзәк Комитеты кушуы буенча килгән булган һәм кызылармеецлар, командирлар, политработниклар алдында чыгышлар ясаган. Аның теләгенә без, әлбәттә, бик шатланып риза булдык. Икенче көнне иртәнге сәгать тугызда юлга кузгалырга карар иттек.

Май ае иде. Бөтен тирә-якта яз хакимлек итә. Арча юлы буйлап шәһәрдән чыгып бераз баргач, уң як кулда кечкенәрәк кенә бер авыл күренде. Михаил Иванович шул авылга кереп чыгарга тәкъдим итте.

— Кереп чыгарга мөмкин, — дидем мин. — Ләкин басу юлы әле кибеп бетмәгән, машиналар уза алырмы икән...

— Ә шулай да тәвәккәлләп карыйк әле. Кереп батсак, авыл агайлары кыр уртасында утыртып калдырмаслар.

Михаил Ивановичның үз уеннан кире кайтмаячагы ачык иде. Шоферга машинаны авылга борырга куштым. Берникадәр вакыт баргач, Михаил Иванович, миңа карап, җиңелчә генә елмаеп куйды.

— Бу авылга ни өчен барырга теләмәвегезне аңлыйм мин, чөнки мин булырга тиешле авыллар исемлегенә кертелмәгән ул. Сезнең урында булсам, мин дә нәкъ шулай эшләгән булыр идем.

Машина, иләмсез үкереп, юлдан әле уңга, әле сулга тайпыла. Әмма ул Бөтенсоюз старостасын алып баручы оста шоферга буйсынмыйча булдыра алмый. Авылга без хәвеф-хәтәрсез генә килеп җиттек.

Колхоз идарәсе урнашкан йорт янына килеп туктауга безне бер төркем ирләр һәм хатын-кызлар сырып алды. Күп тә үтмәде, колхоз председателе дә килеп җитте.

Исәнлек-саулык сорашканнан соң, җыйнаулашып йорт эченә үттек. Өстәл кырына эскәмия китереп куйдылар һәм безгә урыннар тәкъдим иттеләр. Унбишләп ир кеше идәнгә чүгәләде, алар артына берничә хатын-кыз килеп басты. Алгы рәттәгеләрдән бер кыюрагы сүз башлап, нәрсәдер әйтергә җыенган арада Михаил Иванович колхоз председателенә сорау бирде:

— Язгы чәчүгә хәзерлек эшләре ничегрәк тора? Орлык, инвентарь, тарту көчләре җитәрлекме? Колхозчылар ничек яши?

Председатель Михаил Ивановичка җавап бирим дигәндә генә кулына яулыкка төргән савыт тоткан алтмыш-алтмыш биш яшьләр тирәсендәге бер агай урыныннан күтәрелде. Менә ул, өстәлгә куеп, төенчеген чишеп җибәрде. Өч литр сыешлы мискакада сыек кына үлән ашы салынган иде. Агай кесәсеннән ашъяулыкка төрелгән агач кашык чыгарды да Михаил Ивановичка мөрәҗәгать итте:

— Авыз итеп карагыз, Михаил Иванович, менә колхозчы крестьяннар нәрсә белән туклана.

Калинин кашык белән савыттагы ашны болгатып карады да әйтте:

— Әйе, ризык түгел бу.

Шул чак председатель нидер әйтергә теләп авызын ачкан гына иде, карт аның сүзен бүлдереп, ашыга-ашыга сөйләргә тотынды:

— Ипи кирәк безгә, Михаил Иванович, ипи бирегез сез безгә.

Бөтенесе дә тыннарын да алмыйча җавап көтәләр иде. Михаил Иванович, бер әлеге агайга, бер миңа карап, ашыкмыйча гына сүз башлады.

— Булмаганны бар диеп әйтә алмыйм, ипием юк минем... Эшчеләр сыйныфы алпавытлардан тартып алып, җирне сезгә бирде. Сез авылда яшисез, файдаланыгыз җирдән. Икмәк, яшелчә үстерергә, терлек, кош-корт үрчетергә тиеш сез, үзегезне туйдырырга һәм киендерергә тиеш. Җирегез була торып нишләп иписез утырасыз? Ипи бит завод торбасында үсми! Сез шәһәргә дә ипи бирергә тиешсез.

Сүзнең ахырында Михаил Иванович агайдан:

— Сез үзегез кайда һәм кем булып эшлисез? — дип сорады.

— Юк, Михаил Иванович, мин беркайда да эшләмим. Алтмыш яшькә җиткән ирләр эштән азат ителәләр дигән законга сез бит үзегез кул куйдыгыз. Кеше турында бик зур кайгыртучанлык бу.

— Әйе, шундый законга кул куйдым мин... Ләкин сезнең намусыгыз ул законнан өстенрәк булырга тиеш. Без сездән башка барлык кешеләр эшләгән чаклы ук эшләүне сорамыйбыз, моннан без сезне азат итәбез. Әгәр сезнең намусыгыз саф икән, ул сезгә менә нинди киңәш бирергә тиеш. Кулыгызга таяк алып — күрәм, сезгә әле таяк кирәкми — хуҗалык буйлап узыгыз, һәр нәрсәгә хуҗаларча карап, башкаларга файдалы киңәшләр әйтегез. Сездә зур тәҗрибә бар, ә нигә аны авылдашларыгыз белән уртаклашмаска?! Сез аларга начарлык теләми торгансыздыр бит?

Калининның сүзләрен бөтенесе дә бирелеп тыңлый. Кайберләре сизелер-сизелмәс кенә ияклярен кагып, аны җөпли, кайберләре агай басып торган якка елмаюлы караш ташлый. Менә, янәсе, мунча кертәме үзеңне? Хәзер йорт бусагаңнан атлап чыгып кына туктамассың, читтән торып күзәтүче булып түгел, хуҗа булып басу-кырлар буйлап атларсың.

Ул чорда безнең республика колхозларында (һәм бер бездә генә түгел) төп тарту көче булып атлар санала иде. Шуңа күрә атларга һәр вакыт зур игътибар бирелде. Михаил Иванович колхозның язгы чәчүгә нинди хәзерлек белән килүен ахырынача ачыклап бетерергә теләде.

— Халыкта язның бер көне ел туйдыра дигән мәкаль бар. Шулай да сөйләгез әле, чәчүгә ничек хәзерләндегез? — дип кабатлады Калинин.

— Сабаннар, тырма һәм чәчкечләр, шулай ук дирбияләр ремонтланып куелды. Орлык җитәрлек әзерләнде. Атларга да фураж калдырылды.

— Ат башына күпме исәптән?

— һәр атка ике центнер исәбеннән. Бездә, Михаил Иванович, чәчүлек орлык һәм фураж кагылгысыз санала.

— Менә бусы мәсьәләгә хуҗаларча караш. Шуның белән бергә, инде колхозчыларны азык-төлек белән тәэмин итүдә кыен хәл килеп туган икән, алар өчен гомуми туклану кебегрәк нәрсә, көненә бер генә тапкыр булса да мәктәп балаларына кайнар аш оештырырга мөмкинлек табып булмасмы?..

Тирә-юньдәгеләрнең йөзләренә якты елмаю йөгерде. Арадан:

— Әлбәттә, мөмкин, Михаил Иванович,— дигән тавышлар ишетелде.— Бары тик теләк кенә булсын.

— Алайса, менә болай эшлик,— дип сүзен түгәрәкләде Михаил Иванович.— Иптәш Яһудин сезгә үзе килер яки берәр кешесен җибәрер. Бу мәсьәләне шунда бергәләп хәл итәрсез.

Әңгәмә шуның белән тәмамланды һәм без 1919 елда Михаил Ивановичның килүе хөрмәтенә «Калинино» дип аталган икенче бер авылга кузгалып киттек. Михаил Иванович машинада шактый ара сөйләшми барды. Ә мин беренче булып сүз башларга базмадым. Узган елның язында һәм җәендә көчле корылык булу һәм башка кайбер сәбәпләр аркасында, Татарстанда азык-төлек мәсьәләсенең ничегрәк торуын Михаил Иванович үзе дә яхшы белә, әле генә туктап үткән авылда ишеткән нәрсәләр аның өчен яңалык түгел иде. Байтак вакыт шулай тын гына барганнан соң ул үзе сүз башлады:

— Кызганычка каршы, табигатьнең корылык, су басу, боз сугу кебек күренешләре алдында без әле көчсез. Безнең өчен иң авыр сынау булып исәпләнгәне — корылык. Моннан тыш безгә, безнең экономикабызга томаналык, кешеләрнең үз эшләренә бикләнгән булулары, искелек калдыклары зур зыян китерә.

— Әйе, Михаил Иванович,— дидем мин сүзгә кушылып,— егерме беренче елгы ачлыкның гомергә онытыласы юк. Идел буен басып алган ул ачлыкта йөзләрчә, меңнәрчә кешеләр кырылды. Минем үз әнием дә шул ачлыктан үлде. Мине һәм энемне Совет власте коткарып калды.

Михаил Иванович сүзен дәвам иттерде:

— Ә шулай да вакытлар узу белән кеше, аның хезмәте һәм акылы табигать бәлаказаларын җиңүгә ирешер, аны җәмгыятьнең материаль-рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен эшкә җигәр... Без яңа тормышны бик зур авырлыклар белән төзи башладык. һәм аны барыбер ахырынача төзеп бетерәчәкбез.

Калинино авылында без калай түбәле, ике катлы зур агач бина каршына килеп туктадык. Авыл советы һәм колхоз идарәсе шушы бинада урнашкан иде. Өй алдындагыларга сәлам бирә-бирә, икенче катка күтәрелдек. Беренче булып Михаил Ивановичның янына кулына ниндидер кәгазь тоткан утыз яшьләр тирәсендәге бер ир кеше килеп керде. Үзенең шәһәргә эшкә китәргә теләве, ләкин авыл советының аңа рөхсәт бирмәве турындагы зарын белдерде ул Калининга. Михаил Иванович аның гаризасына күз йөртеп чыкты да авыл советы председателенә сорау бирде:

— Рөхсәт итмәвегезнең сәбәбе нәрсәдә?

— Шәһәргә китәргә теләүчеләрнең берсенә дә каршы түгел без,— диде председатель.— Ә менә аңа авылдан кузгалырга киңәш итмибез һәм җибәрмибез дә.

— Ни өчен?

— Эчә ул, Михаил Иванович, чутын-чамасын белмичә эчә. Шуңа күрә аның, шәһәргә барып, безнең авылны адәм мәсхәрәсенә калдыруын теләмибез.

— Күптән эчәсезме?

— Унбиш яшемнән бирле диярлек, Михаил Иванович. Дөресен әйтим, үзебезнең авыл кешеләре боздылар мине. Әтием минем мич чыгаручы, балта остасы һәм буяучы иде. Менә аны мич чыгарырга чакыралар. Өстәл өстендә — шешә. Мич әзер — яңадан сыйлану. Кемнең дә булса абзар-курасын төзәтәме яисә коймасын буяп бирәме — тагын шул ук хәл. Ә мине әти һәрчак үзе белән ияртеп йөртә иде... Башта үзләре кыстый-кыстый өйрәттеләр дә хәзер менә бөтенесенә мин гаепле булып чыгам.

Михаил Иванович гаризаның өске почмагына: «Шәһәргә китү өчен документлар бирергә»,— дигән резолюция салды да, аны авыл советы председателенә сузды.

Аннары үзенең каршында утырган иптәшкә җавап кайтарды: — Әгәр әчүегезне ташласагыз, шәһәр сезне тулай торакта яшәү тәртипләренә өйрәтер.

Ишектә кырык биш яшьләрдәге бер хатын-кыз күренде. Ул бәрәңге утырту өчен җир сорап килгән булып чыкты.

— Балаларыгыз ничәү? — дип сорады аннан Калинин.

— Өчәү.

— Ә ирегез кайда?

— Менә монда утыручы җитәкчеләр аны, колхоз оештыруга каршы кеше дип, төрмәгә яптырдылар.

Михаил Иванович авыл советы председателенә сораулы караш ташлады.

— Эш менә болай тора, — дип сөйләп китте председатель. — Бу апаның ире тимерче иде. Сүз дә юк, яхшы эшләде. Хуҗалыгы нык, урта хәлле крестьян диярлек түгел. Партия һәм хөкүмәтебезнең күмәк хуҗалыклар төзү турындагы директиваларын үти башлауга, крестьяннарны колхозга кермәскә өндәргә тотынды. Чакырабыз да әйтәбез моңа без: «Колхозга керү өчен гариза бирергә тиешсең. Һөнәрле кешегә колхозда начар түгел, ә яхшырак булачак», — дибез. Башта ул уйлангандай булып аска карап утырды-утырды да тамак төбе белән генә җавап кайтарды: «Юк, үгетләмәгез, кермим мин колхозга». Ярый, без әйтәбез, тагын бер тапкыр ныклабрак уйлап карагыз. Хатыныгыз белән киңәш итегез. Шул ук вакытта кисәтеп тә куябыз: гомумхалык эшенә каршы төшеп, башкаларны колхозга кермәскә өндәп, халык арасында коткы таратмагыз. Урыннан торды да, бер сүз дә әйтмичә, чыгып китте бу. Һәм шуннан нәрсә булды дип уйлыйсыз?.. Менә ул, әлеге тимерченең хатыны, ялган сөйләргә ирек бирмәс, үзенең күз алдында әйтәм. Алар, ире белән икәүләшеп, үзебездә генә түгел, унбиш-егерме чакрым ераклыктагы авылларга барып, крестьяннарны колхозга керүдән баш тартырга котыртып йөри башладылар. Без моны яңадан авыл советына чакырабыз һәм: «Кулак элементларны бетерүне безгә синнән башларга кирәк булган икән», — дип, ачыктан-ачык белдерәбез. Авыл советы яңа билгеләнгән салымны башта беразга, аннары биш тапкырга арттырды. Ул аны түләүдән баш тартты. Шуннан соң тиешле органнар, колхозлашуга каршы агитация алып барганы өчен, аны авылдан сөрделәр. Ә гаиләсе монда калды.

Михаил Иванович авыл советы председателенең аңлатмасын зур дикъкать белән тыңлады.

— Бөтен ил күләмендә крестьяннар күмәк хуҗалыкларга берләшәләр, — диде ул аннары гариза тотып авыл советына килгән хатынга. — Колхоз ул халыкның язгы ташкынга охшаган олы хәрәкәте. Мул сулы ярсу елганы күз алдыгызга китерегез. Әгәр сез аның юлына каршы торасыз икән, ул сезне яр читенә алып ташлаячак.

— Әйе, Михаил Иванович, безне инде яр читенә чыгарып ташладылар. Алай гына да түгел, каурыйларыбызны йолкып, шәп-шәрә калдырдылар диярлек. Ә балалар белән мин нишләргә тиеш?

— Әйе, ә балалар белән нишләргә? Сез җәмгыятькә каршы эш алып барырга беләсез, ә менә балалар турында уйламыйсыз. Аннан соң: «Миңа нишләргә?» дип сорыйсыз. Ни өчен соң акыллы киңәшкә башта ук колак салмадыгыз? Моның җавабы бер генә: сезнең иңнәрегезгә шәхси милекчелекнең авыр гере асылган. — Шушы сүзләрне әйткәннән соң Михаил Иванович гаризага: «Бәрәңге бакчасы өчен җир бүлеп бирергә», дип язды да имзасын куйды.

Нәүбәттәге кеше булып, авыл советына яшь кенә бер хатын-кыз килеп керде. Аның гаризасы: «Булышуыгызны сорап мөрәҗәгать итәм Сезгә, Михаил Иванович», дигән сүзләр белән башланган иде. Калинин анда язылганнарга күз йөртеп чыкты да:

— Телдән кыскача гына сөйләп бирегез, — диде.

— Мин шушы авылныкы. Иргә үзем яраткан кешемә чыктым. Бик тату яшәдек. Ике балабыз бар. Колхозга кердек. Мин колхозда эшлим, ә ул кооперация кибетендә эшли иде. Көтмәгәндә ревизия килеп төште. Иремнең җитмәүчелеге килеп чыкты һәм аны биш елга утырттылар.

Михаил Иванович бу ханымның колхозда ничек эшләве турында сорады.

— Бик әйбәт эшли, — дип җавап бирде аңа колхоз председателе. — Тырыш колхозчы. Крестьян хезмәтенең кайсы гына тармагында эшләмәсен, беркайда да сынат-

мый. Чәчәргә, урырга, печән чабарга, кибән куярга дисеңме, барысын да булдыра. Кайбер ирләргә эшкә аннан өйрәнергә кирәк әле...

— Беләсезме, — диде Михаил Иванович, председательнең сөйләвен тыңлап бетергәч. — Кооператив милке — җәмәгать милке ул. Миңа бик зур хокуклар бирелгән булса да, җәмәгать милкенә бәйләнешле мәсьәләне мин үз белдегемчә хәл итә алмыйм, моңа минем хакым юк. Әгәр кооператив членнары ирегезне гафу итү турында карар чыгарып, аны котылдыруны сорасалар, мин аларның соравын закон нигезендә рәсмиләштерермен, колхозда сезнең тырышып эшләвегезне искә алып, ирегезне төрмәдән азат итәргә күрсәтмә бирермен.

Колхозчы хатын, Калининга рәхмәт әйтеп, авыл советыннан чыгып китте. Бер ярты сәгать эчендә кооператив членнарының аның ирен гафу итүләре турында чыгарган карарын китерде. Җыелыш карары язылган кәгазьне авыл советы секретарена биргәндә:

— Ирегезне көтегез, — диде Михаил Иванович колхозчы хатынга.

Соңыннан Михаил Иванович колхоз, мәктәп һәм крестьяннар тормышы белән танышты. Бу колхоз районда урта кул хуҗалыклардан санала, анда инде җәмәгать терлекләре өчен абзарлар һәм башка каралтылар төзелә башлаган иде. Калинино авылыннан без соң гына киттек...

Икенче көнне иртәнге сәгать унда, цирк бинасында, колхозчы делегатлар һәм Идел буе республикаларыннан, Украинадан килгән кунаклар белән шыгрым тулы залда Татарстан колхозчыларының Беренче республика съезды ачылды. Президиумда — Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты Председателе, ВКП(б) Үзәк Комитеты Политбюросы члены Михаил Иванович Калинин, республика җитәкчеләре, Казан заводлары һәм фабрикалары эшчеләре вәкилләре, колхоз алдынгылары...

Съездны партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре иптәш Разумов ачты. «Колхозларны ныгыту һәм 1933 нче авыл хуҗалыгы елын барлык күрсәткечләр буенча уңышлы үтәп чыгу өчен социалистик ярыш оештыру» дигән көн тәртибе буенча докладны Җир эшләре халык комиссары иптәш Искәндәрев ясады. Доклад буенча фикер алышуларда катнашкан район җитәкчеләре, авыл хуҗалыгы белгечләре, алдынгы колхозчылар социалистик ярыш шартларында саналып үтелгән бурычларны тормышка ашыру өчен нәрсәләр эшләргә кирәклеге турында конкрет мисалларга һәм саннарга таянып сөйләделәр.

Менә сүз Днепропетровск өлкәсе делегациясе вәкиленә бирелә. Трибунага шактый дулкынланып, әмма кыю адымнар белән урта яшьләрдәге, ачык йөзле, чәчләрен ике толымга үреп салган бер хатын-кыз күтәрелә. Башта ул съезд делегатларын һәм кунакларны Днепропетровск өлкәсе хезмәт ияләре исеменнән кайнар котлый. Аерым алганда, съездда катнашучыларга ул партиянең Днепропетровск өлкә комитеты секретаре иптәш Хатаевичның сәламен тапшыра. Билгеле булганча, Харьковка киткәнче иптәш Хатаевич партиянең Татарстан өлкә комитеты секретаре булып эшләгән.

— Днепропетровск өлкәсе хезмәт ияләре, колхозчылары һәм совхоз эшчеләре, — дип дәвам итә аннары чыгыш ясаучы үзенең сүзен, — тугандаш Татарстан колхозчылары һәм эшчеләренең социалистик ярышка чакыруын зур канәгатьләнү хисе белән кабул итәләр. Без, украиннар, сезнең республикагызның хезмәт сөючән халкы белән күптәннән ныклы элемтәдә торабыз. Сезнең якташларыгыз — җир казучылар, төзүчеләр һәм башка һөнәр ияләре күмер җитештерү һәм төзелеш эшләрендә безгә зур булышлык күрсәтәләр. Ышанмыйм, безгә сезнең белән ярышу җиңел булмаячак. Сезнең эшчән, тату, физик яктан көчле халык икәнлегегезне без бик яхшы беләбез. Әмма безгә авыл хуҗалыгы машиналары — тракторлар, чәчкечләр, ургычлар бирүче эшчеләр сыйныфы ярдәм итәр. Чакыруыгызны кабул итәбез, ярышырга икән, ярышырга!

Татарстан делегатлары исеменнән Чистай районының Мөслим авыл советы председателе чыгыш ясарга тиеш иде. Украина вәкиле сөйләгәннән соң сүз аңа бирелде. Ул, залдагыларга күз йөртеп алды да, гәүдәсен бераз алга ия төшеп, акрын гына сөйләргә тотынды:

— Без бөек Ленин әйткән кумәк хуҗалык төзүчеләрнең беренче съездына җыйналдык. Колхозлашуның крестьяннарга социализмга бару өчен берләнбер һәм төп юл икәнлеген без яхшы аңлыйбыз. Алга куелган бурычларны үтәп чыгу өчен безгә

хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрергә кирәк. Ә без моңа бары тик завод һәм фабрикаларда, шахталарда һәм транспортта, колхоз һәм совхозларда, кыскасы, һәр җирдә үзара ярышып эшләү нәтиҗәсендә генә ирешәчәкбез. Социалистик ярыш — колхозчыларны коллективизм рухында тәрбияләү, вак буржуаз психологиядән һәм чикләнгәнлектән арындыру өчен гаять әһәмиятле чара ул. Менә шуңа күрә дә без Днепропетровск өлкәсе хезмәт ияләрен социалистик ярышка чакырырга булдык. Бу өлкәнең революцион традицияләргә бай булган алдынгы өлкә икәнлеген без бик яхшы аңлыйбыз һәм ярышта артта сөйрәлмәскә сүз бирәбез.

Съездда республика җитәкчеләреннән М. Разумов, К. Абрамов һәм башка иптәшләр чыгыш ясады. Ахырда сүз Михаил Иванович Калининга бирелде. Аны зур игътибар белән тыңладылар. Съезд республика колхозчыларына һәм эшчеләренә мөрәҗәгать кабул итте.

Съезд барышында Михаил Иванович хезмәт ияләре власте органы — Советларның эше белән танышты, югары уку йортларында хәлнең торышы, галимнәрнең эшләре белән кызыксынды. Михаил Иванович Калининга мин Казан галимнәре — химиклар, математиклар, медиклар, лингвистлар, тарихчылар һәм башка белгечләрнең зур иҗади эш алып барулары, партия өлкә комитеты һәм республика хөкүмәтенең аларга даими ярдәм күрсәтеп торулары турында сөйләдем.

Партия өлкә комитетында әңгәмә вакытында Михаил Иванович без үткәрә торган чаралардан канәгать булуын һәм партия Үзәк Комитетында колхозчыларның Бөтенсоюз съездын чакыру турында карар хәзерләнеп ятуын әйтте. Сезнең республика колхозлары һәм совхоз эшчеләренең ярышы, диде ул, бөтен союз күләмендәге уртак эшебезгә, авыл хуҗалыгын, колхозларны һәм совхозларны үстерүгә зур этәргеч булды.

Аннан без Михаил Ивановичны Мәскәүгә озаттык.

Халык хуҗалыгын күтәрүдә съезд зур әһәмияткә ия булды. Колхозчыларның Беренче республика съезды колхозчы крестьяннарның совет власте һәм Советлар Союзы Коммунистлар партиясе тирәсенә тупланганлыгын, югары патриотизмын, социализм төзү буенча киң җәелдерелгән бөтен халык ярышында Татарстан автономияле республикасының лаеклы урын тотуын күрсәтте. Партия өлкә комитеты җитәкчелегендә Татарстан әүвәлгечә үк алдынгы союздаш һәм автономияле республикалар рәтендә барды.

Михаил Иванович Калининның, безнең республика колхозлары һәм совхоз эшчеләренең ярышы бөтен союз күләмендәге уртак эшебезгә зур өлеш кертәчәк, дип әйткән сүзләре тулысынча акланды. Авыл хуҗалыгын күтәрү, кырчылык һәм терлекчелекне үстерү өчен көрәштә бу ярыш зур роль уйнады. Бу көрәштә эшчеләр сыйныфы, колхозчы крестьяннар һәм интеллигенция катнашты. Беренче сафларда коммунистлар һәм комсомолецлар атлады. Алар үрнәгенә партиясез хезмәт ияләре иярде. Нәтиҗәдә безнең республика Днепропетровск өлкәсе белән ярышта җиңүче булып чыкты. Төп авыл хуҗалыгы эшләрен уздыруда ирешкән уңышлары өчен СССР Үзәк Башкарма Комитеты Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасын Ленин ордены белән бүләкләү турында карар чыгарды.

1934 елның мартында Татарстан АССР Үзәк Башкарма Комитетының дүртенче сессиясе чакырылды. Анда карт большевик, Бөтенсоюз Үзәк Башкарма Комитеты члены иптәш Смидович республикага илебезнең олы бүләген тапшырды.

Һәр эшче, колхозчы, совет интеллигенциясе В. И. Ленинның якын көрәштәше, партия һәм дәүләт эшлеклесе Михаил Иванович Калининны, илебездә социализм төзүгә бөтен көчен биргәне өчен олылап һәм зур хөрмәт белән искә ала.

≈≈≈≈≈≈

**Жубан Мулдагалиев,**
казакъ шагыйре

## Күтеп алган бәхет

Мин Вакытның күрдем туктап калганын,
Минутларның, секундларның янганын.
Күрдем кояшның кыяга баш куеп
Бер мизгелгә тирән уйга талганын.

Ә без ике гашыйк җан тик — ул да мин...
Тойдым бары җанда сөю уйнавын.
Кочаклашу я үбешү — кая ул!
Кулларына кагылырга кыймадым.

Күзләрне — күз, сөйгән җанны җан таба.
Ул вакытны ничек кенә каргама,
Изге иде, саф иде ул, зур иде —
Кызын-улын сакласа да ата-ана.

Һаман әле безнең сөю нур чәчә...
Күзләр-күзгә, җаннар-җанга эндәшә.
Бәлки шуңа — безнең сөю саф булып
Саклангандыр менә шушы көнгәчә.

Мин Вакытның күрдем катып калганын,
Кичерсен Вакыт — кайвакыт каргадым,
Ут астында атакага киткәндә
Туктый Вакыт, җитми кала бер адым.

Кичердем сынавын Әҗәл-җәзаның,
Татыдым яшәү ләззәтен, газабын —
Шуңа да мин көтеп алган бәхеттән
Җырларымны илһамланып язамын.

Чаба Вакыт, күп нәрсәләр үзгәрде.
Җитеп булмас иде булса элгәре.
Магнит тотып кемдер йөгерткән сыман
Чаба һаман — чаба сәгать телләре.

Инде ул кыз әллә кайда — еракта.
Гомер бара соңгы җырыма таба...
Баралмасам, җиткән җирдә калырмын,
Оч син, Вакыт, миңа карап туктама!

## Күкчәтау җирләре

Үз җир булып тоелырга мөмкин
Безгә һәрбер таулы дала иле,
Әмма сабый чактан һәр кишәрлек
Казакъ җире безгә ана иде.

Әле башта күнекмәгән күзнең
Каргавы да мөмкин... Тик мин түгел!
Дала халкы әүвәл заманнардан
Чүлләрдә дә хәтта итте гомер.

Сусызлыкны сәбәп диючеләр
Карап баксыннар бер тирә-юньгә...
Шаулап тора болын кылганнары
Гүзәл Батмак-Дала күлләрендә.

Яманлап, я мактап булмый илне
Я бер, я бер ягын алып:
Нәрсә булыр иде тамчы судай
Охшаш булса халык белән халык.

Гасырлардан килгән гүзәллеккә
Гөнаһ булмас, әйе, бер күз ату...
Муллык белән ташып, түгелеп тора
Күкчәтауның бөек табигате.

Кеше күрсен өчен киңлекләрне,
Күр, мәһабәт таулар күтәрелгән!
Таратырга сагышлары барга —
Иксез-чиксез гүзәл киңлек биргән.

Иркен киңлекләрне сугарырга
Болытлары мул яңгырлар ташый,
Чөнки монда биек таулар аша
Җир белән күк алган туганлашып.

Көн тарата, төн тарата исеп
Татлы чәчәк исен дала җиле.
Дымлы керфекләрдә зәңгәр караш —
Һәр чишмәсе бага, һәрбер күле.

Киңлекләрдә бәйрәм итәр өчен
Кышлар үз вакытын ~~көтеп ала~~.
Ә җәйләрнең кайнар сулышлары
Кызлар сулышыдай өтеп ала.

Кышлар узып, язлар узып китә,
Бар табигать өлгерүгә бара...
Җитә вакыт, алтын-сары булып
Тук башаклар шаулап дулкынлана.

Күлләр, урман, сулар, болын, кырлар
Якты шатлык белән сугарылган.
Бөек Күкчәтауның җирләренә
Шатлык тулган бүген, шатлык тулган.

Чирәм җирләр — яңалыклар җире,
Ул бәйрәмнәр җире —
Яңа дөнья!
Иксез-чиксез шушы гүзәллекне
Гомерем буе җырлау язсын миңа.

Бирҗан булу кирәк түгел миңа,
Охшау кирәк түгел Аханга да,
Тик бүгенге җырда искә алмый
Китә алмыйм алар хакында да:

Ул акыннар оҗмах теләгәннәр
Һәм беткәннәр дөрләп, иртә янып...
Без яшибез менә Кукчәтауның
Туфрагында бүген оҗмах табып.

М. ӘГЪЛӘМОВ тәрҗемәләре

## М. Мирмухсин,

үзбәк шагыйре

### Йөрәк җылысы

Партиябез, синең белән бергә без —
Юл ярабыз таш кыялы үргә без.

Үзбәкстан — туып-үскән җирләрем,
Гөлләр исе бөркеп исә җилләрең.

Без белмәдек элек җирнең катларын,
Тиңсез хәзинәләр анда ятканын.

Нужа үтсә дә үзәккә — дәшмәдек,
Су янында суга сусап яшәдек.

Комсыз байлар, миңрәтеп без — ачларны,
Җирнең байлыкларын безгә ачмады.

Син, Партия, ачтың юлны кояшка,
Юлбашчы да булдың безгә, юлдаш та.

Җир байлыгы хәзер безнең кулларда,
Бохара газ бүләк итә Уралга.

Кабынуын котлап зәңгәр ялкынның,
Кулын кыса Урал үзбәк халкының.

Торбалардан элдереп газ елозын
Илтә безнең дуслыгыбыз җылысын.

Ташкын сыман ургып ерак төбәккә,
Күчә зәңгәр ут йөрәктән-йөрәккә.

Син, Партия — сүнмәс нурлы олы таң,
Җитәклисең безне Ленин юлыннан.

Тигез яктыртасың илнең бар ягын,
Яңа үргә дәшә синең байрагың!

## Зилзилә

Алсу таңның тын бер мизгелендә
Астан тетрәп, астан кызды җир...
Тынны буды салкын таң һавасы,
Бәреп чыкты тәнгә тозлы тир.

Бөтен кала купты, бөтен төбәк,
Күтәрелдек кече-олыбыз.
Үз тирәмә җыям балаларны:
— Нәниләрем, тыныч булыгыз!..

Авыруларны, саклап һәлакәттән,
Йомшак сүзем белән юатам...
Сүз ул — зур көч! Кирәк икән җанда
Яшен яшьни сүздән, туа таң.

Сүз көченә, үз көчеңә ышан,
Сөендермә, шыңшып, дошманны.
Түземле бул, димен, үз-үземә,
Кыю үтә намус кушканны.

Өйләр ава... Тик аумасын кеше!
Ауган йортны була күтәреп.
Яңа Ташкент төзәрбез ил белән
Бар дөньяның исен китәреп.

Зилзиләдән өркеп, һушсыз калды
Рухы сүлпән, холкы юашлар...
Юк, куяннар түгел, кыю җаннар —
Бу көннәрдә безнең юлдашлар.

Без, яралы калам, синең белән,
Синең язмыш — минем язмышым.
Илдәге бар халык өчен уртак
Синең афәт, синең сагышың.

Җир астында тетрәү һаман тынмый,
Син борчылма, калам, без — терәк!
Ничек кенә илермәсен давыл,
Кеше аннан йөз кат көчлерәк.

Гайбәтчеләр шом тараткан саен
Ныгый бара иңдә канатлар.
Ил әмерен төгәл үтәдегез,
Мең-мең рәхмәт сезгә, солдатлар!

Зур көрәштә туа үлмәс дастан,
Зур көрәштә туа батырлар.
Шундый кала тергезербез җирдә —
Таң калырлар аңа гасырлар!

**МӘХМҮТ ХӨСӘЕН**
тәрҗемәләре.

## Шәриф Рахманкулов

# ТЫҢЛАГЫЗ, КАЗАН СӨЙЛИ...

Бөек Октябрьга алтмыш ел тулган көндә Татарстан радиосы үзенең 50 еллыгын билгеләп үтә. Еракта калган ел. Әмма мәдәниятебез тормышында бик истәлекле ел ул. Татар сүзен эфирга таратучы беренче дикторларның берсе буларак, башлангыч елларда радио тапшыруларның ничек оештырылуы, радио эшендә катнашкан, аны үстерүгә үзеннән өлеш керткән культура, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре хакында хәтердә сакланган истәлекләр белән уртаклашасы килә.

Кеше тавышын телефон чыбыклары аша еракка көчәйтеп тарату хыялын Казан элемтәчеләре революциянең беренче елларында ук тормышка ашыра башлыйлар. Һәм аның башлангычы Казан университетын тәмамлаган талантлы инженер А. Т. Углов уйлап тапкан телефон көчәйткече була. Шушы көчәйткеч аппарат телефон үткәргечләр белән рупорга тоташтырыла. Менә граммофон трубасына охшашлы өч рупор Казан урамнарына элenә — беренче тапкыр телдән газета укыла.

Казан халкын таңга калдырган бу вакыйга 1921 елның Беренче май көнендә була. Ул хәбәр «Правда» һәм «Известия» газеталары аша илебезгә тарала һәм аны В. И. Ленин да укый. Укып кына калмый, шунда ук Халык Комиссарлары Советының хуҗалык эшләрен алып баручысына хат яза һәм үзенең бу ачыш белән кызыксынуын белдерә: «Бүген газеталардан укып белүемчә,— ди юлбашчы,— Казанда телефон көчәйтүче һәм җыелган халыкка сөйләүче рупор сыналган (һәм бик матур нәтиҗәләр биргән) икән. Остряков аркылы белешегез. Әгәр дә дөрес булса, Мәскәүдә һәм Питерда куярга кирәк...»

Озак та үтми, Казан радиобазасыннан җибәрелгән рупорлар башкаланың иң зур мәйданнарына куела, үзәк телефон станциясе янында радиостудия эшли башлый. Бу вакыйга Казанда радиосөючеләр хәрәкәтенең җанланып китүенә сәбәп була. Тиздән «Радиосөючеләрнең Татарстан җәмгыяте» төзелә. Җәмгыять үзалдына кабул итү станциясе белән бергәттән җирле тапшырулар алып барырлык станция төзү бурычын куя. Һәм 1927 елның көзендә Казан радиостанциясе эшли башлый. Бөек Октябрь революциясенең ун еллыгын бәйрәм иткән көнне татар сүзе беренче тапкыр радио аша яңгырый.

Минем Казанга килүем нәкъ шушы көннәргә туры килде. Укырга керергә соңга калган идем. Шулай да вакытны әрәм уздырмас өчен, Комлев урамындагы «ВУЗ һәм ВТУЗларга хәзерлек курсларына» урнаштым. Укулар кичке сәгатьләрдә булганлыктан, көндез эшләү нияте белән хезмәт биржасына бардым һәм шунда мәшһүр артист Мохтар Мутинны очраттым. Мохтар абый мине Троицк шәһәре театры буенча белә иде. Ул берничә сезон шул театрда эшләде. Мин дә сәхнәдә һәвәскәр сыйфатында баштарак балалар, ә соңыннан сүзсез рольләрдә катнашкалый идем. Беренче сүзе: «Нишләп йөрисең?» булды.

Кыска гына аңлашудан соң, мине үзе белән алып китте. Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театры бинасы эчендәге бер бүлмәгә кердек. Мохтар абый

өстәл артында утырган хәрби киемле кешегә мине күрсәтеп: «Менә сезгә диктор алып килдем...» — ди. Ә мин диктор сүзенең нәрсә икәнен дә аңламыйча аптырап торам. Аңлашкач, җөрьәт итеп, ризалыгымны бирдем. Сынап карау өчен микрофон алдына бастырдылар. Студиягә беренче аяк басуым, беренче тапкыр микрофонны күрүем. Шул кадәр каушаганмын ки, кәгазь битендәге сүзләрне тота алмый аптырадым, әйтерсең алар сикерешеп, биеп йөриләр. Тирләдем, пештем... Сүзләрне оештырып текстны укый алдыммы-юкмы, белмим, әмма бу үземә ошамады. «Миннән була торган эш түгел», дип уйладым да, төпле бер фикергә килә алуыма шатланып, тиз генә студиядән чыгып сыздым...

Атналар, айлар узды. Икенче эшкә кереп эшли башладым. Радиостудиядәге вакыйга инде онытыла да башлаган иде, тагын Мутин абый очрап куймасынмы.

— Син кая югалдың? Әйдә! — диде дә Карл Маркс урамындагы 36 нчы йортка алып килде. Баксаң, студия шушында күчкән икән. Мин кинәт туктап калдым. Әмма, ни дә булса уйлап өлгергәнче, Мохтар абый кулымнан тотып икенче катка алып менеп китте. Менә без баш редактор бүлмәсендә. Озынча буйлы, гаҗәеп ягымлы, сабыр холыклы бу кеше сүз арасында гына кайбер сораулар бирде дә, миңа дикторлык хезмәтен тәкъдим итте. Эш хакының җитмеш биш сум булганлыгын да сиздереп куйды. Минем өчен бу бик зур акча иде.

Бер күрүдә күңелемне әсир иткән ул кеше Сәгыйть ага Фәйзуллин булып чыкты, ә беренчесе, теге хәрби киемдәгесе, язучы Шамил Усманов булган икән. Сәгыйть абый кул астында миңа бернечә ел эшләү насыйп булды.

Студиянең тәүге елында дикторлык вазифасын башкаручы махсус кеше булмый. Матбугатта Г. Кутуй, Камал II һ. б. исемнәр күрсәтелсә дә, алар дикторлык хезмәтен вазифа төсендә түгел, ә аерым тапшыруларга сәгатьләп чакырылу буенча башкарган булырга тиеш. Моны Г. Кутуйның үз сүзләре белән дә раслап була. Дикторлык хезмәтенә үзенә күрә кечкенә конкурс үткәрелә. Радио аша бирелгән игълан буенча студияга бары өч егет килә. Минем килүем дә шул вакытка туры килә һәм мин дүртенче кеше булганмын. Менә шулчакны безнең белән үткәргән әңгәмә вакытында Г. Кутуйның, «Дикторлык хезмәтен башкару өчен яхшы дикцияле, тавышы матур тембрлы кеше булмавы аркасында, бу вазифаны баштагы айларга һәрберебезгә башкарырга туры килде», дигәне хәтеремдә.

Мин килгәндә, дикторлык хезмәтен журналист, тәрҗемәче Рәшит Мансуров башкара иде. Р. Мансуровның сәламәтлеге нык какшаганлыктан, диктор булып саналса да, тәрҗемә эше белән генә диярлек шөгыльләнде. Мин килеп бернечә ай узуга, бу гаҗәеп тыйнак, хезмәтен төгәл һәм зур тырышлык белән башкаручы иптәш арабыздан китте.

Мин, көтмәгәндә, баш диктор булып калдым. Кайбер тапшыруларга ярдәм төсендә татар театры артистлары да чакырыла һәм бер кадәр амплуа да саклана иде. Мәсәлән, Бөек Октябрь, Беренче май бәйрәмнәре өндәмәләрен укуны хәзерләү эше фәкать Мохтар Мутинга тапшырыла, соңгы хәбәрләрне укуда Мәҗит Илдар, Камал II еш катнашалар. Әдәби-музыкаль тапшыруларның җитәкчесе Кәшифә ханым Тумашева дикторларның иң якын ярдәмчесе булды. Студиядә ул ике тавышка (хатын-кыз һәм ир тавышларын аралаштырып) укуны юлга салды. Алдагы елларда инде бу принцип өзлексез сакланып килендә. Кәшифә ханым Тумашева, драма артисткалары Зәйнәп Хәсәенова, Зәйнәп Камалова хатын-кызлардан беренче дикторлар булдылар.

Тапшырулар өч телдә — рус, татар һәм чуваш телләрендә бара башлады. Рус дикторлары булып Е. Е. Жилина (СССР халык артисткасы) белән И. С. Самбурскаялар (СССР Культура министрлыгында бүлек мөдире, хәзер пенсиядә) эшләде.

Иртәнге тапшырулар сәгать унберде соңгы хәбәрләр белән башланып, «Ударниклар иртәсе» яки «Колхозчылар иртәсе» исемле зур концерт белән тәмамлана. Кичке тапшырулар дүрт-бишләрдән төнге уникегә хәтле бара. Соңгы хәбәрләр, төрле фәннәр буенча лекцияләр, беседалар, әдәби-музыкаль тапшырулар бирелә иде. Даими башкаручылар итеп, штатка җырчылар — Мәрьям Рахманкулова, Гөлсем Сөләйманова, Ярулла Чамаев һәм бер пианист чакырылды. Башта С. Сәйдәшев, аннары В. И. Виноградов җитәкчелегендә кечкенә симфоник оркестр да оештырылды. 1931 елда студия штатына Казан музыка техникумының вокал буенча Е. Г. Ковелькова

(заманында операларда Ф. Шаляпин белән бергә җырлаган күренекле җырчы) классын тәмамлаган Любовь Юрусова алынды. Татар телен яхшы белгән бу җырчы татар концертларында да катнаша һәм шул елларда иҗат ителгән яңа җырларны радиодан беренче булып еш кына аңа башкарырга туры килә. Берничә елдан соң консерватория белеме алып Мәскәүдән Зөһрә Бәйрашова (хәзер Казан дәүләт консерваториясенең профессоры) кайтты. Ул да ике телдә — рус һәм татар концертларында җырлый иде. Болардан тыш, тапшыруларга әледән-әле Казан музыка һәм театр техникумнары студентлары чакырылды. Мәскәү һәм Ленинград шәһәрләрендәге югары музыка уку йортларында укучы Фәрит Яруллин, Хәсән Гобәйдуллин кебек яшь музыкантларыбыз да радионың якын дуслары булып киттеләр. Тематик концертлар оештырып, татар тыңлаучыларын бөек композиторлар иҗаты белән таныштыруда Х. Гобәйдуллин аеруча зур ярдәм күрсәтә иде.

Җырчылар, лекторлар һәм дикторларның осталыкларын күтәрүгә ул елларда ук зур әһәмият бирелде. 1930 нчы елларда җырчылар өчен тавыш куюю дәресләре алып барыла башлады. Педагог Шевцов җитәкчелегендә атнага ике көн үткәрелә торган бу дәресләргә йөрү махсус музыка белемнәре булган җырчылар өчен дә, дикторлар өчен дә мәҗбүри иде. Җырчылар атнага бер тапкыр татар теле түгәрәгенә йөрделәр. Гомумән, артист һәм дикторларның гына түгел, радиодан чыгыш ясаган һәр кешенең сөйләм теле сафлыгына, мәгънәви һәм эмоциональ яктан төгәллегенә ирешү таләп ителә иде.

Баштагы елларда ук, сирәгрәк булса да, студиядән тыш, трансляция юлы белән бирелә торган тапшырулар да оештырыла башлады. Бәйрәм көннәрендә Ирек мәйданыннан, театр һәм цирк биналарыннан олы вакыйгаларга бәйле митинг һәм тантаналы кичәләр трансляцияләнә иде.

Техниканың җитешеп бетмәве аркасында булса кирәк, дикторлар трансляция башланыр алдыннан халык алдына чыгып, сәхнәгә куелган микрофон[1] аша тапшыруның кайдан һәм нинди уңай белән бирелүен игълан итәләр. Мәсәлән, минем үземә дә мәйдандагы трибунага менеп, янсә залда президиум каршына басып, андый тапшыруларны башлап җибәрергә туры килгәләде. Табигый ки, мондый шартларга күнекмәгән дикторлар яхшы ук дулкынланалар һәм тапшыру хакындагы биш-алты җөмләдән торган белдерүне каушый-каушый әйтеп биргәнче тирләп-пешеп беталәр.

Баштарак дикторларга җанлы шаһит булып та йөрергә туры килгәләде. Аеруча авыл җирләрендә радиога бер могҗиза итеп карадылар. Аңлату эшләре алып бару өчен без еш кына авылларга чыга идек. «Менә радиодан сөйләүче кыз белән егет шушылар инде», — дип безне халык алдына бастырып, радиодагы тесле сөйләтеп карыйлар, төрле сораулар бирәләр. Мондый очрашулар гадәттә концертлар бирү белән тәмамлана. Концертта Г. Сөләйманова, Я. Чамаев, оркестр музыкантлары Х. Әбүбәкеров, М. Ширинский, гармунчы Шәүлиханов һ. б. даими катнаша иде. Кайчакта исә үзебез Казанга авыл картларын ияртеп кайтабыз һәм аларны студиядән сөйләтәбез.

— ...Авылдашларым, бу мин, фәлән авыл кешесе фәлән фәләнов. Ишетәсезме? Мин, мин үзем сөйлим... Берәү дә сихерләмәде...— дип башлый агаебыз үзенең чыгышын.— Менә студия дигән йортта утырам... Теге Сәйдәш дигәннәре дә Сәйфуллин[2] тишкәләп ясаган калай түгел, ә зәңгәр күзле бик күркәм, мөлаем бер егет икән... Аннары үз авылларының кешеләре, беркадәр аларның эшләре турында сөйләп алгач: «Калганнарын кайткач бәйнә-бәйнә сөйләрмен. Иртәгә юлга чыгам»,— дип тәмамлый торган иде. Язу танымаганлыктан, мондый чыгышлар иркле була. Ара-тирә «Валлаһи менә...», «Ышанмасагыз, менә җир упсын...» кебек сүзләр янсә студия артистлары хакында: «Әркистр дигәннәре әргән түгел, ә бер төркем кешеләрдән торган уенчылар икән. Тик алларында колга озынлыгыдай берсе, киртәгә кунаклап җилпенгән әтәч кебек, таяк болгап тора...» шикелле каты гына гыйбарәләр дә ычкынып киткәли.

[1] Ул елларда микрофон кулда йөртү, теләсә кая кую өчен яраклаштырылмаган, бик авыр булып, сиртмә белән зур божра эченә беркетелеп куела иде.
[2] Г. Сәйфуллин — революциягә чаклы ук татар халык җырларын калай пластинкага язу өчен прибор уйлап чыгарган музыка мастеры.

Соңга таба сөйләү өчен чакырылган картлар белән бергә җырлый, нинди дә булса музыка коралында уйный белгән кешеләр дә килә башлады. Аларның радио тапшыруларны үз күзләре белән күрүләре, үзләренең дә катнашулары, җырлау-уйнаулары, якташларының боларны үз колаклары белән ишетүләре авыл халкы арасында яшәп килгән төрле шикләрне тиз арада юкка чыгарды.

Бу елларда дикторлар өстенә гаҗәеп күп вазифа йөкләтелә иде. Дәресрәге, диктор студиянең хуҗасы булды. Студия ачкычы диктор кулында һәм ул аның өчен җаваплы. Ни өчендер, әдәби-музыкаль тапшырулар өчен айлык акча подотчет төсендә ай башында ук баш дикторга бирелеп куела иде. Мондый тәртип ае-ае белән кыенлыклар да тудыра. Башкаручылар саны белән артык мавыгып китеп, айлык фондның егерме-егерме биш көн эчендә бетеп калган чаклары да була.

Радиотыңлаучылар концертына катнашучы (ул чакта әле үзешчән термины юк иде) һәм балалар тапшыруына килүчеләр өчен дә җаваплылык дикторлар өстенә йөкләтелде. Балалар тапшыруына чакырылган нәниләрне, аеруча көзге яңгырлы, кышкы салкын көннәрдә, озатып кую да безнең өстә була, тапшырулар исә, гадәттә, кичен бик соң тәмамлана иде.

Радиотапшыруларда катнашырга теләүчеләр (һәвәскәрләр) радио аша чакыру буенча җыелалар, кайбер көннәрдә уйнарга, җырларга килүчеләрне студия сыйдыра алмый. Шуның өстенә, башкарачак номерларын аккомпаниатор белән бер кат үтеп чыгу өчен зурлар да, балалар да студиягә өч-дүрт сәгать алдан килеп утыралар. Менә мондый көннәрдә дикторларга да, радионың башка хезмәткәрләренә дә арудалуны белмичә эшләргә туры килә. Шушы радиотыңлаучылар концертларында катнашучылар арасыннан Разия Тимерханова, Рокыя Бәхтиева, Фәвия Хәсәнова, Гайшә Камаева, Рәйханә Измайлова, Суфия Әхмәдуллина, Зифа Халикова, Вәли Шакировлар соңрак профессиональ җырчылар булып үсеп киттеләр. Кайберәүләре студия штатына алынып, радиода озак еллар эшләделәр дә. Татар сәнгатенең төп көчләре Мәскәүдә укыган елларда радиодан бирелгән яисә авыл, Казан клубларында оештырылган концертлар һәвәскәрлектән күтәрелгән шушы җырчылар катнашында алып барыла иде.

Утызынчы елларда дикторлар өстенә тагы бер эш йөкләнә. Татар телендә иртәнге гимнастика тапшырулары кертелә. Без исә, бик тырышып, демонстратор вазифасын үтибез, төнге уникеләргә хәтле сузылган кичке тапшырулардан соң, тагы таңнан торып, студиягә чабабыз. Физкультурник булып китмәсәк тә, мондый күнегүләрнең файдасы тигәндер дип уйлыйм.

Егерменче еллар уртасында эстрада эше үзәкләштерелмәгән иде әле. Радио эшли башлау белән филармония функциясе, ничектер, үзеннән-үзе радио һәм татар театры артистлары (аеруча Мохтар Мутин) өстенә «йөкләтелде». Шулай итеп, ГОМЕЦның (музыка, эстрада һәм цирк предприятиеләренең дәүләт берләшмәсе) Казан бүлеге оешканчы, шәһәр һәм шәһәрдән тыш бирелгән һәр концерт диярлек асылда радиостудия, рус һәм татар театрлары тарафыннан оештырылды. Завод-фабрика һәм зур предприятиеләр генә түгел, ун-егерме кешелек штаты булган кечкенә учреждениеләрнең дә һәр тантанасы концертсыз узмый иде. Ә инде зур бәйрәм көннәрендә шәһәр эчендә генә көненә утызар-кырыгар концерт бирелгән чаклар да булды. Искиткеч киң колачлы эш иде бу.

Утызынчы еллар башыннан алып, радионың эш мәйданы үсә, эшчәнлеге киңәя. Штатка яңа әдәби хезмәткәрләр, корреспондентлар өстәлә. Студиягә әдәби тапшырулар редакторы булып Хәсән Туфан килә. Башка бүлекләрдә Хәсни Кәрим, Габдрахман Теләш, Сәгыйть Каратайлар кебек шул дәвернең әдип һәм журналистлары эшли. Җырчылар составы да яңа исемнәр белән байый. Штатка такмазачы ике артист: Фәйзи Ковалинский һәм аның кызы Роза Юнысовалар алына. Гомумән, ул елларда ачык сәхнә һәм радио аша бирелгән концертларның берсе дә куплетчылар катнашыннан башка узмады диярлек. Цирк программасында да татар куплетчылары бар иде. Татар театр техникумын тәмамлап, циркта Фәйзи Йосыпов белән Кәрим Морзахановлар эшли башлады. Радио аша бирелгән көндезге концертларга да аларны еш чакыралар иде.

Артистлардан махсус коллектив туплап, татар драма тапшырулары бүлеге оештыру радио тормышында зур вакыйга булды. Бу яңа коллективны берникадәр вакыт

Ташкенттан кайткан күренекле артист, «Сәйяр» труппасы эшлекләреннән берсе Габдулла Камал (Камал I) җитәкли. Труппага Фәттах Латыйпов, Зәйнәп Хәсәенова, Зәйнәп Камалова, Гыйлаҗ Казанский һ. б. килә. Әдәби-драматик тапшыруларда кече формадагы әсәрләр, нәни инсценировкалар, интермедияләр зур урын ала. Драма бүлеге бик актив эшли башлый. Премьералар бер-бер артлы чыгып кына тора. Кайбер спектакльләр көн эчендә икешәр, өчәр тапкыр кабатлана. Аеруча дини бәйрәм көннәрендә труппа шулай өлгер һәм җитез эшли, дини йолалар тәэсиреннән халыкны арындыру юлында көчен кызганмый. Йортлардагы «тарелкалар» белән генә чикләнмичә, татарлар яшәгән урамнардагы баганаларга зур рупорлар элenә һәм төн ката спектакльләр уйналып, концертлар бирелеп тора. Антракт вакытларында шагыйрьләр үзләренең атеистик әсәрләрен укыйлар...

Драма труппасы зур күләмле әсәрләргә дә кыю алына, татар һәм рус язучыларының әсәрләре буенча әзерләнгән инсценировкалар уйнала башлый. Радиоспектакльләрне куюда Вәлиев-Сульва, Мохтар Мутин да актив катнашалар. Академия театры артистлары белән бергә, бу спектакльләргә эшче яшьләр театры артистлары да чакырыла. Шул ук чорда әлеге театрдан берничә кеше радио труппасына даими эшкә килә.

Режиссер Габдулла Камал гаҗәеп сабыр табигатьле, тыйнак кеше иде. Репетиция вакытларында да, көндәлек тормышта да аның тавышын күтәреп сөйләшкәнен ишеткәнем булмады. Ул һичкайчан ачуланмый, кычкырмый, башкаручыдан нәрсә теләгәнен җайлап кына аңлатып бирә. Гомумән, ул олы йөрәкле, үз эшен сөючә, чын мәгънәсендә зыялы кеше иде. Ул һичкайчан вакыт белән исәпләшмәде — көн дими, төн дими — эше бетмичә, студиядән китми торган иде.

Режиссер сыйфатында күп кенә радиоспектакльләр куйган М. Мутин да эшенә һәр вакыт җаваплы карый һәм кечкенә генә детальне дә җиренә җиткереп эшләргә ярата. Ул белемле һәм көчле фантазиягә ия булган режиссер иде. Тик аның характерындагы кырыслыкны кайбер артистлар аңлап бетерә алмый. Әмма эш өчен күңелдән килеп чыккан кырыслык иде ул. Бер генә мисал. Алда әйтелгәнчә, бәйрәмнәр алдыннан тапшырыла торган Партия өндәмәләрен микрофонга әзерләү өчен М. Мутинны чакыралар. Бер караганда, әллә ни кыенлыгы да юк шикелле: текстны алдың, тиешле урыннарына басым ясап, пафос белән укыдың да чыктың. Алай түгел икән. Өндәмәләр укуга Мутин иҗат эше итеп карый һәм үзендә зур җаваплылык сизә. Менә студиядә артистлар белән репетиция бара. Мутин башта күрсәтмәләр бирә, фикерләрен әйтә, аңлата. Бер артист белән бик озак утыра, кат-кат укытып караганнан соң:

— Текстта сүз уңышлар турында бара... Димәк, шатлыклы тонда әйтелергә тиеш, ә синең тавышыңда шатлык сизелми, — ди.

Артист тагын укып күрсәтә. Мутин тагын канәгать түгел.

— Үз илең, үз халкың белән горурлану хисе җитешми...

Тагын укыла, тагын шул ук хәл.

— Тантана... тантана юк...

Аның шулай аяусыз булуын, туры һәм каты әйтүен кайбер артистлар җиңел кабул итә алмыйлар, усаллык дип тә саныйлар иде. Әмма артистларыбыз өчен М. Мутин нәфис укуда үзенә бер мәктәп булды.

Хәсән Туфанның радиода эшли башлавы әдәби тапшыруларны җанландырып җибәрә. Микрофонга язучыларны тарту һәм алар катнашында булган тапшырулар ешая башлый. һ. Такташ, К. Нәҗми, Г. Кутуй, М. Җәлил, Ф. Кәримнәр радиотыңлаучыларны үзләренең яңа әсәрләре белән әледән-әле таныштырып торалар. Ә Кави Нәҗминең кайбер хикәяләре сәхнәләштерелеп, радиопостановка итеп уйнала. Студия артистлары көче белән оештырылган ачык концертларда Фатих Кәрим үз шигырьләрен укый. Хәсән ага Туфан әдәбиятка яңа аяк баскан яшь һәм тәҗрибәсез шагыйрьләргә аеруча зур игътибар бирә. Мәсәлән, әдәбиятка станоктан килгән Мөхәммәт Садри белән Галимҗан Мөхәммәтшиннарга ул даими рәвештә ярдәм итә.

Казан радиосы эшли башлаган елларда, шагыйрьләрнең уку-сөйләү осталыкларын үстерүне күздә тотып, студиядә «Нәфис сүз түгәрәге» оештырыла. Аның инициаторлары Кәшифә ханым Тумашева белән Гадел Кутуй була. Педагоглар итеп татар сәх-

нәсенең М. Мутин, З. Солтанов, Б. Тарханов кебек олы осталары чакырыла. Түгәрәк утырышларында шагыйрьләр радиодан укыячак әсәрләрен әзерлиләр. Монда Ф. Кәрим аеруча өлгерлек күрсәтә, сөйләү осталыгы серләренә тиз төшенә иде.

Трибун шагыйрь Һади Такташның радиодан үз әсәрләрен укуы онытылмаслык тәэсир калдырган. Шулай бер көнне, эштән соң Хәсән ага Туфан белән театрга таба бара идек. Ленин бакчасына җиткәндә, Һ. Такташны очраттык. Ул безгә үзенең «Киләчәккә хатлар»ын язып бетерүен әйтүе булды, Хәсән Туфан:

— Әйдә, әйдә студиягә. Яңа әсәрне радиотыңлаучылар беренче тапкыр авторның үз авызыннан ишетсеннәр, — дип кыстый башлады. Такташ абыебыз да озак ялындырып тормады. Киттек. Радиостудиягә килеп җитәрәк, урамның икенче ягында Вәлиев-Сульва белән С. Сәйдәшев күренде. Алар баш селкеп кенә безнең белән исәнләштеләр. Менә шунда Һади Такташ Хәсән абыйга карап:

— Берсе — татар музыка тәсбихының бисмилласы, икенчесе — театрыбыздагы искелекне дер селкетеп алган тугыз балл көчлелегендәге дулкын,— дип куйды.

Студиягә кереп, икенче катка менү белән Хәсән Туфан аппаратныйга юнәлде, Һади абый белән мин, студиягә кереп, «микрофон включен» диган яшел утның януын түземсезләнеп көтә башладык. Менә ут янды. Микрофонны ачып Такташка сүз бирдем. Ул бик нык рухланып, поэмасын очына-очына яттан сөйләп китте.

Радиостудия эшендә утызынчы елларда ук яңа жанр барлыкка килә. Аның тууы Һ. Такташ үлеме белән бәйле.

Һ. Такташ үлгәч, аны күмү көннәрендә эфир беренче тапкыр траур төсен алды. Шагыйрьнең үлеме турындагы хөкүмәт белдерүләре, некролог, мәрхүмнең үз шигырьләре, каләмдәш дусларының чыгышлары симфоник оркестрда башкарылган матәм көйләре астында барды һәм өч көн буена кабатланып торылды.

Бу тапшыруларның йогынтысы көчле булды. Алар шагыйрьнең якты образын, ялкынлы иҗатын, халыкның аңа мәхәббәтен тирәнрәк тоярга ярдәм итәләр төсле иде. Музыканы текстка ялгау, сүзнең хиссият көчен арттыру әнә шуннан соң, даими кулланылып, гадәткә кереп китте, әдәби-музыкаль тапшырулар жанры формалашты. Беренчеләрдән булып, Хәсни Кәримнең бер нәсере, музыкага салынып, оратория рәвешендәрәк радио аша тапшырылды. Ул әсәр, симфоник оркестр катнашлыгында, ачык концертларда эстрададан да берничә тапкыр башкарылды. Тамашачылар бу яңа жанрны бик җылы каршыладылар.

...Кыска гына истәлектә барысы хакында да сөйләп бетереп булмый, әлбәттә. Йомгаклап шуны әйтергә кирәк: радиостудиянең барлык хезмәткәрләре — редакторлары, әдәби хезмәткәрләре, хәбәрчеләре, режиссерлары, артистлары, җырчылары, музыкантлары һәм техниклары да — халыкны тәрбияләүдә партиянең турылыклы һәм тырыш ярдәмчеләре булдылар.

Казан радиосы беренче көненнән үк партия сүзен халыкка җиткерде, чор белән бергә атлады, бергә сулыш алды. Шуңа күрә дә культурабызны үстерүдә, иҗтимагый тормышыбызны яңа нигезгә коруда, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә ул гаять зур роль уйнады һәм уйный.

◆ ◆ ◆

# ӘДӘБИЯТЛАР ДУСЛЫГЫ — ХАЛЫКЛАР ДУСЛЫГЫ

## ДУСЛЫК ЭЗЛӘРЕ

Безнең көннәрдә милли әдәбиятларның үзара бәйләнеше моңарчы беркайчан булмаганча актив төс алды. Бу процессның шулай үсеп, көчәеп китүендә төрле милләт язучылары арасындагы элемтәләр һәм мөнәсәбәтләр дә мөһим роль уйный. Билгеле, язучылар арасындагы иҗади мөнәсәбәтләр күп төрле. Без укучы игътибарын әлеге зур мәсьәләнең бер генә ягына — төрле әдәбиятларның шагыйрьләре, тәрҗемәчеләре һәм редакторлары арасындагы иҗади дуслыкка юнәлтмәкче булабыз.

Безнең илдәге һәр милли язучы бөтенсоюз аренасына, кагыйдә буларак, бөек рус теле аша чыга. Моны үзебезнең татар әдәбияты мисалында да бик ачык күрергә мөмкин. Габдулла Тукай шигырьләрен рус укучысына башлап П. Радимов, ә Һади Такташ поэзиясен Л. Мартынов кебек шагыйрьләр җиткерде. Муса Җәлилне А. Миних, А. Шпирт, Э. Багрицкий, С. Липкин һәм башка бик күп шагыйрьләр тәрҗемә итте. Әхмәт Ерикәйнең М. Твардовский, С. Липкин, А. Миних, П. Шубин кебек шагыйрьләр белән иҗади хезмәттәшлек итүе билгеле.

Татар шагыйрьләренең әсәрләрен русчага тәрҗемә итү эшенә күренекле совет шагыйрьләре Сергей Александрович Обрадович белән Михаил Васильевич Исаковский аеруча күп өлеш кerтkәннәр. Бу мәкаләдә сүз аларның татар әдипләре, аерым алганда, Әхмәт Фәйзи белән иҗади элемтәләре хакында барачак.

С. А. Обрадович «Кузница»ның күренекле шагыйре, аны оештыручыларның берсе була. Заманында пролетариат әдәбияты ташкынында кайнаган революционер, «Правда» газетасының әдәби хезмәткәре С. А. Обрадович татар әдәбиятын рус укучылары арасында пропагандалауда күп көч куйган. Аның татар әдипләреннән Ә. Фәйзи, Ә. Ерикәй, башкорт шагыйрьләреннән М. Кәрим, Г. Рамазановлар белән алышкан хатлары шул хакта сөйли. С. Липкин, С. Маршак, П. Антокольский, В. Державин, А. Ахматова, Р. Моран, А. Минихлар белән бергә, С. А. Обрадович татар әдәбиятының олы дусты, якын киңәшчесе була. Ә. Фәйзинең рус телендәге җыентыклары С. Обрадовичның «җиңел кулы» аша дөнья күрә. Ул аның 1947 елда «Советский писатель» нәшриятында чыккан «Шигырьләр» китабын редакцияли, «Дулкыннар ни сөйли» җыентыгын чыгаруда ярдәм итә.

Үзара актив хезмәттәшлек ике шагыйрьнең дә иҗат юлында эзсез калмаган. Ә. Фәйзи белән иҗади дуслык нәтиҗәсендә С. Обрадович татар әдәбияты белән шактый якыннан танышкан: эчке рецензияләрдә, чыгышларда һәм хатлардагы бәяләре, фикерләре шуны күрсәтә. Ул Бөек Ватан сугышы фронтларында тормыш сынавы узган шагыйрьләр иҗатын аеруча зур игътибар белән күзәткән. М. Җәлил, Ә. Фәйзи, Г. Кутуй, С. Баттал, Ә. Ерикәй, Ф. Кәрим, Ш. Маннур, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗиевларның шигырьләре белән танышкач («Тормыш хакына», 1941—1944 ел)[1], С. А. Обрадович: «Сугышка кадәрге чор белән чагыштырганда, татар шагыйрьләренең бүгенге әсәрләре конкретрак, реальрәк, тормышчанрак төс алды», — дигән нәтиҗә ясый.

Ә. Фәйзинең «Дулкыннар ни сөйли» китабына язган эчке рецензиясендә С. А. Обрадович аны «оригиналь һәм олы шагыйрьләрнең берсе» дип атый, шигырьләренең конкрет характерда һәм эчтәлекле булуын басым ясап әйтә.

---

[1] Әдәбият һәм сәнгать үзәк дәүләт архивы, 1874 фонд, I тасвирлама, 137 саклану берәмлеге, 21—22 битләр.

Шул ук вакытта ул милли әдәбият вәкилләренә карата ифрат таләпчән дә була. Ә. Фәйзигә чыгачак китабына кайсы шигырьләрне кертү отышлырак булуы турында тагын бер кат ныклап уйларга киңәш итә. Татар шагыйре аның киңәшләре белән һәрчак исәпләшә торган булган. «Иптәш Обрадовичның рецензиясен укыганнан соң, мин кульязманы кабаттан төзедем, яңа шигырьләр белән тулыландырдым, кайбер үзгәртүләр керттем»,— ди ул 1945 елның 14 ноябрендә нәшриятка язган хатында [1].

Ф. Кәримнең фронт лирикасын С. А. Обрадович Иделдән алып Пруссиягә кадәр фашизмга каршы авыр көрәш юлы үткән шагыйрьнең шигъри көндәлеге дип бәяли, аның фикеренчә, Ф. Кәрим шигырьләре үз илен өзелеп яраткан шагыйрь йөрәген һәм рухын ачып салалар, укучыны фронтовик шагыйрьнең хис һәм фикерләр дөньясына алып керәләр [2]. С. А. Обрадович аның «Иптәш», «Мин — гуманист», «Окоп», «Сөйләр сүзләр бик күп алар» h. б. шигырьләренә аеруча югары бәя бирә. Шәхеснең хисләрен сурәтләүдә тулы канлы җанлы сүзләр табып, Ф. Кәрим нәкъ менә сугыш елларында үзенә генә хас шигъри аһәңгә ия шагыйрь булып җитте, ди.

Ул татар шагыйрьләренең күп кенә китапларына рецензияләр яза. Аерым алганда, татар совет поэзиясе җыентыгына язган эчке рецензиясендә (1917—1945 еллар) Шәйхи Маннур белән Нәкый Исәнбәт әсәрләренең милли колоритына югары бәя бирә, М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Н. Баян, С. Хәким, Ә. Исхак шигырьләрен карап чыкканнан соң, бик хаклы рәвештә, «татар поэзиясенең умыртка сөяге бар» [3], дип билгеләп үтә.

Югарыда китерелгән аз гына мисаллар да С. А. Обрадовичның татар поэзиясе белән тыгыз элемтәдә булуын ачык күрсәтә. Ул чын мәгънәсендә безнең язучыларның дусты һәм остазы булган.

Михаил Васильевич Исаковский, бөтен дөньяга танылган шагыйрь булу белән бергә, башка милләт әдипләренең әсәрләрен рус укучыларына җиткерү буенча шулай ук зур эш башкарган кеше иде. П. Тычина, М. Бажан, М. Рыльский, П. Бровка, Я. Купала, Я. Колас кебек шагыйрьләрне рус теленә башлап ул тәрҗемә итә. Аның болгар, немец, кытай телләреннән генә түгел, ә татар, чуваш, белорус, әзербәйҗан, латыш һәм башка телләрдән тәрҗемәләре дә киң катлау укучыларга яхшы таныш.

М. В. Исаковскийны татар әдәбияты белән күптәнге дуслык җепләре бәйли иде. Бер яктан, «Катюша» авторының шигырьләре үз вакытында «Кызыл Татарстан» («Социалистик Татарстан») һәм «Яшь сталинчы» («Татарстан яшьләре») газеталарында, «Совет әдәбияты» («Казан утлары») һәм «Пионер каләме» («Ялкын») журналларында бик еш басылып килде. 1955 елда Татарстан китап нәшрияты М. Исаковский шигырьләрен аерым җыентык итеп тә чыгарды. Ә. Исхак, М. Садри, Ә. Фәйзи, З. Нури, Г. Хуҗи, М. Хөсәен кебек шагыйрьләр аның иҗатын татар укучыларына җиткерү эшенә зур көч куйлар.

Икенче яктан, тәрҗемәче буларак, М. Исаковский үзе дә татар шагыйрьләрен рус телендә чыгаруда күп ярдәм күрсәткән. Ул 1955 елда «Совет Татарстаны поэзиясе» исемле җыентыкны, 1957 елда «Татар поэзиясе антологиясе»н русча чыгару эшенә якыннан торып булышкан. Архив материаллары, аерым алганда, шагыйрьнең Ә. Фәйзи, М. Садри, Ә. Ерикәй, А. Шамовлар белән хат алышуы әнә шул турыда сөйли.

Әдәбият һәм сәнгать үзәк дәүләт архивында саклана торган документлар белән танышканда мин М. В. Исаковскийның Әхмәт Фәйзигә язган кызыклы бер хатына юлыктым. (1373 фонд, 8 тасвирлама, 179 саклану берәмлеге, 1 — 2 битләр.) Ул тәрҗемә мәсьәләләренә, аерым алганда, һади Такташ әсәрләрен тәрҗемә итүгә кагыла. Шул уңайдан шигырь һәм җырлар, шулай ук тәрҗемәләр остасы булган М. В. Исаковский h. Такташ иҗаты хакында кызыклы һәм әһәмиятле фикерләр әйтә.

Архив фондларында татар һәм рус әдипләренең иҗади элемтәләре хакында материаллар күп очрый. Талантлы шагыйрь Михаил Светлов, мәсәлән, Ә. Фәйзинең иң әйбәт әсәрләреннән берсе булган «Флейталар»га берничә тапкыр мөрәҗәгать иткән.

---

[1] Шунда ук, 442 саклану берәмлеге, 1 бит.
[2] Шунда ук, 377 саклану берәмлеге, 17 бит.
[3] Шунда ук, 137 саклану берәмлеге, 1—8 битләр.

Атаклы «Гренада» әсәренең авторы татар шагыйренең иҗатына югары бәя бирә һәм «Флейталар»ны тәрҗемә итү өстендә зур канәгатьлек хисе тоеп эшли.

Архивта шагыйрь һәм тәрҗемәче Павел Шубин белән Әхмәт Ерикәй, Әхмәт Исхак һ. б. татар шагыйрьләренең иҗади дуслыгына кагылышлы материаллар саклана.

Безнең уебызча, бу материаллар совет власте елларында рус һәм татар шагыйрьләре арасында әдәби мөнәсәбәтләр күп яклы һәм нәтиҗәле булган дигән фикерне раслыйлар.

**Николай МУРАДЫМОВ.**



## Ә. Фәйзинең С. А. Обрадовичка хаты

*3 апрель, 1947 ел, Казан.*

**Кадерле Сергей Александрович!**

**Биш шигыремнең юлга-юл тәрҗемәсен җибәрәм. Ярасалар, тәрҗемә итеп, җыентыкка яки антологиягә кертегез.**

**«Флейталар»ны [1] тәрҗемә итмәдем әле, антологиягә калдырдым. Җыентыкның бөтен исеме турында гел уйлап йөрим, ләкин күңелгә ошардаен таба алганым юк. Бәлки Сез ярдәм итәрсез? [2].**

**Хәзер мин Казанда чыгачак бер томлык җыентыгым [3] өстендә эшлим, аны бу көннәрдә производствога тапшыралар. Бөтен тоткарлык сүз башында гына. Ул миңа тагын бер кат карап чыгу өчен кире кайтарылган иде.**

**Хәзер монда чын-чынлап яз, кояш, гөрләвекләр...**

**Май башында Мәскәүгә кайтырга уйлыйм.**

**Сәлам белән Әхмәт Фәйзи [4].**

**Хатыныгызга сәлам.**

---

[1] «Флейталар» — Ә. Фәйзинең зур күләмле поэмасы. Рус теленә М. Светлов тарафыннан тәрҗемә ителгән.

[2] 1947 елда Мәскәүдә С. Обрадович редакциясендә чыккан «Шигырьләр» җыентыгы күздә тотыла.

[3] Шагыйрь 1947 елда Казанда чыккан «Шигырьләр» җыентыгы турында сүз алып бара.

[4] Хатның төп нөсхәсе Әдәбият һәм сәнгать үзәк дәүләт архивында саклана. (1874 фонд, 1 тасвирлама, 442 саклану берәмлеге, 3 бит.)

## М. Исаковскийның Әхмәт Фәйзигә хаты

*21 июль, 1952 ел, Внуково.*

**Кадерле Фәйзи иптәш!**

**Узган кыш татар язучылары белән сөйләшкәндә мин, чыннан да, татар әдәбияты классигы Һ. Такташның бер поэмасын тәрҗемә итәргә ризалык биргән идем.**

**Әмма, әгәр шулай әйтергә яраса, бу минем катгый ризалыгым түгел иде, чөнки, оятыма каршы, ул чагында мин Такташның бер әсәрен дә белми идем. Шуңа күрә аны тәрҗемә итә аламмы-юкмы икәнлеген дә төгәен генә хәл итә алмадым. Моңа тагын шул кадәресен дә өстәргә кирәк, бик кыска бер яки ике шигырь тәрҗемәсен искә алмаганда, минем беркайчан да татар теленнән тәрҗемә иткәнем булмады һәм шуңа да бу телгә, аның үзенчәлекләренә һ. б. өр-яңадан «ияләнергә» кирәк булыр иде.**

Кыскасы, күңелне бу мәсьәләдә Сезгә файдалы була алырмынмы-юкмы дигән шик-шөбһәләр биләп алды.

Әмма татар иптәшләр мине, бернинди дә кыенлыклар очрамас, бөтенесе дә яхшы булыр, дип ышандырдылар. Һәм мин ризалык биргән идем.

Берничә көн элек Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасының юлга-юл тәрҗемәсен алдым. Аны игътибар белән укып чыктым һәм Такташта булган әйберләрне канәгатьләнерлек дәрәҗәдә рус телендә бирә алмаячакмын, дигән нәтиҗәгә килдем.

Билгеле булганча, тәрҗемә ителә торган шагыйрь үзен тәрҗемә итүче шагыйрь белән күпмедер дәрәҗәдә аһәңдәш булсалар гына тәрҗемә әйбәт килеп чыга.

Такташ шигырьләре исә нинди дер бөтенләй үзенчәлекле планда язылган. Бу алар тиешле дәрәҗәдә әйбәт язылмаган дигән сүз түгел, билгеле. Киресенчә, алар бик әйбәтләр. Ләкин алардагы язу манерасы, образлар системасы, шагыйрь буларак, миңа аһәңдәш түгел һәм шуңа күрә мин аларны рус телендә бирә алмамын шикелле.

Мәсәлән, поэмага керешне (мәхәббәт, яшьлек һ. б. турында уйлануларны) алыгыз. Ихтимал, бу бик яхшы һәм көчле өзектер. Ләкин бөтен өзек уйлануларга корылган һәм анда конкрет бер хикәя, вакыйга юк, шуңа күрә аны тәрҗемә итү миңа бик кыен булыр иде. Минем иҗат манерама исә асылда гел конкрет детальләргә корылган хикәяләү стиле хас. Әгәр мин бу өзекне тәрҗемә итәргә тотынсам, ул, мөгаен, минем тәрҗемәмдә кызыксыз, хәтта әчпошыргыч булып чыгар иде.

Бер сүз белән әйткәндә, минем начар тәрҗемә белән әйбәт әсәрләрне бозасым килми. Татарчадан тәрҗемә итү эшендә Такташ кебек шагыйрьнең әсәрләре өстендә өйрәнергә, аның өстендә экспериментлар үткәрергә ярамый. Аны я бик әйбәт тәрҗемә итәргә, яисә бөтенләй тәрҗемә итмәскә кирәк.

Югарыда санап үткән сәбәпләр аркасында, аны әйбәт тәрҗемә итүемә ышанмагач, бу эштән бөтенләй баш тарту күп тапкыр намуслырак булыр дип уйлыйм. Минем бүтән чарам юк.

Шулай уңайсыз килеп чыккан өчен Сездән гафу итүегезне үтенәм. Ләкин, чынлап әйтәм, мин бүтәнчә булдыра алмыйм.

СӘЛАМ БЕЛӘН М. ИСАКОВСКИЙ.

**Солтанморат Акбиев,**
филология фәннәре кандидаты

# ТАТАР МӘГЪРИФӘТЧЕСЕ ТАУЛАР ИЛЕНДӘ

*Тормышта һәркемнең үзе сайлап алган төп эше, төп һөнәре була. Әмма күп кенә кешеләр шуның өстәвенә күңел өчен, җан азыгы өчен башкара торган нинди дә булса тагын берәр шөгыль белән мавыгалар. Әйтик, берәүләр борынгы таңкалар җыя, берәүләр корган агач тамырларыннан, төн йокыларын калдырып, төрле сыннар юна, икенче берәүләр җыр чыгара, шигырь яза.*

*Ә мин үз халкымның культура мирасын — борынгы кулъязмалар, иске китаплар, фоторәсемнәр җыям, төпченеп өйрәнәм, бер-берсе белән чагыштырам, төрле кешеләрдән, бигрәк тә картлардан сораштырып, аларның тарихын ачыкларга тырышам.*

*Менә еллар узу белән саргаеп, чит-читләре телгәләнеп беткән, кызганычка каршы, аны журнал битендә инде күрсәтү мөмкин булмаган бер фоторәсем. Алгы рәтләрдә, кумык халкының милли киемендә, иңне иңгә терәп утырган кырык җиде малай, алардан арттарак шактый өлкән яшьләрдәге үндүрт ир.*

*Элегрәк күрелгән фоторәсемнәр буенча бу кешеләр арасыннан күбесе миңа таныш. Һәм күбесенең тормыш юлы да шактый билгеле.*

*Иң арткы рәттә уң яктан беренче булып басып торган кеше — кумык халкының танылган әдибе Нухай Батырморзаев, алдагы рәттә, иң уртада, китабын күкрәгенә кысып утырган түм-түгәрәк йөзле малай — гражданнар сугышы герое, атаклы язучы Зәйнелгабид Батырморзаев... Бу кешеләр арасында күренекле шагыйрьләр, мәгърифәтчеләр, Дагстанның культура һәм дәүләт эшлеклеләре.*

*Ләкин биредә миңа аларның әлегә таныш булмаганнары да бар. Әйтик, әнә арттагы рәтнең үзәгендә, кулына газета тотып басып торучы кечерәк буйлы, ир урталарындагы берәү. Нәкъ шушы фоторәсем миңа кумык һәм татар халыклары арасындагы тагын бер дуслык җебен ачыкларга ярдәм итте.*

Татар һәм кумык халыклары борын-борын заманнардан ук тарихи элемтәдә булган, күп гасырлардан бирле бер-берсе белән уртак тел табып, Тукай әйтмешли, тел, логать вә әхлак алмашып яшәгән.

Кумык далалары аша Болгар җиренә, аннары Казан ханлыгына Дербенттан, Кубачидан, Әнджидән, Симәндәрдән кәрваннар агылган. Бизәкле паласлар, алтын-көмеш әйберләр, җиләк-җимеш төяп, Хазар диңгезе аша каеклар китеп торган. Болгар-татар җирләреннән исә алар ефәк, фарфор, бал төяп, һәм Дагстан халкы өчен аеруча зур байлык — китаплар алып кайтканнар. Ул китаплар белән безгә, бөтен Россия халыклары, шул җөмләдән татар халкының да, культурасы, алдынгы рухы, мәгърифәтчелек идеяләре килгән. Кумык әдәбиятында, әлбәттә, бөтендөнья әдәбиятларыннан да өйрәнеп, яктылыкка, ирекккә, көрәшкә омтылу агымы формалашкан. Кумык халкының мондый туганлык, дуслык элемтәләре соңра Дагстан әдипләренең әсәрләрендә дә бик ачык чагылган.

Әйтик, Нухай Батырморзаевның «Гарун һәм Зөбәйдә яки бәхетсез Җанбикә» повестенда төп образларның берсе — Казан татары Гайнетдин. Ул — күп укыган,

күп сәяхәт иткән, күпне күргән галим кеше. Ул кыю, аек фикер йөртә, мәсьәлман динчеләренең ялганына ышанмый, — җае килгәндә аларны ачыктан-ачык тәнкыйтьли.

Гайнетдинне көнчыгышның ул чактагы бер культура үзәге булган Казан каласында да яхшы беләләр, хөрмәт итәләр. Аның дуслары арасында күп кенә әдипләр, мөхәррирләр, мәгърифәтче яшьләр бар. Гайнетдин кумык егете Гарунны үзенең дуслары белән таныштыра, аңа иҗтимагый тормышта үз юлын табарга булыша.

Әдәбият тарихында анык билгеле булганча, Гарун — автобиографик образ. Аңарда әдип үз тормышын, үз яшьлеген гәүдәләндерә. Димәк, әсәрдә ул Гарунга үрнәк итеп алынган татар егете Гайнетдиннең дә прототибы булырга тиештер, дигән фикер туа.

Күп кенә эзләнүләр Гайнетдиннең чын исеме Исхак булуын ачыклады. Әлеге фоторәсемдәге моңарчы таныш булмаган йөз белән Гайнетдин-Исхак образы тәңгәл килде.

«Гарун һәм Зөбәйдә...» повестен Нухай Батырморзаев үзенең туган авылы Аксайда иҗат иткән. Ул елларда Исхак та шунда тора. Кызганычка каршы, Исхакның туган елын да, фамилиясен дә белүче юк. Чөнки ул чорда кумыкларда, гомумән, кешене фамилия белән атау гадәткә кермәгән булган. Әтисе яки әнисе исеменә бәйләп, әйтик, Мөхәммәт улы Мәхмүт, Әмир улы Сәет, Әминат кызы Зөһрә дип, я булмаса, аның төп һөнәре буенча, оста Гомәр, арбачы Сабир, чарыкчы Вәли дип йөрткәннәр. Ә Исхакка халык, аның галим кеше булуын искә алып, хөрмәт белән Исхакәнәнде (Исхак әфәнде) дип дәшкән. Һәм бүгенге көнгә кадәр аның якты образы халык күңелендә шул исем белән сакланып килә.

Әлбәттә, Исхакка кадәр дә Аксайда белемле, мәгълүматлы кешеләр шактый булгандыр. Әмма зур хөрмәт билгесе дип саналган «әфәнде» кушаматын кумыклар теләсә кемгә бирмәгән. Андый кушамат бары тик үз хезмәте белән халыкка зур файда китергән, аның уй-фикерләрен аңлаган, кайгы-шатлыкларын уртаклашып яшәгән могтәбәр кешеләргә генә бирелгән.

Аксайга әллә кайдан, чит җирләрдән килеп урнашкан бу татар баласы ничек итеп халыкның шундый зур ышанычын казана алган соң? Нинди хезмәтләре белән ул халык теленә шулай озак елларга кереп калган?

XX гасырның башында Аксайда Габделваһап-Хаҗи исемле алдынгы карашлы бер сәүдәгәр яшәгән. Төрле йомышлар, сәүдә эшләре белән ул Казан якларына да еш барып чыга торган булган. Шулай бер баруында ул Казанда, үзенең элекке танышларында туктаган һәм аларга туган тиешле Исхак исемле егерме дүрт-егерме биш яшьләрдәге егет белән дуслашып киткән.

Бу егет күптән түгел генә ниндидер югары уку йортын тәмамлап кайткан һәм әлегә эшкә дә урнашып өлгермәгән икән. Габделваһапның үтенүе буенча, ул Дагстанга, Аксай авылына укытучы булып китәргә ризалаша.

Аксай авылы элек-электән Дагстанда кумыкларның зур культура үзәге булып исәпләнгән. Анда берничә мәдрәсә һәм дөньяви фәннәр укытыла торган мәктәпләр дә булган. Ул мәктәпләрдә Аксай балалары гына түгел, бәлки күп кенә тирә-юньь авыллардан да килеп укыганнар. Анда татар шагыйре Таҗетдин Ялчыгол да мөгаллимлек иткән.

XIX гасырның күренекле шагыйре Йосыф Аксаевский, Петербург университетында укыткан мәшһүр галим һәм шагыйрь Мөхәммәт әфәнде Солтанов биредә туып үскәннәр һәм башлангыч белемне шунда алганнар. Татар мәгърифәтчесе Хөсәен Фәезханов та озак еллар шушында хезмәт иткән. Үтеп барышлый Аксайда бөек рус язучысы М. Ю. Лермонтов, Л. Н. Толстой, декабрист шагыйрь А. А. Бестужев-Марлинский һәм башкалар тукталып киткәннәр. Әлеге фоторәсемдәге аталы-уллы Нухай һәм Зәйнелгабид Батырморзаевлар, Манай Аделбеков һәм Абдулла Мөхәммәтовлар шунда яшәп, шунда иҗат иткәннәр. Исхак та тау илендә үзенең зур традицияләре белән билгеле әнә шул авылга килеп урнашкан. Баштарак ул Габделваһап-Хаҗи йортында, аннары Сәетовларда торган. Соңра ике катлы кирпеч мәктәп салынган — шул бинаның икенче катында.

Әлбәттә, рус булмаган милләт балаларын укыту эшенә патша хөкүмәте бер тиен дә расход тотмаган. Барлык уку-укыту чыгымнарын, укытучыга хезмәт хакын, җан башыннан җыеп, авыл кешеләре үзләре түләгән. Авыл җыены Исхак әфәндегә һәр укучы өчен аена бер сум түләргә дигән карар чыгарган. Мәктәпне утын, лампа мае, су белән дә ата-аналар тәэмин иткән. Тормышта нинди генә кыенлыклар булмасын, балаларына аң-белем бирү мәсьәләсенә килгәндә бераү дә читтә калмаган.

Яшь укытучы үзенең беренче дәресләрендә үк шәкертләренең күңелен яулап ала. Кулыннан килгәнчә, ата-аналарга да ярдәм итәргә тырыша. Хат яздырасы буламы, гариза-фәлән белән түрәләр катына барасымы — һәркем Исхак әфәнде янына килгән. Һәм ул берәүне дә кире борып чыгармаган. Исхак әфәндfestival ишеге авыл кешеләренең карты-яше өчен һәрчак ачык булган.

Исхак әфәндегә карата аның элекке шәкертләреннән хәзер дә бик күп җылы сүзләр ишетергә мөмкин.

«Ул чак миңа әле сигез-ун яшьләр генә булгандыр, — дип сөйли, мәсәлән, Солтанәхмәт Сәетов. — Әтиемнең дуслары Нухай Батырморзаев, Манай Аделбеков, Исхак әфәнде һәм кайбер авылдашларыбыз кичләрен еш кына безгә җыелып утыралар иде. Әнием чәй куеп җибәрә, өстәл хәзерли. Аннары, безне, өлкәннәргә комачауламасыннар дип, кече якка алып чыгып китә. Ләкин кайчак мин, почмакка качып калып, аларның кызыклы әңгәмәләрен тыңлау бәхетенә ирешә торган идем».

Сәетовларда алар кайчак таңгача утыралар. Дөнья хәлләрен сөйләшәләр, китап, газета укыйлар, агач-хомуз дигән музыка коралына кушылып борынгы кумык җырлары җырлыйлар... «Мең дә бер кичә» әкиятләрен, «Таһир-Зөһрә», «Бүз егет», «Йосыф вә Зөләйха» кыйссаларын, Пугачев, Стенко Разин, Аманхура кебек халык юлбашчылары турында төрле легендаларны Солтанәхмәт беренче кат әнә шул кичәләрдә ишетә.

«Минемчә, безгә җыела торган бу кешеләрнең барысы да диярлек бер чама яшьләрдә иде,— дип яза Солтанәхмәт Сәетов.— Ә минем әти белән Исхак әфәнде яшьтәшләр үк булса кирәк».

Хәзергәчә сакланган кайбер кульязмаларга караганда, Солтанәхмәтнең әтисе 1879 нче елда туган. Димәк, Исхак әфәндегә дә шул чама булгандыр дип уйларга нигез бар. Солтанәхмәтнең әйтүенә караганда, Дагстанда кояш тотылган һәм ком яңгыры яуган елга кадәр (1912—13 еллар) Исхак әфәнде өйдәш булып аларда яшәгән. Шулай булгач, бу истәлекләрнең тарихи дөреслеге шик тудырмый.

Исхак әфәнде төрки телләрдә шигырь төзелешен бөтен нечкәлекләренә кадәр белә, үтемле мисаллар белән, матур әдәбиятта сурәтләү чараларының әһәмияте турында сөйли. Шуңа күрә әдәби иҗатка омтылуы, азмы-күпме сәләте булган һәр кеше үзенең беренче иҗат җимешен тотып аңа килә. «Без беркайчан да укытучыбызның киңәшләреннән чыкмый идек, — дип яза шагыйрь Моллаака Адилханов. — Өйгә кайткач, аның төзәтмәләрен искә алып, әсәрне кучереп яза һәм яңаларын иҗат итә идек». Шулай итеп, Исхак әфәнде үз укучыларында иҗади хезмәткә мәхәббәт хисе тәрбияли.

Яшь мөгаллим үзе дә күп укый, Казаннан, Оренбургтан, Мәскәү, Әстерхан, Петербург калаларыннан татарча газеталар һәм журналлар алдыра, ул шәһәрләрдәге иҗади интеллигенция белән хатлар алыша, элемтәдә тора. Каникуллар вакытында үзе дә баргалый.

Шулай бер баруында ул Казаннан өйләнеп, кәләш тә алып кайта. Туйларын Аксайда уздыралар. Аның кәләше — Камәр атлы Казан кызы, үз заманы өчен шактый белемле, мәгълүматлы яшьләрдән була. Тау иленә килү белән ул да укытучылык эшенә керешә. Ул кумык кызларын укырга, язарга өйрәтү белән генә чикләнми, аларга хезмәт күнекмәләре дә бирергә тырыша. Тегү-чигү, тәмле ашлар пешерү, авыруларга беренче ярдәм күрсәтү буенча аерым дәресләр уздыра. Дәрестән тыш Камәр укучыларына әкиятләр, хикәяләр сөйли, табышмаклар әйтә, мәктәп ишегалдында төрле уеннар оештыра, балаларга җил, яңгыр, яшен, салават күпере кебек табигать күренешләренең ничек барлыкка килүен аңлата...

Тагын бер укучысы — Дагстанның һәм РСФСРның атказанган культура эшлеклесе, шагыйрь һәм драматург Габделваһап Сөләйманов — Исхак әфәнденең Дагстанга килеп чыгуы мәсьәләсендә үзенчәрәк фикер йөртә:

«Минемчә, ул ниндидер революцион эшләрдә катнашканы өчен Казаннан сөрелгән кеше иде», — ди һәм, үзенең бу сүзләрен раслау өчен, шактый нигезле дәлилләр китерә. — Кайчак безнең мәктәпкә үзәктән түрәләр килеп төшә торган иде... Аларны тәрәзәдән күрүгә, Исхак әфәнде кушуы буенча, без әдәбият, тарих, химия дәреслекләрен тиз-тиз генә яшерәбез дә, коръән, ясин кебек дин китаплары алып утырабыз. Тегеләр китүгә яңадан үз эшебезгә тотынабыз... Исхак әфәнденең үзен дә еш кына каядыр чакырып алалар. Өлкәннәрдән ишетеп, без аның жандарм идарәсенә, «кыңгыр» эшләре өчен допроска киткәнен белеп торабыз».

Бу мәгърифәтченең революцион эшкә катнашуы турындагы фикерне раслый торган ныклы документлар әлегә табылмаса да, аны инкарь итәрлек дәлилләр дә юк. Чыннан да, XX йөз башында Казан студентлары, шәкертләр, укучы яшьләр революцион хәрәкәттә бик актив катнашалар. Үзенең бөтен уй-фикерләре, иҗади эшчәнлеге белән азатлыкка, яктылыкка омтылып торучы алдынгы карашлы Исхакның ул көрәштән читтә калуын күз алдына китерүе, әлбәттә, кыен.

Исхак әфәнденең Аксайдагы педагогик эшчәнлеге дә аның кыйбласы кайда икәнен бик ачык сөйли. Әйткәнебезчә, ул дин сабагына бармак аша карый. Әдәбият, тарих, география, математика, химия, физика кебек фәннәр укытуга нык игътибар итә. Болардан тыш ул укучыларга табигать белеме, төрки телләр, гарәп теле, юриспруденция, музыка буенча да башлангыч белем бирә. Кумык балаларын үз ана телләренә мәхәббәтле булырга, аларны халыкның милли культурасын, рухи байлыгын ныграк өйрәнергә, хөрмәт итәргә өнди.

Исхак әфәнденең хезмәт дәресләре дә искиткеч кызык һәм җанлы уза: укучыларга киләчәк тормыш өчен кирәкле күнекмәләрне күбрәк бирергә тырыша, халык тормышын, табигатьне, хезмәт күренешләрен тасвирлый торган хикәяләр укый. Андый әсәрләр дәреслекләрдә булмаса, үзе дә кечкенә-кечкенә хикәяләр иҗат итә.

Ул җәйдән үк төрле-төрле күргәзмә әсбаплар — плакатлар, карточкалар, схемалар әзерли. Казанга яки башка шәһәрләргә барганда глобуслар, карталар алып кайта. Класс стеналарында һәрчак алтын башаклы иген кырлары, зәңгәр диңгезләр, яшел урманнар, хезмәт күренешләре сурәтләнгән төсле рәсемнәр эленеп тора. Бу рәсемнәрне Исхак әфәнде, төрле журналлардан, иске китаплардан кисеп, үзе ябыштыра. Физкультура дәресләрендә йөгерү, сикерү ярышлары оештыра, хәрәкәтле уеннар уйната, укучыларның чисталыгын күзәтеп тора. Әти-әниләренең байлыгына, ярлылыгына карамыйча, барлык балаларга да бер үк төрле таләпләр куя.

Үз шәкертләрен ул аталарча чын күңелдән ярата. Аларны сәяхәтләргә, экскурсияләргә алып бара, төрле үсемлекләр, чәчәкләр, минераллар җыеп, гербарийлар оештыра. Һәм тормышта үзе дә яшьләр өчен пөхтәлек, тугрылык, намуслылык үрнәге була.

Исхак әфәнде мәктәбендә балалар җиде ел укыйлар. Класста, гадәттә, егерме-утыз укучы була. Арадан иң сәләтлеләрен сайлап, ул һәр чыгарылыштан дүрт-биш укучысын Әстерхан, Казан, Уфа, Оренбург шәһәрләрендәге уку йортларына озата. Мәктәпне тәмамлау турындагы таныклык белән бергә, аларга шул уку йортларына «тәкъдим» кәгазе дә бирә. Югарыда телгә алып кителгән З. Батырморзаев, А. Баширов, М. Адилханов кебекләр — заманында Исхак әфәндедән әнә шундый кәгазь алып, олы тормыш юлына чыккан кешеләр.

Исхак әфәнде өлкәннәр арасында да мәгърифәтчелек эшчәнлеген киң җәелдереп җибәрә. Аның шактый бай шәхси китапханәсендә Европа һәм көнчыгыш әдәбиятлары үрнәкләре, Мәскәүдә, Казан, Әстерхан, Уфа, Оренбург, Тифлис шәһәрләрендә чыга торган төрле-төрле газета-журналлар була. Ул үзенең бу алтын хәзинәсен бикләп сакламый, ә мөмкин кадәр күбрәк кешеләргә укытырга тырыша. Шунлыктан Аксайның алдынгы интеллигенциясе тиз арада аның тирәсенә туплана. Яңа чор кумык әдәбиятына нигез салучы Нухай Батырморзаев аның образын үз әсәре өчен прототип итеп алган икән, бу инде, әлбәттә, очраклы хәл түгел.

Исхак әфәнденең шәхси һәм иҗтимагый тормышын, аның карашларын тулырак күз алдына китерү өчен тагын бер вакыйгага игътибар итеп узарга кирәк.

Билгеле булганча, империалистик сугыш елларында ачлыктан, ялангачлыктан, милли һәм сәяси изүләрдән җәфа чиккән халык Россиянең төрле өлкәләрендә кө-

рәшкә күтәрелә башлый. 1916 елның җәендә Аксайда һәм аның тирәсендәге башка күп кенә авылларда восстаниеләр була: Дагстан крестьяннары үз балаларын империалистик сугышка җибәрергә теләмиләр. Чамасыз зур налоглар түләүдән һәм сугыш өчен атларын бирүдән баш тарталар.

Бу восстаниене бастыру өчен Аксайга өч рота солдат һәм казак сотнясы җибәрелә. Патша хөкүмәте баш күтәргән крестьяннардан ерткычларча үч ала. Күп кенә гаепсез кешеләр һәлак була, яралана, егерме ике кеше хәрби суд хөкеменә бирелә.

Аксай картларының сөйләвенчә, бу канлы вакыйгалар вакытында Исхак әфәнде һәм Камәр ханым халык белән бергә булганнар. Рус телен яхшы белгән Исхак әфәнде тикшерү вакытында күп кенә крестьяннарның гаепсез икәнлеген исбат иткән һәм аларны төрмәдән, каторгадан йолып калган.

Исхак әфәнде 1905 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр Аксай авылында яши. Аларның Мәхмүт исемле бер генә малайлары үсә. Әти-әнисе вафат булгач, авыл халкы малайны үз тәрбиясенә ала. Ләкин унике-ундүрт яшьләрендә ниндидер авырудан ул да үлеп китә.

Нәселе калмаган кешенең җирдә эзе калмый дип тә уйлыйлар. Әмма үз тормышын халыкка багышлаган бу мәгърифәтченең эзләре тау илендә тирән уелып калган. Агачны җимешенә карап бәялиләр бит. Кеше дә бары тик хезмәт җимешләре белән генә кадерле. Ә Исхак әфәнденең хезмәте Дагстан җирендә гаять мул җимеш биргән. Педагог һәм шагыйрь, кумык драматургиясенә нигез салучы Алимпаша Салаватов, шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе Баһау Астемиров, шагыйрь һәм рәссам Абдулла Бәширов, егерме ике яшендә деникинчылар атып үтергән герой, танылган әдип Зәйнелгабид Батырморзаевлар...

Үз халкының якты киләчәге өчен бөтен көчләрен һәм хәтта тормышларын биргән бу кешеләр заманында Исхак әфәндедән дә дәрес, иҗат итәргә, яшәргә, көрәшергә өйрәнгәннәр. Аның образы әдәбиятыбызга һәм халык күңеленә кереп калган. Бу язманың авторы да журналның кайбер укучыларыннан Исхак әфәнде турында өстәмә мәгълүматлар бәлки тагы килер дип өмет итә.

Торсын Каһһари

# УЙГУР—ТАТАР МӘДӘНИ БАГЛАНЫШЛАРЫ ТАРИХЫННАН

Мәгълүм булганча, Казан шәһәрендә XVIII йөзнең җитмешенче елларында ук шәрык телләрендә китаплар басыла башлый. «Казан басмасы» дигән исем белән мәшһүр булган бу китаплар Урта Азия халыклары, шул җөмләдән Шәркый Төркестандагы уйгурлар арасында да киң тарала. Бу хәл исә тирән тамырлы уйгур-татар мәдәни мөнәсәбәтләренең тагы да киңрәк колач җәюенә китерә.

Яңа чор татар әдипләреннән Каюм Насыйри, Мәҗит Гафури, Габдулла Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Дәрдмәнд, Сагыйт Рәмиев әсәрләре уйгурлар арасында киң таралып, аларның мәхәббәтен яулый. Үз чиратында, татар укымышлылары да уйгур әдәбиятының кайбер үрнәкләре белән Казан матбагасы ярдәмендә танышалар. Мәсәлән, 1880 елда Казанда рус ориенталисты Н. Н. Пантусов редакциясендә классик уйгур шагыйре Билал Назимның «Китаби газат дәр мелки Чин» («Кытай илендә мөселманнар сугышы») дигән поэмасы, ә 1905 елда исә атаклы уйгур тарихчысы Муса Сайраминың «Тарихы Әмания» исемле әсәре нәшер ителә. Шулай ук Казан университеты профессоры Н. Ф. Катанов җыйган уйгур фольклоры әсәрләре дә Казандагы гыйльми басмаларда дөнья күрәләр.

Октябрь революциясеннән соң Шәркый Төркестан халыкларының күп милләтле совет әдәбияты, җөмләдән Урта Азия халыклары һәм татар әдәбияты белән кызыксынулары аерата көчәя. Чөнки шул яңа әдәбият аша Россиядәге зур үзгәрешләр, яңа тормыш белән танышу мөмкинлеге туа. Бу дәвер татар шагыйрьләреннән бигрәк тә Һади Такташ, Муса Җәлилләр иҗаты уйгур укучыларының мәхәббәтен казана. 1930 нчы еллар башында демократик азатлык өчен барган көрәш вакыйгаларына бәйле рәвештә Шәркый Төркестанда, тормышның башка өлкәләрендәге кебек үк, мәктәп-мәгариф эшләрендә дә сизелерлек үзгәрешләр барлыкка килә. Яңа рухтагы башлангыч һәм урта мәктәпләр ачыла, бу мәктәпләрдә укыту эшләрен алып барыр өчен, җирле татарлардан мөгаллим һәм мөгаллимәләр чакырыла. Тел-әдәбият дәресләрендә алар татар әдипләре һәм шагыйрьләре иҗатыннан киң файдаланалар. Мәсәлән, Г. Тукайның «Туган тел», «Шүрәле» әсәрләре уйгур мәктәпләрендәге барлык уку программаларына кертелгән иде.

Бер үк вакытта Голҗа татар мәктәбендә дә күпләгән уйгур яшьләре белем алды. Мәсәлән, гоминдан төрмәсендә һәлак булган атаклы уйгур Лотфулла Моталлиб шул мәктәптә дүрт ел укып белем алган, революциягә кадәрге татар әдипләренең һәм совет чоры шагыйрьләренең иҗатлары белән танышкан. Лотфулла бигрәк тә Габдулла Тукай, Һади Такташ әсәрләрен яратып укый, соңрак үзе дә шигырьләр иҗат итә башлый.

Бу чактагы уйгур-татар мәдәни багланышларының матур үрнәкләрен матбугат өлкәсендәге хезмәттәшлектә дә күрергә мөмкин. Чөнки Шәркый Төркестандагы

Голҗа, Чүгүчәк шәһәрләрендә торучы татарлар җирле уйгурлар, казакълар белән тыгыз аралашып яшиләр, аларның телләрен, гореф-гадәтләрен яхшы беләләр, омтылышларына теләктәш булып, төрле өлкәләрдә кулга-кул тотышып гамәл итәләр. Менә шушы табигый бердәмлекне расларга теләгәндәй, җирле матбугат та, гәрчә ул нигездә уйгур һәм казакъ телләрендә чыгып килсә дә, тату яшәгән тугандаш халыклардан татар һәм үзбәкләр өчен дә аңлаешлы җиңелрәк телдә басыла, аларның барысына да бертигез дәрәҗәдә хезмәт итә. Әлбәттә, гарәп әлифбасы нигезендәге язуның да традицион уртак булуы мондый хезмәттәшлек өчен вакытында яхшы җирлек тудыра. Мондый хезмәттәшлеккә китергән сәбәпләр турында сөйләгәндә, уйгур журналистикасының чагыштырмача яшь, ә татарларда исә матбага өлкәсендә электән үк бай тәҗрибә тупланууын күрсәтергә кирәк. Менә шуңа күрә 1934 елда Голҗада «Ил дәрьясы», аннары «Шинҗаң иле гәзите» исемендә уйгур телендә чыккан газетаның баш редакторы Хәбип Юничи дигән татар кешесе булса, 1946 елдан соң нәшер ителгән «Инкыйлаби Шәркый Төркестан гәзите»нә татар мәктәбенең элекке укытучысы Әсгат Исхаков җитәкчелек итә.

Матбугат өлкәсендәге бу хезмәттәшлек татар белгечләренең оештыру эшләренә актив катнашуы белән генә чикләнми, әлбәттә. Алар тарафыннан язылган материаллар да җирле газета-журналларда еш басыла. Сыйфатлы әсәрләр язып, газета-журналларның эчтәлеген баетуга сизелерлек өлеш керткән шундый журналистлардан Борһан Шаһиди, Рәхим Сәфәргали, Әнвәр Локман, Хәмит Төхфи, Мөнир Ирзиннарны махсус атап күрсәтергә кирәк. Болардан әдәбият өлкәсендә Рәхим Сәфәргали белән Хәмит Төхфи бигрәк тә актив эшлиләр [1].

Хәмит Төхфи безнең өчен аерата игътибарга лаек. Ул 1944 елдан башлап «Азат Шәркый Төркестан», «Инкыйлаби Шәркый Төркестан», «Алга» газеталарында, «Иттифак» журналында, «Альманах» исемле җыентыкта куплләгән шигырьләр бастыра, шулардан «Әйдә көрәшкә», «Тоткын», «Горький бәйрәменә», «Тынычлык өчен» дигән шигырьләре заман өчен бик актуаль яңгырадылар. Аның көрәшкә өндәү рухы белән сугарылган ялкынлы әсәрләре идея-эчтәлек ягыннан да, сыйфат җәһәтеннән дә җирле матбугатта аерылып торды, киң популярлык казанды. Шагыйрьнең күп кенә әсәрләре әле бүген дә үз әһәмиятен югалтмаган, чөнки аның иҗаты Шәркый Төркестандагы тарихи вакыйгалар, иҗтимагый шарт, көрәш хәрәкәтләре белән тыгыз бәйләнгән. Мәсәлән, югарыда телгә алынган «Альманах»та (Голҗа, 1947 ел) басылган «Вөҗдан» исемле шигырендә түбәндәге юллар бар:

**Золым бер килгәч тормас аптырап,**
**Нурлы тарихны буяр шакшырак.**
**Мондый хурлыкка ирек биргәнче,**
**Намуслы үлем мең кат яхшырак!**

Җирле шартларда уйгур-татар әдәби бәйләнешләрының нигезе Шәркый Төркестанда классик татар әдәбиятының абруе тагы да үсә төшүгә, аңар карата булган хөрмәт-ихтирамның янә дә ныгый баруына китерә. Игътибар үзәгендә иң элек Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил иҗатлары була. Моның шулай икәнлегенә ышаныр өчен, Шәркый Төркестан газета-журналларын актару да җитә. Мәсәлән, 1949—1958 елларда, милли мәдәниятләр өчен шартлар авырая барган чорда да, уйгур матбугатында татар совет шагыйрьләренә киң урын бирелеп килә. Мисал өчен түбәндәге фактларны санау да җитә: «Иттифак» журналында (Голҗа, 1949 ел, 11—12 саннар) Һади Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе», «Тарим» журналында исә (Үрүмче, 1956 ел, 1 сан) «Байрак тегәбез» дигән әсәрләре уйгурча тәрҗемәдә чыга. 1956 елда, Муса Җәлилнең тууына 50 ел тулу мөнәсәбәте белән, «Тарим»да (2 сан) «Ут-йөрәк» дигән махсус мәкалә һәм шагыйрьнең «Кылыч», «Сөйгәнемә» исемле шигырьләре басыла.

Г. Тукай, Һ. Такташ һәм М. Җәлил образлары авыр шартларда яшәгән алдынгы карашлы уйгур шагыйрьләре өчен көрәш, өмет һәм ныклык үрнәге була. Аларның әсәрләре күңелләргә дәрт, өметләргә канат бирен, катлаулы сорауларга җавап булып хезмәт итә. Шуңа күрә дә күңел түрләрендә саклананалар. Мәсәлән, Тукайның

---

[1] Рәхим Сәфәргали иҗатыннан кайбер үрнәкләр. Хәсән Туфанның кереш сүзе белән, «Совет әдәбияты» журналының 1964 елгы 4 санында басылган иде.

«Көчләремне мин кара көннәргә саклый алмадым» дип башланган шигырен («Кыйтга») оригиналда яттан белмәгән бер уйгур әдибе дә булмагандыр дип әйтәсе килә.

Г. Тукайны үзенең остазы дип исәпләгән шагыйрь Хәлил Һамраев аңар багышланган «Тукай» исемле мөхәммәсендә [1] болай җырлый:

**Син газиз татар иленең иң бөек шагыйресең,**
**Шигъри сәнгать дөньясында һәммәдән маһирысың,**
**Руссияне сөюдә ут йөрәк Таһирысың,**
**Моңлы уйгур иленең дә иң якын дус-ярысың.**
**Илһамың бер дәрья булса, син балкучы нур иДең.**

Шәркый Төркестандагы уйгур-татар мәдәни бәйләнешлары хакында сөйләгән чакта, тагы бер мөһим факт хакында әйтмәсәк, мәгълүматыбыз төгәл булмас иде. Сүз Голҗа шәһәрендә Габдулла Тукай җыентыгы басылу хакында бара.

Үз ватаннарыннан бик еракта яшәсәләр дә, күңелләрендә туган ил җылысын, йөрәкләрендә үз халкының моңнарын, рухын кадерләп саклаган Голҗа татарларында һәр елны диярлек Тукай көнен билгеләп узу гадәте бар иде. Бу йолага бөек шагыйрьне үз җырчысы итеп таныган уйгур халкының вәкилләре дә катнашып килде. Шундый юбилейларның берсе аерата истә калган.

Азатлык өчен күтәрелгән кораллы көрәш тәмамланып җитмәгәнлектән, 1946 елда Тукайның 60 еллык бәйрәмен уздыру мөмкин булмады. Шуңа күрә шагыйрь истәлегенә багышланган бәйрәмнәрне бер елдан соң, ягъни Тукайның 61 еллыгы көннәрендә уздырырга туры килде.

...600 дән артык кеше сыйдырышлы зур зал, тантаналы итеп җыештырылган сәхнә әле дә күз алдында. Сәхнә түрендә шагыйрьнең зур портреты чәчәкләргә күмелеп тора. Тукайның тормыш юлы һәм иҗатына багышланган докладтан соң тантаналы кичәнең әдәби-музыкаль өлеше башланды. Сәхнәгә бер-бер артлы яшьләр, мәктәп укучылары чыга, җырлар яңгырый, шигырьләр укыла. Шагыйрь әсәрләре нигезендә эшләнгән инсценировкалар куела...

Тәнәфес вакытында зур фойега чыгабыз. Анда — җирле рәссамнар тарафыннан Тукай әсәрләренә ясалган рәсемнәр күргәзмәсе. Менә бүрәнәгә кысылган кыргый — мәгәр күңелләргә күптән таныш, якын Шүрәле, әнә елга чоңгылыннан атылып чыккан Су анасы...

Әмма Голҗа татарлары тарафыннан зур әзерлек, тырышлык белән уздырылган бу кичәдән калган иң мөһим истәлек, минемчә, Тукай шигырьләреннән тупланган кечкенә мәҗмуга булды. Мин хәзер дә аны еш-еш кулга алам. Аның тышлыгында эре хәрефләр белән: «Г. Тукай. Сайланма шигырьләр» дип басылган. Бераз түбәндәрәк мондый багышлау бар: «Шагыйребез Габдулла Тукайның дөньяга килүенә 61 ел тулу мөнәсәбәте белән бастырылды». Иң аста «Нашире: Голҗа татарларының мәдәни җәмгыяте. 1947. Голҗа» дигән сүзләр язылган.

Югарыда әйтелгәнчә, бу китап авыр шартларда, сугыш хәрәкәтләре тәмам сүрелеп җитмәгән бер чорда басыла. Шуңа күрә аның күләме артык зур түгел: тышлык һәм титул битләрен исәпкә алмаганда, барлыгы 17 генә бит. Ләкин мәсьәлә китапның күләмендә түгел, бәлки эчтәлегендә һәм рухында иде. Чөнки Шәркый Төркестанның бер өлешендә карагруһ гоминданчылар властен бәреп төшергәч дөньяга чыккан бу китап символик мәгънәгә ия.

Җыентыкның икенче битендә шагыйрьнең портреты бирелгән, туган һәм үлгән еллары күрсәтелгән [2]. Хәмит Төхфи тарафыннан язылган ике битле кереш сүздән соң 22 шигырь бирелә: «Шагыйрь», «Әхлаксызлык», «Нәсихәт», «Алтынга каршы», «Сәрләүхәсез», «Милли моңнар», «Чын вә ялган», «Кыйтга», «Шекспирдан», «Толстой сүзләре», «Өзелгән өмит», «Сагынып вакытлар», «Ваксынмыйм», «Тәләһһеф», «Теләнче», «Буран», «Туган җиремә», «Төлке һәм йөзем җимеше», «Васыятем», «Тәэсир», «Туган тел», «Пар ат» [3].

---

[1] М ө х ә м м ә с — биш юллы строфалардан торган шигырь.
[2] Рәсемне һәвәскәр рәссам Г. Исхаков ясаган.
[3] Китапның «Шагыйрь» кебек программа характерындагы әсәрдән башланып, «Туган тел» һәм Казанга багышланган «Пар ат» белән тәмамлануы, һичшиксез, игътибарга лаек факт. Җыентык 20 нче елларда Татарстанда гамәлдә булган, яңартылган гарәп алфавитында, әсәрләрнең тел-стиль үзенчәлекләре сакланган рәвештә басылган.

Җыентыкка кергән әсәрләрнең Тукай мирасын, бу ялкынлы иҗатның кайбер үзенчәлекләрен әзме-күпме чагылдыруын әйтү белән бергә, кереш мәкаләнең дә идея юнәлешенә, рухына игътибар итәсе килә: «Тукайның яшәгән дәвере,— диелә анда,— Чар Русиясенең[1] иң котырган дәверенә туры килгәнгә, аның күпләгән шигырьләре иҗтимагый характерга ия булды. Ул үзенең шигырьләрендә залимнардан, өстен сыйныфлардан ачы көлде, изүчеләрне аяусыз рәвештә сүкте...»

Ниһаять, Казаннан әллә кайларда еракларда татар телендә чыккан бу китапның 700 нөсхәдә «Инкыйлаби Шәркый Төркестан» исемле уйгур халык матбагасында — демократик рухтагы нәшриятта басылып чыгуын искәртеп узасы килә[2].

...Минем кулдагы бу кечкенә китап дөньяга чыкканнан бирле бик күп җилләр исте, бик күп сулар акты. Маочылар хөкем сөргән хәзерге Шәркый Төркестанда кытай булмаган халыкларның культурасы нык эзәрлекләнә. Дөрес, кытай халкының үз демократик культурасы, бай тарихи мирасы да авыр сынауларга дучар ителде. Әмма дәһшәтле «культура революциясенең» шаукымы Кытайдагы аз санлы милләтләр өчен сынау гына түгел, бәлки чын мәгънәсендәге афәткә әверелде. Моннан 30—40 еллар элек Шәркый Төркестанның бәрәкәтле туфрагында барлыкка килгән уйгур-татар әдәби мөнәсәбәтләренең җимешләре дә авыр язмышка очрады. Габдулла Тукай, Һади Такташ, Муса Җәлил китаплары да маочылар кабызган кыргыйлык учакларында яндырылды.

Әмма безнең халыкларыбыз арасындагы чын дуслыкны, эчкерсез самими хезмәттәшлекне бөтенләй йолкып ташлау, юкка чыгару һич мөмкин түгел. Моның шулай икәнлеген бүгенге СССРдагы уйгурлар белән татарлар арасындагы бәйләнешләрнең элеккечә үк дәвам итүендә, хәтта елдан-елга үсә баруында күрергә мөмкин. Ленин нигез салган милли сәясәтнең нуры астында мондый дуслыкка, хезмәттәшлеккә һәммә мөмкинлекләр дә бар. Хәтта кайчандыр Шәркый Төркестанда ук башланган уңай традицияләр бүген СССРда дәвам итмәктә. Мәсәлән, югарыда Голҗадагы хезмәттәшлек буенча телгә алынган журналистлардан Әнвәр Локман, Советлар Союзына кайтканнан бирле, Алма-Атада чыга торган республикаара уйгурча «Коммунизм туги» газетасында өлкән тәрҗемәче эшен башкара; практик журналистикадан фән дөньясына күчкән Мөнир Ирзин исә Казагыстан Фәннәр академиясендә эшли, уйгур матбугаты тарихы буенча махсус тикшеренү-диссертация әзерли, шул юнәлештә күпләгән хезмәтләр дә бастырып чыгарды.

Кыскасы, уйгур-татар матбугат хезмәттәшлеге традициясе киңәя барып дәвам итә. Татар әдәбиятына, ягъни халыкларыбыз арасындагы мәдәни мөнәсәбәтләрнең төп магистральләреннән берсенә килсәк, аның иң күренекле вәкилләреннән Тукай, Такташ, Җәлил әсәрләрен бүгенге совет уйгурлары да бик яратып, хөрмәтләп укыйлар, әледән-әле аларны үз ана теленә тәрҗемә итәләр.

**Алма-Ата.**
**1976 ел.**

## Торсын Каһһари мәкаләсенә карата

*Уйгурлар Шәркый Төркестанда, ягъни Кытай Халык Республикасының көнбатышында, шулай ук өлешчә СССРда яшиләр (якынча 6 миллион). Тарихта тирән эз калдырган бу халыкның бай мирасын күзаллау өчен башкалар тарафыннан кабул ителгән уйгур язуын, мәшһүр Мәхмүт Кашгарый сүзлеген, төрки телләрдәге иң беренче әдәби әсәр «Котадгу билик» дастанын атау да җитә.*

*Татар-уйгур культура мөнәсәбәтләре борынгы чорлардан ук башлана. Мәсәлән, элеге уйгур язуы урта гасырларда Идел буенда да гамәлдә булган. Яңа дәвер уйгур-татар әдәби бәйләнешләре да күп тармаклы, гыйбрәтле (карагыз: «Совет әдәбияты». 1961 ел, 1 сан; «Казан утлары». 1966 ел, 4 сан; 1967 ел, 9 сан).*

---

[1] Царь Россиясе.
[2] Бу китапның хәзергә мәгълүм бердәнбер нөсхәсе мәкалә авторы Т. Каһһари китапханәсендә саклана. Ред.

*Укучылар игътибарына тәкъдим ителгән мәкаләдә шул үзенчәлекле тарихның яңа сәхифәсе актыртыла. Анда сүз, нигездә, Шәркый Төркестан уйгурларының, бигрәк тә Голҗа (Кульджа) шәһәренең әдәби тормышы хакында бара, беркадәре вакыт шунда яшәгән татарлар да телгә алына. Шуңа күрә кечкенә белешмә китерик.*

*1851 елда, Россия белән Кытай арасында төзелгән килешү буенча, көнбатыш Кытайдагы Голҗа һәм Чүгучәк шәһәрләре Россия өчен ачык территория дип игълан ителә. Үз «подданныйларының» мәнфәгатьләрен яклау максатыннан чыгып, әлеге шәһәрләрдә Россия консуллыклары ачыла, килүчеләргә һөнәр-кәсеп һәм сәүдә өчен кайбер җиңеллекләр тудырыла. Нәтиҗәдә Голҗада Россиядән килүче рус, үзбәк һәм татарлардан аерым этник группалар, ягъни колонияләр оеша.*

*Язма чыганакларга караганда, Голҗадагы татар колониясе 1905 елга хәтле үк үзләре өчен мәчет-мәктәп салырлык дәрәҗәдә ишәйгән һәм үскән була. Һәрхәлдә, 1913 елны патша хөкүмәте эзәрлекләвеннән качып килгән Габдулла Буби андагы иске татар мәдрәсәсен реформалап, яңа типтагы мәктәп ача. Озак еллар дәвамында оешкан бу җәмгыять этнографик яктан да, социаль яктан да шактый чуар була. Октябрь революциясеннән соң аның составы тагы да катлаулана төшә...*

*Ләкин, дәүләт чиге ябылып, политик шартлар үзгәрсә дә, консульство бетерелми, чөнки элекке Россия «подданныйлары» совет гражданнары статусына күчәләр. Менә бу хәл Голҗадагы милли колонияләрнең мәктәп-мәгариф, идеологик ориентация өлкәләрендәге үзенчәлекләрен билгеле.*

*Голҗада совет гражданнары карамагында булган ике рус, берәр үзбәк һәм татар мәктәбе эшләп килә. Аларда Мәскәү, Ташкент, Казан дәреслекләре кулланыла. Әмма җирле матбугат, дәүләт һәм хосусый оешмаларда эш йөртү уйгур телендә, гарәп язуында булгач, татар һәм үзбәк мәктәпләрендә дә гарәп әлифбасы гамәлдә кала. Нәтиҗәдә Голҗада туып үскән татарлар, гадәттә, ике-өч язу танып, дүрт-биш тел белә торган булалар. Шуңа күрә аларда җирле вакыйгаларга актив катнашырга мөмкинлек туа. Алдынгы татар яшьләренең демократик азатлык хәрәкәтенә, революцион көрәшкә җәлеп ителүе, прогрессив уйгур, казакъ егетләре белән бергә Чан-Кай-ши төрмәләрендә газапланып, эшафотка озатылулары шуны күрсәтә.*

*1950 елларның башында, СССР һәм Кытай хөкүмәтләре арасында төзелгән килешү буенча, Кытайда яшәүче совет гражданнарына үз ватаннарына кайту мөмкинлеге туа. 1953—1958 еллар арасында Голҗадагы русларның зур өлеше, үзбәк һәм татарларның барысы да СССРга кайтып бетәләр. (Т. Каһһари мәкаләсендә телгә алынган шәхесләрнең барысы да диярлек хәзер Алма-Ата, Фрунзе, Ташкент шәһәрләрендә яши.)*

*Мәкалә авторы Торсын Каһһари 1924 елда Голҗа шәһәрендә туа. Шундагы уйгур мәктәпләрендә укый, мәдәни-агарту оешмаларында, газета-журналларда эшли. 1944 елдан башлап шигырьләр яза, Голҗа һәм Урумче шәһәрләрендә чыккан газета-журналларга катнаша. Ләкин ул, дәһшәтле «культура революциясе» башлангач, төрле эзәрлекләүләргә дучар ителә һәм 1961 елны Советлар Союзына чыгып китәргә мәҗбүр була. Хәзер Т. Каһһари Алма-Атада яши, «Коммунизм тугы» (туг — байрак) исемле республикаара газетада эшли. 1970 елны аның яңа шигырьләр җыентыгы, ә 1975 елны исә Муса Җәлилгә багышланган «Мәңгелек факел» исемле поэмасы дөнья күрә. Ул күпләгән әдәби һәм публицистик мәкаләләр авторы.*

*Журналда тәкъдим ителгән мәкалә уйгурчадан аз гына кыскартылып, кайбер җирләренә аңлатмалар өстәлеп тәрҗемә ителде.*

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# ДАНЛЫ ЮБИЛЕЙНЫ КАРШЫЛАП

*Иҗтимагый фәннәрне тагын да үстерү һәм коммунизм төзүдә аларның ролен күтәрү буенча соңгы елларда партия күргән чаралар, коммунистик җәмгыять төзүдәге бай тәҗрибә, партия ясаган фәнни ачышлар һәм гомумиләштерүләр, ниһаять, илебез тормышындагы зур юбилейлар, аерым алганда Бөек Октябрь социалистик революциясенең 60 еллыгына әзерләнү һәм аны тантаналы төстә үткәрү республикабыз галимнәренең иҗади активлыгын бермә-бер көчәйтеп җибәрде. Татарстан тормышының төрле якларына, үткәненә һәм хәзергесенә багышлап ел саен чыгарыла торган җитди тикшеренүләр, китаплар — шуның бер күркәм чагылышы. Соңгы елларда дөнья күргән кайбер китапларга кыскача гына тукталып үтик. Ышануыбызча, ул китаплар язучылар һәм әдәбият сөючеләр өчен дә кызыклы.*

**ТАТАРСТАН ПАРТИЯ ОЕШМАСЫ ТАРИХЫ ОЧЕРКЛАРЫ. Үзгәртелгән, тулыландырылган икенче басма (рус телендә). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1973. 711 бит.**

Татарстан өлкә партия оешмасы — Коммунистлар партиясенең иң өлкән җирле оешмаларыннан берсе. Аның тамырлары узган гасырның 80 нче елларында Н. Е. Федосеев оештырган беренче марксистик түгәрәкләргә барып тоташа. Мәгълүм булганча, укучы һәм студент яшьләрнең марксистик түгәрәгендә В. И. Ульянов үзенең революцион эшчәнлеген башлап җибәрә.

РСДРПның Казан комитеты 1902 ел азагында оеша. Шуннан башлап бу җирле оешма данлы юл үтә. Аның тарихы белән без шактый тулы төстә «Татарстан партия оешмасы тарихы очерклары» дигән коллектив хезмәт аша 1962 елда танышкан идек. 10 елдан артык вакыт узгач, әлеге монографиянең икенче басмасын кулга алдык. Әлеге басма, беренчедән, соңгы елларда ирешелгән уңышлар, марксистик-ленинчыл теориянең иҗади казанышлары базасында иҗат ителгән. Икенчедән, кыска гына вакыт эчендә тарихның мөһим проблемалары, бигрәк тә Татарстанның совет чоры тарихы мәсьәләләре буенча төпле монографияләр, брошюралар, җыентыклар дөнья күрде. Әлеге басма әнә шул гомумиләштерүләр һәм нәтиҗәләр белән баетылган. Өченчедән, тикшеренүләрнең документаль базасы да шактый киңәйде. Документ һәм материалларның яңа җыентыклары басылды. «Очерклар»ның икенче басмасы яңа чыганакларны һәм фактларны да «эшкә җиккән». Дүртенчедән, әлеге китапта беренче басмага карата чыккан рецензияләрдәге тәнкыйть фикерләре исәпкә алынган. Бишенчедән, Татарстан партия оешмасы беренче басма чыкканнан соң бай тормыш белән яшәде, коммунистик төзелешнең хәзерге чорында яңа тәҗрибә туплады. Икенче басма әнә шул бик кыйммәтле тәҗрибәне дә яктырта.

Китапны иҗат итүгә республикабызның актив эшләүче, җәмәгатьчелек тарафыннан танылган тарихчылары тартылган. «Очерклар»га 1883—1972 елларда Татарстан партия оешмасы тарихына караган төп вакыйгалар хроникасы, гаять бай библиография, исемнәр күрсәткече кушымта итеп бирелгән.

Күмәк монография Татарстан партия оешмасының, партия Үзәк Комитеты җитәкчелегендә, социалистик һәм коммунистик төзелеш этапларында җәмгыять тормы-

шының барлык өлкәләрендәге купьяклы оештыру, идея-политик һәм идеологик эшен яктырта. Партия оешмаларының патша самодержавиесенә, буржуаз стройга каршы һәм пролетариат диктатурасы өчен фидакарь көрәше бай фактик материаллар җирлегендә калку итеп күрсәтелә. Әлеге мәсьәләләрне яктыртканда авторлар партия оешмасының җирле һәм милли үзенчәлекләрне исәпкә алып эш итүен даими күздә тоталар.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң Совет властен урнаштыру һәм ныгыту өчен көрәштә, гражданнар сугышы һәм чит ил интервенциясе вакытында хезмәт ияләрен сыйнфый дошманнарга каршы көрәшкә туплауда өлкә партия оешмасының роле ачып бирелә. Социалистик индустрияләштерү, авыл хуҗалыгын кооперативлаштыру һәм культура революциясе кебек социалистик төзелешнең гомуми закончалыкларын тормышка ашыруда партия оешмасы тоткан урын китапта калку чагылыш тапкан. КПССның ленинчыл милли политикасын эзлекле төстә тормышка ашыруда Татарстан партия оешмасының ролен ачуга аеруча зур игътибар бирелгән.

Бөек Ватан сугышы елларында республика хезмәт ияләрен дошманга каршы көрәшкә туплау — өлкә партия оешмасы тормышында иң якты сәхифәләрнең берсе. Китапта аның бу чордагы эшчәнлеге киң чагылыш тапкан.

Монография безне партия оешмасының нык үскән социализм шартларындагы эшчәнлеге, республиканың экономикасын һәм культурасын үстерүдә аның җитәкчелеге, шул җитәкчелекнең юнәлешләре һәм формалары белән җентекләп таныштыра.

Китапта социалистик һәм коммунистик төзелешнең барлык этапларында Татарстан партия оешмасының әдәбият-сәнгать өлкәсендә партия политикасын тормышка ашыру, художество иҗатын активлаштыру, аның югары идеялелеген һәм сәнгатьлелеген тәэмин итү, иҗат интеллигенциясенең идея һәм профессиональ дәрәҗәсен күтәрү, аның максималь эшләве өчен тиешле шартлар тудыру өлкәсендәге фидакарь эшчәнлеге дә киң яктыртыла.

Әлеге хезмәт белән танышкач, без социализм һәм коммунизм өчен көрәшнең иң мөһим закончалыгын — җәмгыять тормышының барлык өлкәләренә партия җитәкчелеге зарурлыгын тирәнрәк төшенәбез, һаман саен партиянең роле арта баруын, аның халык мәнфәгатьләрен иң тогәл гәүдәләндерүче иң алдынгы политик көч булуын аңлыйбыз.

**Ф. Ә. Табеев. ЯҢА ҮРЛӘР ЯУЛАП (рус телендә). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1976. 272 бит.**

Бу китапта КПССның Татарстан өлкә комитеты беренче секретаре Ф. Ә. Табеев тугызынчы бишьеллыкта республикабыз ирешкән казанышларны барлый, унынчы бишьеллыкта үтәләсе бурычларга, хәл кылынасы проблемаларга туктала. Автор тугызынчы бишьеллыкның коммунизмның материаль-техник базасын төзүдә мөһим этап икәнлеген раслый һәм КПССның XXIV съезды билгеләгән төп социаль-экономик бурычларның уңышлы үтәлгәнлеген канәгатьләнү белән билгеләп үтә. Узган бишьеллыкта Татарстан хезмәт ияләре зур уңышларга ирештеләр. Китапта бу җәһәттән түбәндәге фактлар китерелә: промышленность продукциясен реализацияләүнең бишьеллык планы срогыннан элек — 1975 елның 8 декабрена үтәлде, бишьеллык азагына планнан тыш 458 миллион сумлык продукция алынды. Промышленность җитештерүе күләме пландагы 41,1 урынына 49,4 процентка артты. Халык киң куллана торган товарлар ике тапкыр күбрәк житештерелде. Хезмәт җитештерүчәнлеге пландагы 25,7 урынына 33,1 процентка үсте. Промышленность продукциясе үсешенең 75 проценты хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү исәбенә алынды.

Узган бишьеллыкта партиянең экономик политикасында җитештерүнең нәтиҗәлелеген күтәрү, хуҗалык итүнең интенсив алымнарына күчү үзәк проблема булганлыгына басым ясап, Ф. Ә. Табеев нәтиҗәлелекне тәэмин итүче факторларга, аерым алганда фән-техника казанышларын производствога кертү, продукциянең сыйфатын яхшырту, планлаштыру һәм экономик стимуллаштыруны камилләштерү кебек факторларга конкрет мисаллар китереп тәфсилле анализ ясый. Аннары автор авыр индустрия тармакларындагы, шул җөмләдән машина төзелеше, нефть, нефть-химия, энергетика өлкәсендәге эшләрнең торышына аерым-аерым туктала, капиталь төзелешкә махсус бүлек багышлый. Машина төзелеше тармагының узган бишьеллыкта-

гы эше турында сөйләгәндә, Ф. Ә. Табеев КамАЗ төзүнең колачын сурәтләүгә тиешле урын бирә.

Китапта авыл хуҗалыгында ирешелгән казанышлар, хәл ителәсе проблемалар лаеклы урын алган, авыл хуҗалыгы производствосын специальләштерү һәм концентрацияләү мәсьәләләренә зур игътибар бирелгән.

Халык хуҗалыгының барлык тармакларын кызу темплар белән үстерү, әлбәттә, бишьеллыкның төп бурычы — хезмәт ияләренең тормыш хәлен тагын да яхшырту, тормыш дәрәҗәсен күтәрү бурычын хәл итүгә буйсындырылган. Автор, шуны күздә тотып, тугызынчы бишьеллыкта социаль өлкәдә ирешелгән үрләрне калку итеп күрсәтә. Тормыш хәленең төп күрсәткече булган милли доходның 90 проценты хезмәт ияләренең тормыш хәлен яхшырту максатларына тотылган. Эшче һәм хезмәткәрләрнең уртача эш хакы тугызынчы бишьеллыкта 20 процентка арткан һәм 146 сум, ә җәмәгать куллануы фондларыннан да файдалануны исәпкә алсак, 198 сум тәшкил иткән. Татарстан колхозларында колхозчыларның уртача айлык эш хакы 83 сумга җиткән, ягъни 1970 ел белән чагыштырганда 31 процентка арткан. Күңелне сөендерерлек мондый фактларны китаптан күп табарга мөмкин.

Хезмәтнең соңгы бүлеге Татарстан экономикасын уңышлы үстерүнең төп шарты булган партия җитәкчелеге, аның күпьяклы оештыру һәм тәрбия эшен күрсәтүгә багышланган. Халык хуҗалыгы бурычларын хәл итүдә, совет кешеләрендә югары әхлак сыйфатларын формалаштыруда, аларны фидакарь хезмәткә туплауда автор әдәбият һәм сәнгатьнең дә гаять зур роль уйнавын билгеләп үтә. «Бу өлкәдә безнең республикада, — диелә китапта, — меңнән артык иҗат работнигы эшли. Соңгы елларда алар шәһәр һәм авылдагы социаль-экономик үзгәрешләрне, совет кешесенең югары мораль сыйфатларын тирән һәм дөрес гәүдәләндергән байтак әсәрләр иҗат иттеләр. Алар иҗатында совет җәмгыяте тормышының актуаль проблемаларына һаман зуррак борылыш ясала». «Әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләре, — дип дәвам итә Ф. Ә. Табеев, — киләчәктә дә халкыбызга лаеклы әсәрләр иҗат итәргә бурычлылар. Аларның иҗаты — совет кешеләрен Ватаныбызның тагын да чәчәк атуы хакына яңа хезмәт һәм иҗат батырлыкларына рухландыручы бетмәс-төкәнмәс рухи чыганак».

Шул рәвешле, әлеге китапны укып-өйрәнеп, республикабызның экономик куәтен, тугандаш халыклар гаиләсендә партия һәм хөкүмәтебезнең кайгыртучанлыгын тоеп аның һаман югарырак үрләр яулавын күзалларга мөмкин.

**М. Ф. Вәлиев. ФӘН БИЕКЛЕКЛӘРЕНӘ. Татарстанда фәннең үсеше турында [рус телендә]. М., «Советская Россия» нәшрияты, 1975. 175 бит.**

Без фән-техника революциясе колач җәя барган чорда яшибез. Фән тормышыбызның барлык өлкәләренә үтеп керә. Ул турыдан-туры җитештерүче көчкә әверелә. Нык үскән социализм шартларында фәннең җәмгыять тормышында тоткан урыны янә дә әһәмиятлерәк була бара. Фән казанышларын социалистик стройның өстенлекләре белән бергә кушу — нык үскән социалистик җәмгыятьнең бер закончалыгы.

Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соң безнең илдә фәнне үстерү өчен бөтен шартлар тудырылды. Бу эшкә барлык милләт һәм халык вәкилләре лаеклы өлеш керттеләр. Фән милли кысалар белән чикләнми, ул чын-чыннан интернациональ характерда.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиевның әлеге китабы Татарстанда фәннең үсеше, аның төп юнәлешләре һәм тенденцияләре турында.

Автор элеккеге Россия империясенең артта калган бер төбәгендә Совет власте елларында фәннең киң колач җәеп үсүе процессын илдә тормышка ашырылган тирәнтен социаль үзгәрешләр, ленинчыл милли политиканы эзлекле үткәрү, тугандаш халыкларның хезмәттәшлеге, социализмның халыкның рухи көчләрен уятып-кузгатып җибәрүе нәтиҗәсе буларак күздән кичерә.

Китап революциягә кадәр Казан губернасында фәннең торышына кыскача сәяхәт белән ачыла. Әлеге бүлектә царизм куйган киртәләргә дә карамастан, фәннең байтак өлкәләрендә әһәмиятле тикшеренүләр алып барылуы турында сөйләнелә, безнең төбәктә фәнне үстерүдә, мәгърифәт таратуда Казан университетының роленә басым ясала. Автор, табигать фәннәренең төрле юнәлешләре, төрле фәнни мәктәп-

ләр, шуларны җитәкләгән энтузиаст галимнәр турында кызыклы мәгълүматлар бирү белән берр әттән, гуманитар фәннәрнең хәленә дә караш ташлый, И. Хәлфин, К. Насыйри, Х. Фәезханов, Г. Мәхмүтов, Ш. Мәрҗани кебек татар галимнәренең әдәбият, тел, тарих фәннәрен үстерүгә керткән өлешенә тукталa. Әмма, М. Ф. Вәлиев бик хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, фәнне үстерү, аның казанышларын халыкка хезмәткә кую өчен бөтен мөмкинлекләрне бары социализм гына тудырды. Автор партия һәм Совет дәүләтенең халык интеллигенциясен, аерым алганда фән хезмәткәрләрен әзерләү, халык мәгарифен, югары мәктәпне үстерү буенча күргән эшлекле чараларын анализлый, шул чараларны тормышка ашыруның күркәм нәтиҗәләрен күрсәтә. Соңгы елларда, бигрәк тә нык үскән социализм шартларында, фәнне үстерүгә аеруча игътибар бирелү ассызыклана. Менә кайбер мәгълүматлар: Татарстанда хәзер 12 вуз, ике институт филиалы, СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы, 70 кә якын фәнни-тикшеренү һәм проект институтлары бар. Аларда уникe мең ярым югары квалификацияле белгеч, шул исәптән бер академик, ике член-корреспондент, 3300 дән артык фән докторы һәм кандидаты уңышлы эшли. Сигезенче бишьеллыкта гына да Казан вузларында 100 гә якын докторлык һәм 1000 нән артык кандидатлык диссертациясе якланды.

Китапта әйтелгәнчә, фәннең һәр өлкәсендә Татарстан галимнәренең үз мәктәпләре, үз традицияләре бар. Республикабыз галимнәре фәннең фундаменталь теоретик проблемаларын эшләү белән беррәттән, халык хуҗалыгы ихтыяҗларын канәгатьләндерүне дә күздә тоталар, фән белән җитештерү арасындагы союзның ныгуы турында кайгырталар.

Гуманитар фәннәр, аерым алганда әдәбият фәненең үсешен күзәткән урыннар да махсус игътибарга лаеклы. Совет әдәбият белгечләре алдында СССРдагы милли әдәбиятларның үсүе һәм бер-берсен баетуы процессын, яңа тарихи гомумилек — совет халкының барлыкка килүендә аларның ролен, социалистик реализм теориясенең актуаль мәсьәләләрен өйрәнүнең әһәмиятен күрсәтеп, М. Ф. Вәлиев Татарстан әдәбият белгечләренең бу җәһәттән башкарган эшләрен барлый, күренекле галимнәрне, аларның хезмәтләрен атый.

Кыскасы, бу китап иҗтимагый тормышның мөһим бер өлкәсе булган фән мисалында социалистик стройның өстенлекләрен, культура революциясе, ленинчыл милли политика нәтиҗәләрен бай фактик материал нигезендә дәлилле итеп пропагандалый.

**М. З. Тутаев. ТАТАРСТАНДА ХАЛЫК МӘГАРИФЕНЕҢ ҮСЕШЕ (рус телендә). Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975. 204 бит.**

М. Ф. Вәлиев китабында сүз фән турында барган булса, Казан дәүләт педагогия институты профессоры М. З. Тутаевның монографиясе Татарстанда халык мәгарифен үзгәртеп кору һәм үстерү мәсьәләләрен тикшерүгә багышланган.

Мәгълүм ки, мәгарифне социалистик нигездә үзгәртеп кору һәм үстерү — культура революциясенең бик әһәмиятле составы өлеше. Автор проблеманы пролетариатның революцион көрәшендә культураның урыны һәм роле турындагы В. И. Ленин тәгълиматы белән бәйләп өйрәнә, аның бу өлкәгә карашын, партиянең программ документларын аңлата. Бу, әлбәттә, хезмәтнең югары теоретик дәрәҗәсен тәэмин итә.

Партия һәм Совет дәүләтенең халык мәгарифен үзгәртеп кору буенча күргән чараларын бәян иткәнче, М. З. Тутаев Октябрь революциясенә кадәрге хәлгә күз ташлый. Патша самодержавиесе, татар һәм башка халыкларга карата экономик һәм милли изү политикасы үткәреп, аларны караңгылыкка һәм наданлыкка дучар итәргә омтылды. Китапта шундый мәгълүматлар китерелә. 1897 елда халык санын алу буенча Россиядәге 126 миллион кешенең нибары 26,5 миллионы укый-яза белгән. Казан губернасында һәр 1000 кешегә 179 укый-яза белүче туры килгән. Аның каравы, губернада 1438 кабак, 680 чиркәү, 1890 мәчет булган, поплар һәм муллалар саны укытучылардан алты тапкыр артып киткән. Мәгариф ихтыяҗларына җан башына 12,5 тиен акча тотылган.

Автор хаклы рәвештә исбатлаганча, бары Октябрь революциясе генә милли культуралар үсеше өчен иксез-чиксез мөмкинлекләр ачты. Китапта халык мәгарифен үз-

гәртеп кору һәм үстерүдә партиянең җитәкчелек роле, аның эш формалары җентекләп ачып бирелә. Халык мәгарифен идарә итүнең яңа органнарын булдыру, профессиональ-техник һәм югары белем бирү системасын тамырдан үзгәртү буенча партия һәм дәүләт күргән чаралар, шуларның нәтиҗәләре яңа фактик материаллар нигезендә калку итеп күрсәтелә.

Халык мәгарифе өлкәсендәге культура революциясе ленинчыл милли политиканы тормышка ашыру белән тыгыз бәйләнештә ачыла һәм бу — безнең төбәктә халык мәгарифе үсешендәге аерым үзенчәлекләрне билгели.

М. З. Тутаев бик бай чыганаклар җирлегендә 1917—1940 елларда республикабызда халык мәгарифенең үсешен дүрт чорга бүлеп тикшерә, әлеге процессны бөтен баскычлары һәм мөһим детальләре белән күз алдына китереп бастыра.

Партиянең даими кайгыртуы һәм җитәкчелеге нәтиҗәсендә Татарстан кыска гына вакыт эчендә тоташтан укый-яза белә торган республикага әверелде. Бездә төрле формаларда 827 мең кеше белем ала һәм белемен күтәрә. Вузларда һәм техникумнарда 100 меңнән артык студент укый, алар 50 дән артык милләт вәкиле. Беренче курсларда укучы студентларның 40 процентка якыны — татарлар. Уку-укытуның барлык төрләре буенча әнә шундый кызыклы мәгълүматлар китерелә китапта.

Хезмәтнең йомгак өлешендәге нәтиҗәләр һәм гомумиләштерү исә аеруча зур әһәмияткә ия. Автор яңа культура һәм социалистик мәгариф системасын үстерүдә партиянең җитәкче ролен ышандырырлык итеп күрсәтә, милли культураларның берберсенә йогынтысы, бер-берсен баетуы социалистик культура үсешенең гомуми закончалыгы икәнлеген исбатлый.

Татарстан халык мәгарифенең сугышка кадәрге чорын җентекләп өйрәнгән бу галимнән әлеге өлкәнең нык үскән социализм шартларындагы торышын һәм закончалыкларын ачкан яңа хезмәт көтәсе кала.

В. Белокопытов, Н. Шевченко. **КАЗАН УРАМНАРЫ АЛАРНЫҢ ИСЕМЕ БЕЛӘН АТАЛГАН.** **Төзәтелгән, тулыландырылган икенче басма (рус телендә). Казан, 1977. 400 бит.**

Шәһәр урамнарының исемнәре. Алар күп нәрсә турында сөйли. Беренче чиратта, шәһәрнең данлы тарихы, аның революцион, сугышчан һәм хезмәт традицияләре турында. Исемнәрен республикабыз башкаласы Казан урамнары йөрткән күренекле кешеләр турындагы очерклар җыентыгы белән инде 1973 елда танышкан идек. Китапның авторлары журналистлар В. Белокопытов һәм Н. Шевченко басмага кереш сүздә: «Безнең гасыр — ашкын темплар гасыры. Бу китап язылганда яңа урамнар барлыкка килде, аларга яңа исемнәр кушылды. Вакыт узар, һәм ул геройлар турында яңа китап иҗат итәрләр», — дип язганнар иде. В. Белокопытов тарафыннан әзерләнгән һәм быел, юбилей елында, чыккан икенче басманы әлеге фаразның тормышка ашырылуы дип санарга була.

Казан — борынгы шәһәр. Аның тарихы гасырлар белән исәпләнә. Еллар агышы аның йөзен, рухын үзгәрткән саен урамнарының да исемнәре яңара, заманлаша бара. Шул ук вакытта урам исемнәрендә һәр чорның үз эзе кала.

Казанда 1400 ләп урам бар. Аларның озынлыгы 813 километрдан артып китә. Китапка исемнәре урамнарга бирелгән күренекле революционерлар, галимнәр, әдәбият-сәнгать эшлеклеләре хакында очерклар тупланган. Билгеле, авторлар Казан турында язылган төрле хезмәтләрдән, архив материалларыннан киң файдаланганнар, ә кайбер эшлеклеләрнең биографияләрен эзләнү-тикшеренүләр нәтиҗәсендә ачыкларга туры килгән.

Илебез һәм республикабыздагы революцион хәрәкәтнең атаклы эшлеклеләренә багышланган очерклар, мәгаен, уңышлырактыр. Мисалга С. М. Киров, Г. Ш. Олькеницкий, М. Вахитов, М. Ә. Әхтәмов турындагы язмаларны аерып күрсәтергә мөмкин.

Казанның байтак урамнары әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең исемнәрен йөртә. К. Насыйри, Г. Тукай, Г. Камал, Г. Ибраһимов, С. Сәйдәшев, Х. Әбҗәлилов һ. б. Китапта алар турында да мәгълүматлар бар.

Журналистларның бу китабы хезмәт ияләрен революцион, сугышчан һәм хезмәт традицияләре рухында тәрбия итүгә лаеклы өлеш кертер, шәһәребез тарихы, революцион хәрәкәт, фән, культура тарихы белән кызыксынучыларга белешмә материал булып хезмәт итәр.

**Р. И. Нәфыйков. МУЛЛАНУР ВАХИТОВ (тарихи-биографик очерк). Төзәтелгән һәм тулыландырылган икенче басма. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1975. 224 бит.**

Хезмәт ияләрен азат итү өчен көрәштә катнашкан күренекле революционерларның тормыш юлы — яшь буынны социализм эшенә, коммунизм идеалларына тугрылык рухында тәрбия итүдә иң яхшы мәктәп. В. И. Ленин революциягә кадәр үк яшь эшчеләрне И. В. Бабушкин кебек революционерлар үрнәгендә тәрбияләү зарурлыгы хакында искәрткән иде. Безнең көннәрдә дә тәрбия эшендәге бу юнәлешнең әһәмияте артканнан-арта бара. Бу эшкә тарихчы галимнәр дә лаеклы өлеш кертәләр.

Татарлар арасында революцион хәрәкәт һәм алдынгы иҗтимагый фикер үсешен, аның күренекле эшлеклеләрен армый-талмый өйрәнүче галим Р. И. Нәфыйковның өч рус революциясендә актив катнашкан, В. И. Ленинның көрәштәше, Совет дәүләте комиссары Мулланур Вахитовның тормыш һәм көрәш юлын чагылдырган әлеге китабы нәкъ менә яшь буынга үрнәк булырлык каһарманның героик образын гәүдәләндерә. Без авторның М. Вахитовка багышланган хезмәтләре белән таныш идек инде. Әмма ул җитди эзләнүләрен дәвам итә, яңадан-яңа материаллар, фактлар таба. Нәтиҗәдә, безнең кулда — М. Вахитов турында эчтәлекле тарихи-биографик очерк.

Китапның кереш бүлегендә М. Вахитов кебек каһарманнарның тормыш юлын өйрәнүнең әһәмияте күрсәтелә, темага кагылышлы әдәбиятка төпле анализ ясала, ачыклыйсы мәсьәләләр куела. Кереш бүлекнең янә бер кызыклы ягы шунда: автор документаль чыганакларны бик җентекләп барлый, аларны бер-берсе белән чагыштыра, теге яки бу фактны ахыргача ачыклау максаты белән әледән-әле киң җәмәгатьчелеккә мөрәҗәгать итә. Нәтиҗәдә, автор күп мәсьәләләргә аныклык керткән, күп мәсьәләләрне яңача куйган.

Китапның беренче бүлегендә Р. И. Нәфыйков яңа фактлар нигезендә М. Вахитовның дөньяга карашын формалаштыручы факторларга киң туктала, беренче революцион адымнарын сурәтли, аның Татарстан һәм бөтен Россиядәге революцион хәрәкәт белән күпьяклы элемтәләрен ачыклый.

Икенче бүлектә М. Вахитовның Февраль революциясе чорындагы эшчәнлеге яктыртыла. Аның бу вакыттагы киң колачлы революцион эшчәнлеге Мөселман Социалистлар комитеты белән бәйле. Аның җитәкчелегендәге бу революцион оешма милләтче буржуазиягә каршы, бердәм агым теориясенә каршы килешмәүчән көрәшеп, татарларда сыйнфый аерымлануны тизләтте, революциядә пролетариатның җитәкчелеген тәэмин итүгә булышты, хезмәт ияләрен революцион һәм интернационалистик рухта тәрбияләүдә зур эш башкарды.

Монографиянең соңгы, өченче бүлегендә М. Вахитовның Бөек Октябрь социалистик революциясеннән соңгы эшчәнлеге сурәтләнә. Билгеле ки, М. Вахитов Мөселман эшләре комиссары, Үзәк мөселман хәрби коллегиясе председателе сыйфатында В. И. Ленинның турыдан-туры җитәкчелеге астында эшли. Р. И. Нәфыйков үзенең хезмәтендә «В. И. Ленин һәм М. Вахитов» темасының әһәмиятле аспектларын ача. Шул ук вакытта комиссариатның татар-башкорт хезмәт ияләре арасында алып барган күпьяклы пропаганда һәм оештыру эше анализлана, бу эштә М. Вахитовның роле ачык күрсәтелә.

Хезмәтнең кыйммәте шунда, аерым кешенең эше бөтен татар тормышындагы, бөтен ил тормышындагы революцион хәрәкәт фонында ачыла. Шуңа күрә дә шәхси биография гомуми, иҗтимагый вакыйгаларның фокустагыдай чагылышы булып алга килеп баса.

Р. И. Нәфыйков китабының публицистик рух белән дә сугарылган булуы олы революционерның язмышы хакында тирән кайгыртучанлык белән өртелүе игътибарны тагын да ныграк җәлеп итә.

**К. Ә. Нәҗипова. ТАТАРСТАНДА ПРОМЫШЛЕННОСТЬНЫ НАЦИОНАЛИЗАЦИЯЛӘҮ (1917—1921) (рус телендә). Мәскәү, «Наука» нәшрияты, 1976. 312 бит.**

Социалистик революциянең, капитализмнан социализмга күчүнең төп закончалыкларыннан берсе — җитештерү средстволарына капиталистик милекне юкка чыгарып, социалистик милек урнаштыру. Бу закончалыкны промышленностьны социалистик национализацияләү юлы белән тормышка ашырырга мөмкин. Татарстанда әлеге мөһим чара ничек үткәрелгән, аның нинди үзенчәлекләре булган? Монографиядә әнә шушы сорауларга җавап бирелә.

Казан губернасы промышленносте уртача үскән губерналар рәтенә кергән. 1917 елның беренче гыйнварена кадәр Казан губернасы фабрика-завод инспекциясенә буйсынган предприятиеләрнең саны буенча Россиянең Европа өлешендәге 47 губерна арасында 20 нче, фабрика-завод эшчеләре саны буенча 22 нче урында тора. 1913 елда Татарстан территориясендә 20 промышленность предприятиесе була.

К. Ә. Нәҗипова промышленностьны национализацияләүнең беренче адымы буларак продуктларны җитештерүгә һәм бүлүгә эшче контроле урнаштыру проблемасын тикшерә. Эшче контроле фабрика-завод комитетлары йөзендә Октябрьга кадәр үк барлыкка килә һәм Татарстандагы байтак предприятиене колачлый. Автор Казан партия оешмасының фабрика-завод комитетлары белән элемтәсен, аларга ярдәмен ассызыклап күрсәтә. Социалистик революциядән соң эшче контроленең роле һәм әһәмияте дә үзгәрә. Ул югарырак баскычка күтәрелә, социалистик революция бурычларын хәл кылу өчен көрәш формасына әверелә. Эшче контроле промышленностьның туктаусыз эшләвен тәэмин итеп кенә калмыйча, хуҗалыкка җитәкчелек итүнең яңа алымнарын үзләштерү мәктәбенә дә әйләнергә тиеш була.

Автор Татарстанда промышленностьны национализацияләү процессын тәфсилләп анализлый, аның үзенчәлекләрен дәлилли, әһәмиятен ача, мәсьәләне үзеннән элегрәк тикшергән галимнәрнең нәтиҗәләренә ачыклыклар, төзәтмәләр кертә.

Промышленностьны национализацияләүгә керешкәнче экономик органнар оештыруга зур игътибар бирелә. Пролетариат диктатурасының экономик политикасын тормышка ашыручы орган буларак халык хуҗалыгының югары Советы һәм җирле совнархозлар оештырыла. К. Ә. Нәҗипова аларның структурасын, функцияләрен, эшчәнлек юнәлешләрен һәм формаларын күп санлы яңа документлар белән дәлилләп ачып бирә. Аннары автор промышленностьның төрле тармакларында национализацияләүнең ничек гамәлгә ашырылуын күрсәтә. Әдәбият-сәнгать эшлеклеләре һәм әдәбият сөючеләр өчен шунысы кызыклы булыр: монографиядә полиграфия промышленностен халык милкенә әверелдерү процессы киң яктыртылган. Бу тармакта национализацияләү 1917 елда башлана, 1921 ел башына дәүләт карамагына күчкән типографияләрнең саны 28 гә җитә. 1921 елның маенда полиграфия промышленностен национализацияләү тәгәлләнә. Нәтиҗәдә, реакцион матбугат материаль базадан мәхрүм ителә. Әлеге база совет матбугатын һәм китап бастыру эшен юлга салырга, аларны халыкка хезмәткә куярга җирлек тудыра.

Китапта шулай ук дәүләт милкенә күчкән предприятиеләр белән идарә итү, продукцияне җитештерү һәм бүлүгә учет-контроль урнаштыру, социалистик дисциплина өчен, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү өчен көрәш, кадрлар әзерләү кебек мәсьәләләр киң яктыртылган. Монография бай библиография һәм таблицалар белән тәэмин ителгән.

К. Ә. Нәҗипова, Татарстанда промышленностьны национализацияләүнең 1921 елда тәгәлләнеп, экономиканың яңа законнар буенча кызу темплар белән үсүен, чәчәк атуын, социалистик хуҗалык итү системасының өстенлекләрен дә күрсәтә. Әлеге китапны укып, илебезнең бүгенге экономик куәте чыганакларына тирәнрәк төшенәбез, социалистик системаның өстенлекләрен калкурак итеп күз алдына китерәбез.

**ФЛОРИД ӘГЪЗӘМОВ,**
тарих фәннәре кандидаты.

# КЫЗЫК ӨЧЕН ТҮГЕЛ...

Рөстәм Мингалимовның «Бәхетле исем» китабы, жанр нигезендә, биш өлешкә бүленгән. Аларның беренчесендә фәлсәфи һәм кинаяле шигырьләр; икенче бүлектә хезмәт темасына багышланган әсәрләр; өченчесендә дуслык, бердәмлек турындагы әкият-шигырьләр; масаючылар, мактанчыклар, бушбугазлар турындагылары дүртенче тема; бишенче бүлектә табигать турындагы шигырьләр җыйналган. Билгеле, бу бүленеш шартлы рәвештә генә, чөнки шагыйрь иҗаты шушы биш темага гына сыеша алмый.

Балалар өчен язылган бу шигырьләрнең күбесен ак сакаллы агайлар да, язу таный башлаган малайлар да үз итеп, яратып укыячак, чөнки шагыйрь Рөстәм Мингалимов әсәрләре алты яшьтәгеләр өчен дә, алтмыштан узганнарга да рухи азык була ала.

**Көрәшәләр болыннарда,**
**Урманда-аланнарда.**
**Тәгәрәп алмаш өлгерә**
**Көрәшче агайларга!**

**...Малайлар атта киләләр,**
**Тояклар җирне кага.**
**Көчле малайлар үскәнне**
**Хәбәр итеп дөньяга**
**Тояклар җирне кага.**

«Тояклар җирне кага» шигырен укып бирәүләр сабан туе бәйрәме күренешенең оста сурәтләнүеннән зәукый ләззәт алса, икенче бер укучы шигырьдәге тел төбен, кинаяне аңлап калыр. Бу бит сабан туе күренеше генә түгел, шагыйрь сабан туе батырлары турында гына сөйләми икән ләбаса. Кыр батырларына, күк батырларына, хезмәт батырларына, көрәшчеләргә алмаш үсә дигән ышаныч белдерә автор.

Менә тагын бер кызык шигырь. Хәер, кызык дип әйтү шигырьнең көлкеле булуы турында түгел, фәлсәфәсенең әһәмиятле һәм кызык булуында. Сәләте һәм һөнәрләре була торып та үзенә дә, җәмгыятькә дә файда китермәгән кешеләр турында шагыйрь Рөстәм Мингалимов менә ничек әйтә:

**Бер карарга килә алмый йөргән.**
**Теләсә ул поши була алган!**
**Я мылтыклы аучы була алган!**
**Кем булырга! Шуны белми яшәп,**
**Ул йөз яшьлек бүре булып калган.**
**...Яшәрергә, хәзер яшь эт булып**
**Миңа нярергә тели икән.**
**Ләкин әйткәнемчә, аңа йөз яшь,**
**Инде аның сихере-сере беткән.**

(«Йөз яшьлек бүре турында», 39 бит.)

Балалар өчен кызыклы гына булган бу әкияттә олылар өчен дә әһәмиятле булган гыйбрәтле фикер бар. Татар халкының «Ак Бүре» әкиятен бүгенгегә кайтарып, шагыйрь кызык әсәр язган. Халык әкиятендә Ак Бүре төрле кыяфәтләргә керә ала, кешеләргә файда эшли. Ә Рөстәм әкиятендәге сәләтле бүренең бөтен гомере заяга узган. Гомумән, китапта әнә шундый тирән мәгънәле, гыйбрәтле шигырьләргә зур урын бирелгән: «Боз шәүлә», «Ишетелер авылга», «Үсми калдым» һ. б.

Рөстәм Мингалимов ялкаулардан, иренчәкләрдән олыларча акыллы итеп, сиздерми генә көлә дә белә.

**Ә шушы кыз бакчасына**
**Су сибәргә оныткан.**
**Шуңа күрә су күтәреп**
**Килеп җиткән болытлар.**

**Көннәрне тәмам бозды,**
**Аһ, бу кызны, бу кызны!**

(«Көннәрне тәмам бозды», 14 бит.)

Йокы батыры ялкау Булат («Батыр Булат» шигыре), булачак механизатор Хәйдән урынсызга мыскыллап көлүче Хөсәен («Хәй күршесе Хөсәен» шигыре) һәм башка тискәреләргә дә шагыйрь ачы тәнкыйтеннән өлеш чыгарган.

Масаю, көпрәю һәм төрле мактанчыклар турында язылган әсәрләр әдәбиятыбызда аз түгел. Үгездән көнләшеп кабара торгач шартлаган бака турында да укып беләбез. «Бәхетле исем» китабында да бу тема шактый үзенчәлекле чагылыш тапкан. «Бөтен дөнья күргәндер» мәсәле, «Куначада йоклый торган автомобиль» әсәрләре шуңарга ачык мисал булып торалар. Хыяллана торгач бер тавык автомобильгә әверелгән, имеш, әверелүен әверелгән, ләкин бәхет таба алмаган. Хәзер сары чебешләр иртеп бакчада бик йөрисе килә икән дә бит...

**Аннан менеп куначага**
**Бер йоклыйсы киләдер дә!!**
**Куначада йоклый торган**
**Автомобиль юк хәзергә.**

«Бердәмлектә көч», «Йөз сум акчаң булганчы, йөз дустың булсачы», «Аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» кебек бихисап мәкальләр белән татар халкы бердәмлек, дуслык, үзара ярдәм һәм кумәклекнең куәтен зурлаган. Бу нисбәттән Рөстәм Мингалимовның да балаларга әйтер сүзе юк түгел.

**Дошманны егып була —**
**Дусларың гына булсын!**

(«Дусларың гына булсын», 8 бит.)

**Яшьтәш малайларын яратмаган —**
**Алар аңа тиң дә түгел сыман.**
**Сер сөйләргә сердәш табалмаган —**
**Читләшкән ул таныш кызларыннан.**
**Уртасында җирнең ялгыз калган —**
**Ком чүлендә ялгыз казык сыман.**

(«Аңа ничек ярдәм итим икән?» 58 бит.)

«Өч әтәч һәм бер агай» әкиятендә дуслык, бердәмлек темасы бөтенләй башкача хәл ителгән.

**Бер әтәч кара булган,**
**Икенчесе ак булган,**
**Өченчесе кызыл булган,**
**Я ышанма, я ышан.**

**Кызыл һәм кара әтәч**
**Дуслашып та алганнар,**
**Ак әтәчне бер сумга**
**Сатарга уйлаганнар.**
**Уйлаганнар бер сумга**
**Алып ашарга ярма.**

Ләкин бу матур план тормышка ашмый кала—«зур куллы агай» әтәчләрнең өчесен дә бер капчыкка салып суярга алып кайтып китә. Мәсәл-әкиятнең мәгънәсе ачык: кардәшеңне сатып бәхетле була алмассың!

Р. Мингалимов халык авыз иҗаты әсәрләрендәге сюжет, тема һәм идеяларне дә оста гына файдалана белә. Халык иҗатындагы зирәклек, акыл көче, бердәмлек идеяләре белән сугарылган әкиятләр Рөстәм әсәрләрендә үзенчәлекле һәм яңача яңгыраш табалар. «Яхшылык һәм яманлык» әкияте шуның матур бер үрнәге булып тора.

«Төнге әкият» поэмасы да үзенең гыйбрәтле эчтәлеге белән игътибарны җәлеп итә. Шәһриташ каласында яшәүче барча җан иясе үзара талашып бер-берсен ашап, бер-берләрен сатып, кырып бетерәләр, Шәһриташны су басып китә. Һәр әкиятнең дә әйбәт тәмамлануы кагыйдә түгел ич, гөнаһлары өчен гөнаһлылар фаҗига күрергә тиеш дип саный шагыйрь.

Китапта табигатькә карата миһербанлы булу, аны саклау турындагы шигырьләргә дә зур урын бирелә. «Җәйнең эссе чагында», «Шундый уйлар», «Син гаепле сыман», «Быел миңа әллә нәрсә булды...» шигырьләре, бер яктан, туган як табигатенең гүзәллегенә чиксез соклану хисләре белән сугарылган булсалар, икенче яктан, табигатькә ваемсыз, миһербансыз булганнарга карата ачу-нәфрәт белән язылган әсәрләр. Шул ук темага багышланган «Аны шатлык җыры озата китәр» поэмасы да аерым игътибарга лаек.

Гомумән Рөстәм Мингалимов әсәрләре кызык өчен генә, көлке өчен генә язылмаган. Шагыйрь тирә-юньдәге күңелсезлекләрне күрергә, алар турында уйланырга, алар өчен ачынырга өнди.

Партиябез һәм хөкүмәтебез яшь буынны коммунистик рухта тәрбияләүгә гаять зур игътибар бирә. Һәр ватандаш — укытучымы ул, язучымы, сәнгатькәрме, яисә башка һөнәр иясеме — бу мөһим эшкә кулыннан килгәнчә өлеш кертергә тиеш. Р. Мингалимовның бу китабы, нигездә, шул олуг проблемага багышланган булуы белән аеруча актуаль һәм зур әһәмияткә ия.

РОБЕРТ БАТУЛЛИН.

# УРАЛДАН ХАТ

Башта ук шуны әйтим, мин бүгенге зур татар әдәбиятының күптәнге актив укучыларыннан берсемен. Милләтем буенча башкорт булсам да, Тукайлар, Такташлар, Ибраһимовлар иҗат иткән әсәрләрне укымый яшәүне күз алдыма китерә алмыйм.

«Казан утлары» журналында күренекле язучыбыз Ә. Еники, яшь тәнкыйтьчеләр белән очрашып, әдәбиятның тормыш белән бәйләнеше турындагы бик күп сорауларга җавап бирде. Мин бу хатны шул уңай белән язам да. Кайбер мәсьәләләрдә Әмирхан Еники белән килешә алмавымны белдерәсем килә.

Әңгәмәдә язучыга: «Басылып чыккан әсәрләрнең сәнгать дәрәҗәсе ник түбәнәя, сыйфаты төшә бара һәм безнең әсәрләр күңелне тартмый, укылмый, безне бер яктан да баетмый да, дулкынландырмый да?» дигән сорау бирелә. Минемчә, бүгенге татар совет әдәбиятына мондый бәя белән килешеп булмый. Чөнки хәзерге татар әдәбиятының укучыны мавыктыргыч, югары сыйфатлы бик күп әсәрләре бар. Бу әсәрләр, үз укучыларын табып, халыкның рухи байлыгына әйләнде инде. Аларны яратып укучылар күбәйде. Мәсәлән, Чиләбе шәһәрендәге татар-башкорт китапханәсенә йөрүчеләр белән фикер алышканда, шул нәрсә ачыкланды: күбесе татар язучыларының яңа әсәрләре белән кызыксына, аларны укып барырга тырыша. Сүз мондә тулаем әдәбият турында бара. Аерым әсәр, нинди генә зур күләмле булмасын, нинди генә олы талант белән язылмасын — бөтен әдәбиятны тәшкил итми. Шул бер китапны укып чыгу белән генә кеше тормышның бар якларын да күреп бетерә алмас. Андый могҗизаның булуы мөмкин түгел. Матур әдәбият укып рухи хәзинәңне баетырга, күңел теләкләреңне канәгатьләндерергә телисең икән, төрле темага, төрле жанрда язылган әсәрләр белән танышырга кирәк, дип уйлыйм. Тамчы тама-тама чиләк тула дигәндәй, төрлесен укый-укый бер уртак фикер туа бит.

Татар совет әдәбияты — киң диапазонлы әдәбият. Җылы ләйсән яңгыры җирне ничек яшәртсә, яхшы китаплар да күңелгә шундый шифалы була. Мондый әсәрләр татар әдәбиятында аз түгел. Яшь тәнкыйтьчеләр «әсәрләрнең сыйфаты түбәнәя башлады» дип нәтиҗә ясарга ашыкмасыннар димәкче булам.

Мин үзем тәнкыйтьнең оператив һәм үткен булуы ягында. Тәнкыйтьтән мәхрүм калган әдәбият үсүдән туктый. Ләкин мин, укучы буларак, берьяклы гына тәнкыйтьне хуплый алмыйм. Кимчелекләрне күреп тә, теге яки бу әсәрнең уңай якларын читләп узу кебек гөнаһтан арынган булсын ул тәнкыйть. Теләгем шундый.

Г. Әпсәләмовның «Ак чәчәкләр» романы басылып чыккач, бу әсәргә карата тәнкыйть фикерләре бик каршылыклы булды. Укучылар романны яратып каршылады, ә тәнкыйтьчеләр — аны «сүтеп ташларга» кереште. Әмма вакыт аңа үзенең гадел хөкемен чыгарды. «Ак чәчәкләр» — ил күләмендә киң таралган әсәр буларак танылды.

Без «Казан утлары» битләрендә Ә. Еникинең «Гөләндәм туташ хатирәсе»н зур кызыксыну белән укыдык. Журнал кулдан-кулга күчеп йөрде. Ш. Маннурның «Агым суларга карап» әсәре дә, автор үзе әйткәнчә, «йөрәк җыры, гомер китабы» булып укыла.

Журнал битләрендә без әдәбият тарихына кагылышлы материалларны көтеп алабыз. Хәзерге әдәби процесс белән үткән тарихны бергә бәйләп өйрәнү укучының дөньяга карашын киңәйтә, әдәби зәвыгын үстерә. Болар барысы бер бөтен хис — бүгенге татар совет әдәбияты белән горурлану тойгысы тудыра.

Шунысын да әйтәсем килә, күренекле язучылар журнал битләрендә «Бүгенге әдәбият һәм язучы» дигән темага әңгәмәләр белән катнашсалар, әдәби процесс тагын да җанлана төшәр иде.

**МӘХМҮТ ЯНБАЕВ,**
**Чиләбе өлкәсе,**
**Аргаяш поселогы.**

# ЯЗУЧЫГА БЕР СОРАУ

Мин китап «чире» йоккан кешеләрнең берсе. Язучыларыбызның моннан күп еллар элек иҗат иткән әсәрләрен дә, яңа китапларын да кулдан куймыйм. Күңелемдә — әдипләргә рәхмәт хисе. Укучыларга шатлык та, ял да, юаныч та бирүче ул талант иясе мең яшәсеннәр иде!

Соңгы арада танышкан яңа әсәрләрнең берсе Б. Камалов иптәшнең «Канатлы кырмыска» повесте булды. «Казан утлары»ннан укыдым аны. Шунда ук «Күршеләр», «Күңел кыңгыраулары» дигән китапларын да яңә күздән кичердем. Язучыга рәхмәт сүземне әйтәсем килә башлады. Бу хатны шуңа күрә язам да.

Хөрмәтле Барлас Камалов иптәш! «Канатлы кырмыска», минемчә, бик әйбәт, бик җиңел язылган. Четрекле тема алынган, кешеләрне һәрвакыт борчый торган хәлләр, шабашникларның комсызлыгы һ. б. сыйфатлары гәүдәләндерелә.

«Канатлы кырмыска»ны укый башлагач та, иң курыкканым шул иде: «Яшь кенә егет Ильяс шушы Самат комсызлыгының корбаны була гына күрмәсен!» — дип уйладым. Аның язмышы күңелне борчымаслык түгел. Шөкер, Ильяс исән калды. Ләкин тагын бер теләгемне әйтим. Самат үзе дә ниндидер вөҗдан газаплары кичерергә тиеш түгелме икән соң? Гомумән, аның тормыш тарафыннан «акылга утыртылуын» күрәсе килә. Әсәрдә шул як — Саматка сабак бирерлек вакыйгалар ачылмаган шикелле. Нишләп әле яшь кыз Нурсинә аңа бик җиңел һәм тиз генә теләктәшлек күрсәтә? Ышанырга моңа, ышанмаскамы? Әлбәттә, булдыклы кеше ул Самат. Әмма аның булдыклылыгы гел үз файдасына гына хезмәт итә. Монысы да табигый дип фараз кылыйк. Тик Саматларга «отпор» бирә торган көч тә бар бит тормышта. Шуны да ачасы, күрсәтәсе иде.

Ялгышсам, гафу итегез. Мин әсәрне ничек аңласам, шулай яздым инде.

**РӘШИДӘ ШӘРИФУЛЛИНА,**
Актаныш районы,
Пучы авылы.

# ЗАМАН ГЕРОЕ

„Казан утлары» журналының бишенче санында «Инженерлар» дигән әсәрне укыдым. Шуның хакында берничә сүз әйтмәкче булам.

Без, укытучылар, һәрчак өмет белән яшибез: үзебез белем биргән укучылар киләчәктә кем булырлар? Аларны дөрес тәрбиялибезме икән? Бу сораулар тынгы бирми. Җавапны тормышның үзеннән һәм әдәбияттан эзлибез.

М. Хәсәновның «Инженерлар» әсәрендә мин шундый кешеләрне очраттым кебек. Болар — Имам Хисамович, Ислам Имамович, Петр Ильич. КамАЗ гигантының инженеры Имам — хәзерге заманның һәм хәтта, әйтергә мөмкин, киләчәкнең белемле, культуралы, инсафлы кешесе. Теләсә нинди мәсьәләне хәл итә ала. Туган илнең чын патриоты. Чит илләрдән килгән делегацияләр белән аралашкан чакларда ул тагын бер ягы белән ачыла — төрле телләрне яхшы белә. Аның бу сыйфаты халыклар арасында хезмәттәшлек һәм дуслыкны ныгытуга булыша. Образ шулай үсә.

Имам Хисамовичның үз илен, туган телен, халкының гореф-гадәтләрен ихтирам итүен башка милләт кешеләре дә санлый. Билгеле, интернациональ дуслык төрле милләтләрнең бер-беренә ихтирам итешүдән туа инде.

Язучының мәхәббәт һәм гаилә мәсьәләләрен чагылдыруын да хуплыйсым килә. Аның геройлары мәхәббәттә йөрәк кушканын эшлиләр. Минемчә, бик дөрес бу.

Кыскасы, М. Хәсәновның «Инженерлар»ы — безнең көннәр таләбенә җавап бирә торган әсәр. Яшь буынны тәрбияләүдә безгә булышлык итәрдәй китап.

**МӨХӘММӘТ НУРМӨХӘММӘТОВ,**
мәктәп директоры.
БАССР, Башкорт Шиде авылы.

# СӘМУМ КИЧКӘН ГЕРОЙЛАР

Газиз Кашаповның «Сәмум җиле» повестен бер тында укып чыктым. Гыйбрәтле язмышлар, олы вакыйгалар игътибарны биләп алды.

Минемчә, авторның иң зур уңышы — Рамиз Җәләев образы. Аңарда безнең замандашларыбызга хас сыйфатлар тупланган. Илгә тугрылык, интернациональ дуслык, партия һәм халык эшенә бирелгәнлек, шуның хакына утка-суга керергә әзер тору кебек патриотик хисләр дулкыны укучыны да тыныч калдырмый. Совет Армиясендә хезмәт иту елларында ул үзен хәрби эшне һәм солдатлар психологиясен яхшы аңлый белгән командир итеп таныта. Монысы — чүлдәге эпизод. Ә инде интернациональ бурычын үтәгән чакта Рамиз — кыю һәм тәвәккәл сугышчы. Тик шунысы мине бераз гаҗәпләндерә: госпитальдә яткан чагында аңа ни солдатлар, ни командирлар — беркем хат язмый. Солдат дуслыгы болай булмый торгандыр, дип уйлыйм. Генерал Орловның Рамизга рухи тәэсире зур бит әнә. Ә үз частеның командиры хат язса, Җәләевка тагын да йогынтылырак булмас идеме икән?

Дөрес, Җәләев кемнәрнеңдер ярдәменә мохтаҗ түгел. Бөтен авырлыкны, яралар әрнүен, үлемне җиңәрлек көч бар анда. Ул терелеп аякка баскан чакта, аның белән бергә шатланасың. Үзенең кыюлыгы, ныклыгы белән күңелгә урнаша Җәләев. Безнең әдәбиятка Мересьевлар, Островскийлар рухының дәвамы булып керә. Үрнәк алырлык образ бу.

Мин, хатын-кыз һәм ана буларак, Ирина Андреевна образын төрлечә аңларга тырышып карадым. Кайбер очракларда аның тормышчанлыгына ышанасың, ә кайвакытларда килешеп җитә алмыйсың. Иң беренче чиратта, ул — хәрби кеше. Автор аны шулай сурәтли дә. Хәрби врач, авылда баласын калдырып, фронтка китә. Испания вакыйгаларында катнаша. Инде сугыш беткәнгә дә 11 ел, ә Ирина Андреевна һаман хәрби киемен салмаган. Киемен салмавы бер хәер, ул үзенең хатын-кыз, ана булуын да онытты, ахрысы. Испаниядән кайткач, Галләметдин абзыйның хатына ышанып, улын яки аның каберен күрергә дә бармый. Бөтен ил авыр көннәр кичергәндә Ирина Андреевнаның шәхси эшләрен алгы планга куймавы да аңлашыла, ләкин аны тормышчан образ итеп күрәсе килә. Әгәр дә ул: «Сугыш кырларыннан кайтмый калуым да бар, улымның каберен булса да күреп, хушлашып кайтыйм», дисә, укучы күзе алдында Ана образы тагын да калкурак булып басар иде. Юк бит, сугыштан соң да моны эшләми ул. Нинди ана йөрәге түзсен икән моңа?! Әсәрнең тәэсир көчен билгеле чамада йомшартып торган нәрсә шул түгелме икән дип тә уйлап куям. Аны коеп куйган врач итеп кенә түгел, хатын-кыз сурәтендә дә күрәсе килә. Тормыш туктамый лабаса, аңа күз сирпүчеләр дә булмый калмагандыр, үз йөрәге талпынып куйган минутлар да булгандыр. Кеше бит, бигрәк тә хатын-кыз, эше белән генә түгел, хисе белән дә көчле. Менә бу яктан Ирина Андреевна образында тормышчанлык житенкерәми шикелле. Һәрхәлдә, әсәр мине шушы җәһәттән ышандырып бетерми.

Сәмум кичсәләр дә, кешеләр кеше булып кала. Дөресрәге, шулай калу хокукын яклап сәмум кичәләр.

**РИММА ИСМӘГЫЙЛОВА,**
**Башкортстан АССР,**
**Туймазы шәһәре.**

# ШУЛ ДА БУЛДЫМЫ ӘХЛАК?

*Хезмәт иәләре иреген монополистлар җәбере булган капитал илләрендә: «Советлар Союзында кеше хокуклары чикләнелә һәм бозыла», дигән агулы һәм ачулы ялә сүзләре белән бик күпләр авыз чайкый. Моның быел җиденче дистәгә аяк басучы Дәүләтебезгә каршы мәкерле пропаганда икәне көн кебек ачык.*

*Безнең беркайчан да эшсезлектән интеккәнебез булмады һәм булмаячак. Үзенең һәр гражданын Ил түләүсез — хәтта үзе түләп! — укыта, түләүсез дәвалый, карт көнендә ярдәмсез калдырмый. Парламентка сайланганда да, осталыгы һәм сәләтен фәнгә, сәнгатькә, художестволы иҗатка багышлаганда да барча милләт вәкилләре бертигезләр... Менә шундый алар, закон сүзләре белән Конституциягә язылган безнең хокуклар! Аларның һичкайчан чикләнгәне яки бозылганы булмады һәм булмас. Патриотлар һәм интернационалистлар булган совет кешеләренең морале — кешеләргә теләктәшле, ярдәмчел һәм гуманлы мораль ул. Әйтелгән яки язылган сүзләр генә түгел, ә дәүләт тарафыннан бөтен яктан тәэмин дә ителгән күренешләр болар! Атаклы әдип Марк Твен үз заманында: «Америка Кушма Штатларында законнарның һич тә чиге юк, һәм аларны тормышка ашыруның башлануы да һич булмый»,— дип язган. Буржуаз илләрдә законнар һәм хокуклар мәсьәләсе хәзер дә нәкъ шулай. Алар берничек тә тәэмин ителми һәм теләсә ничек бозыла, шуңа күрә дә... алар кешеләрне бозык моральле итә.*

*Күбесе чит илләрнең үз чыганакларыннан сайлап алынган түбәндәге чәнечкелешаян парчаларны «Шул да булдымы әхлак?» дип елмаймыйча һәм көлмичә уку мөмкин булмастыр кебек.*

## УРТАКЛЫК

— Синьор, миңа мең лира акча биреп торсагыз икән: иртәдән бирле бернәрсә ашаганым юк.

— Мин дә шулай.

— Алайса, ике меңне бирегез һәм кичке ашка мин сезне чакырырмын.

## ТӨРЛЕЧӘ УТЕНУ

Хәер соранып йөрүче берәү урамда чамасыз юан ханымны очрата.

— Зинһар ярдәм итсәгез икән, мин менә өч көн инде бернәрсә капканым юк!

— И ходаем! Миңа да шундый ихтыяр көче бирсәң иде лә!

## СҮЗНЕ БҮТӘНГӘ БОРУ

— Минем эш хакымны бераз күтәрә алмассызмы икән, хуҗам, юкса, хатыным ганлә расходларыбызның очын-очка ялгый алмый!

— Мин сезне аңладым, мистер Браун, ә нигә соң сез экономиялерәк бүтән хатын алмыйсыз?

## ИСКЕ БӘЯ БЕЛӘН

— Бүгеннән башлап икмәккә бәяләр күтәрелде бит.

— Ә сез миңа кичәге ипине бирегез.

## ТАГЫН ИКЕСЕ КЕМ

Джек исемле ялчы көннәрнең берендә үз хуҗасына әйтә икән:

— Мин сездә инде өч ел хезмәт итәм. Өч кеше башкарасы эшне көн саен бирүзем эшлим. Ә эш хакын... бары тик берне генә алам. Миңа өстәмә түләү кирәктер дип уйлыйм.

— Юк, — ди хуҗа. — Мин сиңа бернәрсә дә өсти алмыйм. Әмма син теге ике кешенең исем-фамилиясен әйт. Мин аларны, әлбәттә, эштән чыгара алам!

## БАКЧАДА

— Сез хәзер буйый торган бу эскәмия кичке сәгать тугызларга чаклы кибеп җитәр микән? — дип сорый бер хәерче.

— Ә ник сорыйсыз моны? — ди буяучы.

— Чөнки мин бик соң йокларга ятарга яратмыйм.

## ОЯТЫ КАЧКАН

— Урамда болай теләнеп йөрергә ничек оялмыйсың?

— Өемә китереп бирсәләр шәп булыр иде дә бит, фатирым юк шул минем...

## ЮМАРТ ИР

— Син беләсеңме, үләр алдыннан Мартинес үзеннән калган бар байлыгын балалар йортына бирергә васыять әйткән.

— Кара нинди юмартлык! Ә нәрсәләре калган соң аның?

— Биш баласы!

## УРЫНСЫЗ ҮЛЕМ

— Ә син үзеңне күпмегә страховать иттең?

— Ун мең гульденга.

— Ни бары шулай гынамы? Моның өчен генә үлүнең кирәге дә юктыр, минемчә...

## КАЙГЫРМАГЫЗ...

Яңа фильм төшергәндә режиссер актерга катгый боерык әйтә:

— Сез, Билл, менә шушы текә ярдан түбәнгә сикерергә тиеш буласыз.

— Анда мәтәлгәндә минем муеным сынмасмы соң?

— Кайгырмагыз, бу — фильмның иң соңгы кадры ич.

## КЕМ НИЧЕК КЫЗЫКСЫНА

— Базарга алып чыгарлык дәрәҗәдә ябык булсын өчен бу тавыкка нәрсә ашаттыгыз сез? — дип сорый бер юан ханым.

— Ник бу хәтле кызыксынасыз?

— Минем дә ябыгасым килә.

### УРЫН ТАБУ

Урам уртасында яткан бер ханым янына полицейский килә:
— Хәлегез начармы әллә?
— Юк, хәлем яхшы. Иремнең машинасын куярга урын алдым.

### НӘРСӘ АЛДЫҢ!

— Мин үз тавышымны илле мең долларга страховать иттем, — ди бер җырчы ханым.
— Ә ул акчага нәрсә алдың соң? — дип сорый аның ахирәте.

### РӘХИМ ИТЕП...

— Гафу итегез, сэр, якын-тирәдә полицай күрмәдегезме?
— Юк, күренмәде.
— Рәхмәт. Алайса, рәхим итеп, сез миңа хәзер үк янчыгыгызны чыгарып бирегез.

### АҢЛАТУ

— Һич аңлый алмыйм, нигә соң әле миссис Джонс тавышын күкләргә чөеп мактыйсыз. Миссис Смит тавышы аныкыннан күп яхшырак бит.
— Аның каравы, миссис Джонсның әтисе күп тапкыр баерак.

### ТҮЛӘҮСЕЗ БИРЕЛМИ

Лондон трактирчысы полиция чакыра:
— Инспектор әфәнде! Менә бу әрәмтамак миннән аракы сорый, ләкин түләүсез булсын ди. Шуны үз идарәгезгә алып китегез, зинһар!
— Нишләп алып китәргә ди? Аракы бит бездә дә түләүсез бирелми.

### УЙЛАГАН

— Сез ул кибетне басарга кергәндә хатыныгыз, балаларыгыз турында уйладыгызмы?
— Уйладым, әмма аларга яраклы бернәрсә дә таба алмадым.

### ЗУР ЫШАНЫЧ

— Газетага биреп бастырылган игъланнарның нәтиҗәле булуына ышанасыңмы син?
— Әлбәттә, ышанам. Мин, мәсәлән, кибетемә каравылчы кирәк дигән белдерү биргән идем, шул төнне үк кибетемне бастылар.

### ЯРЛЫ КЕШЕ

Монте-Карло каласындагы бер казино залыннан карта уйнап бик күп акча откан берәү чыга. Караңгы урамда аңа икенче берәү эндәшә:
— Мсье, фәкыйрегезгә ярдәм итмәссеңме икән? Аның бит кулындагы менә шушы револьверыннан башка бер генә байлыгы да юк...

## ТАНЫШУ

Бер мәҗлестә ике инглиз таныша:

— Даммингс булам мин. Промышленник: күмер һәм кокс.

— Ә мин — Блэкстон. Төрмә начальнигы: ипи белән су...

## ИКЕ ГАНГСТЕР ГӘБЕ

— Я, Джон, эшләрең ничек бара?

— Бер дә зарланырлык түгел шикелле. Кичә яңа автомобиль сатып алдым, бүген үз районыбыз судьясын һәм полиция комиссарын сатып аласы бар.

## АКЧА ТҮЛӘТЕР ӨЧЕН

Америка төрмәсендә бер җинаятьчене электр урындыгына утыртырга алып баралар.

— Безгә якын туганнарыгызның адресын бирегез, — ди төрмә күзәтчесе.

— Минем гәүдәмне илтеп бирер өчен кирәкме?

— Юк, электр өчен акча түләтергә.

## КАССИРЛАР САНЫНЧА

Корал кибетендә берәү иң яхшы пистолет сатып алмакчы.

— Сезгә алты пуля белән корыла торганы кирәкме, әллә сигез беләнме?

Шуннан клиент кибеттәге телефоннан каядыр шалтырата:

— Алло! Бу Морган банкысымы? Әйтегез әле, зинһар, сездә ничә кассир эшли?

## ЯЛГЫШ УЙЛАГАН

Мотоцикллы полисмен машинага утырган бер ханымны куып тота.

— Мин кычкырганда нигә туктамадыгыз?

— Гафу итегез, сэр, мин аны сезнең тавыштыр дип белмәдем... машинам белән таптатып узган кеше кычкырадыр дип уйладым.

## ИКЕСЕ ДӘ АЛТЫН

— Әнә теге урам чатында минем алтын сәгатемне салдырып алдылар.

— Ә нишләп шул чакны кычкырмадыгыз?

— Кычкырырга ярамый иде шул — авызымда дүрт алтын тешем бар бит минем.

## ИКӘВЕ ДӘ БЕР ҖИРДӘ

Зур бер сәүдә фирмасының ике эре компаньоны ресторанда кичке мәҗлестә утыралар икән. Кинәт шуларның берсе урыныннан сикереп тора:

— Ай аллам, сейфымны бикләргә онытканмын бит мин!

— Тыныч бул, дус кеше, без бит икебез бергә монда утырабыз.

## СЫЙФАТ ӨЧЕН КӨРӘШ

Техастагы корал кибетенә берәү килеп керә һәм пистолет сатып алырга тели.

— Ник кирәк ул сезгә? — дип сорый сатучы.
— Күршемне атып үтерергә телим.
— Мин сезгә иртәгә хәтле түзәргә тәкъдим итәр идем.
— Ни өчен?
— Сез бүген бик ачулы күренәсез һәм бик дулкынлангансыз, атсагыз да тидерә алмассыз шикелле.



### ИРЕДЕР ДИП УЙЛАП

Төнлә бер өйгә карак керә. Башына хуҗа хатыны суккач, ул хуштан язып егыла — полиция килгәндә дә әле аңына килә алмый ята.
— Котлыйбыз, мадам. Сез бик кыю икәнсез!
— Алай ук күкләргә чөеп мактамагыз ла. Мин бит аны иремдер дип уйлаган идем.

### КӨНДӘШЛӘРЕ КҮП

— Сез сейфны ничек итеп ачтыгыз? — дип сорыйлар Чикагода зур йорт баскан бераүдән.
— Юк, мин бу сорауга монда җавап бирә алмыйм, чөнки залда бик күп конкурентларым утыра.

### ТЕАТР ЯНЫНДА

— Монда нишлисең син, Пауль?
— Ничек нишлим ди? Хатыным белән театрга килдек.
— Ә ник театрга кермисең?
— Бүген машинабызны сакларга минем чират.

### ҮСЕШ ТИЗЛЕГЕ

— Бу сөйкемле чал джентельмен кем соң ул?
— Төрмә начальнигы.
— Күр син аны, нинди тиз күтәрелгән! Ул бит карьераны төрмәдә утырудан гына башлады.

### СЕРЕ БЕР ГЕНӘ

— Төрмә сагы бик начар эшли, — ди инспектор төрмә начальнигына, — әмма соңгы елларда бер генә тоткын да качмаган. Моны нәрсә белән аңлатасын?
— Һәр көн иртән, инспектор әфәнде, мин тоткыннарга газиттән иректәге тормыш шартлары һаман саен начарлана баруы турында хәбәрләр укыйм.

### АЕРМА

Бераү гостиницага килеп керә һәм:
— Буш урыннар бармы? — дип сорый.
— Ике урын бар,— дип аңлата администратор,— берсенең хакы егерме, икенчесенеке утыз франк.
— Ә аларның аермалары нинди соң?
— Утыз франклы номерда тычкан тота торган тәбе бар.

### ТАМАГЫ ТУК

Синьор кунаклар китә. Шул чакны аның өендә телефон шалтырый.
— Карале, дус кеше, мин бүген сиңа килә алмыйм бит.
— Ник? Нәрсә булды? Әллә чирләдеңме?

— Юк. Берни дә булмады.
— Ә ник килмисең?
— Чөнки тамагым тук.

### АЛАЙ ТҮГЕЛ...

— Ул мине ишәк дип атады, судья әфәнде!
— Бәлки аның бик ашыккан чагы булгандыр?
— Юк, һич алай түгел! Ул башта миңа бик озак һәм бик нык игътибар белән карап торды.

### ИКЕСЕ БЕРГӘ

— Прессон өйләнгән дип ишеттем. Яратып алдымы икән кәләшен, әллә малына кызыгыпмы?
— Минемчә, монда икесе дә бар кебек: кызны байлыгына кызыгып алган, ә акчасын — яратып.

### ВӘГЪДӘ ИТКӘН ИКӘНСЕҢ...

— Карагыз әле, синьор, машинагызны мин сатып алганда аның бер ел эчендә бозылган яки эштән чыккан бөтен нәрсәсен миңа соңыннан бирергә вәгъдә иткән идегез, әйе бит?
— Вәгъдә иткән идем шул.
— Шулай булгач, рәхим итеп, миңа сул аякның бот сөяген һәм ике кабыргамны бирегез.

### ТАГЫН БЕР ТӨШ КҮР

— Төшемдә кара төстәге яңа машина алганыбызны күрдем, — ди фрау Мюллер, җиде төн уртасында ирен уятып.
— Икенче ягыңа әйләнеп ят, бәлки машина алырлык акча безгә каян киләсен дә күрерсең.

### БИШЕНЧЕ ТАПКЫР

Голливуд кинойолдызы бишенче тапкыр иргә чыга. Бу юлы — француз рәссамына.
— Бу никах сезне бәхетле иттеме?
— Бик тә, бик тә бәхетле итте! Моннан соң мин һәр вакыт француз рәссамнарына гына иргә чыгачакмын.

### НИШЛӘМӘК КИРӘК

— Минем белән очрашканчы син инде ике хатын аергансың дип сөйлиләр, дөресме бу?
— Нишләмәк кирәк, мин хатыннарның бары тик иң шәпләрен генә сайлый беләмдер, күрәсең, шуңа күрә аларга бүтәннәрнең дә өйләнәсе килә.

### ИКЕ ХАНЫМ СӨЙЛӘШӘ

— Элек хатын-кызлар ир-затта нинди яхшы яклар күрделәр икән? Шуны беләсе иде...
— Кайчан элек?
— Әле акча дигән нәрсә уйлап табылганга чаклы.

### ЯРАТМЫЙДЫР ТӨСЛЕ

— Беләсеңме, Аннет, ирем мине яратмыйдыр төсле тоела.
— Ник алай уйлыйсың?
— Минә икенче ел инде аның өйгә кайтканы юк.

### ЯҢАЛЫК

Тычкан тәбеләре сатучы бер фирма кешесе ишек шакый.
— Ә безнең тәбебез бар инде, — ди хуҗа.
— Бу бит әле күптән түгел генә уйлап табылган өр-яңа төр тәбе — без аны тычканы белән бергә сатабыз.

### ТАБЫШЛЫ КҮРЕШҮЛӘР

— Баламны дәвалаган өчен бик кыйммәт сорыйсыз, доктор.
— Ул кызамык белән авырганда сезгә мин унлап тапкыр килдем бит.
— Ә минем балам, бөтен класска кызамык йоктырып, сезгә аз табыш китердемени?!.

### СӘЕР САН

— Ни өчен терлекләр кешеләргә караганда азрак чирли?
— Чөнки бездә утыз врачка сан ягыннан бер ветеринар гына туры килә икән.

### ЫШАНУ

— Минем кызым алтын тәңкә йоткан, аңа ашыгыч операция эшләргә кирәк. Шуны доктор Робинсонга ышанып тапшырырга мөмкинме?
— Һичшиксез. Ул чын мәгънәсендә намуслы кеше.

### КИЛМӘСЕН ИДЕ

Больницада ятучы бер бай промышленник санитар кызга әйтә икән:
— Хәлемне белергә минем варисым килмәвен бик теләр идем. Чөнки ул минем белән исәнләшеп кулымны кысканда һәр вакыт кан тибешемне капшап карарга ярата.

### БҮЛӘГЕ ДӘ БАР

— Чәч үстерә торган берәр дару юкмы сездә?
— Менә дигән препарат бар! Әгәр шуны берьюлы ун флакон сатып алсагыз, бүләк итеп, сезгә бер парик та бирәчәкбез...

### АШЫГЫЧ СОРАУ

— Бу «Ашыгыч ярдәм»ме? — дип телефон шалтырата берәү. — Һәм сөйләп китә. — Биредә бер кешенең хәле бик начар... Карагыз әле, сезнең тавышыгыз чиксез матур ишетелә! Бүген кичен кайда булырга һәм ни эшләргә җыенасыз икән? — шуны беләсе иде...

### ҮЛЕМНӘН КОТЫЛУ

— Синең этең мине үлемнән коткарды.
— Ничек итеп?
— Мин чирләп ятканда ул безнең йортка врачны кертмәде.

## СӘБӘБЕ БАР

— Һәр кичне шушы тол ханым Браун өендә чәйләр-мәйләр эчеп утырасың. Ник соң шуның белән никахлашмыйсың инде?

— Мин үзем дә бу хакта уйлаштыргалыйм, — ди Джонс. — Әмма өйләнешсәк, кичләрен мин кайда ял итәрмен икән?!

## ГӨНАҺЫН ӘЙТТЕРМӘКЧЕЛӘР

Үлем түшәгендә ятканда Американың бер сенаторы тәүбә сүзләрен әйтә:

— Мин казна акчасын урладым, мошенниклар һәм гангстерлар белән эш иттем, карт-корыларны һәм ятим балаларны ач тоттым, минем өчен иң мөһиме акча иде, кулымда властьны тоту иде...

— Җитте сиңа,— ди изге ата аңа,— политиканы калдырып торыйк, нинди дә булса гөнаһлы эшләрең булмадымы? Шул турыда әйт син.

## АКЫЛЛЫ ХӘЙЛӘ

— Баш кассирның банктагы бөтен акчаны урлап Көньяк Америкага качу фактын мин әле аңлый алам. Ә менә аңа директорыбыз хатынын да нярту ниемә кирәк булды икән?

— Бик акыллы эшләгән ул. Аны бит хәзер директор һичкайчан да эзләп тормаячак.

## ПЛЕНКАСЫ ЮК

Берәү күпердән торып елганы сурәткә төшерә икән. Аның янына бер ханым йөгереп килә дә кычкыра:

— Анда бер кеше бата!

— Кызганычка каршы, минем пленкам бетте шул инде,— ди фотограф кулларын җәеп.

## ЭТЕ ТАНЫМАГАН

— Битегезне кем шулай тырнап бетерде, мистер?

— Үз этем.

— Ничек шулай булды соң?

— Беләсезме, ул кичне мин эчмичә кайткан идем һәм этем... мине танымады.

## ӘЙБӘТ НӘТИҖӘ

— Барган курортыгызда дәвалануларыгыз ничек булды, мадам Винсент? Теләгәнегезгә ирешә алдыгызмы?

— Нәтиҗәгә һичшиксез ирештем, доктор әфәнде: ике кызымны да кияүгә биреп кайттым.

## БУШ УРЫН

Футбол карарга ханым үзе генә килгән. Янында бер урын буш. Стадиондагы таныш-белешләр сорыйлар:

— Ә ник ирегез килмәде?

— Ул үлде бит.

— Алайса, туганнарыгыздан берәрсен чакырасыгыз калган.

— Туганнарым барысы да аны күмәргә киттеләр.

## АШЫГУ

— Кая чабасың бу хәтле ашыгып, танышыңа сәлам биреп узарга да вакытың юкмы әллә?

— Гафу ит, бик ашыгам шул. Шефымны күмәргә барышым иде, ә ул соңга калуларны бер дә яратмый.

## НИЧЕК КҮМӘРГӘ!

— Мәетне кайсы разряд белән түләп күмдерергә телисез, мсье?

— Иң арзанлы белән — дүртенче разрядтан.

— Ә сез беләсезме соң дүртенче разрядның нәрсә икәнен? Ул — венокны мәет үзе күтәреп бара дигән сүз.

## НИК БАРСЫН...

— Син Янсонны күмәргә барачаксыңмы?

— Нишләп барыйм ди? Ул бит мине күмәргә килмәячәк!

## БУТАЛЫШ

— Әнә теге кыска чәчле һәм сигарет тартып утырган бала малаймы, кызмы?

— Кыз һәм, шуны да белегез, минем кызым ул!

— Гафу итегез, сэр, сез аның әтисе дип мин һич уйлый алмас идем.

— Ә мин аның әтисе түгел, анасы булам!

## «ӘЙБӘТ МАЛАЙ»

— Джон — бик әйбәт малай ул, — ди укытучы бер дәрестә. — Дусты суга батканда аны коткарып калган. Әйт әле, Джон, шундый батырлык кылганда нәрсә уйлап эш иттең син?

— Дус малаем минем трусикны киеп суга сикергән иде.

## БАЛА БЕЛӘН АТА СӨЙЛӘШӘ

— Мин бит сиңа шырпы белән уйнама дип әйттем. Әллә оныттыңмы шуны?

— Мин бит шырпы белән уйнамыйм, тәмәке генә кабызам.

## БУЛУ-БУЛМАУ

Бәләкәч бер америкалы малай: «Миңа автомат пистолет ал!» — дип атасын аптырата. Атасы алырга теләми:

— Мин семья башлыгы булган чагымда синең кулга пистолет эләкмәячәк.

— Ә минем пистолетым булу белән син семья башлыгы булып калмаячаксың...

## АБЫЙСЫ ЭНЕСЕН ЭЗЛИ

— Минем туганымның улы сезнең интернатта үзен ничегрәк тота?

— Ә сез аның абыйсымыни? Ул бүген иртән сезнең җеназага киткән иде бит...

## ТУКТА, ӘНИ!

Бала әнисеннән үтенә:

— Зинһар өчен, әтине башы белән стенага бәрә-бәрә кыйнаудан тукта инде, юкса, аның зиһененә зыян килер дә ул миңа мәсьәләләр чишеп бирми башлар.

## КЕМ НӘРСӘ САТЫП АЛАЧАК!

— Юньсез бала! Син бит Смит ханым малае белән тагын сугышкансың! Тагын өр-яңа күлмәк сатып алырга кирәк...

— Күлмәк нәрсә ул! Ә Смит ханымга малай сатып алырга кирәк булачак әле!

## РЕЦЕПТ ҮЗГӘРӘ

Бер бизнесмен үзен дәвалаган врачка шуны белдерә:

— Мине даими кайгырткангыз өчен бәхиллим һәм рәхмәт йөзеннән, мин сезне, доктор әфәнде, үземнең васыять кәгаземә теркәмәкче булам. Мин үлгәч сезнең кулга миллион доллар акча керәчәк.

— Рәхмәт! — ди доктор һәм шунда ук өстәп куя: — Мин сезгә әле хәзер генә язып биргән рецептны кире бирегез әле. Аңа кайбер төзәтмәләр кертәсе бар икән.

## КИТӘ ҺӘМ КИЛӘ

— Әгәр алай икән, мин хәзер әнием янына кайтып китәм! — дип кычкыра чыгырыннан чыгып ачуланган хатын үзенең иренә һәм шуны өстәп куя: — Аннары аны бездә торырга алып киләм.

## ТЕЛ КҮРСӘТҮ

Бәләкәй генә бер авыл яныннан поезд узган саен тимер юл буена бер карт килә дә машинистка телен чыгарып күрсәтә икән. Шуны күп мәртәбә күргән берәү: «Ник машинистны алай үртисең?» дип сорый карттан.

Тегесе хәйләле елмая да әйтә:

— Аңа тел күрсәткән саен, ул, миңа тидерим дип, бер ташкүмер кантары ыргыта, ә мин шул күмер белән мич ягам.

## ПЛЯЖДА

— Әллә бирегә эш сәгатьләрендә коенырга йөрисеңме?

— Монда мин эшем буенча йомыш белән киләм.

— Нинди йомыш?

— Үземә яңа секретарь сайлыйм.

## ИПИ ШҮРЛЕГЕ

Сыраханәгә килеп кергән бик ябык һәм тәбәнәк буйлы бер ковбой шунда күргән озын һәм таза гәүдәле берәүгә әйтә икән:

— Ипи шүрлегенә кундырганны телисеңме?

— Әйе, — ди теге эре генә.

— Алайса, син әнә теге күрше сыраханәгә кер, минем шүрлеккә әле яңа гына шунда менеп төштеләр.

## КОММУНИСТЛАР КИҢӘШӘ

Партия Үзәк Комитетының яшь әдипләр һәм сәнгать вәкилләре иҗатын кайгырткан карарына җавап итеп, Татарстан Язучылар союзында яшь каләмнәр белән эшләү аеруча игътибар үзәгенә куелды.

Союз идарәсе каршында яшьләр белән эшләү өчен махсус комиссия төзелде, консультация бюросына тәҗрибәле язучылар беркетелде. Язучылар партия оешмасының һәм Союз идарәсенең утырышларында яшьләр белән эшләү мәсьәләләре әледән-әле тикшерелеп тора.

Язучылар союзы каршындагы партия оешмасының август ахырында үткәрелгән утырышында шул ук мәсьәлә куелып, консультация бюросы җитәкчеләре Илдар Юзеев һәм Михаил Скороходовлар доклад ясады. Фикер алышуларда Язучылар союзы председателе Гариф Ахунов, местком председателе Абдулла Шәрәфетдинов, язучы Нәби Дәүли, яшь тәнкыйтьче Мансур Вәлиев һ. б. чыгыш ясады.

## ЯҢА ТӘРҖЕМӘЛӘР

Мәскәүдәге «Художественная литература» нәшрияты «Бөтендөнья әдәбияты китапханәсе» сериясеннән 179, 180 томнарда «Совет поэзиясе» дигән китаплар бастырып чыгарды.

Бу китапларның беренчесенә татар шагыйрьләреннән олы буын вәкилләре Һади Такташ (Л. Мартынов, Р. Моран тәрҗемәләре), Әхмәт Ерикәй (С. Липкин, Б. Ахмадуллина, Е. Евтушенко, Я. Козловский тәрҗемәләре), Хәсән Туфан (Р. Моран тәрҗемәсе), Муса Җәлил (С. Липкин, Э. Багрицкий, Б. Зернит, М. Львов, В. Ганиев, Л. Пеньковский, И. Сельвинский, С. Маршак тәрҗемәләре) шигырьләре бирелгән.

«Совет поэзиясе» китабының икенчесендә Сибгат Хәким (Р. Моран, Р. Кутуй, Н. Беляев тәрҗемәләре) һәм Равил Фәйзуллин (Р. Кутуй тәрҗемәсе) әсәрләре урнаштырылган.

*
* *

Мәскәүнең «Советский писатель» нәшрияты Горький һәм Тукай премияләре лауреаты, шагыйрь Сибгат Хәкимнең поэма һәм шигырьләрен туплап, «Врата времен» дигән китап чыгарды. Китапка Сибгат Хәким биографиясе һәм иҗаты турында кыскача белешмә, шагыйрьнең фоторәсеме урнаштырылган. Шигырьләрне Р. Моран, Р. Кутуй, Н. Беляев һәм Р. Хәкимовлар тәрҗемә иткән. Күләме 5 табак, тиражы 17 мең. Художнигы М. В. Эльконина.

*
* *

«Детская литература» нәшрияты Рафаэль Мостафинның «Муса Җәлил» дигән китабын басып чыгарды. Герой шагыйрьнең балалык һәм яшьлек еллары турында сөйләгән бу китапның тиражы 50 мең.

*
* *

Украин телендә «Совет поэзиясе антологиясе» чыгарга әзерләнә. Украин укучылары бу антология аша татар халкының төрле буын шагыйрьләре иҗаты белән танышачаклар. Бөек Ватан сугышында һәлак булган Муса Җәлил, Рәхим Саттар, Әгъзам Камал, Мансур Гаяз, Фатих Кәрим, Хәйретдин Мөҗәй кебек татар язучыларының иҗатына да бу китапта киң урын биреләчәк.

*
* *

Алма-Атаның «Казахстан» нәшриятында философия фәннәре докторы, профессор Касыйм Бейсембиевның «Казагыстанның иҗтимагый-политик һәм фәлсәфи фикерләр тарихыннан очерклар» дигән китабы басылып чыкты. Бу китабында автор беренче татар большевистик газета «Урал»ның редакторы Хөсәен Ямашев эшчәнлегенә дә киң туктала.

«Хөсәен Ямашевның революцион һәм әдәби-публицистик эшчәнлеге революцион-азатлык хәрәкәтендә гадәттән тыш әһәмиятле һәм эшлекле күренеш булды дип әйтергә төпле нигез бар. Большевизмның башланган чорында ук дөньяга көчле марксист-пропагандистны, эшче халкының азатлыгы кебек бөек эш өчен тормышын корбан иткән кешене, Ленин гвардиясе солдатын биргән татар иҗтимагый фикеренең гаять зур күтәрелештә булуына дәлил иде ул»,— дип яза К. Бейсембиев.

*
* *

СССР Госстрое каршындагы гражданлык төзелеше һәм архитектурасы буенча Дәүләт комитеты һәм СССР Архитекторлар союзы органы булган «Архитектура СССР» журналының июнь санында «Казан архитектурасының үсеш юллары» дигән зур мәкалә басылган. Мәкаләнең авторы — Архитекторлар союзының Татарстан бүлеге

председателе Сәйяр Айдаров. Шул ук сандагы икенче мәкаләне архитектор Г. Пичуев язган. Ул «Казанның гомум шәһәр үзәге» дип атала. Шәһәребездәге торак төзелешләренә багышланган өченче мәкаләнең авторлары Татгражданпроект институтының генераль планнар бүлеге начальнигы Г. Солдатов һәм шул ук институтның баш архитекторы И. Галинин.

Журналның тышлыгына В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының яңа уку корпусы, ә эчендә исә шәһәребездә барган яңа төзелешләрдән күп санлы фотолар урнаштырылган.

## КЫЗЫКЛЫ ОЧРАШУЛАР

Татарстан Язучылар союзының Г. Тукай исемендәге клубында Башкортстанның халык шагыйре, СССР Дәүләт премиясе, Станиславский исемендәге һәм Салават Юлаев исемендәге премияләр лауреаты Мостай Кәрим белән очрашу булды.

Очрашуда язучылар, шагыйрьләр, әдәбият белгечләре һәм күп санлы әдәбият сөючеләр катнашты. Шагыйрь аларга үзенең яңа шигырьләрен укыды, иҗат планнары белән уртаклашты, күп төрле сорауларга җаваплар бирде.

*
* *

Муса Җәлил һәм җәлилчеләрнең тормыш юлын, фашистларга каршы көрәшен, герой шагыйрьнең иҗатын өйрәнүче Рафаэль Мостафин Пермь өлкәсендәге татар теле укытучылары белән очрашты. Аларны татар әдәбиятындагы яңалыклар белән таныштырды. Пермь телевидениесыннан чыгыш ясап, Җәлил һәм аның көрәштәшләре турында сөйләде.

*
* *

Казанның Укытучылар йортында балалар язучысы Ләбибә Ихсанова белән төрле өлкәләрдән килгән татар теле укытучылары очрашты. Балалар әдәбияты, яшь буынны тәрбияләү — сөйләшүнең төп темасы шул иде.

*
* *

Ижевск шәһәрендә, Бөек Октябрьның 60 еллыгына багышлап, совет әдәбияты бәйрәме уздырылды. Бернична көнгә сузылган бу бәйрәмгә күрше республикалардан, өлкәләрдән төрле милләт язучылары, шагыйрьләре чакырылган иде. Алар завод-фабрикаларда эшчеләр белән очраштылар, М. Горький исемендәге ял паркында чыгыш ясадылар. Бәйрәмдә Татарстаннан шагыйрь Роберт Миңнуллин катнашты. Ул әлеге әдәби кичәләрдә, очрашуларда, шулай ук Ижевск телевидениесендә чыгышлар ясады.

*
* *

Татарстан Язучылар союзының тәнкыйтьчеләр секциясе тәнкыйтьчеләрнең әдәбият сөючеләр белән очрашуларын һәм аларга хәзерге әдәбиятның актуаль мәсьәләләре турында сөйләүләрен планлаштырган иде. Шушы планны үтәү йөзеннән тәнкыйть секциясе житәкчесе Флүн Мусин Әгерже районында булды һәм район укытучылары белән очрашты.

*
* *

Казанда балалар өчен чыгарыла торган «Ялкын» журналы редакциясе Польшадан килгән кунакларны кабул итте. Рус телен өйрәнүче поляк укытучылары Татарстан тарихына, язучылар, художниклар һәм сәнгать эшлеклеләренең хезмәтенә кагылышлы күп сораулар бирделәр.

Журнал редакциясенең әдәби хезмәткәрләре — яшь шагыйрьләр Фәннур Сафин, Хәйдәр Гайнетдинов һәм Эльмира Шәрифуллиналар кунакларны үз иҗатлары белән таныштырдылар.

*
* *

Куйбышев, Тольятти, Новокуйбышевск шәһәрләрендә татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукайга багышланган әдәби-музыкаль кичәләр булып узды.

Г. Тукай әсәрләре нигезендә төзелгән әдәби-музыкаль композицияне «Ялкынлы яшьлек» ансамбле башкарды. Бу ансамбль менә 8 ел инде Куйбышев шәһәре В. И. Ленин исемендәге металл коючылар заводының Культура сарае каршында эшләп килә. Аның чыгышларын һәркайда яратып карыйлар.

*
* *

Северодвинск шәһәренең 12 нче номерлы урта мәктәбендә «Кызыл канәфер» исемле яшь җәлилчеләр клубы эшләвен журналыбызның элеккерәк саннарында язган идек.

Җәй айларында, Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет театры Северодвинск шәһәренә гастрольгә килгәч, яшь һәм өлкән буын җәлилчеләрнең кызыклы очрашулары булды. Укучылар «Алтынчәч» һәм «Җәлил» операларын зур кызыксыну белән тыңладылар.

*
* *

Мәскәүдә ВЦСПС органы булган «Высота» журналы каршында оешкан Бөтенсоюз эшче әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышы булды. Берләшмәнең күптәнге члены, Үзбәкстан Журналистлар союзы премиясе лауреаты, Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең тормыш юлын өйрәнүче Исхак Зәбиров үзенең яңа эзләнүләре һәм табышлары турында сөйләде. «Җәлил белән янәшә» дигән китабы белән таныштырды, берләшмә членнарының сорауларына җаваплар бирде.

## КҮРГӘЗМӘ ЗАЛЛАРЫНДА

Казан Художниклар йортында Свердловск художнигы Николай Григорьевич Засыпкинның күргәзмәсе булды. Бер айга якын вакыт эчендә аны меңнәрчә казанлылар карады.

* * *

Зеленодольск шәһәрендә Рәшит Имашевның рәсемнәр күргәзмәсе булды. Күргәзмәгә рәссамның живопись һәм график әсәрләре куелган иде.

Рәшит Имашев актив эшләүчеләрнең берсе: китапларга рәсемнәр ясый, газета редакцияләренең кушуы буенча республикабыздагы төзелешләргә, авыл районнарына бара. Ләкин аның яратып эшләгәне— портрет жанры. «КамАЗ» темасына эшләүчеләр берләшмәсенә кергән Рәшит язган портретлардан Социалистик Хезмәт Герое Борис Новолодский, СССР Верховный Совет депутаты Рәис Сәлахов, Резеда Рафикова, татар әдәбияты классигы Габдулла Тукай, шагыйрь Хәсән Туфан портретларын тамашачылар аеруча яратып карадылар. Гражданнар сугышы темасына багышланган «Хәбәр», «Хушлашу», «Очрашу» картиналары да уңыш казанды.

Үзенең эшләрен Рәшит Имашев Октябрьнең 60 еллыгына багышлаган иде.

* * *

Республикабызда икенче мәртәбә инде эстамп күргәзмәсе булып үтте. Анда куелган плакатларны ТАССРның атказанган сәнгать эшлеклеләре И. Язынин, Е. Киселева, художниклардан И. Колмогорцева, И. Закиров, Э. Ситдиков һ. б. эшләгән иде. Бу плакатлар КПССның XXV съезды карарларының тормышка ашуын, шәһәр һәм авыл хезмәткәрләренең удар эшләрен, алдынгы тәҗрибәләрен пропагандалауда зур роль уйныйлар.

## ФӘННИ ЭКСПЕДИЦИЯ

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалының Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты этнографлары «Татар халкының этнографик атласы»н төзергә әзерләнәләр. Шул максаттан чыгып, Идел буенда яшәүче барлык татарларның традицион һәм хәзерге көнкүреш, җир эшкәртү культурасы, йорт-җир җиһазлары, бизәнү әйберләре һ. б. бөтен бер программа белән өйрәнелә башлады. 1980 елларга хәтле бу атласның фәнни нигезе тупланып бетәргә тиеш булганлыктан, шул максатны тормышка ашыру өчен, Казан этнографлары хәзер фәнни экспедицияләргә чыгалар.

Быелның җәендә тарих фәннәре кандидаты Рәмзия Мухамедова җитәкчелегендәге бер бригада республикабызның Сарман, Мөслим, Тукай районнарының кайбер авылларында булып, бай материал туплады. Этнографларның икенче бер группасы тарих фәннәре кандидаты Йолдыз Мухаметшин җитәкчелегендә Куйбышев өлкәсендәге татар авылларын өйрәнде.

## АРХИВ ТУЛЫЛАНА

СССР Фәннәр академиясе Казан филиалы Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институтының фәнни архивы зур саклагычка әверелә бара. Бүгенге көндә архивта 84 фонд һәм коллекция саклана. Алар үз эченә 10 меңнән артык эшне берләштерәләр. Анда татар әдәбиятының күренекле вәкилләре Г. Тукай, М. Җәлил, Г. Ибраһимов, М. Гафури, Ф. Әмирхан, С. Рәмиев, М. Колый, Һ. Такташ, Г. Камал, К. Тинчурин, Г. Коләхметов, Г. Кутуй, К. Нәҗми, Ф. Бурнаш, Г. Баширов, М. Гали, З. Башири, Н. Думави һ. б., фән эшлеклеләре СССР Фәннәр академиясенең член-корреспонденты В. А. Богородицкий, Ш. Мәрҗани, К. Насыйри, Н. И. Воробьев, Н. Ф. Калинин, Н. Ф. Катанов, М. Х. Корбангалиев, Ш. А. Рамазанов, С. Г. Вахидов, Г. В. Юсупов, Х. Г. Гыймади һ. б., сәнгать эшлеклеләре С. Габәши, З. Солтанов һ. б.ның фондлары бар. Моннан тыш архивта иң соңгылары — XIX гасыр азагына караган бер меңнән артык борынгы кулъязма китаплар саклана.

Фәнни архивның әһәмияте инде күптән республика чикләреннән чыкты. Монда Идел, Урал буе, Урта Азия республикаларыннан һәм өлкәләреннән, Мәскәү һәм Ленинградтан, Украина һәм башка җирләрдән килгән тикшеренүчеләр үзләрен кызыксындырган материаллар табалар. Чит илләрдән килгән кунаклар да архивка кермичә китми.

Соңгы вакытта архив саклагычына тагын бай гына материаллар кабул ителде. Алар арасында М. Җәлилнең архив материаллары да бар. М. Җәлилнең әле дөнья күрмәгән шигырь, сәхнә, тәрҗемә әсәрләре, либреттолар, элек билгеле булган әсәрләренең вариантлары, язучының шәхси документлары, хатлары бар. Шулай ук күптән түгел генә РСФСРның һәм Татарстанның атказанган артисты Зәйни Солтановның архив материаллары керде. Аларны институтка Ш. Рахманкулов бүләк итте. Анда татар театры тарихы һәм теориясе буенча очерклар, рецензияләр, 30 лап артистка характеристика һәм үз куллары белән язган автобиографияләре бар.

Быел гына да институтның фәнни архивына 200 дән артык борынгы гарәп, фарсы, иске татар телендәге кулъязма кабул ителде. Шуларның 50 ләбен Автомотосөючеләр бөтенроссия ирекле җәмгыятенең Татарстан республика советы директоры И. А. Батырев тапшырды. Алар бу китапларны шимбә өмәсе вакытында оешма урнашкан йорт подвалыннан тапканнар.

Архив фондын борынгы кулъязмалар белән баетуга әдәбият секторы хезмәткәрләре Ш. Абилов, Ә. Шәрипов, М. Әхмәтҗанослар зур өлеш кертәләр.

## ҮЗЕШЧӘННӘР ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

Казан Төзүчеләр культура сараеның халык бию ансамбле Прагада үткәрелә торган традицион Тынычлык һәм дуслык бәйрәмендә катнашты. Мәскәүдә хезмәт ияләре үзешчәннәренең Бөтенсоюз фестивалендә Зур Алтын медаль белән бүләкләнгән бу коллективның чыгышларын прагалылар зур кызыксыну белән карадылар.

*
* *

Минзәлә районының Халык җыр һәм бию ансамбле Польша шәһәрләре — Варшава, Краков, Шешов, Закопане һәм 1912—1914 елларда Владимир Ильич Ленин яшәгән Поронино шәһәрләрендә күп санлы концертлар бирде.

Минзәләлеләрне һәркайда көчле алкышлар белән каршыладылар, поляк яшьләре белән очрашулар аеруча җанлы һәм эчтәлекле үтте. Якташларыбыз Поронино шәһәрендә бөек юлбашчыбызның музей-йортын зур дулкынлану белән карадылар.

*
* *

Түбән Кама шәһәренең «Нефтехимик» культура сарае каршындагы «Яшьлек» бию ансамбле Болгария һәм Румыниядә концертлар бирде һәм сәнгатебезне пропагандалауда зур уңыш казанды.

## ХЕЗМӘТКӘ — ХӨРМӘТ

Совет әдәбиятын үстерүдәге хезмәтләре өчен һәм 70 яшь тулу уңае белән язучы **Гариф Гобәй** (Г. Ш. Гобәйдуллин) **Октябрь Революциясе** ордены белән бүләкләнде.

*
* *

Тынычлыкны яклау эшендә актив катнашканнары өчен Тынычлыкны яклаучыларның Совет Комитеты язучы **Мирсәй Әмирне** һәм шагыйрь **Зәки Нурины Мактау грамотасы** белән бүләкләде.

*
* *

Совет әдәбияты өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм 60 яшь тулу уңае белән язучы **Рәйсә Гыйният кызы Ишморатова КПСС өлкә комитеты** һәм **ТАССР Министрлар Советының Почет грамотасы** белән бүләкләнде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Казан дәүләт курчак театры артистлары **Галия Садыйк кызы Таһировага** һәм **Гәүһәр Ярулла кызы Шәрифуллинага**, Муса Җәлил исемендәге **татар дәүләт** опера һәм балет театрының опера солисты **Камил Нургали улы Якуповка Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет театр сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Г. Камал исемендәге татар дәүләт академия театрының баш художнигы **Мөэмин Гали улы Сутюшевка РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет музыка сәнгатендәге хезмәтләре өчен Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры артистлары **Рәмзис Хәнипович Гайсинга** һәм **Владимир Васильевич Праченкога Татарстан АССРның атказанган артисты** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет сәнгатен үстерүдәге хезмәтләре өчен Татарстан АССР Министрлар Советы Телевидение һәм радиотапшырулар комитетының телевидение дикторы **Иркә Шаһибәк кызы Сакаевага Татарстан АССРның атказанган артисткасы** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Совет музыка сәнгате өлкәсендәге хезмәтләре өчен Габдулла Тукай исемендәге татар дәүләт филармониясенең симфоник оркестры дирижеры **Равил Әнвәрович Мартыновка Татарстан АССРның атказанган сәнгать эшлеклесе** дигән мактаулы исем бирелде.

*
* *

Республикабыз хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү эшендә күрсәткән хезмәтләре өчен Татарстан АССР Министрлар Советы Телевидение һәм радиотапшырулар комитетының радиотапшырулар дикторы **Мәрьям Ислам кызы Арслановага Татарстан АССРның атказанган культура работнигы** дигән мактаулы исем бирелде.

◆ ◆ ◆

# ҖИҢҮ АТЛЫЙ ЛЕНИН ЭЗЕННӘН

**ЗАҺИТ ХӘБИБУЛЛИН**
музыкасы


**ЗӘКИ НУРИ**
шигыре

**Без йөртәбез Ленин әләмен
Җилфердәтеп кыю җилләрдә.
Житкерә ул йөрәк сәламен
Бик күп дуслар, бик күп илләргә.**

**Җирдә балкый Ленин яктысы
Нурын сибеп ерак-еракка.
Хәтерләтеп кояш балкышын
Мәңге яшәр Ленин йөрәктә.**

**Аяз таңлы безнең иртәләр,
Без Ленинча яшәп көчләләр:,
Дуслар безне якын итәләр,
Дошманга без мәңге үчлеләр.**

**Җиңү атлый Ленин эзеннән,
Ул һәркемнең якын юлдашы.
Ленинчылар илдә төзегән
Партия бар — безнең юлбашчы.**



## Киләсе санда:

Быелгы елның соңгы санында сез, хөрмәтле укучыбыз, проза әсәрләреннән Ә. Баяновның «Тавыш — табигать бүләге» дигән яңа повесте, Татарстанда яшәүче рус язучысы М. Скороходовның «Тундра хикәяләре» белән танышырсыз. Проза әсәрләреннән тагын күренекле әдип Герберт Уэллсның «Тәвә кошлары белән сәүдә» исемле хикәясе Фатих Хөсни тәрҗемәсендә бирелә.

Тугандаш казакъ халкының күренекле әдибе, Ленин премиясе лауреаты Мохтар Әуэзовның тууына быел 80 ел тула. Шул уңай белән журналда аның «Өйләнү» дигән хикәясе тәкъдим ителә.

Поэзия сөючеләребез киләсе санда Р. Мингалимов, Д. Сирай, Э. Мостафин, Ш. Маннапов һ. б. шагыйрьләрнең туган ил, республикабыз, аның башкаласы Казан турындагы шигырьләрен укырлар. М. Зариповның «Моңлы Казан, нурлы Казан» дигән очеркы да Татарстан башкаласына багышланган.

Тарихи темага бирелгән язмалар арасында тарих фәннәре докторы, профессор Рәфыйк Нәфиковның «Беренчеләр беренче сафларда» дигән материалы аеруча әһәмиятле. Ул моннан 90 ел элек Казан университеты студентларының революцион сходкасы, анда В. И. Ульяновның катнашуы хакында сөйли.

Уникенче санда Габделҗаббар Кандалыйның тууына 180 ел тулуга багышланган материаллар, күренекле композитор Александр Ключарев турында татар шагыйрьләре Н. Арсланов һәм М. Садри истәлекләре урнаштырыла. Әдәби тәнкыйть, китап күзәтү, безнең календарь, түгәрәк өстәл янында сөйләшү бүлекләренең һәркайсы укучылар өчен кызыклы материалларга бай.

«Нәниләр дөньясы» сәхифәләрендә Ш. Галиев, Р. Миңнуллин әсәрләре, «Елмаеп та, көлеп тә...» бүлегендә З. Нури шигырьләре урнаштырыла. Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары, 1977 елда журнал битләрендә басылып чыккан әсәрләр исемлеге бирелә.

Бәясе 50 тиен
Цена 50 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210